# казан утлары

1

ЯНВАРЬ-1973



М. ШАБАЕВ



К. СИБГАТУЛЛИН



Р. МОСТАФИН



Р. ВӘЛИЕВ

### 1972 ЕЛДА БҮЛӘК АЛГАН АВТОРЛАР

«Казан утлары» редакциясе узган ел журналыбызда басылып чыккан кече жанрдагы иң яхшы әсәрләргә бүләк бирү тәртибен керткән иде.

Редколлегия тарафыннан 1972 ел бүләккә түбәндәге авторлар лаек дип табылды:

Марс Шабаев. 4 санда басылган шигырьләр циклы өчен — 125 сум.

Кадыйр Сибгатуллин. 1 санда басылган шигырьләре өчен — 125 сум.

Рафаэль Мостафин. 1, 4, 5, 9 саннарда басылган тәнкыйть мәкаләләре өчен — 125 сум.

Равил Вәлиев. 2, 3, 4 саннарда басылган «Каурыйлар чыныкканда» исемле очеркләр циклы өчен — 125 сум.

Редакция бүләк алган авторларны кайнар котлый һәм иҗатларында яңа уңышлар тели.

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

1
ЯНВАРЬ
1973

## БУ САНДА

Г. АФЗАЛ. Нигә тошка керә... Шигырьләр . . . 3
Э. КАСЫЙМОВ. Һаваларда тургай. Роман . . . 12
К. СИБГАТУЛЛИН. Тагын ачарбыз күк. Шигырьләр 56
Х. ХӘЙРУЛЛИН. Канатлар талмасын. Повесть . 62
З. НАСЫЙБУЛЛИН. Яшәү өчен. Шигырьләр . . 108
Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Бөтнек үләне исе. Хикәя . . 112
М. ХӘСӘНОВ. Йөрәк сере. Хикәя . . . . . . 121

ОЧЕРКЛАР

М. ЗАРИПОВ. Тылсым нясе . . . . . . . . . 125
В. ГУДКОВА. Гомер буе укытучы . . . . . . 134
М. ӘМИРХАНОВ. Шахта иленә сәяхәт . . . . 140

СӘНГАТЬ

Җ. ФӘЙЗИ. Җырлар эзлим . . . . . . . . . 147
З. ШАҺИМОРАТОВ. Эпизодик рольләр аша . . 161

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ш. ӘХМӘДУЛЛИН. Шигърият мәйданында... . . 174
И. НУРУЛЛИН. Укучы бер генә төрлеме! . . . 185
Яңа китаплар . . . . . . . . . . . . . . 186
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 6. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

**Баш редактор: Гариф Ахунов.**

**Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

---

Производствога бирелде 9/X-1972 ел. Басарга кул куелды 21/XII-1972 ел. ПФ 04149. Кәгазь форматы $70 \times 108\,{}^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83046 экз. Заказ Г-668. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советының нәшриятлар, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең К. Якуб исемендәге матбугат комбинаты. Казан, Бауман урамы, 19. 1973 ел.

## Гамил Афзал

# Нигә төшкә керә ул таңнар?

*Магнитогорск истәлеге*

Кичәгедәй генә күңелдә,
Нигә төшкә керә ул таңнар?
Әйтерсең лә күңел түренә
Кызган тимер белән басканнар.
Тимерчелек цехы шушында,
Мин бер татар бөтен цехында,
Мин сандаллар ясыйм, сандаллар...
Нигә төшкә керә ул таңнар?

...Металл кебек кырыс чырайлар
Йокы күрми ауган чагында
Нигә кирәк юк-бар сораулар,
Немец тора Мәскәү янында.
Брезент чалбар, брезент пинжәкле,
Киез итек кигән абзыйлар,
Бүрәнәдәй авыр беләкле,
Үгез кебек усал карыйлар.
Аркаларда буй-буй тоз каткан,
Юлбарыслар сырты шикелле.
Һәр нәрсәгә тузан, корым яткан,
Һава кызган, һава төтенле.

Җәһәннәмдәй гөрли зур мичләр,
Кокс газы яна аларда.
Өч тонналы чуен чүкечләр
Ухылдашып суга сандалга.
Ыргак белән тотып, каптырып,
Сандык чаклы кызган тимерне,
Кабыргасы белән яткырып,
Боргалыйлар конфет шикелле.
Тимер сыгыла тимер сугуга,
Аңа тагын утка төшәсе,
Кызыл өрлек булып сузыла
Сугыш алласының көпшәсе.
Яңа хәбәр килгән фронттан —
Фашист вәхши киткән Ржевтан,
Кемгә кабер анда, кемгә дан,
Әллә шәфәкъ нуры, әллә таң.
Даң, даң, даң...

Кайсы айның кайсы числосы,
Нигә аны уйлап торасы,
Тәүлек тә юк хәзер, сәгать тә,
Яңа йола кергән гадәткә.
Тик бер кодрәт эшне ишәйтә,
Тик бер кодрәт таңны киңәйтә:
— Совинформбюро ни әйтә?
— Совинформбюро ни әйтә?
Таң төсеме, әллә кан төсе
Кызу мичнең кызыл яктысы.
Озын кыскыч тоткан шәүләләр
Кабалана, ашыга барысы.
Гүя кызык уен тапканнар,
Кызык өчен учак якканнар
Җәһәннәмдә йөргән шайтаннар.
Йомыры башлы, очлы койрыклы,
Тамчы сыман хикмәт чүкиләр.
Тимер шаблон белән үлчиләр.
Шуның берсе төшсә тегендә,
Шәһәреңнән калыр көл генә.
Бик күңелле хәбәр алынган:
Фашист елан киткән Орелдан.
Орелдан, Орелдан,
Дан, дан, дан...

Корым, сөрем кырыс йөзләрдә,
Вакыт шундый: беркем елмаймый.
Егетләр дә көлми, кызлар да,
Тик усаллык яна күзләрдә.
Яхшы хәбәр алган көнебез,
Вагоннарга «товар» төйибез,
Кызлар яза «товар» сыртына:
«Үлем килсен фашист йортына!»

Вентилятор җиләс җил өрә,
Пролетлар сөрем-төтенле.
Олы этләр өргәнгә күрә,
Кече этләр өргән шикелле.
Чаң-чаң суга кече чүкечләр.
Монда шундый хикмәт ясала,
Хәтерләтә нечкә торбаны,
Танк түше калын булса да,
Тишеп кенә чыга торганы.
Яңа хәбәр йөри кич-иртән:
Килмешәкләр киткән Киевтән,
Киевтән, Киевтән,
Таң, таң, таң...

Инде ташу талгын юл алды,
Кабалану-каушау югалды.
Сменалар эшли иркенләп,
Сәгать теле кебек текелдәп.
Инде һәркем көлә, елмая,
Уен-көлке сүзләр кыстыра,
Кәгазь суза,
Янчык чыгара,
Гүя гомер сиңа дус тора.

Алда юллар авыр булса да,
Сөенеч бар дөнья кадәрле:
— Безнекеләр инде Польшада —
Совинформбюро хәбәре,
Совинформбюро хәбәре.

Менә һәркем һәркемне кочты,
Майга каткан бүрекләр очты,
Пилоткалар, кепкалар очты.
Ура!
Һәркем һәркемне кочты.
Шау-гөр килә завод тирәсе,
Моны ничек сөйләп бирәсе!
Бер елыйсы килә иркенләп,
Бер көләсе килә, көләсе!
Мәңге бетмәс вәхшәт шикелле,
Җан өстендә торган албасты
Бетте,
Янды,
Очты төтене.
Безнең корыч,
Безнең тырышлык
Тереклеккә иркен юл ачты.
Өйдә калучыга өй яхшы,
Әйдәп баручыга юл яхшы.
Кичәгедәй әле күңелдә,
Нигә истән чыкмый ул таңнар?!
Гүя аны башның миенә
Кызган тимер белән басканнар.
Тимерчелек цехы шушында,
Мин бердәнбер татар цехында,
Мин сандаллар юнам, сандаллар.
Ул сандалга ниләр салганнар...
Һаман төшкә керә шул таңнар.

## Прометейга үпкә

Без ул чакта шактый нужа күрдек,
Ачы җилләр үтте җелеккә.
Билдән түбән тире каплап йөрдек,
Ыштан да юк, малай, җилет тә.
Аңсыз халык бик күп микроб йотты —
Кайнамаган суда күп алар.
Эчәкләрне бөтереп эч авыртты,
Язын-көзен үтереп бизгәк тотты,
Булды инде күргән нужалар.

Тормыш авыр.
Чи ит ашадык та
Елгаларга ятып су эчтек.
Шул чагында Прометей исемле
Башлы егет барын ишеттек.
Аны-моны уйлап чыгарырга
Син бик маһир егет булгансың,

Аллаларның кухня учагына
Авыз ачып карап торгансың.

Прометей, син елгыр егет идең,
Кулың тик тормады чүтеки;
Шыпырт кына Зевс өенә кердең,
Шырпыларын... эһем... һи-һи-һи...
Син бик оста хәйлә уйлап таптың,
Бик җилле мал кулга төшердең;
Кырын-ярын ятып учак яктың,
Чәй кайнаттың,
Кәтлит пешердең.

Синнән күреп без дә учак яктык,
Аю ите пешә учакта.
Әбәт көтеп ут янына яттык,
Кәефләр шәп иде ул чакта.
Бер мамонтны бәреп үтердек тә
Бифштекс пешереп ашадык.
Мамонт өендәге коры муктә
Коллективный тора башладык.

Аннан тирмә кордык,
Культура юк,
Каян килсен әле культура!
Тирмә уртасында мөлкәт булып
Уты пыскып яткан көл тора.
Авыр әле тормыш,
Бирешмибез,
Безнең хәзер ут бар, якты бар.
Мамонт юкта күсе-фәлән тоттык,
Казан асып учак яктылар.
Бу — прогресс дидек,
Алга бару.
Прометейга ура, яшәсен!
Иң симезен итнең сиңа бирдек,
Башлы мужик, дидек, ашасын!

Ләкин Зевс эшне сизгән икән,
Үзе килгән безнеңояга,
Җилтерәтеп сине алып киткән,
Кадакларга кушкан кыяга.
Синең эшләр хөрти иде, парин,
Ләкин без дә йоклап ятмадык.
Кадакларны йолкып аттык барын,
Богавыңны өзеп ташладык.

Син качтың да
Тагын учак яктың,
Шак-шок итеп нидер кыландың,
Тимер чүкеч таптың,
Кадак кактың:

Хәтәр мылтык уйлап чыгардың.
Бу — прогресс дидек,
Җилле нәрсә,
Дөнья булгач, дус бар, дошман бар.
Безнең кулда мылтык күрселдәсә,
Килеп карасыннар дошманнар!
Шуннан китте... һәр малайда мылтык,
Президент та чыкмый урамга.
Берәүнең дә башы ике түгел,
Почмак саен атып торганда.
Кешеләргә төбәп мылтык атты,
Кешеләргә төбәп туп атты.
Үзәннәргә кара төтен ятты,
Кызыл елга булып каннар акты,
Миләр чәчрәп калды ничаклы!

Син, Прометей, чаптың чор артыннан,
Син остардың, хәтәр шомардың:
Полкларны кырып ташлый торган
Пулеметлар уйлап чыгардың.
Мин булдырам аны, мин беләм, дип,
Атом утын тоттың кул белән.
Дөнья китте хәтәр юл белән...

Синең утта үкереп илләр янды,
Дөньяларны ялкын-ут алды.
Ут сүндереп йөреп куллар талды,
Сарайлардан сары көл калды.
Прогрессмы бу?
Нагасаки көле,
Хиросима көле бизәкме?
Җанны үтерә торган агу җиле,
Прометей, әйт, сиңа кирәкме?

Җәһәннәмдәй утлар уйнасын дип,
Тере җаннар ялкын суласын дип,
Дөньяң белән күмер буласың дип,
Ясадыңмы атом бомбасын?
Дөнья күкләрендә йолдыз булып
Куандыр син безне, куандыр!

Таш кыяга сине бәйләп куеп,
Зевс, бәлки, хаклы булгандыр...

Акыл булган җирдә өмет бар дип
Ышанса да яшел офыклар.
Гөмбәсыман зәһәр болытларга
Карап тора синең оныклар.
Да, Прометей,
Сине хурларга да,
Зурларга да акыл ояла.
Сине
кабат
тимер кадак белән
Кадакларга, бәлки, кыяга!

## Карт солдат

Ярты гомер ут эчендә үтте
Дошман белән пычакка-пычак.
Күңел сабыр, өмет итми күпне,
Мактау кәгазьләрем бер кочак.

Дан өчен дә, мал өчен дә түгел,
Үлем белән яшәү көрәште.
Метр белән үлчәп җирен, күген,
Корыч булып басты көрәшче.

Ал таңнарның ямен күрер өчен,
Гасырлардан килгән өн өчен,
Башны текә тотып йөрер өчен,
Менә шушы якты көн өчен,

Безнең буын усал, кырыс халык,
Гөнаһлы да булдык, изге дә;
Үзебез өчен генә тырышмадык,
Юксынырлар әле безне дә.

●

Җыелып килгән ачу чиктән ашкан,
Җир йолдызын ташка бәрерлек,
Гомер-гомер кайнап кристаллашкан
Явызлыкка каршы — гаделлек.

Кылыч йөзе кебек күз карашы,
Яшен уты поскан шушында,
Ике дошман тора кара-каршы,
Җир әйләнә штык очында.

## Тынлыкта

Кайвакытта шау-шулардан аерылып ялгыз калам,
Җаннарым арып шулардан, мин тынычлап уйланам.

Җил дә исми, шылт та итми, юк комачау, мең шөкер;
Җан димен мин, ян димен мин, юк күңелдә бер фикер.

Данмыни бу, ялмыни бу, эшмени бу тик яту,
Буш хыяллар болгату да юк чебенгә туп ату!

Бар һөҗүмгә, бар үлемгә, ян, йөрәк, сызлан, йөрәк!
Һәр күңелгә һәр көнендә дау кирәк, шау-шу кирәк!

# Сагыш

*Бакый Урманчега*

Агачтан киселгән сын ул,
Иңе-буе ике карыш,
Түбән очның Тимерҗаны —
Йөзе-бите яхшы таныш,
Түбәтәен кыңгыр салган,
Күзләрендә ачы сагыш.

Тимерҗан абзый утыра,
Читәнгә аркасын терәп.
...Көннәр гаять коры тора,
Кемгә ялын, кемнән сора:
Икмәк кирәк!
Акча кирәк!

Түрәләр, байлар симерә,
Бар син, алар белән ярыш!
Келәтне тычкан кимерә,
Бер подаука калды арыш,
Сагыш...

Түбәтәен кыңгыр салып
Сабан туйда мәйдан тоткан,
Бер тәенчек бирнә алып,
Бибиәсма ябышып чыккан
Әтәчле таңнар кайларда!

Уйласаң исләреӊ китәр
Тимерҗанның егет чагын:
Кара камзул, кызыл билбау,
Килеш, ыспай кием-салым.
Аулак өйләр, уен-көлке,
Йөзек салыш, алка салыш...
Сагыш!

Каюм хәлфәдә укыган
Малае солдатка китте,
Хаты юк күптән.
Ничә айлар, еллар үтте
Сәлам көтеп көн дә иртән!
Сагыш!

Бер капчык кипкән җимешкә
Кызын байларга саттылар,
Битне сыйпап,
Дога кылып,
Ят җирләргә озаттылар.

Бала — бәгырь, бавыр ите,
Үзәк өзеп, елап китте,
Булгандыр, шәт, ак өмете —
Күз тотып йөргән егете.
Рәнҗеп китте, елап китте,
Бала — бәгырь, бавыр ите...
Сагыш...

Бибиәсма гүр иясе,
Урыны оҗмахта булсын,
Баш очында каен үсә.
Налог түләргә акча юк,
Өтермән диләр, югыйсә.
Бер подаука чүпле арыш...
Сагыш!

Агачтан ясалган сын ул,
Буе-сыны ике карыш,
Йөзе-бите яхшы таныш —
Түбәтәен кыңгыр салган
Түбән очның Тимерҗаны,
Күзләрендә сагыш,
Сагыш...

●

Судан чыккан да баскан
яр башына,
Алтын чәчләре төшкән
иңбашына,
Канаттай кулын куйган
каш өстенә,
Алтын болытлар ага
баш өстендә.
Күк күзләре — чалт аяз
җәй иртәсе,
Табигатьнең иң гүзәл
бер иркәсе.
Кызыл гөлләр үстерер
зәңгәр бозда;
Бөтен галәмнең сере
шушы кызда.

●

Җил-яңгыр тимәсен, ах алла, диделәр,
Өф-өфләп, кадерләп килделәр;
Җил-яңгыр тимәгәч агачны корт баса,
Нишләр ул тамырдан кортласа!

●

Уен-көлке сипкән сүзе була,
Көлеп торган гамьсез йөзе була,
Тормыш сәхнәсендә көн дә — артист,
Ялгыз калгач кына үзе була.

●

Хак сүз, нык сүз тамырларга үтә,
Тимер иман кебек була сүз.
Күп сөйләнгән сүзнең кадере китә,
Иске чүпрәк кебек уңа сүз.

Дөнья нурлы, күңел изге иде,
Әйтерсең лә аппак көзге иде,
Ак аһәңнәр иңүен көтә иде,
Сабый сулышы кебек иртә иде.

Кара эчле мәнсез адәм килде,
Өстәлемә тау-тау тирес өйде.
Каралып һәм ямьсез уйлар уйлап,
Күңел калды гарьләнеп һәм елап...

## Алга китү

Кирәк чакта ярамый бит дип тормаган,
Борынгылар ат урлаган, кыз урлаган;
Культуралы заман буры алга китте —
Фикер урлау, сүз урлауга барып җитте.

## Аймылыш

Ул акыллы иде һәм яхшы да,
Юлларыбыз никтер аймыл булды;
Ул карьера артыннан чапты да
Трибунага менеп маймыл булды.

## Эдуард Касыймов

# ҺАВАЛАРДА ТУРГАЙ

РОМАН

### 1



Елның елында Госман җәйләрен туган авылына бер кайтып килә торган иде.

Кем сагынмас, кем зарыкмас туган якның күңелдәге дулкыннарны чайкап җибәрә торган җанга чиксез татлы сихри хозурлыгын!

Әмма бу юлы Госманны туган авылына ашыктырган икенче төрле сәбәп тә бар иде. Монысы җанга алай нәфис канатлар үстерерлек булмаса да, күңеленнең бер почмагына мәңге кырып алмаслык юшкын утыруын теләмәсәң, аны онытырга да, читкә кагарга да ярамый иде.

Әле күптән дә түгел, җәйге елларында Кизелдән кайтырга чыгар алдыннан булды бу сөйләшү...

Басынкы-мыштым гына йөргән әнисе Зөләйхабануның өлкән улына нидер әйтергә теләвен сизенеп килә иде Госман. Тик карчык җаен гына туры китерә алмыйча аптырый иде шикелле.

Җайны-сәгатьне Госман үзе тудырды: бүтәннәр җыйнаулашып кибеткә-нигә дип кузгалгач, Госман, юк-бар сылтау табып, өйдә калды. Тегеләр күздән югалырга да өлгермәде, мондый аулакны күптәннән көткән әнисе, вак җыерчыклар яргалаган йөзен куанычлы нурландырып һәм үтә җылы, үтә якын тавыш белән:

— Улым, кил әле, кер әле монда... Зур йомышым-әманәтем бар иде сиңа,— дип, Госманны үзенең кечерәк кенә бүлмәсенә дәшеп алды.

Монда ялтыравык калай челтәрләр белән бизәлгән олы гына сандык өстенә аналы-уллы янәшә утырыштылар.

— Ни йомыш, әни?

Әмма әнисенең зиһене кисәк чуалыбрак китте, ахры, карчык беравык сүзен башлый алмыйча торды. Күзләрен дым каплаган, тез башлары өстенә салган арык кулларының бармак очлары сизелерлек булып калтырый иде.

— Ни... иртәгә китәсез инде сез, улым,— диде ул, ниһаять, авыр сулап.— Күңелем тагын кителеп калырдыр инде...

— Нигә, әйдә, кайтабыз, әни! Гөлфия монда ничек тә үз җаен табар әле...

---

Кыскартып басыла.

— Гөлфияме? Нәние беләнме? Юк-юк, улым, аның бит, беләсең, ордым-бәрдем...
— Интегүләрең житкәндер, дим, әни.
— Алай димә, улым. Интегүен дә интекмим... Озакламый яңа яслеләрен салып бетерәселәр, ди. Менә шул чакны инде, ходай кушса, жилжил кайтып та төшәрмен, улым. Сабыр төбе — сары алтын, ди, түзим инде, булышыйм үзләренә...
Әни-карчыкның бу хакта сүзне куертып торасы килмәде.
— Ә йомыш дигәнем шул иде,— дип, каяндыр мендәр-ястыгы астыннан, эчкәредән, кибет кәгазенә бик пөхтәләп төргән юкарак кына бер нәрсәне алды да аны ике куллап күкрәгенә кысты.— Синең анда үзебезнең авылга кайтып килергә юнең булырмы?
— Ник булмасын.
— Син... ни... минем ахирәтем Нурдидә апаңны беләсең бит? Шуңарга менә бәләкәй генә бүләк хәстәрләп куйган идем. Шәлъяулык бу... Әллә нигә соңгы араларда төшләремә бик еш керә башлады. Исән-сау гына булса ярый ла... Тапшырырсыңмы, улым?
— Тапшырмый ни... Рәхәтләнеп!..
Төргәк Госман кулына күчте. Ләкин ана кешенең әманәте моның белән генә бетмәгән икән әле, ул күлмәгенең кайсыдыр төшеннән иплә кенә кәгазь акчалар чыгарды.
— Инде монысы... Мәле, куен кесәңә эчкәрерәк тыгып куй.
— Нигә бу, кемгә? Миндә акча беткәнмени?
— Хәер-сәдакага дигән акчам бу... Әйтмә, синеке кирәкми миңа! Үз өлешемнән, үз хәзинәмнән булсын! Анда авылыбызның карт-корысына, ятимнәренә, аннан килеп, гүр ияләре — әрвахлар хакына өләшәсе... Нигъмәтжан абзый сырхау түшәгендә, ди, аңа бирәсе, күршесе Хөснижамал түтәйгә бирәсе — әйбәтләп дога кылсын. Аннары тагы...
— Соң, әни...
— Кашың-күзең жимерелде, авырсынасыңмы әллә? Коммунист башым белән сәдака өләшергәме инде, дисеңдер... Юк, күңелнең тамчы да рәнжемәве кирәк. Син, алайсам, болай ит, улым: моны да ахирәтем Нурдидә апаңа тапшыр — ул үзе чамалар кемгә нихәтле бирәсен. Күңелләр бер бит безнең...
— Чынлап та шулай гына итәрмен, әни!
...Инде менә хәзер ул Акбалык элеваторына ашлык илтә барган автомашинаның буш әржәсендә оча. Көрәнсу йон плащын жилбәгәй жибәреп, салкынча жилнең тыгыз дулкынын күкрәге белән яра-яра кайта. Бала чактан таныш булган биек тупыл-тирәкләрнең яшел ябалдашлары, ала-кола йорт түбәләре, зират урманы, Акай тавы ашкынып каршыга йөгерешә...
Туган авылның яме дә ямь генәме соң!
Юк, бу ямь-хозурлыкка шундук чумып, тәмам эреп киткәнче, жилкәдә зур бер йөк булып утырган әманәтне үтисе булыр. Иң әүвәл шуны...
Машина, бакча артларындагы такыр юлдан дыңгыр-дыңгыр тузан болыты куптарып, амбарларга таба юл тотты — Госман Олы урам башында басып калды.
Тирән сулап куйды.
Олы урамны машина-тракторлар актарып бетергән.
Койма-читән буйлата сузылган шомарак сукмактан Госман нык-нык басып алга атлады.
Нурдидә түтиләрнең йорты Арткы урамда. Әйе, тукталмаска, борылмаска — иң әүвәл шунда!
Клуб каршындагы чат башында акшарланган тәбәнәк таш баганалар. Алар үзара юан-юан чылбырлар белән тоташтырылган. Әчтә аллыгөлле чәчәкләр. Уртада таштан түгел, юан тимер торбадан бик пөхтә, шома итеп киселгән һәм югарыга, шактый биеккә, очлаеп-нечкәреп

менгән өч кырлы һәйкәл. Ул гигант штык сыман. Иң очта алсу кангы манчылган йолдыз яна. Күркәм дә, үзенчәлекле дә... Бик тә башлы егет диләр бу клуб мөдире Расихны!

Ил азатлыгы өчен һәлак булганнар, хәбәрсез югалганнар авылда йөзәрләгән...

Аның үз әтисе дә бар булганы белән шушы металл штыкта мәңгеләшкән...

Читләтеп үтә алмады, колхоз идарәсе каршында кузгалырга торган «газик» тирәсендә чуалучы ир-ат янында тукталып, хәл-әхвәл белеште. Бераз гәп корып торды.

Аннары кибеткә сугылды.

Баш өстеннән инешкә таба кыйгылдашып казлар очып үтте...

* * *

Менә ул Арткы урам. Бәрәңге бакчалары инеш ярына төшеп терәлә. Кайчандыр аларның үз урамнары иде бит бу... Элгәре, бик күп элгәре, ямь-яшел чирәмлек иде — Госманнар аңарда рәхәтләнеп аунарлар, туйганчы көрмәкләшерләр иде. Хәзер монысы да буйдан-буйга каезланган... Читән-койма кырыйларында чирәм бар барын, әмма анысы да казкүркә чемченерлек кенә...

Нурдидә түтиләрнең алты почмаклы йортлары, челтәрле капкалары былтыргыдан аз гына сорылана төшкән. Зәңгәргә буялган тәрәзәләрендә исә чуклы-чуклы, аллы-гөлле чәчәкләр тагын да күбәйгән сыман...

Шактый киң, иркен ишегалды түрендә Нурдидә карчыкның кечe килене Миңнур, «ти-ти» дип чакыра-чакыра, тавык-чебешкә җим сибеп тора иде. Капыл карады, бер мизгел каушап калгандай булды.

— Һай, энекәй генәм! Кем дисәм, Госман абый! Әйдүк, әйдүк!

Чебеш-тавык өерен тузгытып, коштабагын җиргә атып бәрде, кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә, килеп тә житте.

— Ах аллам, ничек болай?! Сезнекеләр исән-сау калдымы соң? Үзең ничек? Нигә инде тагын япа-ялгызың?..

И китте тезеп, и тотынды сорашырга!.. Үзе сыңар кулы белән тулып ашкан күкрәкләре өстендәге ачык изүен каплагандай итә, үзе үткер күзләре белән кителмәгән кунакка төбәлгән...

— Әнкәй дисеңме? Өйдә юк бит әле ул: Лубъянга киткән иде.

— Лубъянга? — Госманның сөмсере шундук коелды.

— Әйем, өченче көнне үк әле... Тегендә лубъяннар тик ятмый икән: олы килендәшем тагы бер малай тапкан! Шуларның бәби туена бәбәй ашы апкиткән иде әнкәй... Инде алтынчысы! Әллә орденга-мазарга үрелергә дип тырыша инде килендәшем... һи-һи!

Миңнурның бу хәбәре дә, сөйкемле кеткелдәве дә Госманның кәефен кисәк күтәреп җибәрде.

— О, алайса!..

— Ә без үзебез баралмадык: Габделбәр көне-төне комбайнда, ә үзем... менә!..

Ишегалды кош-корт белән генә түгел, бала-чага белән дә тулган иде — Миңнур, канат кагарга җыенгандай, кулларын җәеп, шуларга ишарә ясады. Нәниләр кайсы кая таралышып, баскан, утырган җирләреннән таныш булмаган бу абыйның авызында елык-ялык иткән алтын тешләренә күз чекрәйтеп, бөтенләй өнсез-авазсыз катып калганнар иде. Бары да кызлар: сумала чәчлеләр, тузгыган салам башлылар... Госман, кабарган плащ кесәләрен бушатып, аларга татлы-тәмле нәрсәләрен өләшеп чыкты.

— И балакайларым, кунак абыегызга рәхмәт әйтә дә белмәдегез ләбаса!

Балалар кайсы оялчанланып, муенын җилкәсенә кысты яки, башын кыңгыр салып, читкә борылды, кайсыбере, кыюрагы, иреннәрен кыймылдатты. Ә елтыр күзләре һаман да кунак абыйларына төбәлгән иде.

— Синекеләр кайсы дип сорыйсы да юк, Миңнур.

— Әйе: сары-сары сап-сары гәрәбәләр инде — тач этиләре!

— Туктале, ничәү инде синең? Монда икәвесен күрәм.

Миңнур җавап кайтарырга өлгермәде: болдыр ишеге ачылып китте дә аннан янә бер «сап-сары гәрәбә» атылып килеп чыкты һәм ачы чәрелдәп сөрән салды:

— Әни дим! Олан уянды да шыңгырдый башлады. Имезәсеңме? — Кызчык кинәт тотлыгып калды:— Ай, абый... исәнмесез!

— Тирбәтә тор, кызым. Мин хәзер...

Госман болдырга таба бер-ике адым атлады.

— Саумы, сеңелкәш! Мәле, чибәрем, тот әле!

Кызый, бурлаттай кызарынып, «әй!» диде дә ялт кына кире кереп китте.

— Бик тә оялчан инде. Үземә тамчы да охшамаган... Шулай, Госман абый, дүрткә тулдылар инде. Иң кечем бишектә... Анысы да кыз бала.

— О, котлыйм, котлыйм! Син лубъяннарны әйткән булдың, үзегез дә тик ятмыйсыз икән лә.

— Бездәй караңгы авыл җирендә шулай инде: бала-чага үрчи. Теге ни... мәзәктәгечә... һи!..

— Караңгы? Электр кергәненә бишбылтыр, әнә телевизорыгызның антеннасы болытка терәлгән.

— Телевизор, электр... Хәзер кайда юк ул? Сезнең кала хатыннарыгыз гына бала табудан, бала үстерүдән шүрли, ахрысы...

— Бик тә шүрли, Миңнур! Имеш, артып китсәләр, үз ирекләренә балта чабалар.

Миңнур әлек тә четердәп торган чая телле, оялу дигән нәрсәгә исе китмәүчәнрәк холыклы бер кыз иде. Хәзер, инде дүрт бала анасы булгач, бигрәк тә: ни уйласа, бары да теленд, ахры... Әмма әдәп дигән нечкә нәрсәне бөтенләй үк йолкып атмаган икән: шаян сүзне ярты юлда бүлде дә, гәпне үзе теләгән якка борып, әүвәлге сабакташы һәм дусты Гөлфия хәлен төпченергә кереште.

— Ичмасам, булдырды ул Гөлфия: Акбалыкта укып, китапханәче булды.

— Минем сеңелкәш бераз көнләштерәме әллә үзеңне?

— Көнләштерә дип... Юк, шахта җирендә тормас идем мин, сезнең химиклар поселогында да тормас идем: тузанлыдыр, сасыдыр һавасы, кирәкмәгән ыгы-зыгысы тагы... Авылга ни җитә!

— Анысы шулай. Мин үзем дә, Миңнур, Казанга укырга киткәндә, агроном-бакчачы булырга ниятләгән идем. Имеш, үзебезнең инеш буйларын, тау битләрен җиләк-җимеш бакчасы итәм. Барып чыкмады: кирә алмадым. Химик булдым. Инде менә, син әйткәнчә, сасы газ эчендә тырмашып ятам.

— Һи, сиңамы үкенергә, Госман абыкаем! Көлдерден... Авылдамы, мәктәптәме зуррак җыелыш булган саен, менә кемнән үрнәк алырга, менә кемгә иярергә кирәк, тугансайлар, дип, сине телгә алмыйча калмыйлар. Берданбер фән депутатыбыз бит син!

— Кандидаты, диген.

— Чуртым булсын! Барыбер фән кешесе. Белеп мактыйлар. Уку зур эш инде ул. Әнәтерә, үзебезнең авылдан гына да хәзер әллә кемнәр әллә кайларда гыйлем сендереп ята. Мин генә ул яшьрәк чакта, акны карадан аера алмыйча, җүләр сатып йөргәнмен.

— Сиңа утыз да юк бит әле, укырга керергә бер дә соң түгел. Әйтик, заочно берәр техникумга-мазарга...

— Аяк-кул бәйләнгәчме? Һи... Туктале, сүз боткасы пешереп ник торабыз әле монда? Әйдәче, самоварлар куеп, үзеңне бер иркенләп сыйлыйммы, Госман абый. Әйдә!

— Рәхмәт, Миңнур. Тик чәйләп тормам мин. Йөрисе җирләрем, күрәсе кешеләрем байтак әле. Салкын сөтең яки әйрәнең булса гына...

— Булмыймы соң! Күз генә тия күрмәсен, сыердан галәмәт уңдык без.

Болдыр баскычына җиткәндәрәк, Госман Миңнурны кулыннан эләктереп туктатты да:

— Минем әнием тегеннән Нурдидә түтигә бәләкәй генә истәлек бүләге биреп җибәргән иде,— дип, плащының куен кесәсеннән кәгазь төргәкне алып сузды.— Мәле, тапшырырсың.

— Үз кулың белән бирсәң соң? Әнкәй бүген кичкә кайтырга тиеш.

— Шулаймы? — дип, эченә җылы йөгергәнлеген тоеп, җиңел сулап куйды Госман.— Минем аңа тагын да зуррак аманәт тапшырасым бар иде әле. Анысы да анидән...

— Менә, ичмасам, ахирәтләр: заманасында нужа арбасын да бергә җигелеп тартканнар, инде хәзер картлык рәхәтләрен дә бүлешәләр.

Нәүрәптән җил-җил алып менгән сөте чынлап та тешләрне камаштырырлык салкын һәм гаҗәеп тәмле иде. Госман аны зур кәсадән ләззәтләнеп кенә йоткалаган чагында, Миңнур, үзе дә татлы бер рәхәттә оеган рәвештәрәк, көлемсерәп карап торды.

Миңнур капка төбендә бер өер сумала чәчлеләр, гәрәбә башлылар чолганышында, кулларын күкрәкләре өстенә салган килеш, җай гына баш селеккәләп басып калды — кунагы урам буйлап ары атлады.

Шулай инде, туган авылына кайтты исә, Госманның коргаксыган теле язылa да куя. Теле белән бергә күңеле дә... Кемне очратса, кем белән сөйләшсә дә... Бу Миңнур бигрәк тә: һичкайчан зарлану-сыктану белмәс, авызында гел бал да май. Ире белән ничек икән, кайнанасы белән? Әллә ни юктыр. Иркен һәм күңелле тормышларына күләгә генә төшә күрмәсен инде...

* * *

Һава гаҗәеп саф һәм аз гына җиләс иде.

Инде кая барырга? Иң әүвәл Акай тавы башына менәргәме? Әллә басу юлы белән үз җаена иркенләп кенә урманга таба китәргәме?

Акай тавыннан авылны тузан болыты куптарып көтү кайткан чагында күзәтүе кызыклы. Кояш баер алдыннан...

Урам уртасыннан барганда, бер йорт турысына җитәрәк, адымын әкренәйтте: үз нигезләре...

Госман бик әйбәт хәтерли: ул бәләкәй чакта алар мунча хәтле генә өйдә укмашып яшәгәннәр иде. Әтисе сугыш алдыннан гына ул өйне утынга сүтеп, көч-хәл белән яңасын, бераз зуррагын өлгертеп куйган иде һәм: «Минем гомергә җитәр», дигән иде. Ләкин аның калган гомере бик тә кыска булды...

Ә хәзер монда, аларның нигезендә, бөтенләй яңа йорт эре-эре ак ташлардан тезелгән фундаментта биегәеп-кукраеп утыра. Түбәсе шифер, капкасы шыңгырдап торган урыс капка. Каралты-курасы тагы.

Заманасында Нужа бабай аларның капкасын көн дә диярлек шакып, өзлексез йөдәтер-җәфалар иде, ә хәзер боларга сугылмыйча гына үтәдер, курка торгандыр. Авылда кемнәрнең бусагасын таптый икән ул юньсез бабай хәзер? Әллә аның туган авылын бөтенләй читләтеп йөри микән? «Ятим-фәкыйрьләрне Нурдидә түтиең үзе белер», дигән иде әнисе...

Капка тоткасына аркылы таяк кыстырылган иде, шунлыктан Госман бу шәп йортта торучыларга кереп хәл-әхвәл белешә алмады.

Басу юлы такыр, тузанлы. Ян якларда урылган-сугылган өем-өем комбайн саламнары тезелешеп ята. Уңыш мулдан булган, ахрысы.

Ызан башларында, чит-чатларда алабутага тикле күренми хәзер. Зәңгәр чәчәкне дә биздергәннәр шикелле.

Басу юлы аулак, тузанлы.

Озын кара толымлы, шомырт күзле буйчан һәм оялчан Дөм-дөм кызы Әсма кайда икән хәзер? Шушы юлдан озата барган иде бит Госман аны... Әйләнә-тирәләре бил тиңентен шау арыш иде, ә баш өсләрендә шашынып тургай сайрый иде...

Аулак иде, сихерле һәм гүзәл иде дөньялары.

Үпстермәде, кочтырмады, арыш арасына качты...

Күпме сулар акты инде? Ничә бала анасы булды икән хәзер нечкә билле Әсмабикә кызый?

Тургай... Госман хәтерләми: шул көннән соң дәртле кошның алай шашынып сайравын тыңлаганы булдымы икән аның? Үзләрендә, химиклар күгендә, янгырамый шикелле ул. Яратмый, күрәсең, һавасын кошкай...

Дөм-дөм кызы үзе дә, тургай кебек, тирән зәңгәрлектә югалды лабаса...

Тургай... Инде күз. Инде яңгырамый аның зеңгер-зеңгер авазы. Бик биектә аксыл-соргылт болытлар гына агыла бирә.

Һава тын. Дөнья моңсу...

Яшьлек эзләренә басып атлавы күңелне җилкендерә дә, яман сагышландыра да шул...

* * *

Ерактан ук сузылып килгән сырт артыннан зәңгәрсу урман очы күренә башлады.

Нияте әллә ни зурдан түгел иде Госманның: урманның бу читендәге тугайлыкта, сабан туйлары уздырыла торган төштә, тукталып тын алыр, чишмәсенең тәмле суыннан авыз итәр, аннан соң инде, кордон кырыеннан, умарталыкка сугылмыйча гына, эчкәрегә кереп китәр. Чикләвек елы түгел, диләр, алай да тәмләп карарлык кына очрамасмыни? Урманның бер почмагын кистереп үтсә, йомшак һәм тонык сулы Мәмет елгасына барып чыгар. Анда тирән һәм зур буа: иске су тегермәне...

Апасы Нурҗиһанны исенә төшерде. Мәмет тегермәне юлында бер кышның зәһәр буранында адашып, өшеп, чак кына үлмичә калган иде — бәхетенә, егылган җиренә авыл агайлары килеп чыгып, кире тегермәнгә җылыга илтеп салганнар. Ачы әрем тәме килгән оны белән үрәчәле чанасын басу түреннән ике көн үткәч кенә табып алып кайттылар. Ул чакны апасына уңалты да тулмаган иде бугай...

Ни дисәң дә, нужа бизмәненең саллырак ягы да, язмыш таягының авыррак башы да ганиләдә — малаймы ул, әллә кызмы — иң әүвәл олы бала җилкәсенә төшә. Нурҗиһан апасы, аз гына буй җиткерә төшкәч, әнисенә, туганнарына җиңелгәрәк килмәсме дип, укуын ташлап, колхозның кара эшенә ат урынына җигелде: көлтәсен дә ташыды, тырмасын да тырмалады, хәтта байтак вакытлар плугарь да булып йөрде. Ир-ат арасында эшләгәнгә күрәдер инде, үтә каешланып, хәтәр генә сүгенергә дә өйрәнеп алды. Әмма бер мәлне, көзнең бозлы-яңгырлы бер кичендә, колхоз келәтеннән иң азаккы тиярен алып кайткач: «Ни хәл итием, көн-төн эшләп тә, кыш буена бер ялгызымның тамагына җитәр-җитмәс кенә бит бу» дип, гарьләнеп елады-елады да, атна үтмәстән, берәүләргә ияреп, шахта җиренә китеп барды. Егерменче кышын кышларга...

Хәзерге заманда хатын-кызны җир астына төшертмиләр — закон кушмый, ә ул теге чакны ирләр белән янәшә кара тирләрен агыза-агыза

жир каезлады, күмер чапты... Апасы шулай кыз башы белән маңгаенна кара тирләр агыза-агыза ярдәм итешмәгән булса, Госман үз язмышында юнь ала алган булыр идеме соң? «Зур кеше булдың син», диләр... Их, апа-апакай! Күпме тиешле сиңа энекәшең? Гомереңдә түләп бетерә алырмы, әллә мәңге әҗәтле булып калырмы?..

Инде хәзер үзенең Кизелында, кайчандыр яшьлегендә җан тирләрен агызган, җелеген суырган басу-кырларны «үлеп сагынганлыгын» әйтеп, бимазалана, мул һәм иркен тормышлы йортыннан, әүвәлге байбикәләр сыман, авылдашларына хәер-күчтәнәч җибәреп тора.

Госман шәп кенә барган җирендә капыл тукталды. Ул инде үр сыртына менеп үк җиткән иде.

Якында, каршы яктагы офык буйларын иңләп һәм күңелне чамасыз үзенә тартып, калын урман зәңгәрсулана, ә арт ягында, киң һәм озын иңкүлектә, ала-кола түбәләре, биек ябалдашлы карт тирәкләре белән җанны кытыклап, туган авылы җәелеп ята иде.

Туктале, ничек булды әле бу? Әнисе белән апасының әманәт-гозерен санга сукмаган шикеллерәк килеп чыкты түгелме? Әйе, иң әүвәл үз җаең җай, үз күңелең күңел, үз хисләрең хис, диде...

Әнә анда — туган мәктәбе. Куе сәрби куаклары һәм өрәңгеләре эчендә күмелеп утыра. Ничек читләтеп үтте соң әле ул аны? Уйлаганниятләгән дә иде бит, югыйсә. Унны тәмамлагач, аңа юл башы ярырга бик тә булышкан укытучысы, хәзер инде мәктәп директоры Сабир абыйсы белән күрешеп, бер иркенләп сөйләшәсе сүзе дә бар иде...

Күз алдына Хәбибрахман карт килеп басты. Заманасында Госманның әтисе белән ерак сәфәрләргә китеп, бәхет эзләгәндә аның якын дусты булып йөргән кеше... Былтыр күрешә алмады: картны Акбалык больницасында дигәннәр иде. Менә бит, аңа да сугылмады. Әлбәттә, өендә ята торгандыр ул. Монысында карт янына буш кул белән керү килешмәс. Кибеттә аның өстенә яисә башына ярардай бер-бер нәрсә бардыр әле. Рәхәтләнеп кисен — әтисенең бер ядкәре сыман булыр, ичмаса... Бүтән карт-коры тагын...

Ә ни өчен кич житкәнен һәм Лубъяннан Нурдидә түтинең кайтканын көтәргә, ди? Әнисе-апасы кушканны үз күңеле, үзенең җылы куллары белән бирсә-өләшсә, ни булган соң? Ә бәлкем көтәргәдер түтине?..

## 2

Үзәк лабораториядә әле күптән түгел генә оешкан физхимия группасына алай итеп, болай итеп бер-ике өр-яңа прибор кайтартуга ирешкәннәр иде. Аларны кичекмәстән җаена китереп, эшкә җигү чарасына керешергә кирәк иде. Госманның үз слесаре ялдан әле кайтмаган иде, шунлыктан ул ремонт-механика цехы башлыгы Груздевка шалтыратып, берәр юньлерәк һәм төплерәк кул остасы җибәрүен үтенде.

— Приборлар куеласы өстәлләр дә вак-төяк кенә — әллә ни катлаулы түгел. Тик үтә пөхтәлек кирәк, Валентинны җибәрсәң, шәп булыр иде,— диде.

— Юк, Валентин дусыңнан өметеңне өз: реактив тозлар цехының бик тә ашыгыч эшенә муеннан чумды әле,— дип гыжлады теге телефон трубкасына.— Алай да синең белән эшнәлекне бозарга ярамас: Валентин сыңарын җибәрермен. Алтын куллысын!

Менә ул егет аның кабинетында... Төз һәм калку буйлы, үткен елтыраган коңгырт күзле. Тамак төбе белән коры гына исәнләште дә, инструментлар тутырылган күн букчасын шылтыратып, бусага төбендә таптангалап алды.

Валентинның сыңарымы бу? Төгәл эшли белерме, булдырырмы?

— Уз, утыр. Мин хәзер.

Госман карап бетерәсе кәгазенә төбәлде. Әмма ул шундук тагы башын калкытты: егетнең чалымнары ана таныш кебек иде. Ләкин Госман, маңгаен җыерчыкландырып, никадәр чамаларга тырышса да, егетнең кемлеген хәтер-хәбәренә китерә алмады.

— Ни... кирәк-ярак нәрсәләреңне барын да алдыңмы?

— Алдым кебек.

Госман үзенең ахмаграк сорау биргәнлеген шундук абайлады.

— Тәк, кем дип танийм инде сине?

— Бүгенгесе көнне слесарь кисәге Фуат Шәйморатов дигән кеше мин,— диде егет коры-житди тонда һәм ияген учлады да сәер көлемсерәп өстәп куйды.— Ә болай кайчакларда кайберәүләр «Бөдрәш» дип кенә эндәшкәлиләр.

Кылт исенә төште Госманның...

«Шул бит, үзе! Моннан ике ел чамасы элек бөтен поселокны шаулаткан Шәйморатов... Бөдрәш! Кара син... Теге чакны хөкем залында сул кулы, инбашыннан ук ап-акка уралып-бәйләнеп, муенына марля белән асып куелган иде. Ә йөзе-кыяфәте сап-сары, тап теге дөньядан әйләнеп кайткан кешенеке төсле иде... Алай да үзенең элеккеге әшнәләренә карата ничек кырыс та, усал да, гадел дә була белде егет!»

Шәйморатовның, тәмам савыгып, эшкә яраклы хәлгә килгәч, кире АТХга шоферлык эшенә кайтмыйча, заводның ремонт-механика цехына урнашканлыгын Госман ишеткән иде. Инде хәзер күр: Груздев аны «алтын кулларның берсе» дигән була, «Валентинның сыңары», ди...

— Сезгә ни-нәрсә эшләп бирергә кирәк соң, Госман абый?

«Зөлфәне дәшергәме әллә? Теге чакны гыйшык-мыйшык утында янгандай кыланып, бик тә дуамалланып йөргән иде кызый... Хәзер ничек икән? Бөтенләй үк суынып беттеләр микән? Кызык: аларны менә монда Зөлфәнең эшләгән җирендә очраштырсаң, ә?»

— Эшме? Хәзер, энекәш...

Госман лабораториядәге группалар белән кабинеттан гына сөйләшү өчен җайланган аппаратның тиешле төймәсенә басты һәм, Фуат Шәйморатовка төбәлеп караган килеш, микрофонга эндәште:

— Рәшит дим, Сәлмәнов, кер әле! Чакырган кешебез килде.

— Күптән көтә идем,— дип гөрелдәде аппарат.

Бу җәйне генә әле Казан университетын тәмамлап килгән һәм монда яңарак кына оештырылган физхимия группасына җитәкче булып алган яшь белгеч Рәшит Сәлмәнов керде. Ул Фуат Шәйморатов белән кул кысышып алгач, үзен шактый ук олыгайтып күрсәткән сары сакалын сыйпаштыргалап:

— Әйдә, алайса, дус кеше, сутәрдәен сутик тә ялгардаен ялгарбыз: җан керсен әле хроматограф дигән нәрсәкәйгә,— дип көлемсерәде.— Вакытың кысан түгелме?

— Түгел.

— Кара аны, Рәшит, сез анда чамалабрак маташыгыз,— дип кисәтте Госман.— Синең ул нәмәрсәкәең назлы баладан да болайрак шикелле.

— Беләм, Госман Габдулыч. Әмма без аның назына биеп китмәбез, үзен биетербез. Дөрес бит, дус кеше?

Фуат Шәйморатов күн букчасын селеккәләп бусага төбенә барып баскан иде инде, ул тигез ак тешләрен елтыратып елмайды гына...

* * *

Бүген кичке бишкә парткабинетка пропагандистларны чакырткан иде бит әле Госман. Политмәгариф системасында менә-менә укулар башланырга тора, менә инде бары да әзер кебек, шулай да тиешле кешеләр белән соң мәртәбә төпле бер әңгәмә уздырмыйча һич ярамый иде.

Менә бу елны пропагандистлык вазифасыннан азат ителгән булса да, Госман Әхмеров партком секретаренең идеология эшләре буенча урынбасары буларак, политик укуларның әйбәт башлануы, уңышлы дәвам итүе өчен дә ин җаваплы кеше, димәк ки, бу моментны йоклап уздырса, соңыннан үкенеп бетә алмаячак...

Парткабинетта яңа журналлар инде килгән булырга тиешле, әңгәмәгә кадәр аларны күздән кичерү зыян итмәс дип, ул эшеннән иртәрәк китәргә уйлады.

Берәрсе юлын бүлгәнче-ниткәнче дип, ашыгып, кабинет ишеген бикләп алды. Ләкин үзәк лаборатория бинасыннан ишегалдына чыккач, моннан нихәтле тизрәк таярга омтылса да, тукталмыйча булдыра алмады: иске тоз-сульфат цехы ягыннан бирегә таба, бетон сукмакка шакшок баса-баса, бер солдат килүе күзенә чалынды. Шундук исенә төште: кадрлар бүлеге башлыгы Мәҗитов әле иртәнге якта ук телефоннан аңа: «Гөргери картның армиядән кайткан төпчеге эшкә керергә ниятләп йөри. Сиңа да сугылырга куштым. Үзегезгә бик тә кулай булуы ихтимал», дип, егет хакында кайбер мәгълүматларны да әйтеп, искәртеп куйган иде.

Госман егетнең килеш-килбәтенә сокланып карап торды: төз һәм җинел гәүдәсен туры тотып, җил-җил атлый, очып китәргә җыенгандай, кулларын хәтәр селтәнә. Менә ул бил каешын алдан артка таба сыпырып алды да, борылып, тоз-сульфат цехының бер ишеге төбенә баскан өч-дүрт кызга кул болгады. Тегеләр, дөньяларын онытып, авызларын ерганнар иде.

Шак-шок атлап килде, шып тукталды һәм, исемен-фамилиясен әйтеп, каты иттереп кул кысты. Ихтыярсыздан, шушы җилле тегәллеккә буйсынып, Госман үзе дә ничектер исемен әйтмичә кала алмады.

— Ә мин сезне күптәннән беләм бит, Госман абый.

— Шулаймы? Ә мин сине нишләптер начар хәтерлим. Киткәнче син механическийда эшләгән идең, ахрысы?

— Түгел. Реактив тозлар цехында эшли башлаган идем. КИП буенча... Ә сез ул чакны баш инженерның урынбасары идегез әле.— Егет этисенеке шикелле үк очлы ияген угалап алды.— Хәтерлисез микән, бер чакны сез баш инженер Мороз белән икәү без тәкъдим иткән бер яңалыкны үз күзегез белән карарга цехка килгән идегез. Тәкъдимебез вентиляция системасын үзгәртү турында иде.

— Әйе, әйе...

Госманның күз алдында, томан эченнән калкып, майга буялып беткән, артык тәбәнәк һәм чандыр гәүдәле, әмма әкәмәт елгыр күзле егет пәйда булды. Ә хәзер күр инде: этисе моның җилкәсеннән генә булыр. Килешкән үзенә солдат шулпасы!

— Завод белән танышып йөрим, диген, алайса... Я, ничек? — дип сорады Госман.

— Әйбәт! Иске цехларда да байтак кына үзгәрешләр күренә, ә яңалары турында әйтәсе дә юк: күңелләр җилкенә! Менә бит сез дә, Госман абый, мин югында ике катлы йортка кереп утыргансыз, элеккесе шикелле утын сарае түгел бу.

— Шулай, Марс туган, арбабыз, шыгырдап булса да, үргә таба тәгәри,— дип елмайды Госман.— Озакламый ике ел тула инде монда күчкәнгә... Әйдәле, күрсәтим әле үзеңә!

Вакыты бик тар, ашыга иде Госман. Шулай да солдатка аны-моны сиздермәде. Егетнең асылы завод буйлап эш караштырып, үзенә кунарга урын эзләгәндә, форсатны кулдан ычкындырырга ярыймыни?

Лаборатория бинасына кире керделәр. Госманның бәхетенә, икенче катка күтәрелгәч, аларга лабораториянең барий тозлары группасыннан инженер ханым очрады. Госман аны солдат егет белән күрештердетаныштырды да егетне ханым карамагында калдырырга ниятләп:

— Үзем бик тә ашыгам, Алевтина Лейбовна. Сез инде, зинһар, вакытыгызны җәлләмичә, бу иптәшкә лабораторияне күрсәтеп чыксагыз иде,— дип үтенде. Һәм солдат сизмәгәндә генә ханымга күз кысып алды:— Иң азактан Рәшит янына кертерсез. Ул үзе белер...

* * *

Парткабинеттан шактый соң чыкты Госман. Кәефе күтәренке иде: пропагандистларның барысы да диярлек ныклы хәзерлектә тора, димәк ки, сынатмаячаклар...

Күк йөзе ап-аяз, караңгы. Бихисап йолдызлар җемелдәшә.

Бүген байтак эшләр эшләнде, алай да тамчы да арылмады. Гәүдәсендә-тәнендә һәр буын, һәр мускул дәртсенеп, зыңлап тора сыман. Җәйге ялдан соң шулай булмый ни!

Чат башына житеп, кайтыр ягына борылырга иткәндә генә, үзәк лаборатория ягына күз салды. Ни күрсен: тегендә бинаның өске катындагы өч тәрәзәсе ап-якты. Кислотачылар бүлмәсе шикелле... Зөлфә «Чулманнефть» геологларыннан кирәкле мәгълүматларны алып кайткан да шуларны тикшереп-чагыштырып утыра микәнни, тынгысыз җан? Әллә Рива Галиева кандидатлык минимумына әзерләнү өчен эштән соң утырып калган да дөньясын онытканмы? Бәлкем икесе бергәдер? Госман үзе дә кичләрен еш кына шулай эшләп калгалый бит.

Өенә шалтыратып-нитеп тормады — анда тыныч тыр: хатыны Зөбәрҗәтнең больницага дежурлыкка барасы юк иде — Госман лабораториягә таба атлады.

Проходнойда балдызы белән маңгайга-маңгай бәрелешә язды.

— Һо, Зөлфә! Инде китүең дәмени?

— Әйе, китүем, җизни.

— Тукта, Акбалыкта юлың уңдымы соң?

— Бары да булды. Тик, зинһар, иртәгә сөйләшербез, җизни. Башым чатный... Иртәгә иртән, яме?! Хуш!

Госман авызын ачып аны-моны әйткәнче, балдызы караңгыда эреп югалырга да өлгерде.

Икенче катта ут инде сүнгән, әмма ишегалды ягына түбәнге каттан якты төшкән иде. Шул, сары сакалбай Рәшит җенләнеп утырадыр, билгеле...

Юк, физхимия бүлмәсендә сакалбай үзе генә түгел икән, аның тирәсендә Гөргери картның төпчеге солдат да, «слесарь кисәге» Фуат та онытылып утыра иде. Күр, моңарчы... Күзләре тоныкына гүләп утырган хроматографның экрен-тигез шуышкан угына төбәлгән. Лаборатория башлыгы керүен абайламадылар да...

Госманның:

— Булдымы әллә? Эшлиме? — дип эндәшүенә, өчесе дә сискәнеп, бердән урыннарыннан куптылар.

— Эшли, Госман Габдулыч! Әйттем ич биетербез дип...

— Шәп, шәп! Булдыргансыз!.. Тик ни... сез нишләп әле моннан бер төн күбәләген өркеттегез?

— Нине?

— Төн күбәләге Зөлфәне! Минем балдызны ягъни...

Фуат Шәйморатовның йөзе кырыс үзгәрде, ә Марс-солдатның, киресенчә, тагын да балкый төште.

— Һе, кайда иде ул? Без аны күрмәдек тә...

— Ярар, күрмәсәгез... Ә монысы өчен... монысы өчен мин сезне күкләргә чөяр идем, егетләр! — дип гүләде Госман һәм чуар шакмаклы кепкасын бер кырыйдагы урындыкка таба очыртып җибәрде.— Инде дериватограф дигән шәп нәрсәкәйне дә кулга төшереп, көйләп җибәрә алсак... Их, дөньялар җимертергә булыр иде!

«Төнге күбәләк» турында Госман тап өстенә китереп баскандай әйтте: Зөлфә чынлап та лабораторияләренең түбәнге катында ят кешеләр барлыгын, шуларның берсе Фуат икәнен сизенгән һәм, бу хәлдән коты алынгандай, чыгып сызган иде...

3

Бөек Менделеев тарафыннан элементларның периодик системасы ачылуга тулы бер гасыр.

Ленинградта юбилей съезды уздырылачак.

Бөтен дөнья галимнәре купкан булырга охшый...

Заводның баш инженеры Мороз бу съездга элэгү турында күптәннән хыяллана, юк, болай дию генә аз: ул анда катнашачагына ныклы өмет тота иде. Бердән, аның заводы Россия күләмендә иң борынгылардан, илнен химия промышленностена нигез ташы салганнардан исәпләнә, димәк ки, моннан кемнәрнедер чакыртмыйча чаралары калмас, икенчедән, ул, Иван Семеныч, бу борынгы предприятиенең баш инженеры булып утыра, алай гына да түгел, Д. И. Менделеев исемендәге Бөтенсоюз химия җәмгыятенең биредәге башлангыч оешмасында Совет председателе вазифасын да үти... Менә боларны әйтеп, Мороз җәмгыятьнең республика идарәсе президиумына үтенеч хаты да язган иде. Моның өстенә, Иван Семеныч ара-тирә Казанга шалтыраткалый һәм, хәл-әхвәл белешкәләп, андагы җитәкчелекнең исенә төшереп торгалый иде. Ул шалтыраткан саен идарәнең җаваплы секретаре, отставкадагы подполковник Мещеряков, гадәтенчә кыска һәм шик-шөбһәгә урын калдырмаслык итеп:

— Хафаланмагыз: президиум онытамы соң? Заманасында бөек Менделеев пироколлодийны нәкъ менә сезнең заводта ачкан лабаса,— дип куя һәм шул кыскалыгы, көр тавышы белән баш инженерның күңелендәге өмет ялкынын дөрләтеп җибәрә иде.

Ниһаять, шалтыраттылар. Мещеряков үзе...

— Сез анда, Иван Семеныч, инженер Госман Әхмеровтан сөенче ала аласыз: съездга бара егетегез!

Морозның күкрәк эчендә нидер өзелеп төшкәндәй булды, зиһене чатнап китте:

— Госман Әхмеров?!

— Әйе.

Баш инженерның сыкрану-ачыну аша авыр сулап куюы тимер чыбыклар буйлап Казанның үзенә үк барып житкәндер, әлбәттә...

— Димәк, минем ишелəр бер тиенгә дә тормый.

— Нишләп алай булсын? Безнең республикадан унҗиде делегат тиешле, ә җәмгыять членнары дүрт мең ярымнан ашып китә... Кемнәрне сайлап җибәрергә кушар идегез? Дөрес, бу исемлеккә академиклар яки член-корреспондентлар керми керүен, алар махсус чакырыла.

— Алай икән... Госман Әхмеров дисез.

— Соң, сезнең башлангыч оешмада кем иң актив? Шул үзе түгелме? Без бик беләбез. Әхмеровның уйлап табулар комитеты биргән унлап авторлык таныклыгы бар, төрле журналларда дистәдән артык мәкалә бастырган. Аннан килеп...

— Бик дөрес дим, бик барсын, тик...

— Нәрсә «тик»?

— Эһем... Юк, болай гына... Ярар, хәерлегә,— дип, бик тә ясалма рәвештә кеткелдәп алды Иван Семеныч.— Ә үзегез барасызмы соң, Денис Гаврилыч?

— Бармыйча! Миңа бит тегесен кайгыртасы, монысын җайлыйсы.

Иван Семеныч дәү йодрыгы белән телефон аппаратына кундырыр

хәлдә иде, ләкин кундырмады, тик чәнти бармагы юанлыгындагы кара-кучкыл сөяк кысалы күзлеген, борыны өстеннән җәһәт кенә кубарып алып, өстәлендә өелеп яткан кәгазьләр арасына атып җибәрде дә таптакыр баш түбәсен сыйпаштыргалады.

Баш инженерның күз алдында Госман Әхмеров пәйда булды.

— «Чын фән кешесе, инде үз өйрәнчекләре бар», янәсе... Соң, Әхмеров үзе дә әле аның шәкерте сыман гына лабаса! Әйе, шулай: Госман Әхмеров хлорлы барий цехында япь-яшь мастер булып йөргән чагында, аны смена башлыгы итеп күтәрүдә, аннары үзеннән бушап калган урынга цехка җитәкчелек постына калдырганда иң әүвәл Иван Семеныч сүзе сүз булды. Бүтән чакта тагы...

Инде хәзер тегендә президиум бизмәнендә Госман Әхмеров тәлинкәсе авыррак тарткан, имеш... Узындырмыйлармы малай актыгын! Эш болайга китсә...

Иван Семеныч үзен үтә җәберсетелгән, хәтта кыйналган сыман бер хәлдә тойды.

«Әллә идарә президиумының председателе мөхтәрәм профессорның үзенә шалтыратып караргамы? Юк, ярамастыр: теге сынса сынар, бары-бер бөгелмәс. Марк Львович бу хәбәргә ни дияр икән? Тукта, «куандырыйк» әле үзен...»

Директор үз кабинетында япа-ялгызы гына иде.

Иван Семенычның хәбәре аңа әллә ни тәэсир итмәде дә кебек: калын күз кабакларын салмак селкеткәләп, гадәти нәрсәне ишеткәндәй ваемсызрак чырай белән тыныч кына тыңлап торды, ахырда чәнти бармагын мыегына тидергәләп алды.

— Әйтәм, кыяфәтең балтасы суга төшкән кешенеке төсле, Иван Семеныч.

— Соң, Марк Львович, гомер уза бит. Андый съезд тагын кайчан була әле? Буласы да юк.

Директор, башын артка таба, кәнәфиенең биек аркасына ташлап, кулларын җәйде дә гамьсез генә көлемсерәде.

«Юри кылана, сынатасы килми... Ә бит әле кайчан гына съездга эләгергә ай-һай дәртсенгән иде». Иван Семеныч, менә шул хәлне исенә төшереп, директорны чеметеп алмакчы булган иде дә телен тешләде, тик бер мизгелдән:

— Шәп чирттеләр безнең борынга, Марк Львович, ә? — дип кенә төрттереп куйды.

— Чиртсәләр соң... Тукта, син Әхмеровның съездга баруына каршы мәллә? — Марк Львовичның чырае сагаюлы җитдилеккә таба үзгәрде.— Аны анда җибәрмәскә төплерәк берәр сәбәбең бармы әллә, Иван Семеныч?

— Сәбәп дип...— Баш инженер киң җилкәсен бөрештерде.— Бер нием юк. Болай лаеклы сыман ул... Шулай да...

— Эш кешеләре без, Иван Семеныч! Чүп белән кәефне бозмыйк. Җигелеп тартасы нәрсәләр байтак.

— Көн-төн җигелеп тартырга дисәң, без инде...

— Ярар, уфтанмыйк...— Директор йөнтәс беләгендәге сәгатькә күз төшереп алды.— Онытмагансыңдыр: озакламый миндә утырыш. Көнелне чүп-чардан арындыру кирәгер... Уйлашыйк-киңәшик тә төпле генә бер фикергә килик әле ул сернокислотный хакында.

— Аны уйлый-уйлый башлар тубал булды инде, җуләрләнмәсә ярый кеше...

— Таякның саллы башы синең муен тамырыңа төшәмени соң, Иван Семеныч? Иң әүвәл менә кемгә...— Марк Львович үзенең калын иңбашына каккалап алды.— Алай да шыңшынмыйм кебек... Җитмәсә тагы, Мәскәүгә укырга китәсе дә бар...

— Сез чынлап та китәргә исәп иттегезмени, Марк Львович?

Баш инженер директорның Мәскәүгә җитәкче кадрлар өчен оештырылачак ике айлык курска чакырылганлыгын белә иде. Әмма Левин, төплерәк сылтаулар табып, анда китмәскә дә ниятләп тора иде кебек.

— Бармыйча булмастыр. Бүген иртүк шалтыратып тагын искә төшерделәр. Бер атнадан сәфәргә!

«Әнә ни өчен Менделеев съездына исе китмәгәндәй кыланды. Курсларга укырга алынгач, бик теләсәң дә, съездга эләгә алмассың шул», дип, үзалдына ачы көлемсерәп куйды Мороз. Аның кәефе тагы да кырыла төште. Ленинградка съездга бара алмау хәсрәте өстенә монысы тагы... Ике ай буена — үзе бер гомер — кеше өчен җавап биреп утыр әле монда! Ах, яратмый иде Иван Семеныч директор урынында калырга — бигрәк тә шушындый киеренке бер чорда!

## 4

Зөлфәнең чынлап та башын ташка орырдай хәлгә җитеп, үтә кәефсезләнгән чоннәре иде.

Барысы да шул Зәбире аркасында...

Коры куык булып чыкты, ахрысы...

Кулга-кул сугып вәгъдәләшмәсәләр дә, хатларында бу җәйге ялларында бергәләп берәр кая — Кырымгамы яисә Кавказ ягынамы — сәфәр кылу хакында үзара ныклы сүз куешканнар иде. Ләкин хыяллары комнан ишелгән икән...

Соңгы тапкыр күрешүләре кышын Зөлфә Казанга сессиягә баргач булган иде. Эшеннән ничек ычкына алгандыр, Зәбир, аны сагынып, Тольяттидан очып килеп төште. Ике-өч көнгә генә булса да...

Ах, нинди куанычлы, ләззәтле һәм татлы минутлар иде ул! Әйе, минутлар гына...

Дусты Сәриягә тикле:

— Уйламаган идем: бозга да ут кабар икән,— дип, Зөлфәдән мәсхәрәле көлгән иде.

Ахырда ачуланыштылар хәтта...

Олы мәхәббәтнең олы вәгъдәсе дә булмый калмый, диләр. Зөлфә моның шулай буласына ышана да, куана да иде.

Аерылышкач, хатларында да сөю-ышану ялкынын торган саен көчәйтә генә бардылар.

Җәйгә тикле ал да гөл барды.

Ә җәйгә кергәч... Юк, ялкыннары суынмады-сүрелмәде кебек: ничектер, төбенә кылыч чапкандай, капыл киселде.

Монысында, Зөлфәнең җәйге сессиясе озын-озакка сузылачагын, ягъни сөйгәненең бушрак кичләре күбрәк буласын белсә дә, Зәбир Казанга килмәде. Ул гынамы, хатларыннан да өзде...

«Бер-бер хәл булганмы әллә үзенә?» дип, Зөлфә яман пошаманга бирелде. Ахырда түземе төкәнеп, телефонга чакыртты. Юк, егеткә берни дә булмаган икән. Әүвәлгечә ал да гөл, ди. Тавышы да элеккечә көр, шук, дәртле... Тик эше чиксез күп, вакыты бик тә кысан булуыннан гына зарланып алды, хәтта уфтанып та куйды. Азактан телефон трубкасын чупылдатып үпкәндәй итте...

Зөлфәнең күңеле янә дөрләп китте. Ләкин озакка түгел: тегенең тавышы-тыны тагын ишетелмәс булды. Кыз үзен тагы да куерак соры томан эчендә калгандай тоеп, тәмам миңгерәүләнеп йөрде. Кая анда фән дип баш ватулар!

Сессиясен ничек кирәк алай тәмамлауга ук, ике уйлап тормастан, «Метеор»га утырды да Идел буйлап Тольяттига юл тотты.

Ул аңа, барып төшәчәген белгертеп, телеграмма суккан иде. Ләкин пристаньда аны каршы алучы кеше күренмәде. Кыз анда сугылып, мон-

да төртелеп байтак гомер йөрде, байтак көтте. Бәлкем, ул аның телеграммасын алмагандыр?

Зәбир хатларын почтага «До востребования»гә генә яздырта иде. Зөлфә бик теләсә, тырышса, егете торган тулай торакны, һич югы, ул эшләгән заводны тапмыйча, аның эзенә төшмичә калмас иде.

Каршы якта яшеллеккә күмелеп мәһабәт Жигули таулары калкынып утыра. Горур таулар!

Түбәндә, көч-егәр туплап, дингездәй җәйрәп яткан зур су, күкрәк тутырып сулыш алгандай, алкын-талкын дулкын тирбәтә. Якында гына олы ГЭС гүли... Зөлфәләр заводына да яктылык нурлары да, егәр-куәт тә томырылып шушыннан килә бит.

Бетон ярларын меңләгән халык чуарлаган, асфальт юллардан йөзләгән машиналар чаба. Катлам-катлам тезелешкән биек йортлар да узышка чыккан кебек. Һавада кызган чуерташ исе, сумала исе. Һава үзе түбәннән актарылып кайный сыман; зәңгәр күктәге аксыл-зәңгәр болытлар исә шул кайнауның пары шикелле...

Дингездәй җәелгән елга битеннән дәү-дәү дулкыннар тәгәрәшеп киләләр дә, ярның бетон текәлегенә бәрелеп, чәлпәрәмә җимереләләр. Бетон җансыз да, кансыз да... Әнә, вак көймә-катерларны әйтәсе дә юк, теплоходлар куптарган дулкыннарда зур-зур дебаркадерларга тикле тирбәнгәләп ала. Алар җанлы сыман: ыңгыр-шыңгыр итәләр...

Бетон ярга басып дулкыннар чайкалуын күзәткән хәлендә, хафалы уйлары кызның күкрәген тырнап-тырнап алгалады. Нәүмизлек...

Ә каршысында мәгърур һәм гүзәл Жигули...

«Юк, уйламасын әле. Ялынып-бәйләнеп йөри димәсен әле...»

Зөлфә, күктәге алтын кояш Жигули тавының кучкылт түбәсе артына кереп яшеренгәндә, Идел буйлап югарыга таба менүче зур теплоходның тынчу карынына кереп поскан иде инде...



* * *

Ниһаять, көткән кешесеннән җавап килде.

Мескенләнә язып, гафу үтенгән. Аннан соң, эшендәге тыгызлыктан, вакыт тарлыгыннан зарланган да һич тартынмый-нитми яңа хәбәрен кисеп салган: сөйләшенгән көннәрен көтеп житкерә алмыйча, ялга чыгарга мәҗбүр булган һәм профсоюз путевкасы белән Үзбәкстанның борынгы калаларыннан йөреп-әйләнеп тә кайткан икән. «Путевка яна дип, бугазга ябыштылар, китмичә чарам булмады, син кичерерсең инде мине», дигән. Азакта, татлы-купшы сүзләрен җәлләмичә, «мең-мең кат үпкәнлегән» белдергән дә шуның артына әллә нинчә өндәү билгесе кадап куйган. Бу соңгысы, бәлкем, гап-гади инерциядән генәдер әле...

Күр син аны! Яңа-ялгызы гына кайларга әлдерткән! Куешкан вәгъдәсүзләрен бозып, таптап... Алданрак хәбәр салырга йөрәге дә җитмәгән...

Ә сөйгәне Зөлфә монда аның бер сүзенә зар-интизар булып ятты. Бергәләп көньякка — Кырымгамы, Кавказгамы — җәннәт сәяхәтенә китәләр, имеш... Җитмәсә, Зөлфәсе монда дус-ишләрен алдалап йөрде: янәсе, завкомга путевка килгәнен генә көтә. Югыйсә, завкомга сугылып, үтенеп караганы булса икән бер...

Ике арада тыгыз бәйләнгән мәхәббәт кылларына искәрмәстән үткен пычак йөзен сыдырып җибәрүе булдымы бу? Кулы ничек күтәрелде икән?

## 5

Иртәгә генә эшенә барыр да берсекөнгә, ниһаять, ялга китәр!

Баягынак, лабораториядә бетмәс анализларның берсе белән чыланеп утырган чагында, үлеп ашыйсы килгәнлеген тойган иде. Ә хәзер менә,

эштэн бушап, проходнойдан үткәч, ул тойгының инде басылганлыгын сизде. Әмма карынны өзлектерергә ярамастыр. Болай да аңардан үтә сәерсенеп йөриләр.

Бер көнне лабораториядә иң якын хезмәттәше Рива:

— Ике күзең тагы да зураеп утырып калды синең, Зөлфә. Сырхауланмыйсыңдыр ич? Әллә бер-бер хәл булдымы? — дип төпченергә кереште.

Җизнәләренә барып керсә, апасы Зөбәрҗәтне әйтерлегең юк: һаман бәйләнергә генә тора. Соңгы керүендә ул:

— Кыланма, кызый! Сизәм мин: нидер бар синдә... Яшермичә әйт: Зәбирең аркасындамы син җелек киптерер көнгә төштең, ә? — дип, бәгыренә энә чәнчергә тотынды.

Әмма Зөлфә, гамендә дә булмагандай кыланып, шукланып кителдәде генә:

— Бер ни дә юк, апа! Нормально!

Ә инде тегесе ачуын тагын да кабарта төшеп, тирәнгәрәк керә һәм Кукмарадан әнисен чакырту белән дә яный башлагач, Зөлфәнең дә чыгыры кирегә таба әйләнеп китте, һәм ул зәһәрләнеп:

— Кысылмагыз! Үзем белермен, сабый бала түгел! — дип кырт кисте. Тапканнар беркатлы кешене!

Инде кая сугылырга? Тулай торагына кайтса, тумбочкасында соңгы араларда каты-коты гына... Ашханәгә кереп, бер иркенләп утырыргамы, әллә кафеда аягүрә генә ярармы?

Кырымнардан бер рәхәтләнеп ял итеп, хәл җыеп кайтсын әле, күзләре дә үз урынында булыр, җаны да үз оясында тыныч кына, иплә генә ятар... Әлбәттә, әлбәттә!

Ә завод директоры Левин кызык: җизнәсе Госман аның өстәленә полиэтилен янчыкта кардай ап-ак соданы чыгарып салгач та, күзләре шар булган тегенең... Зөлфә белән Рива, җир астының тозлы эремәләреннән шул кардай ак кальций содасын бүлеп алабыз дип, лабораториядә көне-төне ми черетеп, аз җәфаланмадылар шул... Директорың гына түгел, министр хәтле министрның күңеле эреп китәрлек монда!

Ул җизнәсенең үтенечен кире кага алмаган, шундук йомшакланып, Риваны Бакуга йод-бром заводына командировкага җибәрергә күнгән, тик Зөлфә хакында гына менә... Юк, каршы килмәгән килүен.

— Анысын Кырымга Сакы бром заводынамы? Ай-яй, икесен бер вакытта җибәрү ярамас та, килешмәс тә... Соңрак-соңрак, Госман Габдулыч,— дип, беравыкка кичектерергә кирәк тапкан.

Җизнәсе Госман алай ансат кына күнә-чигенә торган кешеме соң? Аңа, бер уйласа, карар итсә, көнендә-сәгатендә булсын. «Инде болай да нефтькә иярәп чыккан тозлы суларны тикшерү эше озакка сузылды, һаман да бер урында таптанып тору асыл егетләр һөнәре түгел», ди. Һаман да шулай, яулыкка чапкан ат шикелле, каядыр ашкына, кабалана. Теләгәнемә өлгермәм, җитешмәм дип чын-чынлап курка, ахрысы. «Ходай тәгалә безгә вакытны бик җәллэп, бизмәнендә мыскал-мыскал итеп кенә үлчәп биргән. Син чамалыйсыңмы, сизәсеңме шуны, балдызкай?» дип, шаярту аша төрттереп куйгалаулары тикмәгә түгел, билгеле.

Әлбәттә, җизнәсе директорга баш орып ялынмаган — бусы аның холкына сыймаган нәрсә, ләкин үз ниятеннән чигенергә дә исәп итмәгән.

Зөлфәнең гаризасына кул куеп, дирекциягә приказга җибәрер алдыннан ул капыл гына:

— Ярар, балдызкай, тиешле отпускаңа тагы биш көн өстәргә күндем мин. Ләкин син дә мин кушканга риза булырсың,— диде, сынаулы карашын төбәп.

— Ә ни соң ул? — дип аптырашта калды Зөлфә.

Кырымга барасың бит син. Монда боларга ялынып торганчы, әллә дим, анда Сакы заводына да сугылып чыгасыңмы? Юл уңае бит.

— Әй, жизни, кеше анда, үзең әйтмешли, ял итәргә бара, син тагы...
— Үлмәссең. Ике-өч көнгә генә. Ул арада әлләниләр күреп, белеп алырга була. Аларның производствосы белән танышу үзеңә дә зыян итмәс. Сиваш буйларын әйләнерсең. Кызык бит. Ә инде акча ягы дисәң, аньлык кына расходны үзем капплармын.
— Хикмәт акчадамыни, жизни! Хикмәт җаенда.
— Теләсәң, җаен да табарсың. Мин сиңа алар исеменә бик әйбәтләп хат язып тоттырырмын. Заводта ниләргә күбрәк күз салырга икәнен дә төшендерермен. Хәер, онытмас өчен, бусын да кулыңа язып тоттырырга була.
Җизнәсенең күз карашы бик тә инәлүле, бик тә үз иде, һәм Зөлфә:
— Ярый, алайса, Кырымга баргач, күренер... ничек тә тырышырмын,— дип, күнсә дә күнде, күнмәсә дә күнде.
Эш, эш... Вакыты-көне ул кадәр җәл дә түгел түгелен, әмма эш дигәне үзе! Инде монда да гарык булганчы туелган иде, тегендә барса, тагын шул ук эш — кадалып кына ла китсен!
Ә Зәбиргә ул ике-өч тапкыр төн буе хат язды: тегенең үз вәгъдәсендә тормавына яман ачу белгертеп, нәфрәтләнеп... Ләкин язган бер хатын иртән торуына ерта барды: үзен һаман да мескен һәм нәүмиз хәлдә тою, аннан да бигрәк бу халәтне бүтән берәүгә сиздерү авыр иде аңа. Юк, бичара дип уйламый торсын әле!
Ахырда, әле кичә генә, ул аңа телеграмма сукты. Бер генә сүз белән: «Рәхмәт!» дип... Кызның бар булган ачу-нәфрәте дә, өстенлеге һәм горурлыгы да шул бер сүзгә тупланган иде. Телеграммасы киткәч, ул үзен шактый җиңеләеп калгандай хис итте.

* * *

Кафеда аягүрә генә тамак ялгап чыккач, Зөлфә Туйма аша салынган күпергә килде. Күпер яңа, нык һәм биек. Аның чуен челтәрле култыксасына таянды. Түбәндә шактый саеккан елга эреле-ваклы ташларга йомшак кына орынып, бөтерелә-алкалана ыбыр-шыбыр агып ята. Ә күк йөзе зәп-зәңгәр, аяз. Тымызык һавада анда-санда пәрәвез очканы күренгәли. Әбиләр чуагы...
Көннең ямен хлорлы барий цехының торбаларыннан бөркелгән кара-соргылт төтен генә җибәрә. Эчпошыргыч ямьсез болыт...
Инде кая барырга? «Коммуна» кинотеатрында сеанс башланмаган кебек әле. Тик кинофильмы юньле түгел, ахры: ул тирәдә халык әллә ни күренми иде.
Тулай торагына кайтсынмы? Анда да күңел тартмый. Ерак сәфәргә әзерләнәсе бар барын да... Юк, өлгерер әле.
Анда, аның бүлмәсендә, әүвәлге ишләре — сердәшләре юк инде хәзер: берсе сигезенче мартта, икенчесе май азагында, химиклар бәйрәмендә, бу туйдырган ояларын ташлап очты. Кияүләре белән кулга-кул тотышып, һәркайсы үз куышын һәм уртак язмышларын корырга-үрергә тотынды. Тик Зөлфә генә иске ояны саклап калды. Аянычрак хәл: бүлмә ветераны!
Җәй уртасында Красноярскидан техникум тәмамлап килгән яңа бүлмәдәшләре — болай ару гына кызлар үзләре, әмма бик тә яшьләр әле: кичләрен эштән бушаган сәгатьләрендә бар уйлаганнары, бар кайгыртканнары күлмәк һәм юбкаларының итәге тирәсендәрәк чуала. Әдәп-ни дигәнгә исләре дә китми, һаман да: «Тагын да кыскарак итәргә, тагын да биегрәк, бот төбенә хәтле үк күтәрергә булмасмы икән?» дип өзгәләнәләр. Зөлфә бик әйбәт белә: аның аяклары бу сары авызларныкыннан күп тигез, күп күркәм, ләкин алар кебек кыланырга кыюлыгы җитми. Дөньяда оят дигән нәрсә дә бар бит әле...
Күпер арттa калды — кыз асфальттан шакы-шокы атлаштыргалап, Олы урам белән Революция тавына таба юл тотты. Бераздан, берәр

таныш-белеше очрап, юк белән башын катырырга тотынмагае дип, Олы урамнан читкә, аулаграк юлга борылды.

Көз алдына Зәбир килеп басты.

Сагыну-зарыгулары инде сүрелгән, ул сөйгән егетен аеграк акыл белән бөтенләй икенче яклап нечкәли иде.

Әйе, кай ягы, нииндирәк сыйфатлары белән Зөлфәнең күңелен биләп алды соң әле ул?

Теге чакны яшьләр фестивале ачылган көнне Казанның спорт сараенда күреп алган ул Зөлфәне. Бик тырышып, бик хәтәр биегәннәр иде шул алар — халык Сашко белән икесен кабат-кабат сәхнәгә чакырды... Менә шул чакны инде хәйран тамашада Зәбирнең акылы тәмам чуалып, күкрәгендәге җене кузгалган да... Концерт бетүгә ни эзләгән ул Зөлфәне, әмма таба алмаган. Зөлфәнең эзенә алай ансат кына төшәрлек тә түгел иде: ул бер төркем үз ишләренә ияреп, япон яшьләре белән шаугөр килә-килә, төнге Казан урамнарында яшьлегенең иң гүзәл бер таңын аттыруда иде.

Эзләгән — тапкан, ди. Икенче көнне үк яшел наратлы, алтын комлы Идел ярында — Яшьләрнең халыкара спорт лагеренда, җил ташлагандай әллә каян гына килеп чыкты да койрыгына басты ул аның...

Фестивальнең башында ук Зөлфә ерак кояш чыгышы иленнән килгән яшьләрнең берничәсе белән дуслашып өлгергән иде. Арадан берсе — балкортыдай нечкә билле, гаҗәеп җиңел һәм житез гәүдәле, чишмә тавышлы Экима Титоси аны аерата үз итте. Теге дә биюче, бу да...

Бер мәлне бүтәннәрдән аерылып, лагерьның аулаграк читенә киттеләр дә яшь наратлар арасында яшел чирәмлектә тотындылар һөнәршөгыль алмашырга. Авыз эчләреннән генә көйли-көйли... Бусы алтын чәчләрен тузгытып, бөгелә-сыгыла татар биюен өйрәтергә тырыша, ә тегесе, карлыгач канатыдай кашларын салмак каккалый-каккалый, нечкә-нәфис хәрәкәтләр белән япон биюен, үзенекен төшендерергә ашкына. Бер-берсенең телләрен белмәүгә тамчы да исләре китми. Ләкин икесенә дә кыен әле. Өр-яңа биюгә өйрәнү алай ансат һәм тиз генә отып алырдай нәрсәме соң!

Шулай көлешә-көлешә азапланган чакларында, берәү наратлар арасыннан калкынып килеп тә чыкты һәм таза, нык кулы белән Зөлфәнең беләгеннән эләктереп тә алды. Кыз кисәк куркынып:

— Ай, ни кирәк сезгә?! — дип кычкырып куйды.

Шунда, күзләрен зур ачып, ипләбрәк караса: Зәбир...

— Ни эзләдем! Ә син монда кайда икәнсең,— диде егет, еш-еш сулап.— Саумы дим, саумы?

— Бик сау!.. Үзең соң ни хәлдә? — дип җавап кайтарды Зөлфә, үзенең тавышы да, гәүдәсе дә калтырануын тоеп.

— Шәп! Әле кичә иртән генә сине күрермен дип уема да китермәгән идем... Ә хәзер шатлыгым күлмәгемә сыймый! Тукта, ни дип качтың әле син монда бу Каракүз-сылу белән, ә? Һе-һе, аңладым — әйтмәсәң дә була! — Зәбирнең шаулап көлүендә шатлык та, дәрт-егетлек тә ташып тора иде. Ул кояшта шактый янган, каралган иде, хәтта борыны тирәсендәге вак сипкелләре дә беленми башлаган иде.— Әйдәгез, ни торабыз әле монда тораташ кебек катып? Тегендә халык катерда Иделне айкап кайтырга җыена бит! Киттек, дим, тизрәк!

Япон кызы белән Зөлфә ык-мык итеп торган арада, Зәбир аларны җәһәт кенә култыклап та алды, жил-жил йөгертеп тә китте.

Әмма текер-текер ни йөгерсәләр дә, өлгермәделәр: яшьләрнең жыргөрелтесенә күмелгән чибәр катер, ярдан аерылып, Идел көзгесенә дугайлатып тирән буразналар сала-сала, эчкәрегә таба юл алган иде инде.

Эмма Зәбир төшеп-югалып калырдай бәндәләрдән түгел, ашкынып бер кырыйга китеп барды һәм күз ачып йомган арада диярлек авызын ерып әйләнеп тә килде: буш көймә тапкан икән.

— Берәрсе килеп тыкшынганчы, әйдәгез! Бер рәхәтләндерим әле үзегезне Идел суларында! — дип, зур хәзинәгә юлыккан кешедәй гөрелдәде ул һәм, япон кызы да аңласын өчен, куллары белән ишкәк ишкәндәй иттерде.— Мадмуазель каршы түгелдер бит?

Зөлфәдән хәтта сорамады да: мөгаен, аның әчке ризалыгы, йөзенә үк чыгып, нурланып балкыгандыр...

Әллә ни зур булмаган җыйнак кына, җиңел генә көймәгә өчәүләшеп кереп утырдылар.

Идел шаулый-гөрли иде, катерлар һәм моторлы көймәләр куптарган дулкыннарда тирбәлүе искитмәле рәхәт иде.

Зөлфәнең Зәбиргә үпкәсе дә, хәтта ачуы да бар иде, һәм кыз студент егетне: «Ә ник әле син, хөрмәтле иптәш, безнең Чулман заводыннан практикадан киткәч тә, хатларыңны капыл-капыл өздең, биргән сүзләреңдә тормадың, әэләренне суга салдың?» — дип, баштарак чәнчеп алмакчы да булган иде. Ләкин талгын дулкыннарда иплe генә тирбәлгәндә һәм бөтен Идел битендә төрле телләрдә саф җыр булып әчкерсез хисләр өермәсе бөтерелгәндә, кызның күңелендәге андый гына вак-төяк, бер-ике уфтануына ук, эзсез эреп юкка чыкты.

Күрешүләре һәм кавышулары шулай булды. Аңа инде бүтәне ялганып китте.

Көндез күләгәләрен, ә кич һәм төннәрен сулышларын бергә куштылар.

Ә бер төнне Идел ярында, шактый түбән китеп, хәтта таң аттырдылар. Әйләнә-тирәләре серле-сихерле әкият дөньясыдай иде: елга өстендә төрле төсләрдә бихисап утлар җемелдәшә, артларында моңлы һәм талгын бер көйгә карурман шаулый, түбәндә, су читендә, вак дулкыннар чапыр-чупыр бетмәс серләрен серләшә...

Әйт: онытырлыкмыни шундый минутларны?

Фестивальгә катнашуы Зөлфәнең язмышында иң бәхетле һәм иң нурлы сәхифә булды, Зәбирнең килеп кушылуы исә ул бәхетне колач нпләмәслек итте, нурлы көннәрен меңләгән яңа төсләр белән бизәде. Моны инде Зөлфәнең күңеленнән һич ни дә җуеп ала алмас иде. Тик тагын да куанычлырак бәхет иңсә, тагын да гүзәлрәк ямьнәр килсә генә бераз тоныкланып калуы ихтимал иде.

Тегендә, үзенең Тольяттиендә, Зәбир дә ул көннәрне онытмагандыр ич? Онытырга тиеш тә түгел! Әллә ниме?..

* * *

Революция тавының түбәсенә менеп житкән иде инде. Зөлфә артка, киң үйсулыкта төтен болытлары таратып яткан заводка, таба борылып карамыйча гына, бер мәлгә тукталып тын алды.

Кисәк әчтә нидер чәнчешеп куйды — исенә төште: Фуат Шәймөратов белән моннан ике ел элгәре шушы сукмактан бит әле ашыга-кабалана Революция тавына менгәннәр иде алар. Гөргери бабай Абуздыриннан музей өчен истәлекләр язып алырга барышлары иде.

Егетнең, үткен коңгырт күзләрен чак кына кыса төшеп, саран көлемсерәгән какча йөзе соры томан әченнән калкынып, чагылып үткәндәй булды...

Теге көннәрне Идел фестиваленнән шатлыклы, бәхетле хисләргә күмелеп кайткан чагында, ялкынлы утлардан салкын суларга керәсен уена да китермәгән иде. Үзе яшәгән химиклар каласына кайтып төшсә, Зөлфәне яман һәм хәтәр хәбәр көтеп, сагалап торган икән: аңа күз атып,

гыйшык-мыйшык очкыннарын дөрләтергә йөргән егете Фуат Шәйморатов Акбалык больницасында әҗәл якасында, ди. Әллә кемнәр түгел, караклык-явызлык юлына баскан элекке әшнәләре, нидәндер үч алмакчы булып, сул як җилкә тамырына пистолеттан атканнар, ди... Егетнең бәхетенә, Акбалыкның атаклы хирурглары Нечаев белән Сабирова өйдә туры килеп, шулар гына аны саклап калган, ди...

Дусты Сәриядән сорашып аңышты тагы: егет Кизнер станциясеннән кайткан вакытында тегеләргә аулак басу юлында тап булган, ди, ә Кизнерга ул яшь чагында Крупскаяны күреп тә, сөйләшеп тә белгән Мәһинур исемле бер карчык янына хәл-әхвәл сорашырга барган икән, ди...

Моны ишеткәч тә, Зөлфә егылып китә язды: Фуат музей эше — нәкъ менә Зөлфә йомышы белән йөргән икән ич...

Анына кайтып, сөйләшерлек хәлгә килгәч тә, сине сорашты: хәбәре юкмы, кайтмыймы әле? дип... Бик тә көтә ул сине,— диде Сәрия.— Уйласаң, күрешергә дисәң, Акбалыкка бергә барырбыз,— диде.

Бардылар.

Зөлфә калтыранган куллары белән ак япмалы тумбочка өстенә чәчәкләр утыртып куйды. Егетнең сул як кулбашы, өлешчә арка ягы һәм күкрәк тирәсе гипста һәм ак биләүдә иде. Әле кайчан гына янып торган какча йөзенә куркыныч аксыл-сары төс ингән — мендәрләреннән әллә ни аерылмый да... Иреннәре дә күп-күмгәк. Тик беренче карашка моңсу һәм нәүмиз күренгән коңгырт күзләрендә генә әүвәлге үткенлек яши иде, һәм аларда хәтта куаныч нурлары да бар иде сыман. Хәер, Зөлфә аңа озаклап туп-туры карый алмады да...

— Ничек соң, фестивалегез әйбәт үттеме, күңелле булдымы? — дип сорады егет, күгәренгән иреннәрен хәлсез генә кыймылдатып.

— Әйбәт... күңелле үтте, Фуат... Фуат абый,— дип җавап кайтарды Зөлфә, тамак төбенә ачы төер утырганлыгын тоеп.

— Син монда Мәһинур әбинең килүенә кайтып өлгермәдең бугай?

— Өлгермәдем.

Мәһинур әбиләренең завод музеена гаять кызыклы истәлекләр тапшырганлыгын һәм яшьләр-укучылар белән бик тә күңелле очрашулар уздырып киткәнлеген Зөлфә ишеткән иде инде.

Тагын ни сорашкандыр, ни сөйләшкәннәрдер — Зөлфә хәтеренә сеңдерә алмады: ул үзен әллә кайда төптә, тирән упкын эчендә калгандай тойган иде.

Палатадан чыгып китәр алдыннан Фуат хәлсез, әмма гаҗәп кайнар кулын Зөлфәнең беләгенә салып:

— Бик рәхмәт килүеңә, Зөлфә,— дип пышылдады.— Син дә әйбәт теләктә булсаң, тиз терелермен... Теләрсеңме?

Зөлфәнең күз төпләренә бөрчек-бөрчек яшь бәреп чыккан иде.

— Теләрмен, Фуат... абый...

Юк, Акбалыкка бүтән бармады ул, барырга теләмәде. Бәхетенә, менә шушылай ук җәйге ялы килеп җиткән иде — химиклар каласыннан тизрәк ычкыну ягын карады.

Ялыннан әйләнеп кайткач, ишетте: Фуатны Акбалык больницасыннан, туганнарына, дус-ишләренә дә якын булыр, үзенә дә җиңелрәккә килер дип, химикларның үз стационарларына кайтарганнар икән, егет тиз үк сәламәтләнеп килә, инде чыгып йөри, кәефе дә әйбәт, ди. «Болай булгач, фестивальдәге хәлләрне барып текмә-тек сөйлим әле үзенә. Сузуда, яшереп йөрүдә мәгънә юк. Тикмәгә өметләнеп ятмасын, инде үз хәлендә, ди, бит»,— дип уйлады Зөлфә. Күчтәнәчкә Кукмарадан әнисе биреп җибәргән бал белән карлыган вареньесы да бар...

Көзнең ямьсез-шыксыз бер көне иде. Ачы җилдә вак иләктән яңгыр берөзлексез сибәли иде.

Больницада плащын салып, өстен-башын рәткә китергәч, халат соравына каршы санитарка апа аңа:

— Ашыкма, аз гына сабыр ит, сеңелкәш. Ул егет янына синдәй бер чибәр килде инде... Әнә торалар,— диде.

Зөлфә ни күрсен: коридорда тәрәзә каршысында кулбашлары ак ураулы Фуат янында, аңа иңгә-иң орынып дигәндәй, берәү басып тора. Тигез, матур балтырлы, чем-кара күпергән чәчле. Ак халатын да болай гына, иңбашларына гына элгән. Тукта, чегән кызларыдай үтә чибәр Асия лабаса бу! Кызый озын-нәзек имән бармагы белән тәрәзә пыяласына нидер язып азаплана, ә тегесе, егет үзе, сәер генә елмаеп, баш селкә-селкә аның язганнарын укып тора.

«Ах, үзенә ия табылган да икән!» дигән уйдан Зөлфәнең күкрәк эчендә нидер чатнап алды. Ачыну да, куану да түгел, әллә ни...

— Менә, зинһар, Шәйморатовка тапшырырсыз әле, апа... Кемнән икәнен әйтмәсәгез дә була,— дип, кучтәнәчен санитаркага тоттырды да, плащын да киеп тормастан, кире ачы җил һәм поскак яңгыр кочагына атылды Зөлфә...

Егет аулакта туры килмәде, кыз булдыра алмады...

Әчтәге, күңелендәге серләрдән күбенеп китүең ихтимал иде. Ике-өч көн үткәч тә, бушанды ул. Әмма егетнең үзенә түгел, сеңелесе Сәриягә сөйләде. Абыйсын янә бер күңелсез һәм авыр хәлгә төшерәсе килмәгәндер Сәриянең дә. Ләкин ул дусты Зөлфәнең дә хәлен аңлады.

— Нишләтәсең, мәхәббәттә көчләү юк инде ул. Үзем аңлатырмын. Ә син курыкма: синдәгедәй, миндәгедәй генә ныклык бар абыйда,— диде.

Соңрак шул ук Сәриядән ишетте: Зөлфә илткән бал белән варенье банкаларын Фуат тегендә палата форточкасыннан бакчага корыган кычыткан арасына тондырган, ди.

Уфтанырлыгың да бар шул...

...Революция тавы әллә кайчан артта калган иде инде. Зөлфә моңарчы һич аягы басмаган соргылт-яшел чирәмле әллә нинди урамга килеп кергән иде. Менә ул тагын да аулаграк тыкрыкка борылды... Чү, якында гына шаулатып туп тибәләр. Стадион тыкрыгы ич бу! Мингерәүләнгән башы менә кая китереп җиткергән. Анда, стадионда чабып йөргән җилкуарлар арасында, Фуат белән Марсның да булуы ихтимал бит. Юк, юк!..

Җәһәт кенә кире борылды.

Ап-аяз күктә кояш кызарып баюга таба юл тоткан. Көзнең әчпошыргыч алтын кояшы...

Зәбир хакында күңелен борчыган хәсрәтен кемгә сөйләсен? Хезмәттәше Ривагамы? Әмма ул үзе дә тол, үзенең дә хәле хәл, аның юньлебашлы киңәш әйтүе икеле... Дусты Сәриягәме! Тагын җебегәнлектә, пешмәгән бәлеш булуында гаепләп, каһкаһәләп көлмәсме? Ә бәлкем аңлар? Әйе: «Ераграк берәр сәфәргә китәсе итсәң, әйтерсең әле: безнең Альбертка юньлерәк кием-салым туры килмәсме?» дигән иде бит әле ул.

Автобуска утырып, шәһәрнең Чулман якасындагы яңа өлешенә китте.

Менә ул чамасыз олы кап сыман биш катлы таш йорт. Иң биектә аларның балконы... һо, балконга Сәрия үзе чыкты — димәк, өйдә... Чуар халаты астыннан көмәне әллә каян беленә. Зөлфәнең күңел сердәше инде икенче нарасыен көтә... Бу якка күз салмады да, кулындагы чүпрәген бауга элде дә кире кереп китте. Зөлфәнең хәлен аңлар ул, аңларга тиешле!

Зөлфә капыл тукталды: йортның икенче башыннан кинәт калкып чыгып, уң кулын хәтәр селкә-селкә, сукмактан болай таба Фуат килә иде.

Әлбәттә, ул да сеңелесе Сәрияләргәдер. Зөлфәне күрергә өлгермәде кебек.

Кыз ялт кына янәшәдәге болдыр ишеге артына сеңде: «Фуатның үтергеч-яндыргыч карашы... Юк, кирәкмәс, кирәкмәс!..»

## 6

Киң күңелле Ленинград каласы бу көнне химикларга үзенең иң зур, иң әйбәт тамаша урынын — өр-яңа «Октябрьский» концерт залын биргән иде. Юбилейның тантаналы беренче кичәсенә моннан да зуррак, моннан да күркәмрәк игътибар булуы мөмкинме соң?

Тик менә һава гына, хәерсез, әле һаман айнып, әйбәтләнеп китә алмый, әле һаман тотрыксызлануда иде.

Иртәнге якта көн ярыйсы иде, хәтта аз гына сындырып, йомшартып җибәргән кебек иде. Күк гөмбәзендә төньяк-көнбатыш юнәлештән агылган сәләмә болытлар арасыннан мәшһүр кала йөзенә, алтын нурлары белән ягымлы елмаеп, ара-тирә кояш карап куйгалый иде. Өченче көнге шикелле, болытлар тыгызлана, ямьсез булып куера төште, җил дә көчәйде, саргайган агач яфракларын себереп-очыртып, «җен туен уйнарга» кереште. Ул да түгел, ачы һәм зәһәр җилдә кыеклатып, шәһәрнең чибәр йөзенә шыксыз, салкын янгыр да сыдырып-сыдырып алгалады. Нишлисең, көз шул бу, көз — Ленинград көзе...

Съездның тантаналы ачылуы көндезге сәгать өчкә билгеләнгән иде.

Госман Әхмеров, әлеге билгеләнгән вакытка ярты сәгать чамасы калып килгәндә, ике урам кушылган чат башыннан «Октябрьский» концерт залына сокланып карап тора иде инде. Заманча гаҗәеп җиңел конструкцияләрдән корылган мәһабәт бина көләч йөзе белән сине ерактан ук үзенә тарта, пыяла һәм алюминийдан эшләнгән иркен ишек-канатларын ачып җибәреп, тизрәк эчкә үтәргә чакыра сыман иде.

Ләкин Госман соклангыч бина эченә кереп чумарга ашыкмады. Ул, мәйдан аша үтеп, бинаның яссы һәм шоп-шома гранит баскычыннан күтәрелде дә, берәр кеше көткән кыяфәт белән, тәмәке пыскыта-пыскыта, әрле-бирле йөренергә кереште.

Уң тарафтан да, сул тарафтан да кешеләр тоташ ташкын булып бинага табан агыла да агыла. Юеш асфальттан выжлатып җиңел автомобильләр, автобуслар килеп туктый. Боларның хәрәкәте бер мизгелгә дә өзелмәстер, һич бетмәстер кебек.

«Октябрьский» концерт залы эченә үтсәң, тагын да күркәмрәк, тагын да ямьлерәк икән. Кая гына карашыңны төбәмә, һәр нәрсә күз явын алырлык затлы-зиннәтле әйберләрдән гаҗәеп пөхтә һәм нәфис итеп эшләнгән. Бинаның көн яктысы белән нурландырылган иркен вестибюль-фойеларында шома, ялтыравык идәнгә аяк басып атлап китүеңә үк, күңелнең, рәхәт кытыкланып, ниндидер саф, йомшак дулкыннарда тирбәлә башлавын аермачык тоясың.

Халык байтак җыелган иде инде. Йөзләгән-меңләгән кеше... Залларга зур тантана алдының тыелгысыз шау-шуы, гөрелтесе тулган, халык арасыннан ерып үткән-сүткән чакларда, әледән-әле чит-ят авазлар, сәер янгырашлы сүзләр колакны чыңлатып ала. Шулай булмый ни: съездга ике меңләп делегат сайланган һәм шул тикле үк кунак чакырылган, ди.

Госман, сөйләшкәләп торырга берәр якташ очрамасмы дип, тегендә барып сугылгалады, монда килеп караштыргалады. Ләкин бу хәтле халык арасында берәр танышына юлыгуы ай-һай ла!

Ә мәһабәт сарай эчендә халык ишәйгәннән-ишәя торды. Госман буыны — урта яшьтәгеләр дә байтак, хәтта аңардан шактый яшьрәкләр дә аз күренми. Ләкин, бик тә табигый, съездга җыелганнарның күпче-

әлеге өлкән яшьтәгеләр иде. Һәм нәкъ менә шуларның — химия дөньясында җан аямый чәч агарткан акыл ияләренең — сабыр рухы, мөхтәрәм олылыгы һәм үзара итагатьле мөнәсәбәте хакимлек итә, тантаналы мәҗлес һавасына ук үзенчә күркәм бизәкләр бирә, ямь-нур өсти иде.

Тукта әле, залның аргы башыннан болай таба олы гәүдәсен төз-туры тотарга тырышыбрак һәм шома идәнгә салмак-салмак баскалап, академик Вольфкович килә түгелме соң? Әйе, нәкъ үзе. Госманны таныр микән?

Язын, март аенда, Мәскәүгә баш инженерларның һәм үзәк лаборатория җитәкчеләренең зур киңәшмәсенә чакырылгач, килгән халык алдында бүтән белгечләр белән рәттән академик Вольфкович та чыгыш ясаган иде. Ил куләмендә төрле минераль ашламалар җитештерүгә бик зур өлеш керткән һәм химиянең бу тармагында «ата» саналган олы галимне алар колак торгызып тирән кызыксыну белән тыңладылар. Госманга академикның үз-үзен тотышындагы артык гадилеге, тыйнаклыгы аерата ошап куйды, һәм ул «ятып калганчы атып кал» дип, җене котырып, тегене бушрак һәм аулаграк бер мәлендә «эләктереп» тә алды. Госманның киңәш-табыш дигәне, әлеге дә баягы, җир астындагы тозлы эремәләрдән халык хуҗалыгы ихтыяҗларына ярардай нәрсәләрне җитештерү-хәзерләү проблемасына карый иде.

Вольфкович аны, башын кыңгыр салыбрак һәм калын чал кашларын куша язып, зур дикъкать белән тыңлады да:

— Бик дөрес, сөеклем! Безнең фәннең бу тармагында да колач иңли алмаслык перспективалар ачыла... Сез, сөеклем, дәрт-сәләтегезне шушыңарга багышлыйсыз икән, гомергә дә үкенмәссез. Ихлас күңелдән киңәш итәм,— диде.

Ә инде Чулман заводы шартларында эзләнү-тикшерүләр өчен генә түгел, ирешелгән нәтиҗәләрне турыдан-туры производствода сынап карау өчен дә зур уңайлыклар булуын ишеткәч, карт галим бөтенләй кабынып китте:

— Соң, шулай булгач! Һич кичектермәгез, хәзердән үк тотыныгыз! Алай-болай кыенлыкларга юлыксагыз, конкрет булышу кирәксә, рәхим итәсез, мин көчемнән килгән ярдәмне күрсәтергә тырышырмын.

Әнә шулай карт башы белән дә җанына яшьләрчә ялкын өрдереп җилкендергән иде ул Госманны...

Академик таныды сыман: Госманның сәламенә җавап йөзеннән гәүдәсен аз гына бөгә төшеп һәм күңелле баш кагып үтеп китте. Танымаса да гаеп түгел: химикларның Менделеев исемендәге Бөтенсоюз җәмгыятенә баш булып утырган зур галим Вольфковичка Госман ишеләр аз мөрәҗәгать итәдерме? Җитмәсә, кырыкмаса-кырык төрле комиссияләргә катнаша, ди, аларында да кемнәр белән генә эш итми торгандыр. Менә монда, шушы съездны оештыру комитетында да Вольфкович уртага җигелгәннәрнең берсе. Бу яшенә җиткәч, дәрт-дәрман дигәне каян килә, барына да ничек өлгерә алгандыр инде. Академик булсаң, шулайдыр, ахры: бар булган гыйлемең өстенә кырыкмаса-кырыкка ярыла белү гыйлемен дә үзләштерү кирәктер...

Госман күз кырые белән генә бер мәл тегене күзәтеп торды.

Вольфкович үзе шикелле чал чәчле, әмма югарак, озынчарак гәүдәле ике чибәр генә карт янына җитеп туктады да, тегеләр белән кул кысышып алгач, бик тә күләчләнеп, нидер сөйләргә-аңлатырга керешге. Тегеләрнең дә күкрәкләрендә депутат значогы белән берәр-икешәр лауреат медальләре ялтырый иде. Мөгаен, фән дөньясында зурдан казанган академиклардыр әле.

Озын, киң фойеның баш-башларында китап сату оештырылган иде. Күпләр шунда ябырылган. Госман да килеп кысылды. Шунда, ни күрсен: өстәлгә җәеп салган китаплар арасында бик тә кыйммәтле, бик тә

кирәкле кулланма әдәбият та тулып ята иде. Ах итте. Алтын бәһасе торырдай бу китапларны кочагыңа сыйган кадәр сайлап аласы иде дә кана... Шушындый тантаналы бәйрәм кичендә, шушы зиннәтле сарайда ничек күтәреп йөрмәк кирәк аларны? Юк, бетмәстер әле, иртәгә, иртәгә...

Бу минутта Госман әлеге байлыкның бик күп өлеше инде иртәгәгә калмаячагын һич тә күңеленә китермәгән иде. Аның ирен чәйнәп үкенәселәре алда иде әле. Хәер, җебегәнлектән бигрәк, тәҗрибәсезлек хикмәтедер: Госман шушындый зур җыеннарга йөреп шомарган бәндәмени?

Китап өстәлләре яныннан көрсенеп читләшергә иткәндә генә Госман берәүнең:

— О-о, сэ экселән! [1] — дип, тел шартлатып, пышылдавын ишетеп алды.

Борыла төшеп, җилкә аша күз салса, янәшәдә ирле-хатынлы берәүләр баскан. Инглизләр, ахрысы, юк, французлар кебек: татарчага бик тә якын борын авазлары һәм нечкә, йомшак сузыклар белән аз гына көйләгән сыман сөйләшәләр. Алларында, өстәл читендә — зур альбом. Аның бер битен ачкан саен, мадам белән мсье икесе беравыздан янә:

— О, сэ ориҗиналемаң! А ма гранд сюрприз! — дия-дия, ялтырап, нурлар чәчеп ачылган сурәтнең шоп-шома читләреннән бармакларын йөрткәләп алалар иде.

Инде шактый олы яшьләрендәге бу парлы кунакны данлы кала күренешләре бер җилкендерсә, альбомның искитмәле һәйбәт эшләнүе икенчеләй сокландыра иде шикелле. Дөнья меридианнарын аз гизмәгәннәрдер болар, алай да... «Сезнең Париж гынамы? Менә көн генә бераз ачыла төшсен, безнең Ленинград каласында барын да үз күзегез белән күреп, хәйран хәлләрдә акылыгызны җуеп йөрерсез әле бер»,— дип, күңеле бик тә хушланып, үзалдына мыштым гына көлемсерәде Госман.— Ә инде кәгазенең шәплегенә исегез китсә... Анысы инде, анысы... Әйе, дөньяга тел шартлатып сокланырдай кәгазь тусын өчен, иң һәйбәт бланфиксны әллә кайда түгел, нәкъ менә безнең Чулман ярларында, ерак-еракларда, сез белмәгән, сез ишетмәгән борынгы заводта җитештерәләр дә инде. Ә бәлкем, ул завод хакында ишеткәнегез дә бардыр, хөрмәтле мсье белән мадам? Моннан бик күп әүвәл, теге гасырга бу гасыр ялганган чакта ук әле, безнең завод, сезнең Париж хәтле Парижыгызга үрелеп, үзендә эшләп чыгарылган продукциянең шәплеге белән дөнья күләм күргәзмәдә Алтын медаль яулап алган ич».

Госман борын чөяргә, мактанырга әвәс кешеләрдән булмаса да, күр, юк кына сәбәптән һавалы бер горурлык белән әнә нindирәк уй-хис дулкынына чумып алды. Ә нигә, аз гына һаваланса, мактанса да, хакы бар: чын дөресе шулай лабаса...

Альбомның бик тиз арада сатылып бетәчәге көн кебек ачык иде: әнә бит чит-ят илләрдән килгән халык аңа ничек ябырылган — өстәлнең теге башындарак каратут йөзле әллә һиндлылар, әллә гарәпләр сатучы кыз алдында һавада кул уйнаткалап, ишарәләп азаплана, ә мондарак французлар, немецлар («Битте, битте шён, фрауләйн!» — боларын Госман шундук аңлап алды), тагы әллә кемнәр...

Үзе дә абайламастан, әлеге парлы француз кунакларына ияргәндәй вәкарьле генә ым каккалап һәм йомшак-төче тавыш белән Госман да сатучы туташтан альбомны матурлап төреп бирүен үтенде.

Бик тә зур эшне булдырган кеше кыяфәтендә канәгатьләнеп, уч төбенә йөткергәли-йөткергәли, берәзлексез кайнашкан халык арасына янә

---

[1] Гаҗәеп, искитмәле *(французча)*.

ысылырга китеп барган чагында, Госман, һич көтмәгәндә, профессор Гыйлем Камай белән йөзгә-йөз бәрелешә язды.

— Һо, Әхмеров! Кем... Госман энекәш! — дип, ягымлы күкрәк тавышы белән гөрләп алды профессор һәм, жылы туганлык-якынлык хисләен аермачык сиздереп, Госманның кулын бер мәл ычкындырмыйча орды.— Я, дускай, сөйлә, хәлләрең ничек? Кәефләр шәпме?

— Шәп, Гыйлем ага... Әкәмәт!

— Молодец, алайса... Ә мин, Госман энем, синең дә безнең делегациягә эләгүеңне ишеткәч, чын-чынлап куандым. Ихлас!

Беравык шулай күңелле генә хәл-әхвәл сорашкалап, тегесе-монысы турында сөйләшеп алгач, Гыйлем Камай әйләнә-тирәсенә күз йөртәйөртә:

— Ә бина гажәеп,— дип баш селеккәләп торды.— Моның тамаша залында акустика искитмәле, ди, архитекторларга бүгенге көннең иң кыллы киңәшчесе электроника булышлык күрсәткән, ди. Дөньяда иң әйбәт концерт залларыннан исәпләнә икән бу хәзер. Фән, техника, уганкай!

— Бүген азакта зур концерт буласы бит. Тәмләп карарбыз, Гыйлем ага... Концертка Аркадий Райкин да катнашачак, имеш.

— Әйе, Райкин... Монда, бик беләсең килсә, сәнгатьнең иң атаклы осталары атлыгып кына тора, шушында чыгыш ясауны үзе өчен зур бәхеткә саный, ди.

— Октябрь юбилеена Ленинград халкы өчен менә дигән бүләк булган шул бу.

— Искитмәле!

Профессор, гәпне капыл гына съезд хәлләренә күчереп, сорап куйды:

— Син программа белән таныштыр бит?

— Әлбәттә.

— Мин үзем бу съездда нинди дә булса зур ачыш турында хәбәр ителер дип өметләнмим. Алай да докладларда кызыклы фикерләр, дулкынландыргыч сүзләр аз булмастыр. Ни дисәң дә, безнең алда фәннең китлары чыгып сөйләячәк бит, аннан килеп, төрле министрлар... Алар инде, үзең дә беләсең, чүп белән башны катырмаслардыр, шәт, ә?

— Кем белә бит. Тыңлап карарбыз!

— Ах сине, энекәш! Син әле аз гына скептик та икәнсең! — Гыйлем Камай гәүдәсен шактый арткарак ташлап, янә бер рәхәтләнеп көлеп алды.— Әмма шунысы да бар: кайчакны шушындый жыенга килеп, өйдә ел буе күз дөмектереп укыганнан да күбрәк белеп, ишетеп кайтасың. Димәк ки, йоклап уздырмыйча, барын да күңеленә дә, миенә дә сеңдерергә тырышып утыру әйбәт булыр, дим. Дөресме?

— Әлбәттә, Гыйлем ага,— диде Госман, профессорның беркатлырак киңәш-нәсыйхәтенә елмаеп.

Ул да түгел, профессор халык арасында берәр танышын күреп алды, ахрысы, Госманның терсәгенә ипле генә орынды да:

— Ярый, Госман энекәш, әле күрешкәләрбез, сөйләшкәләрбез... Яратам синдәй яшьләрне! Тик үзең читләшмә, ямә! — дип, көләчләнеп ым какты.

— Читләшмәм, Гыйлем ага.

Бер мизгелдән профессорның тап-такыр шома башы ыгы-зыгы килгән халык арасында күренмәс үк булды.

Госман мөхтәрәм якташы белән аз гына сөйләшеп алудан да күңеленә чамасыз жиңеллек һәм рәхәтлек дулкыны җәелүен тойды. Нинди сихри көчкә ия бу профессор Гыйлем Камай? Күңеле кояш нурыдай саф һәм жылы булганга мы?

Госман әкрен генә залны әйләнергә керешә.

## 7

Сәхнә түрендә даһи галимнең зур портреты.

Рәсемнең түбәнге өлеше гөлчәчәкләргә күмелгән.

Сәхнәнең алгы өлешендә өстәлсез-нисез генә рәт-рәт тезелешкән шома, ялтыравык урындыкларга президиум кереп утырышты. Академиклар, министрлар, Ленин каласының җитәкче кешеләре...

Залда тынлык урнашты. Басынкы тантаналы тынлык.

Сәхнә түрендә Менделеев акыллы күзләрен зур ачып, уйчан карашын каядыр читкә, еракка төбәгән. Әмма, бөек зиһен иясе нурлы карашын читкә, еракка төбәсә дә, җитди киеренкелектә колак сагайтып, залны тыңларга җыенган сыман иде.

Академик Кириллин салмак тавыш белән, залдагы тынлыкны тирбәлдереп, үзенең кереш сүзен башлады.

...Госман инде хәзер тынычлана төшкән, күңелен баягы шөбһәле уңайсызлану-ятсыну тойгылары бимазаламый иде. Ул хәзер сәхнәдән яңгыраган сүзләрне зур игътибар, тирән дикъкать белән тыңларга тиешле иде, һәм ул шулай итәргә, чын-чынлап колак сагайтырга тырышып утыра да иде.

Ләкин — аптырамаслык та түгел — кайчакны күңел дигәнең ихтыяр көчен күрсәткән ерганактан да тыныч һәм иппле генә агып китәргә бик үк теләми икән. Госманның җанында хәзер бөтенләй бүтән төрле дулкыннар күтәрелеп айкалырга, зиһенендә моңарчы һич көтелмәгән уйфикерләр кайнашырга керешкән иде. Шуңа күрә залда яңгыраган бик күп сүзләр, кайчакны үтә кызык, үтә әһәмиятле фикерләр дә Госманның колак төбендә әллә тоткарланмыйча, аңына барып җитмичә, узып кына китәләр иде.

Залда Үзәк Комитетның котлау сүзләре яңгыраганда, съезд, дәррәү кубып, аягүрә басты — һаваны бер мәл салмак, әмма куәтле алкышлар тетрәтеп торды.

Ә сәхнә түреннән Дмитрий Иванович, һаман да карашын ерак киңлекләргә төбәгән хәлдә, тыңлавын гына белә, чалым-кыяфәте һич үзгәрми. Юк, дәррәү алкышлар купкач, йөз чалымын җылы яктылык нуры балкытып узды шикелле. Әчтән, күкрәк түреннән тулышып күтәрелгән куанычның яшерен бер дулкыны сыман...

Татлы-баллы сүзләре күбрәк булганга күрә микән, съездны оештыру комитеты җитәкчесе академик Семенов сөйләгән чагында, даһиның йөзкыяфәтендә әлеге куану-балку нурларына аз гына көлемсерәү чалымы да кушылды кебек. «Күкләргә алай ук чөймәсәң дә ярар иде, энекәш! Алла да түгел, пәйгамбәр дә түгел, заманасында, нәкъ менә сезнең шикелле үк, гап-гади кеше иде, аның кыйналу-җәберсетелүләрен дә аз татымады ла бабакаегыз!» димәде микән ул?

Әмма Ленинград университеты профессоры Щукарев һәм аның соңында академик Флеров докладларын тыңлаганда инде, Дмитрий Иванович янә җитди уйчанлыкка чумып, колак сагайткан, аның хәттә кин, ачык мангаенда җыерчыклар да ишәйгән сымак иде. Инде сүз нәкъ менә аның бөек хезмәте, химия дөньясында, юк, фәннең бик күп тармакларында да революциягә китергән даһи ачышы турында бара иде. «Ягез, я, тагынниләр булды, тагын ни белән сөендермәкчесез? Бик әйбәт, бик дөрес, дусларым: фәндә эзләнү-ачышларның чиге бер кайчан да булмаячак...»

Химия... Табигатьнең серле могҗизалар дөньясы...

Андагы ачышлар, анда ирешелгән казанышлар. Соңгы еллардагы зур сикереш...

Җир йөзендәге халыклар хәленә аның йогынтысы азмы әллә? Тормышның җиңеләюе. Яңару, яшәрү... Аерата үзебезнең Туган илдә. Монда һәркем үз яшәешендә дә көн саен, адым саен сизәдер ләбаса. Ә кила-

чәктә, хәтта иртәгә-берсекөнгә, химия тагы нинди могҗизалар тудырмас, дисең!

Менделеев үз гомерендә нибары элементларның периодик законын — бу бөек, революцион ачышын гына иҗат иткән булса да, аның исеме фән һәм халыклар теленнән мәңге төшмәс иде, әлбәттә. Ләкин, даһи акыл шуңа күрә даһи дадыр инде, ул химия фәненең кайсы гына тармагына күз салмаган да анда, төпле уй-фикерләр йөртеп, зур ачышлар ясамаган. Юк, андый зур ачышлар һәм андый титаник эшчәнлек турында Госман хәтта хыяллана да алмый — моңа тик сокланырга һәм гаҗәпләнергә генә мөмкин.

Госманны шунысы җилкендерә һәм куандыра иде. Менделеев сирәк очрый торган даһи акылга гына түгел, бәлки зур ихтыяр көченә дә ия булган, күкрәгендә янган ут-ялкынны һичкайчан, тәмам хәлдән таеп, җан биргәнче, сүндермәгән-сүрелдермәгән. Әнә ул Баку нефтен өйрәнгән чагында, аны чагыштыру максатында ялыкмый-нитми Америка хәтле Америка җирләренә аяк басып, Пенсильвания нефтен дә тикшереп-белеп кайта. Илле өч яшендә кояш тотылган бер көнне, һаваның югарыгы катламындагы газлар хасиятен тикшерү өчен, егетләрчә кыюлык-батырлык күрсәтеп, аэростатка күтәрелә. Ә гомеренең ахыргы өлеше якынлашып килгән бер чакны Чулман ярларында утырган Ушков заводына озын-озак сәфәргә юл тотуы? Кая монда ирену-нитү?! Ялкынланып үзенә махсус лаборатория кордыра һәм төтенсез дарыны уйлап та таба, эшләп тә чыгара! Бу соңгысы белән бөек галим ачышларны фән үзәкләрендә, зур калаларда гына түгел, бәлки сәләтең һәм тырышлыгың җитәрлек булганда, ерак провинциядә, «җәһәннәм тишегендә» гап-гади завод шартларында да эшләргә мөмкин икәнлеген исбат итеп күрсәтә. Монысы инде Госман кебекләр өчен үтә кызыклы да, гыйбрәтле дә...

Чулман заводының баш инженеры Иван Семеныч еш кына үзен буразна атына тиңли. Бик тә сәер. Битарафлык-гамьсезлекме бу? Әллә бүтән берәр сыйфатның чагылышымы? Камчылаудан куркып, кемнеңдер әмер-фәрманы белән генә буразна ерту... Ләкин кем һәм ни хакына? Буразна атының моңарда гаме булганы бармы? Ә бит кеше...

Юк, Госман буразна аты түгел, ул фәндә үз тармагының гади бер солдаты. Дөрес, ул зур ачышларга исәп тотмый, чөнки ходай биргәне бик тә чамалы. Әмма аның да яулап алынырга тиешле үз үрләре, үз биеклекләре бар, күкрәгендә куәтле типкән утлы йөрәге бар. Әйе, Госман да үзенең бар булган сәләтен, көчен-тырышлыгын җигәчәк һәм үз максатларына һичшиксез ирешәчәк! Димәк ки, һаман да һөҗүмдә, атакада булырга кирәк, һаман да җан аямый эшләргә, эшләргә!..

Тәнәфес игълан ителде. Ләкин халык урыныннан купмады: залны тутырып музыка яңгырый башлады. Бөек галим Менделеев яраткан музыка: үлемсез Бетховенның илаһи аппасионатасы...

Съезд рухына гаҗәеп тә кулай һәм хуш килде, бигрәк тә Госманның җанына һич көтелмәгән татлы һәм куандыргыч азык булды бу.

...Фойеда Госман янә Гыйлем Камай белән очрашты. Ләкин монысында профессор үзе генә түгел иде, ул Харьковтан килгән доктор Нур Сафиуллинны култыклап алган иде. Шушындый да җирдә өч якташ очрашса, авызлар ерылмыйммы соң!

— Саумысыз, Нур Шәфигуллович! Каефләр изгеме, ал да гөлме?

— Изге, туган... Үзеңдә соң?

Сафиуллин шактый ук бирешкән кебек. Моннан дүрт-биш ел әүвәл Госман диссертациясенә өстәмә материаллар туплау нияте белән Харьковка барып чыккан иде һәм анда Сафиуллиннан киңәш-табыш алып утырганда, абзыйның җитен чәчләрендә энҗе бөртекләрен күрмәгән дә иде, ә хәзер бөтенләй бәсәргән ич бу! Әмма коңгырт күзләре әүвәлгечә җитез үткенләнеп һәм сынаулы сөзеп карыйлар иде.

Икесе дә болгар-татар йортының Иделгә Чулман кушылган чатыннан килеп, фән дөньясында зур абруй-дәрәҗә яулаган галимнәр. Берсе — Гыйлем Камай — гомумән, химия фәнендә татарның беренче профессоры булса, Нур Сафиуллин химиянең ТНВ[1] тармагында беренче доктор. Тик менә Госман гына... Ә нигә, Госман да үз туган авылы Мортның беренче һәм әлегә бердәнбер фән кандидаты лабаса!

Янә халык арасына кысылып, тегесе-монысы хакында күңелле генә сүз алмашкалап йөргән бер мәлне Нур Сафиуллин, әйләнә-тирәләрендә шактый еш яңгыраган сәер, ят авазлар тәэсирендә, ахры, капыл гына:

— Якташлар, әйтегезче: үзебезнең халыктан без ничәү соң әле монда? — дип сорап куйды.

— Безме? Казан делегациясендә без дүртме-бишме татар. Сине дә кушсак, Нур Шәфигуллович... хәзер, ашыкма...— Гыйлем Камай атлаган җирендә туктады да беркатлыланып, әмма бик тә җитди кыяфәттә белгән кешеләрнең исемнәрен әйтә-әйтә, бармак бөгәргә тотынды. Бер кулы тулгач, икенчесенә күчте.

— Ә теге кем... Новосибирскидагы академик егетебез? Ул да, бәлки, мондадыр?

— Әйтә алмыйм. Танымыйм шул мин аны, гәзиттә бер тапкыр сурәтен генә күргәнем булды. Алай-болай президиумда утырмады микән?

— Утырса да, гаҗәпләнерлегең юк. Тик бик яшь диләр бит үзен. Менә Госман дус тирәләре, ахры.

— Ә тагын кемнәр юктыр дисез? Без белмәгән, без ишетмәгән, ә? Үзебезнең химия фәненә эз сала башлаганнарны гына әйтәм әле мин...— Гыйлем Камай тирән итеп сулап куйды.— Ниһаять, килде, җитте заманалар!.. Әле бая соңгы докладны тыңлаганда уйлап утырдым. Бөек Менделеев, Бутлеров кебек корифейлар, җиң сызганып, зур ачышлар ясаган бер дәвердә, йөз ел әүвәл генә әле, безнең татарда ни булган да ни көтелгән? Кара урманның да дөм караңгысында адашкандай, ачлыктан, бетмәс золымнардан җәфа чиккән, наданлыктан интеккән мескен бер халык... Юк, мескен үк түгел түгелен. Кыю да, тырыш та, фидакарь дә халык... Әмма, гафу итәсез, шул караңгылык, наданлык сөреме эчендә дә һәр яктылык нурын дошман итеп, ана кылыч-балта чабучылар көн саен туып кына торган лабаса! Җәл безнең бабайлар, бик тә җәл! Сон Дмитрий Иванович үзенең әлеге даһи ачышын ясаган дәвердә безнең караңгы татар күгендә янар йолдыз булып кабынган кемнәрне әйтә аласыз? Хәлфиннәр, Шиһап Мәрҗани, Фәезхановлар диярсең инде... Ә безнең үз фәнебез дөньясында? Бердәнбер Каюм Насыйри түгелме?

— Әйе, аны бердәнбер дисәк тә, зур хата булмастыр,— дип ияк какты Нур Сафиуллин.— Ә бит аның да хыялында...

Каюм Насыйри... Йөз ел әүвәл...

Әмма бу мизгелдә Госман Әхмеровның уй-хәтере алай ераккa, бер гасыр ук артка чигенмәде. Аның күз алдыннан капыл гына үз этисенең шәүләсе узып киткәндәй булды.

Нибары чирек гасыр гына элгәре... Тап шушында, Ленин каласы төбендә, дәһшәтле ут эчендә данлы шәһәрне явыз илбасарлардан саклап яткан чагында, аның этисе солдат Габдулла Әхмеров ерактa басу капкасы янында әнисе, апасы-сеңелесе белән бергә кайнар яшьләрен мышлтым гына агызып басып калган юеш авызлы улының кайчан да бер зур фән юлыннан ныклы адым белән атлап китәсенә өмет тотты микән, андый хәлне хыялына китерә алдымы икән һәм улының нәкъ менә алар саклап калган данлы калага олы бер съездга делегат сыйфатында

[1] ТНВ — (*технология неорганических веществ*) — органик булмаган матдәләр технологиясе.

илэсен, ичмасам, төшендә генә булса да күрү бәхетенә ирешә микән? Эктыр, ул заманда ут эчендә сиңа... Әллә...

Һаман да хәтерендә Госманның: сугышка чыгып китәр алдыннан ына әтисе, аны үз янына дәшеп, беравык сөйләшеп алган иде. Өр-яңа иләренең әле ясалып та бетмәгән өр-яңа болдырына утырышканнар де алар. Шунда, азаккы сүзләре итеп, әтисе: «Ярый, бәхил бул инде, лым... Нишлисең, ут эченә керәсе дә килми, китмичә дә булмый. «Ил әхете — ир бәхете», дигәннәр шул бабайлар. Значитсы, синең, сезнең әхеткәйләр өчен дә китәм инде, яман булма, акыллы була күр инде, лым»,— дия-дия, күкрәгенә кысып, аның колагына җылы пышылдавын ргән иде. Димәк...

— Туктале, ни уфтандың әле син, Госман дус?

Госман иңбашына салынган кулның ныклыгын да, җылылыгын да ермачык тойды.

— Юк ла, болай гына, Гыйлем ага... Ни... Берәү бер вакыт: «Ил әхете — ир бәхете ул» диган, ди...

— Бик матур әйткән. Соң, андый сүз исеңә төшкәч, уфтаналармыни, некәш?... Әйдә!

Халык ашыкмый-кабаланмый, җай гына ачык ишекләрдән утырыш-ар залына агыла башлады. Җир йөзендәге дистәләгән телләрнең төрле вазлар гөрелтесенә кушылдырып, үз туган телләрендә матур сөйләшә-айраша, безнең өч агай да ул агым эчендә айкала иде.

## 8

Химиклар каласының кояш баешы ягында — җирдән калкынып күтә-елгән дүртәр-бишәр катлы игезәк таш йортлардан әллә ни ерак та үгел — дугайланып, сөзәгрәк кенә үр сузылып китә. Түбәндә исә шак-ый ук тигез һәм киң үзәнлек. Анда әле уңга, әле сулга каерылып, урыны елән талгын, урыны белән шашкын сулы Тойма агып ята. Елга да, аны очагына сыендырган киң үзәнлек тә еракта Акбалык юнәлешендә үгелҗемләнеп торган урман итәгенә орынып уза да, ерагайган саен р-калкулыклар кысрыклавында һаман да тарая-тарая, зәңгәрсу рәшә чендә, мәгърур Чулман-дәрья киңлекләре җәелгән тарафларда күк елән тоташып, күздән югала.

Бик борынгыда әлеге үр битләрендә калын нарат урманы шаулап тырган, ә түбәндә, уйсу җирләрдә исә балтасыз-нисез ерып үтә алмас-ык әрәмәләр һәм алар арасында бил тиңентен печәнле, хуш исле тугай-ар булган...

Хәзер хәл бөтенләй үзгә.

Ике-өч чакрымга сузылган үр битләре, ялап алгандай, шәп-шәрә. Ізын бередә, үр кашында, беренче булып ямь-яшел химиклар шәһәр-егенең баласы-чагасы туп тибәргә иң әүвәл шунда ябырыла. Карт-ортка да калышмый: кышның озын айларында муртайган буын-сеңер-әрен язгы кояшның шифалы нурларында җылыту һәм азрак янару, ыгу өчен, үр кашының аулаграк, шау-шусызрак төшләренә чыга. Үр-алкулык язмышында иң күңелле, иң хозур чак бу... Әмма җәй уртасы итмәс борын ук, бигрәк тә кайнар һавалы атналар тоташтан ялганып а китсә, сөзәк үр йөзе танымаслык булып үзгәрә, ул, әҗәл түшәгендә выр чәчәк зәхмәтен кичереп яткандай, көеп-саргаеп бетә, шадраланып ала.

Киң үзәнлектәге хәл дә күзгә ямь биреп, күңелне әллә ни куандыра лмый. Язгы ташу вакытында ярый әле: Тойма ташып ярларыннан ыккач, су үзәнлекнең байтак өлешенә, кай елларда үр итәкләренә үк итеп җәелә дә үзенең ялт-йолт җемелдәве, нурлы балкышы янсә чулы йөз чытулары, моңсу дулкыннары белән күңелләрне кытыклый. Ләкин бу хәл дә озакка сузылмый: бер-ике атнадан елга үз ярларына

кайта һәм үзәнлек тырналган, каезланган кара-кучкыл йөзе белән ян калкып чыга...

...Бүген дугайланып сузылып яткан үр битендә йөзләгән, меңләгә халык.

Бөтен завод купкан.

Бүген зур өмә. Юбилей алды өмәсе...

Кулларда көрәк, чиләк, носилка. Йөзләрдә нур.

Сөзәк үр битендә парк кормакчылар, аны яшеллеккә күммәкчеләр.

Әле монда тукталгалап, әле теге очка житеп, кызу-кызу Васил Землянов йөренә. Ул партком члены, зур өмәне оештыру штабының башлыгы ул. Кай арада аңа Фәрит Бәдриев тә ияреп киткәли. Икесе д ялан баш, икесе дә янып пешкән. Барысы да жиренә житкерелеп эшләнсен, алдан уйланганча төгәл һәм матур булсын, бигрәк тә аллеялар тигез һәм килешле чыксын дип кайгырталар. Шуңа күрә аларга тыз-быз йөренмичә булмый да торгандыр.

Төп киңәшчеләр — тәжрибәле карт бакчачы Тиунов. Бусы алай кабаланмый. Берәрсе янында тукталып,— гадәттә, ул яшьрәк бер кыз була — муен артын сөртештерә-сөртештерә, аңа сабыр һәм ипле генә киңәш бирә, кайчакны картраклар янында акыл сатып та алгалый, тик әләй-вәләйрәк кыланучы берәр булдыксызны күрсә генә, бармак янап:

— Син нәрсә?! Әбиең бакчасы дип белдеңме моны?! Әллә үзең исерек, әллә утырткан агачларың исерек! — дип, тегене иптәшләре алдында кызартып китеп бара.

Күк йөзе ап-ак. Кояш инде үзенең иң югары ноктасына менеп житте кебек. Ул жәйгечә шаян һәм ягымлы елмаеп, ярыйсы гына әйбәт кыздыра. Зыңлап торган саф һавада пәрәвезләр оча. Октябрь аена кергәннәренә дә инде атнадан артык. Әбиләр чуагының азаккы көннәредер...

Һәм менә шул пәрәвез жепләре очып торган тын һавада башта әкертен, аннары торган саен куәтләнә барып, калын гөрелте авазы ишетелә башлады. Күпләр аны шундук танып алды: вертолет! Ялгышмаганнар: галәмәт зур бүксәле, озын койрыклы чикерткә корыч канат-калакларын зыр-зыр әйләндереп һәм дәвәеп, болар өстенә килеп житте дә аз гына түбәнәя төшеп, салмак кына әйләнә башлады.

Йөзләгән кеше, эшләреннән бүленеп, күккә төбәлде.

— Әнекәй генәм! Баш өстебезгә киногa төшерүчеләр килде микән әллә?

— Ә нигә, төшерсәләр дә...

Бу авазлар яңгырауга, бериш кыз-кыркын ихтыярсыздан чәч-яулыкларын төзәткәләп алды.

— Бик исләре китте, ди.

— Ахмак булмагыз, кызлар. Буровикларның вахта вертолеты гына бу.

— Шулайдыр, ниткән кырмыскалар жыйналган икән монда, бу ни гажәп бу дип, бик тә беләселәре килгәнгә күрә генә әйләнәдер алар.

— Ә бәлкем бөтенләй алай түгелдер дә... Арадан берәр чибәребезне урларга йөрмиләр микән? Чамалагыз, кызлар!

— Минедер! Мине урларга ниятләп килгәннәрдер әле! — дип, бот чапты чүмәләдәй төптән юан бер апа.

Үр буен шаулатып килгән авазлар яңгырады...

* * *

Жирдә кул изәп вертолетны сәламләгән яшь-жилкенчәк арасында чибәр кыз Асия да бар иде. Тимер кош күз күремендә эреп юкка чыккач, кыз, ис-акылына килеп, хезмәттәше Надяга эндәште:

— Әйдә, бетереп куйыйк әле монысын да... Зур булып, шәп булып үссен, миләшләре әчкелтем-татлы булсын, име?!

— Без утыртыйк та, татлы булмасын, имеш!

Әллә ни озак маташмадылар, миләш кызын тез тиңентен чокырга батырдылар да тамырларын ян-якларга рәтләштергәләгәч, кара туфрак алып, аны мул иттереп чокырга сипteләр һәм, иплэп кенә таптый-таптый, яшь агачны өр-яңа нигезенә шыплатып та куйдылар.

— Булды бу!..

Шул чакны ни күрсеннәр: утыртасы агачлар өемендә бер генә төп тә калмаган, якында казынган иптәшләре алып та бетергән. Болар тавыш куптарып тормады, тик куанычлы елмаешты гына: икәү генә утырткан агачлар да дистәдән артып киткәндер инде, бераз тын алганда да зыян итмәстер, шәт... Кагындылар-ниттеләр, чәнти бармакларын тыгып кына яулык кыегы астыннан чәчләрен рәтләделәр.

— Карале, Надечка, монда тагын агач китерерләр, аңарчы мин бер карап әйләнеп килим әле. Бүтәннәр ничегрәк эшли икән. Кызык бит.

— Кызыгын кызык та, кара аны, киткән җирендә батып ятма! Үзем дә ул арада әнә пожарниклар сиптергән суда кулны чайкап килләм дә тамак ялгап алам әле. Иртән валчык та капмаган идем, коры чәй генә...

— Әй, алдашмасана: кул гына чайкамакчы, имеш! Пожарниклар янына кемне чамалап баруыңны беләм лә мин...

— Үзең соң! Әнә теге очта, җаным, синең дә...

Асияның күңеле тыныч түгел иде. Ул баядан бирле иң аргы башта эшләүчеләрне, Надяга сиздермәскә тырышып кына, күзли иде. Тегендә ремонт-механика цехы агач утырта. Күбесе ир-ат, егетләр. Ләкин, кызый күз нурларын нихәтле генә нечкәртеп карамасын, алар арасында Фуатны абайлый алмаган иде. Әллә чыкмаганмы? Югыйсә, әле кичә кичке мәктәптән кайткан чакларында гына: «Андый да өмәгә бармасаң, яшен сугар!» — дип сайраган иде ич. Ялга каршы берәрсенә юлыгып, тагын бер-бер хәл булганмы әллә үзенә? Юк, әнә теге колгадай озын буйлы, зәңгәр беретлы иптәше Юриктан барып сорашмыйча, белешмичә, җаны тынычланмастыр, ахры...

Асияның заводта таныш-белеше аз түгел иде, әмма аннан да бигрәк, әллә каян балкып торган шул чибәрлеге аркасында, аны тагын да күбрәк халык таный да, белә дә иде. Кызый моны үзе дә бик әйбәт чамалый иде. Шул сәбәпле, ягъни тиктомалга йөренүе белән, андагы агач утыртучыларның күзенә кылчык булып кадалмас өчен, башыннан яулык кыегын суырып алды да, сумала чәчләрен аз гына тузгыта төшеп, үтә эшлекле, җитди кыяфәт белән, читләтебрәк, яшь агач үсентеләре арасыннан атлап китте.

Бераз киткәч тә адымын әкренәйтте: якында гына, үр бите буйлап аңардан бераз түбәндәрәк, үзәк лаборатория халкы чыр-чу килә. Болар матур һәм тигез иттереп юкә үсентеләрен тезеп чыкканнар — бер өлеше үзәккә таба кыеклап сузылган аллеяга да охшаган. Килештергәннәр. Ләкин боларның да утыртыр агачлары беткән, болар да урманнан яңа үсентеләр кайтканын көтәләр, ахры: кирәк, чиләк, кәрзин ише нәрсәләрен кайсы кая ташлаган да, урталыкка башлыклары Госман Әхмеровны алып, шарык-шырык көлешеп торалар. Тегесе бер кулын һавада болгаштырып, авызындагы алтын тешләрен елтырата-елтырата, ниндидер кызыклар сөйли кебек.

Асия күз карашы белән әлеге төркемне кармалап алды. Юк, арада Зөлфә күренми иде. Аны каядыр көньякка олаккан диганнәр иде, димәк, әйләнеп кайтмаган әле. Эх, шул сары ябалак Фуатның баш өстендә бөтерелмәгән булса, дуамалрак холыклы егет Асияның нәфис канатларына күптән үк сырпаланмас идемени соң?

Адымын кызулатты, ләкин бик тиздән туктап ук кала язды. Монда да аның әүвәлге хезмәттәшләре, фармакопея хатын-кызлары, мәш килеп, бәләкәй-бәләкәй ак чыршылар утыртып азаплана иде. Булачак паркның үзәк тирәсе, шушында, ахрысы. Белгәннәр аны бизәүне кемгә тапшыра-

сын! Шулай итми ни, фармакопея цехы күптәннән үк әлеге заводта бердәнбер коммунистик хезмәт цехы исемен йөрткән ләбаса... Әле кайчан гына Асия үзе дә алар арасында иде. Тукта, күрче, Вероника Борисовна үзе дә шунда икән бит. Парткомга сайланып, анда секретарь булып эшли башлавына инде ел тулып килә торгандыр, әмма шулай да әле һаман үз кешеләрен, үз коллективын онытa алмый. һаман да күнеленә якынрак тота, күрәсең. Югыйсә, аңа, партком җитәкчесенә, кайда казынса да барыбер түгелмени? Эш кызуында тир бәреп чыккан бугай, бер мизгелгә генә тураеп, кул аркасын ачык маңгаена тидергәләп алды да янә ныла-бөгелә тимер көрәге белән түгәрәк чокырдан кызгылт-көрән балчыкны ыргыткаларга керешге.

Кисәк Асияның әүвәлге хезмәттәшләренә кушылып, алар белән бергә әнә шулай тирләп-пешеп җирдә казынасы, актарынасы һәм тын алырга туктаган араларда туйганчы сайрашасы-көлешәсе килеп китте. Ни дисәң дә, бик тә күнегелгән, күңеленә бик тә якыннар иде шул... Юк, ярамый: әнә анда бер кырыйда Фуатның әнисе Рабига апа, тураеп, билен язарга азапланып маташа. О, аның күзләрен бер агартып караулары...

Ремонт-механика цехы егетләре, буй-буй сарылы-кызыллы яулык кыегын кулында ипле генә селеккәләп, терт-терт атлап килгән кызны, эшләреннән бүленеп, күтәп алдылар һәм, кызый якынлашкач, аның зәңгәр трико кигән зифа гәүдәсенә, иңнәренә сибелгән җете кара чәч толгәшләренә чиксез сокланып утлы карашларын төбәделәр. Кайсыдыр тел шартлатып та алды. Бу асыл сөякнең иясе кем икәнлеген алар бик әйбәт белә, ул егетне якын һәм үз итә, алай да беришесе кызга төбәп чәнечкеле укларын атмыйча түзә алмады:

— Каян инде әле бу фәрештәкәй?

— Асыл кош, кил әле бире, шушы өрәңгене икәүләп, бик әйбәтләп кенә утыртып куйыйк әле! Алмагач булып үсмәсме?

Асия, тигез, кара кашларын бөгеп, аларга кул гына селтәде һәм, колгадай озын буйлы Юрик янына килеп, аңа туп-туры текәлде:

— Юрик, ни... Фуат кайда? Өмәгә чыкмадымы әллә?

Монысы да, көрәк сабына таянган килеш, гәүдәсен чалышайтты да, мут көлемсерәп, кызга баштанаяк сөзеп карады.

— Ә нигә ул? Соң мин аны үзем дә бик шәп алыштыра алам ла...

Асия кырт кисте:

— Син дә теш ыржайтмасана!.. Фуат кайда дим мин сиңа?

Егет, капыл шиңеп, гәүдәсен бөтенләй икенче якка чалышайтты:

— Улмы? Ул ни... урманда ул! Урманнан безгә агачлар җибәреп тора. Әнә тегесен дә Фуатлар казып озатканнардыр.— Юрик бер читтә тукталып торган автомашинага таба ым какты. Автомашинаның әрҗәсеннән ике егет соңгы үсентеләрне җиргә биреп тора иде.— Монда иртәрәк килгән ир-атның җыенысын урманга озатканнар... Җәл, име?

— Алайса, урманда?..

Асия тынып калды, күкрәген тагы да калкуландырып, уфтанып алды һәм аз гына уйланып торганнан соң, баскан җиреннән ялт кына кубып, инде кузгала башлаган автомашинага таба элдертте. Авыз ачып торган егет, ис-аңына килеп, чәнечкеле сүзләрен сиптерә башлаганчы, кызый автомашина әрҗәсенең арткы бортына барып ябышты да бераз гына йөгергәч, гаҗәеп бер җитезлек белән селтәнеп, өскә атылды...

## 9

Юл читендәге түгәрәк аланга, агач куелыгыннан иң әүвәл, аз гына аксабрак, Мирыч килеп чыкты. Аның артыннан бүтәннәр күренде. Биш-алты кеше. Һәркайсы өчәр-дүртәр үсенте күтәргән. Алан читендә үсеп утырган карт юкә күләгәсенә байтак кына үсенте өеп-сөяп куелган иде инде. Әле чыгарганнарын да шунда китереп тезделәр.

— Тагы да шулай бер-ике керсәк, янә бер машина тулыр да, шәт,— диде Мирыч, куе төк баскан ияген сыпыргалап.— Ярар, ашыккан — ашка пешкән, ди, кабаланмыйк... Тәмәкечеләр, бер көйрәтеп алсагыз да була.

Урманга агач казырга киткәннәрнең бу төркеменә, беркем әйтмәсә дә, Мирыч баш булып алган иде. Аның тәкъдименә каршы килмәделәр. Аланның кояшлырак төшенә чыгып, бәләкәй генә зелпе куагы төбенә, йомшак үләнгә утырыштылар.

— Урманны шәп тазартабыз бүген, ә? — диде Фуат Шәйморатов, һавага төтен көлтәсе бөркеп.

— Тазартуын тазартабыз да, урман хуҗасы бәйләнмәсә ярый инде,— дип, шөбһә белдерде аның дусты Марс Абуздырин, ләкин шундук үз шөбһәсен үзе үк таратырга итте: — Бәлкем, бәйләнмәстер дә: без, ул әйткәнчә, җиренә җиткереп эшлибез кебек лә. Инде ул кушканнан юанракларын да алгалыйбыз икән, аннан гына урман бөлмәгәндер, мәгәр?

— Шулай. Алар ешлыкларны үзләре акча түләп тә чистарттыралар әле. Урманга файдага гына ул: калган хәтлесенә иркенәеп үсәргә җай,— диде Маркел Сысоев, кулын колак төбенә куеп тыңлаган хәлдә. Ул, хлорлы барий цехында ничәмә еллар инде калын барит плитәләрен авыр чүкеч белән вата-вата, аз гына саңгыраулана төшкән иде.— Менә безнең Чувашиядә ул карый беләләр урманны!

Мирыч, кырын яткан җирендә уң аягын кымшандыргалап алгач, җимерек-төксе йөз белән үги улы Фуатка төбәлде:

— Синең ничек, Фуат, калак сөягең сызлаштырмыймы?

— Юк. Аның сызламый башлавына инде биш былтыр. Хирургларга рәхмәт: әйбәт ямаганнар.

— Ә минем, җен алгыры, ранный аяк тагын сулык-сулык итә. Үтерә инде. Һава бозылыр, ахрысы.

— Һава? — Марс ап-аяз күккә күз йөртеп алды да, үтә аптыраган кыяфәттә, армийский фуражкасын баш түбәсенә үк эшереп куйды.— Соң, өмәне ике көн рәттән буласы дигәннәр иде, көн бозылса, димәк... Ох, әллә ничә мең үсенте дип лаф органнар иде бит.

— Кайгырма, һава да иртәгә үк бозылмастыр әле. Минем аяк ике-өч көн алдан хәбәр сала башлый ул.

— Хәбәрен хәбәрдер, әмма ләкин, туганкайлар, яшеллек эчендә утырсаң шәп инде ул. Калабызның эче аз-маз рәткә керде керүен, анысы ярый,— диде Маркел һәм, ике кулын да күкрәгенә салып, тирән итеп сулап куйды.— Тик әйләнә-тирәбез әле һаман да яман сугыш давылы үткән кебек ләбаса! Дөресме, Ваня?

Иренчәгрәк Иван Юрлов, җиргә капланып яткан көенчә, боларның сөйләшүенә бөтенләй гамь белгертмичә, авызыннан үлән арасына төтен җибәреп азаплана иде. Ләкин колаклары сакта булган икән: егет, авызын бөрештергән шәйгә, аз гына күтәреп торды да, бу юлында төтен белән бергә сүзләрен дә бөркеп чыгарды:

— Йөргән кызыңны кая алып барырга белми йөдисең кайчакны...

Үзалдына мыштым гына көнбагыш ярырга керешкән киң, калын җилкәле Гыйрфан да телгә килде:

— Хак сүзгә җавап юк, нәкъ өстенә басып әйттең, Ванюша. Мин үзем бер вакытны шулай...

Гыйрфан — тел бистәсе. Ул Мирычның кордашы һәм хезмәттәше, ягъни икесе бергә тара цехында мичкә ясыйлар. Аның бер ябышса, бигрәк тә хатын-кызларга бәйле мәҗараларын тезәргә тотынса, кайларга кереп китәсен бик әйбәт белгән һәм гәпнең бу сикәлтәле сукмагын бик үк өнәп бетермәгән Мирыч Гыйрфанны баштук капыл бүләргә ниятләде:

— Ашыкмачы, кордаш, анысын сөйләп бер көлдерерсең әле.

— Кәлкеме соң!.. Кызганыч хәл: якын тирәдә шул урман-куаклык булмау аркасында, Казанның үзеннән килгән яшь кенә бер апай әрәмгә китте. Мин әнә ни хакта...

— Ярар, дим, бер сөйләрсең әле... Урман турында, яшеллек турында сүз купкач, син миңа иң элек шуны әйт әле: гәҗит алдырасыңмы син? Һич югы, радио яисә телевизор тыңлаштырасыңмы, карыйсыңмы?

— Син бигрәк, Мирыч, бу заманны гәҗит тә алдырмагач...

— Алайса, күзеңә яисә колагыңа чалынмыйча калмагандыр... Завод-фабрика корам дип, дуамалланыбрак ябышсаң, бик тә аяныч хәлләрнең дә килеп чыгуы бар икән. Яман хәлләрнең... Мин сиңа һаваның, ягъни атмосфера катлавының бозылуы хакында әйтәмен. И шулай ук табигатьнең зарарлануы турысында.

— Җыеп әйткәндә, биосфера турында. Шулаймы, Мирыч?

— Менә-менә, биосфера. Рәхмәт, Марс энекәш! Узган атнаны гына телевизордан шул хакта галәмәт шәп тапшыру булган иде. Карый алдыгыз микән? Урман — яшеллек дигәнебез, ул сиңа, бар булган файдасы өстенә җир йөзенең һавасын индустрия агуыннан да тазартып, сафландырып тора икән.

— Иске авыздан яңа сүз!..

— Инде дә шул ачылды миңа: Америка, Япония кебек индустрияләре дуамал үскән бериш илләр, яшеллек дөньялары бик нык кимегәнгә күрә, кислородка хәзердән үк зур мохтаҗлык кичерәләр, ди... Үзләре эшләп чыгарган агудан үзләре үк тончыга башласын әле! Бөтен бер илең, бөтен бер дәүләтең белән шулай, ә!

— Көнбатыш Германия тагын,— дип кыстырды Сысоев.

Мирычның кучкылтрак ябык йөзендә баягы авыртыну чалымнары югалган, ул аягы сызлавын бөтенләй онытты да, ахрысы. Һәрхәлдә, эчтән нурланып балкыган кыяфәте абзыйның инде бөтенләй бүтән халәттә икәнлеген аермачык сиздерә иде. Менә ул чүгәләде, аннары үз җаен белеп кенә янтаеп утырды һәм, йомшак үләнне сөялләнеп каткан тупас бармаклары белән сыйпаштыра-тараштыра, күңелендә күптән өлгереп, күптән ныгыган уй-фикерләрен бер җепкә тезә башлады.

— Учакта янган ут-ялкынны кайсыбыз гына яратмый торгандыр. Җылысын да җылы, матурын да матур... Әмма, дускайлар, шул ялкын менә шушы чибәр урманны яларга керешсә яки анда берәр йорт-мазарны урап алса, матурмы? Дәһшәтнең дә дәһшәте!.. Ярый, андый ук куркыныч нәрсәне мисал итмик әле... Шулай басу юлыннан барасың, ди. Әйләнә-тирәдә иген кырлары. Арышмы анда, бодаймы. Инде тәмам өлгереп, пешеп житкән... Күңелләрең хушлана: хозурның да хозуры! Ярый, тагы да бер-ике атнадан шунда ук юлыктың, ди. Игеннәр һаман да алтынланып, дулкынланып тора. Әмма ләкин матурмы? Юк, ямьсезнең дә ямьсезе, күңелне әрнетә үк башлый... Ник дисәң, җыелмаган, әрәм булып ята... Кешегә файдасы булмаса, коры матурлык кына әле ул сиңа пүчтәк шул! Яки менә...

— Белмәгән идем: син, Мирыч, аз гына философ та икәнсең әле...— Моны, дустанә көлемсерәп, Марс Абуздырин әйтә куйды.

Кочкан тезләрен ычкындырып, Гыйрфан, ниһаять, кымшанып куйды һәм зәһәр көлемсерәп авызын җәйде. Аңа чеметтереп алырга җай чыкты, ахрысы...

— Матурлык дип, фәлән дип борчак сиптергән буласыз, ә үзегез җыен яман хәлләр турында, җыен афәт турында... Таптыгыз!

— Әһә, ахры, сиңа да үтте бугай! — дип кеткелдәде Мирыч, әмма шундук тавышына янә житди төсмер бирде.— Ямь-матурлык хакында уйласаң, аның теге ягын да — яман хәлләрен, афәтен дә — истән чыгарасың бармы? Мин үзем кара акылым белән шулай дим: матурлык

ул буш та, кысыр да булмасын!.. Әллә әнә анда дөнья читендәге япуннар кебек, үзең чыгарган сасыны сулап, агуланып, саргаеп яшәр идеңме?

Ул, башын аска иеп, бераз гына дәшми торды, аннары янында беркем дә юк төсле, үз күңеле белән сөйләшкәндәй, әкрен генә сөйләп китте:

— Безнең илдә көн дә саен диярлек төрле-төрле карарлар чыгып, кәгазьгә язылып тора. Ягъни әйтергә теләгәнем: хөкүмәт хезмәт иясе сыйныфының хәле, тормыш-көнкүреше яхшырсын дип тырыша. Сугышларда интеккәннәребезне истә тотуыдыр, мөгаен. Әнә шул әйбәт карарлар арасында иң әйбәте дип мин табигать дөньясын саклау хакындагы карарны әйтер иен. Югыйсәң, азмыни әле бездә кайнар башлар, үзбелдекләнеп китүчеләр? Ул белеп тора, әйтик дамбаны урман ярып түгел, бераз гына читтәнрәк салып була, юк, алай мәшәкатьле, алай итсә, аның вакыты китә... Менә хәзер шундый үтә дә белдекле кайнар башларның кулыннан тотып алды хөкүмәт: тукта, тәти абзый, балтаңны куеп тор, диде, әйбәтләп торып уйлап кара, күршең белән киңәш-табыш ит, диде... Агачны аударырга, хәзерге төсле техника заманында, биш минут җитә, үстерергә йөз ел кирәк.

— Син, Мирыч, ялгышып кына минем белән бергә мичкә ясап ятасың икән лә,— диде Гыйрфан, тагын бер чәнчеп алырга ниятләп.— Бу акылың белән сиңа министр гына буласы калган!

— Һе, министр, имеш! Ә нигә, ул да кеше, мин дә кеше. Хәер, хата юлдан китсә, министр кебекләргә таякның саллырак башы төшәргә тиеш кебек. Ә миңа калса, мин...

Урман авызы ягыннан янә машина гөрелтесе ишетелә башлады. Мирыч, кисәк айнып киткәндәй, кул сәгатенә күз төшереп алды һәм ирексездән көлеп җибәрде:

— У-у, егеткәйләрем, байтакка сузганбыз икән. Ярый, аңлаштык кебек, инде дә кузгалышыйк! Бусын уздырыйк та икенче машина безнеке булсын...

* * *

Өлкәнрәкләр басынкы тынлыкта урман ешлыгына таба алдан атлады, яшьләр — Марс белән Ваня — этешә-төртешә аларга иярде. Түгәрәк алан уртасында тик Фуат кына калды. Ул, яфракларына соргылт төс индереп утырган яшь чибәр имән үсентесенә текәлгән хәлдә, уйларына бирелеп, кымшанмыйча кырын ята бирде. Моны абайлап алган Гыйрфан, иптәшләреннән аерылып, кире килде.

— Син нәрсә? Мирычның тәмле теленнән оеп, йокымсырап киттеңме әллә?

Егет җәһәт кенә сикереп торды:

— Кая, көрәгеңне бир әле! Син анда минекен алырсың. Мирыч күрсәтер.

Абзыйның тимер көрәген тартып алгач, Фуат әлеге имән үсентесе янына килде һәм аның төбеннән ярыйсы гына ара чамалагач, таза аягы белән нык басып көрәкне җиргә батырды.

— Син нәрсә? Моны казып алмакчы булдыңмы? Лесник килеп чыкса, кирәгеңне бирә бит.

— Пошынма, лесникны гына җайлый белербез анысы... Бик матур имәнкәй бу, монда олтан булып утырганчы, безнең паркта солтан булып үссен әле. Төшендеңме?

— Күр, тилене...

Гыйрфан, башын селкә-селкә, урман эченә кереп китте. Ә Фуат, коңгырт беретын башына кысыбрак батырды да иплән кенә үсентенең төбен казырга керешә. Ашыкмады, кабаланмады, алай да маң-

гаена тиз арада тир бәреп чыкканлыгын тойды. Дулкынланганга күрә- дер, ахры.
Бер мәлне, тын алырга дип тукталса, исе китте: каршысында, энҗе тешләрен елтыратып, Асия басып тора! Дәшми-нитми үзе... Аңгы-миңге хәлдә калды егет. Бер мизгел аптырау катыш сокланып күз чекерәйтеп карап торгач, үзе дә авызын ерды.
— Син ничек монда?..
— Килдем менә... Машина... Кызык бит.
— Һе, кызык... Тегендә авыр булдымы әллә? Дезертир димме инде үзеңне?
— Нишләп алай булсын,— диде кыз, иреннәрен турсайтып, һәм тузгый төшкән чәчләрен артка таба ташлады.— Без Надя белән икебезгә дистәдән артык утырттык инде. Тик җибәргән үсентеләрегез генә бетеп китте, ялкаулар! — Аннары Асия матур һәм үз итеп көлемсерәде.— Сиңа булышмага килдем.
— Кара син... Ярый, бик рәхмәт!
Кыз янәшә үк килеп басты.
— Күрче, имән бит бу, име, Фуат? Ә тегендә нишләптер бер генә имән дә юк... Үсәр дисеңме?
— Тамырларына зыян китермичә, әйбәтләп казып алсаң, ник үсмәсен, ди? Үземнән аерым бер истәлек булсын, дидем инде. Үзем казып алам, үзем үк утыртам да... Юк, көлмә син!
— Ә ни өчен үзең генә? Мин дә монда бит, яныңда, Фуат... Икәү утыртыйк.
Егет кызның назлы-иркәле, ягымлы йөзенә текәлеп тора алмады, карашын түбән күчереп:
— Алайса, ярый, Асия... Әйдә, ябышыйк...— диде. Һәм көрәген янә җиргә батырды.
Кыз җиңнәрен терсәк тиңентен сызганды да, чүгәли төште һәм:
— Берүк тамырларын саклый күрик инде, берүк әйбәт үсәрдәй булсын,— дия-дия, Фуат казып йомшарткан туфракны нәфис бармаклары белән актара башлады.

## 10

Җиргә аяклары ничек басканлыгын да тоймады диярлек Асия. Шулай булмый ни!
Бүген ул Фуат белән бергә агач утыртты.
Бергә!
Бик күпләр моны үз күзләре белән карап торды.
Фуат иң башта яшь имәнне паркның урта тирәсендәрәк сузылып китәсе берәр аллея почмагына утыртырга ниятләгән иде. Ләкин Асия:
— Зинһар, алай итмик инде. Ул бит тик безнеке генә... Берәр аулаграк, тынычрак төшкә утыртыйк. Соңыннан, имәнебез зуп-зур булып үскәч, аның күләгәсенә килеп, ямь-яшел чирәмендә рәхәтләнеп юанырлык булсын,— дип үтенде.
Егете берсүзсез күнде моңа...
Агачны бик әйбәтләп утыртып куйгач һәм төбен суга мул итеп туендыргач, алар аның каршысында беравык тын гына басып тордылар. Өмәгә җыйналган халык инде таралыша башлаган иде. Үр итәкләрендә көлешкән авазлар, күңелле шаян җырлар яңгырап тора иде. Кояш инде түбәнәюгә юл тоткан һәм аның байыйсы төшендә, офык читендә, кабарынып-кучкылланып бүре-бүрек болыт өемнәре калкынган иде. Нәкъ менә шул яктан аз гына салкынча, дымлы җил исә башлады. Егет тирән итеп сулыш алды да чак кына калтыранулы тавыш белән:
— Шулай, Асия, бергә-бергә караштыргаласак, ник үсмәсен, ди?

Бик әйбәт, бик матур булып үсәр әле, менә күрерсең,— дип куйды.
Бергә-бергә...

Өйгә таба жил-жил атлаган шәпкә, кыз үзенең хыялы белән күз алдына китереп бастырды: менә ул бәләкәй имән үсентесе зуп-зур булып үсеп, буйга да житте, ди, инде. Ябалдашы шундый киң, шундый күркәм — дөньяда бер. Имән төбендә ямь-яшел йомшак үлән, әйбәт күләгә... Менә бер дә бер көнне алар Фуат белән икәүләшеп шунда киләләр. Яннарында нәниләре дә бар. Малай булса да ярый, кыз булса да... Юк, бераү генә дә түгел, икәү-өчәү, дүртәү инде... Бөтерчекләр кебек кенә, ямь-яшел үләндә тәгәрәшәләр, көрмәкләшәләр балакайлары. Ә Фуат белән ул, жиргә кырын ятып, яшелле-кызыллы ашъяулыкка мул итеп сибелгән ризыктан авыз иткәли-иткәли, йөрәк парәләренең уйнавына сокланып туя алмыйлар. Ә көн аяз, кояшлы, купшы имән күләгәсендә исә рәхәт... Менә бер мәлне, яшьлек елларын исләренә төшергән бер чакны, Фуаты аны кочагына кысып ала да калын күкрәк тавышы белән тирән хис, зур куану аша әйтеп сала:

— Көзнең матур бер көнендә икәүләшеп утырткан имәнебез, безнең бәхеткә, күр, нинди шәп булып үсте бит, ә! — ди...

Ә нигә, килмәсмени шундый бер көн, шундый матур бер заман? Үз бәхетләренең дә тамырлары, шул таза имәннеке кебек, бик тирәнгә үтеп, киңәеп-жәелеп китәрдер әле...

Асияларның өйләре Тойма аръягында, каланың Можга юлына чыккан башында иде. Аулаграк тыкрыкта утырган иске баракның үзенә аерым болдырлы бәләкәйрәк ике бүлмәле почмагында торалар. Әнисе белән икәү генә. Фатирлары әллә ни шәптән булмаса да, үз куышлары!.. Гадәтенчә, әнисе өмәгә чыгарга исәп итмәде, ул нишләптер кешекара арасында буталып йөрүне бик үк өнәми, үзе өчен авырга саный иде, ләкин, аның каравы, кызының андый зур эшләргә катнашуына чиксез куана, аны һаман да жилкендереп торыр иде.

Бүген дә иртән Асия жыенып чыгып китәр алдыннан:

— Бар, кызым, бар. Ичмасам, син кеше алдында сынатма инде! Кайтуына үзең яраткан джемнан ни дә булса әмәлләрмен. Хәзер менә камыр куям,— дип калган иде.

Инде ике күзен дүрт иткәндер. Самовары өстәлдә чыжлап утырадыр, Асия яраткан жир жиләге джемыннан кызартып сумсалар пешергәндер, һәм ул тәмле нәрсәкәйләр аш табагында, чуар тастымал астында аны көтеп парланып яталардыр...

Тойманың тыгыз, каты агымлы сайлыгында эре-эре ташлар. Ярдан ташка, таштан ярга тар гына такталардан басма салынган. Ашкын су эреле-ваклы ташларга бәрелә-сугыла ага да ага. Асия басма уртасында бер мәлгә тукталып, тынлап торды: һай, матур да бу Тойма-сылуның менә болай чылтыр-чылтыр килүләре! Бүген бигрәк тә!

Асия, басма тактасын су битенә чыпырт-чыпырт бәрә-бәрә, берара тирбәнгәләп алды.

Фуат инде үз өенә кайтып та житкәндер: алар өенә буласы парк якынрак бит. Әнисе Рабига апа табын әзерләргә керешкәндер. Фуат бу минутта, бәлкем, юына торгандыр. Пырх-пырх юынганда, Асиясын бер мизгелгә генә булса да күз алдына китерде микән? Ә кыз шашкан көчеле белән әле һаман да аның янәшәсендә... Менә басма тактасында тирбәлгән чагында да егетнең таза кул жылысын, иңбашларыннан нык тотып кысуын әле һаман да тойган кебек, ике колагы белән дә аның кайнар пышылдавын әле һаман ишетә кебек...

Тик егетнең әнисе Рабига апа соңыннан ниләр китереп чыгарыр да ниләр яудырыр өсләренә? Хәер, Фуат череп ямьшәйгән бәрәңге түгел ләбаса. Ул белер...

Каршы яктагы сөзәк ярдән әкрен генә күтәрелде, урамга кергәч, адымын янә кызулата төште.

* * *

Менә инде аларның искереп кучкыллана төшкән шыксыз зур, тәбәнәк бараклары, менә чалышайган үз болдырлары... Тышкы ишекне шыгырдатып ачмас борын ук, Асия һавага мул булып таралган тәмле исне аермачык тойды, хәтта кипшенгән иреннәре җаелде дә китте. Димәк ки, әнисе чынлап та пешеренгән, димәк ки, сүзендә торган!

Бусаганы җиңел генә атлап, эчкә үтте.

Күр, әнисе табынны да бүген түр яктагы өстәлгә әзерләгән. Ак самовары да чыжлап утыра, төсе килгән матур сумсалары да... Ләкин кызның иреннәре капыл бөреште, нәфис борын яфрагы тартышып ук куйды: табын түрендә кукраеп аракы шешәсе утыра һәм, аңардан да бигрәк, өстәл башына бер ир заты кереп кунаклаган иде. Баш түбәсе шома, такыр, колакларыннан өстәрәк, чигә тирәләрендә, учма-учма чәч бөтеркәләнеп тора, күз кабаклары салынкы... Кыз аны шундук таныды һәм тануыннан бусага төбендә өнсез-иссез дә калды.

Баеп барган кояш, офык артыннан калынаеп килгән болыт өерләре артына кереп яшеренгәнгә күрәдер, ахры, өйләренә кичке эңгер канатын җәя башлаган иде инде, әнисе тизрәк ут кабызырга кузгалды. Ә теге бәндә исә утырган жиреннән капыл гына купты да, авызын киң җәеп, калтыранган кулларын алга сузып, тамагын кыргалый-кыргалый, кызга таба атлады.

— И кызым, менә инде син дә... Кара инде, нинди булып үскәнсең... Кая, күрешик... Саумы, кызым!

— Бик сау!..

Дерелдәгән йөнтәс ябык куллар хәлсезләнгәндәй түбән таба салынып төште.

— Я инде, кызым!..

Асия үз караваты янына чаршау артына кереп посты да нечкә, озын бармаклары белән муенына ябышты. Бу мизгелдә аның үзенең дә бөтен гәүдәсе, электр тогы тоткандай, дер-дер килә иде. Менә теге бәндәнең куллары инде чаршауны кармалый башлады, үтә мескен, бөтенләй беткән тавышы кызның күңел кылларына урелергә итенде:

— Алай ярыймыни инде? Аз гына да кызганмыйсыңмыни этиеңне? Җаның өшемәгәндер лә синең, Асия акыллым?

— Кагылма миңа!

Кыз, бөрешеп, нәүмиз бер кыяфәттә кул кушырып торган әнисенә яман күз атып, алгы бүлмәгә чыкты. Монда юкә чапчактан калай кружка белән чумырып салкын су алды. Эчкән чагында тешләре калайга шыкыр-шакыр бәрелгәләде. Гәүдәсенә сеңгән салкын су белән бергә миен дә үтә салкын, рәхимсез уй ярып үтте: йомшарга ярамый, ярамый!..

Калай кружка чапчак капкачы өстенә зыңгылдап килеп төште.

— Әһә, килдеме көнең? Инде миһербанлык сорап, кызгандырырга ябыштыңмы?! Ә теге заманнарны үзең соң кызгана белдеңме? Ә хәзер яланырга чыктыңмы? Эти, имеш... И хәерче җан!

— Дөнья бит, кызым... Ниләр килмәс, ниләр үтмәс адәм башыннан... Мин сезне бөтенләй борчымас та идем, билләһи, кызым...

— Ышандылар, ди, сиңа! Кирәгебез төшмәсә, күзгә күренер идең, ди. Бездән дә, бүтәннәрдән дә качып йөргән чакларыңда, ай, рәхәт булгандыр да, безгә бик ачы иде шул.

— Тәүбә инде, мең тәүбә!..

— Һе, тәүбә, имеш... Инде хәзер мин үзем кеше булгач, әни дә адәм рәтле тормыш кора башлагач кына... Юк инде, әни теләсә ни әйтсен, ә мин тагы да мәсхәрәләнергә юл куймам, ишеттеңме?! — Асия-

ның йөзе башта көл төсенә кереп агарынган иде, ә хәзер кан чәчрәп чыгардай кызарынган, бүртенгән иде.— Ишеттеңме, юл куймам! Бар, бездә эзең дә, исең дә булмасын! Поселокта ук булмасын! Инде моннан гарык синең аркада күргән мыскыллардан...

— Бу тикле үк кыланмасана, кызым. Синдә генәмени нерва? — дип куркынып пышылдады әнисе.

Кая монда тынычлану!.. Асия усал-ярсулы карашы белән әнисен дә яндырып алгач, аягы белән тибеп ишекне ачып җибәрде дә сулышына буылып эндәште:

— Алдыңнан артың матур! Я, ник каттың? Әһе, шулаймы, чыкмыйсынмы, сыпыртмыйсынмы? Алайса... алайса, мин үзем!..

Асия җәһәт кенә чөйдә эленеп торган плащын йолкып алды. Җилләнеп тышка ыргылган кыз артыннан ишек шапылдап ябылды. Мондагылар, Асияның үз әтисе Корбан Сәләхов белән үз әнисе Мәүҗидә Таипова, өнсез бер хәлдә, тораташтай катып калдылар.

## 11

Асияның гомер юлы шактый кыска әле. Алай да, шул яшь кенә гомерендә дә кызый, җанын әрнетеп, күңелендә авыр җәрәхәтле эзләр калдырган нәрсәләрне бер генә тапкыр кичермәде.

Шуларның күбесе әтисенә бәйле. Юк, әнисенә дә...

Сабый вакыты, ягъни тормыш дигәннең кырлы-мырлы якларын белмәгән, аның ачысен әле татып карамаган рәхәт бер чагы иде. Ләкин рәхимсез, мәкерле дөньяның аны алай озак киңәндерәсе, хәтта мәктәпкә барып керәсен дә көтәсе килмәгән...

Җәй уртасының галәмәт кызу бер көнендә Тойма буенда чыр-чу килә-килә су кергәч, кояшта кызынып яталар иде. Әнә шунда чебеш басарга ауга чыккан козгын шикелле, Тойма буендагы ашъяулык кадәр комлыкка әллә каян гына эре сипкелле җирән Рәхилә килеп чыкты. Үзеннән бәләкәйрәкләргә һич рәхим-шәфкать күрсәтми торган бер кызый шунда. Нишләптер, әллә курчак кебек артык матур булганы өчен, әллә берөзлексез чырык-чарык көлеп йөргәнгә күрә, ул Асияны аерата кыерсыта иде.

Килеп чыкты да кулындагы сыек тал чыбыгы белән тамызгалап бер-икесен елатып алды, аннары тагы да усалланып:

— Ягез әле, маймычлар, тезелешеп утырыгыз да ике күзегезне дә зур ачып кояшка карагыз,— дип әмер итте.— Кайсыгыз, күзен йоммыйча, озаграк карый ала микән?

Буйсынмый чаралары юк. Асия, баш өстендә чыжылдап бөтерелгән тал чыбыгыннан курыкканга, барын да уздырмакчы иде. Ләкин булдыра алмады. Кояшка аз гына текәлеп карагач ук, күзләрен челтмелт йомгалый башлады. Күз төпләренә бөрчек-бөрчек яшь бәреп чыкты. Рәхилә аны гына күзәтеп торган икән, төкеренә-төкеренә җиргә чүкте:

— Я, ник йомасың? Сөртмә дә! Икесен дә зур ачып кара!

— Булмый бит...

— Нишләп булмасын? Сине бит җилдән туган, диләр. Ә җилдән туган бала, бик беләсең килсә, ике күзен дә зур ачып, кояшка би... и... ик озак карап тора ала, ди... Я!

— Нишләп мин җилдән туган булыйм? — Асия, ярдәм эзләп, иптәшләренә күз салды. Тегеләр комда кайсы ничек утырган булса, шулай, авызларын ачып катып калганнар иде.— Минем әнием дә бар, әтием дә булган...

— Әтиең? Ә кайда соң ул?

— Сугышта үлгән. Аның картычкасы да бар әле. Комод өстендә генә. Мин аны көн дә саен күреп торам Тузаның да һаман-һаман сөртәм...

— Сугышта үлгән, дисеңме, чәчрәп китим, дисеңме? Картычкасы тагы... Хи-хо-ха!.. Соң сиңа ничә яшь инде? Әһә, тагы бер айдан җиде тула. Ә сугыш беткәнгә ничә ел? Бик беләсең килсә, унбер ел булды инде, маймыч! Алайса, син әтиең үлгәчтен, дүрт ел узгач кына тугансың икән... Ха-хи-хи! Шулай булгач, җилдән тумыйча, каян тагы?

— Син үзең җилдән тугансың! Шуңа күрә җип... җип... җип-җирән дә син!

Ул көнне Тойма буеннан елап, бүртенеп кайтып керде Асия. Җирәнбаш Рәхилә кулындагы сыек тал чыбыгы яндырган балтыр итләре әрнүе бер хәл иде. Тән җәрәхәте ни — әрни дә бетә, әмма тегесе...

Әнисе кайчаннан бирле сузган ялганының менә болай капыл гына тотыласын уена да китермәгән иде, ахрысы, бөтенләй коелып төште. Ләкин кызына күңелен ачып салырга, чын хәлне аңлатып бирергә ашыкмады. Үзен тиз үк кулга алды, төче генә елмаеп:

— Нишләп инде, кызым, кеше җилдән туа димени? Юкны, булмаганны лыгырдаган ул җирән саесканн. Синең әтиең бар иде, нишләп булмасын! Сугышта да йөргән ул, тик исән генә түгел инде... Ә син ул җирәнбашлар белән уйнама, алар тирәсендә йөрмә,— ди-ди, кызын үзенчә юатмакчы, юмаламакчы булды.

Әмма Асиянын саф йөрәгенә кан саварга өлгергән иде инде, ул мондый гына юмалауга эреп китмәде, дымсу, җете кара күзләрен әнисенә төбәгән килеш:

— Әтием сугышта үлгән булгач, мин нишләп әллә ничә ел буе тумыйча торганмын, алайса? Мин бит зур инде, әнием, син миңа ялганламыйча гына әйт инде,— дип, үз сүзен тәкърарлады. Аннары комод өстенә бәләкәй рамга куелган фоторәсемне күтәреп алып килде.— Ә бу минем үз әтиемме? Ул сугышта үлдеме?

— Бу, кызым, синең үз әтиең буласы иде дә булалмыйча калды шул,— диде әнисе, уфтанып.— Сугышка кабат киткәчтен, ул хәбәрсез югалды... Ул минем беренче ирем иде, мин аның белән нибары ярты ел гына торып калдым, аның исеме дә Корбан түгел, Хөрмәтулла иде. Синең үз әтиең Корбан да сугышта булган, күкрәген медальләр белән тутырып кайткан кеше иде. Тик ни... мин аның белән дә әллә ни озак тора алмадым: әтиең Корбан бик еракта, алтын чыккан җирләргә акча эшләргә дип киткән җиреннән кайтмады, үлеп калды. Ул чакны син туган идең инде, тәпи дә йөри башлаган идең, кызым... Аңладыңмы?

Ләкин хакыйкатьнең ярым-йортылысы гына булган икән әле бу. Шулай да ул көнне кызга «җилдән туманлыгын» төшендерү һәм аның сабый күңелен тынычландыру өчен шушы хәтлесе дә җитә язды шикелле.

Тик шунысы аяныч иде: җирән чәч Рәхилә авызыннан чыккан әлеге яманатны бала-чага эләктереп алган иде инде, сирәк-мирәк булса да, ачулары килгән чакларда ул сүзне тотырып әйтәләр, кайвакытларда тагын да яманрак, ямьсезрәк иттереп: «Әй, син, кысылма, чикылдама әле, уйнаш калдыгы!» дип тә ычкындыргалыйлар иде.

Бәхетенә каршы, беренче классны тәмамлавына ук, әнисе Казагыстанга чирәм җирләргә китәргә ният итте һәм Асияны да үзе белән алды. Монда, яңа җирдә, дала иркенендә оешкан совхозда кызның колагы теге сүздән тынып, җаны тыныч йөрде. Ике-өч елдан соң, әйләнеп кайтуларына инде пионер галстугы тагып алган әүвәлге «маймыч» иптәшләре дә чуплектә актарынып, аннан иске-москыны казып чыгармадылар.

Әүвәлге сөйләвендә әнисе үзенең беренче ире Хөрмәтулласы турында тамчы да алдамаган икән. Сугыштан яраланып кайткан лейтенант

булган икән теге. Әнисенең заводта көнне төнгә ялгап, фронт өчен кислота житештереп яткан чагы, дәртле-жилле чагы. Танышканнар, күпмедер йөрешкәннәр дә язылышканнар. Әмма Хөрмәтулласы, аягындагы җөе тәмам төзәлеп беткәнен дә көтмәстән, кикриген хәтәр шәбәртеп:

— «Инде Германның үз җиренә керделәр... Монда ятып булмас. Барып, бетерешеп кайтыйм әле хәшәрәтләрне. Аннан инде тынычта сайрашып гомер итәрбез, түземеңне җый, сөеклем»,— дип, үз теләге белән янә фронтка китеп барган.

Ләкин шул китүеннән эзсез югалган... Әйе, Хөрмәтулласы — сөекле ире, законлы ире! Тикмәгә генә әнисе аның фоторәсемен комодның иң күрекле төшенә утыртып, әлегә тикле саклап-кадерләп тормый торгандыр, тикмәгә генә бөтенләй бүтән кешедән туган кызына да «Таипова» дип аның фамилиясен яздыртмагандыр...

Ә менә Асиянын этисе Корбан белән бөтенләй бүтән хәл. Күңелсез янсә ямьсез генә дә түгел, бер уйласаң, җирәнерлек тә...

Сугыш бетеп, икеме-өчме ел үткәч, килеп төшә бу Чулман буена. Монда күкерт кислотасы цехына эшкә керә. Асияның әнисе дә шунда...

Үзе җете күмер күзле, сумала чәчле — чегән кебек чибәр, ди. Теле тагы: елгыр шома, былбыл телләре, ди... Монда үзенең Хөрмәтулласын көтә-көтә гаҗиз булган һәм өметен җуя башлаган яшь хатын тирәсендә бөтерелергә тотына. Тора-торгачтын, тегенең башын-күзен тәмам әйләндерә. Әмма ул чибәр ир Казан каласының Пороховой бистәсендә алмадай хатынын, җиләктәй ике кызын калдырып-ташлап килгән икән.

— Юк, мин ул бәдбәхет, ул себерке белән судлашып, барыбер араны өзәчәкмен,— дип гайрәт чәчә бу.— Аның соңында инде без дә законлы булырбыз, кайгырма,— ди...

Ләкин өчме-дүртме ай торуларына ук, эшендә нииндидер кыенлык килеп чыкканга күрәдерме, әллә бүтән берәр сәбәптәнме, нәниенең тууын да көтмәстән, читкә шылу ягын карый...

Соңрак белде Асия: теге вакытта беренче сөйләвендә әнисе алдаган икән: кызның этисе Корбан, зур акчаларга кызыгып, алтын чыккан ерак җиргә дә китмәгән, анда үлеп тә калмаган... Ул исән икән! Исән!.. Боларны ташлап киткәч, бер-ике елын Чулман суында ниндидер пароходта кем хезмәтендәдер йөргән-йөргән дә Сталинград каласында тагын берәүгә сарышкан, әмма андагы өендә дә озак ятмаган, янә каядыр олаккан...

Әнә шулай, үз этисе бар көенчә, сугышта хәбәрсез югалган лейтенант фамилиясен йөртеп һәм бер үк вакытта «Корбановна» дип тә аталып, тормышта үз сукмагын сайларга да, аннан үз җае белән генә атларга да тиешле иде Асия.

Асия моңарчы этисен бер генә тапкыр күрү «бәхетенә» ирешкән иде. Тегенең юл уңаеннан гына сугылуы идеме, әллә монда тагын да эшкә кереп, бераз торырга ниятләгән идеме,— ни уйласа да уйлагандыр, әмма ул болар һич көтмәгәндә килеп төште. Чынлап та чибәр генә икән үзе. Ул җемелдәп торган җете кара күз-каш, елкылдаган күпертмә чәч — тап Асиянықыдай. Авызында гел бал да май.

Дүрт-биш көн кундыргач, әнисе аны бер заман җиде төн уртасында күршедәге тол хатыннан, яртылай чишенгән килеш әче бал чүмереп утырган җиреннән, җилтерәтеп алып чыкты. Шуның таңында ук «шома абзаң» кире пристань юлларыннан табан ялтыратты.

Инде менә тагын килгән. Инде тәмам бетешеп килгән кебек: сумаладай чәчләреннән җилләр искән, күз төпләре шешенке, куллары дер-дер... Тик теле генә һаман да «эт каешыныкы»: татлы-баллы...

Ләкин кызы Асия аның теленә елан агулары кушылганлыгын белмимени?

Соңгы вакытта алар аның Казанга иң әүвәлге хатыны һәм буй җиткергән кызлары янына кайтып, ярыйсы гына тора башлаган дип ишеткәннәр иде. Аларны тагын ташлап китте микәнни? Ә монда ник килгән, тагы нинди ниятләр белән йөри? Әлбәттә, юньлегә түгелдер.

Ичмаса, Асияның шушындый куанычлы бер көнендә, завод өмәсендә сөеп йөргән егете Фуат белән бергә-бергә агач утыртып, аралары үтә якынаеп, нечкәреп киткән бер көнендә юл каршысына, тешләре үтмәсләнгән карт бүре булып, чыгып утырмаса икән!

Асияның үз әнисенә дә үпкәсе дә, ачуы да бәләкәй түгел иде.

Ярый, Хөрмәтулласы сугыштан кайтмаган, эзсез югалган, ди. Ләкин кабаттан кемгә, ни хәлдә чыгасын нигә бер генә дә абайламады микән? Хатыны, алмадай балалары бар икәнен белгән килеш, җылы куенына шул юха еланны сыендырган бит. Кайчакларда: «Шул сугыш зәхмәте аркасында гына инде»,— дип, үзенчә акланмакчы була.

Аннары килеп, бер авызы пешкәч, нишләп инде бөтенләй җебеп, туарылып каласы итте икән? Теге бәндәсенең азгынлыгы әнисен дә намус һәм вөҗданыннан биздергәнме әллә? Бик бәләкәй вакытында, дөнья хәлләрен әле аңламас, танымас чагында, Асия әнисенең ничек яшәгәнлеген белми, әлбәттә. Ләкин соңыннан, үсә төшкәч, аз күрмәде, аз ишетмәде. Казагыстанга баргач та, ул ни сәбәптәндер ир-атның көмешен түгел, хәтта бакырын да эләктерә алмады. Анда һаман да ир-атның күгәргәнрәкләренә юлыкты шикелле... Ә монда кайткач, шушы иске баракның бер почмагында тора башлауларына? Төннәрен ниндидер ят ирләр белән пышын-пышын сөйләшүләрен, ниндидер чит-ямьсез авазларны ишетеп, уянган чаклары аз булдымыни Асияның?

Гыйшык-гашрәткә чумды дигәч тә, әнисе, дөрес, артыгын тузынмас, киңәймәс, әшне бик сак рәвештә яшертен тотар, итәк-чабуын бик ипле җыеп, бик ыспай йөрергә тырышыр иде. Ләкин уты барның төтене чыкмый каламыни?

Менә инде байтак еллар Асияның әнисе Мәүҗидә Таипова инсафлылар юлыннан атлый. Әүвәлге гөнаһлары булмаган да кебек. Карчык-корчыкны ашка чакыргалый, кемгәдер нидер өләшкәли...

«Алма агачыннан ерак төшмидер... Җимешнең, һай, татлысыдыр бу!» дигәнрәк мәгънәдә мутланып янган әрсез күзләрне Асия аз очраткалыймыни? Кайберәүләр кыек-мыеклап торуларны да кирәксенми хәтта...

Әмма әнисенең вөҗданы да, намусы тик ятмаганлыгын, һаман кымыржып торганлыгын Асия бер мәлне тагы да ачыграк сизде. Бусы инде, киресенчә, күркәм һәм нәфис бер хәлгә бәйле иде.

Былтыр җәй азагындарак булды ул. Бер кичне клубта аны киң, таза күкрәкле, төз гәүдәле ярыйсы гына күрекле егет белән таныштырдылар. Диңгезче, ди, Мурманскидагы сәүдә флотында хезмәт итә икән. Дөньяда күрмәгән иле калмаган шикелле. Ләкин аз гына да мактанмый, һаваланмый, бик тә тыйнак һәм ыспай тота үзен. Берадан Асия аңлап алды: утыз тирәләрендәге бу егет химиклар каласында яшәүче туганнары янына кыз күзләргә һәм үзенә гомерлек юлдаш алып китәргә дип кайткан, имеш. Асияны өч-дүрт кич өенә кадәр озатып куярга тырышып карады, тик бусы гына, бүредән өреккәндәй, тизрәк читкә шылу җаен чамалый белде... Егет, кызга артык тыйнак һәм ыспай күренсә дә, вакыты бик тар, бик кысан булгангадыр инде, бер көнне ул кыз югында әнисе белән турыдан-туры сөйләшкән, өстәвенә, әйткән сүзенең ныклыгын расларга исәп итептер, мөгаен, аңа шәп бер бүләк тоттырырга итенгән: һиндстан илләренең үзендә затлы тукымадан эшләнгән гаҗәеп нәфис ашъяулык, ди...

— Бүләгенә әллә ни исем китмәде... Малай чагыннан ук беләм

мин аны. Үз акылындагы, төпле егет кебек... Нәсел-нәсәбе дә әйбәт,— диде әнисе, кызына кыюсыз гына текәлеп.— Үзе тагы, укытыр идем, зур белемнәр бирдерергә ризамын, ди... Әллә нитәсеңме, кызым? Яшең шактый бит инде...

— Булса соң... Егете, бәлкем, чынлап та әйбәтлеккә әйбәт тәдер, әмма... Юк, бармыйм! Миңа монда да үз ишем чыгар әле. Укуны да үзем җайлый белермен, кешегә салынмам,— дип кырт кисте Асия.

Дөрестән дә, кызның күз атып йөргән һәм күңеленә инде тәмам кереп урнашкан егете Фуаттан калышмас өчен, кичке мәктәпнең тугызынчы классына керергә әзерләнеп, җенләнгән чагы иде.

— Мин үзем дә алай җәелеп китмәдем, сузган кулларын кысарга ашыкмадым,— диде әнисе һәм, өстәл янында терсәгенә таянып утырган җирендә тирән уйга чумып, озак кына тын торгач, сызланулы тавыш белән янә әйтте: — Ирең дингезче булса, аның шунысы да бар бит әле: ул чыгып китәр дә айлар буе дөнья гизеп йөрер, ә син аны япаялгызың көтеп ятарга тиешлесең. Ирсез тормыш — ярым-йорты тормыш. Ачы язмышымда миңа үз гыйбрәтем дә бик җиткән! Инде сиңа күчә күрмәсен, сиңа язмасын!

Әнисенең пошаманлы уйларга бирелеп, кызы хакында һаман да хафаланып торуын Асия, әлбәттә, юньлегә, аның, олыгая төшкәч булса да, янаруы-сафлануыдыр дип юрады. Бу инде кызны бер мәлгә генә куандырып калдырмады, әнисенә таба араны бик нык якынайттырып, аны бөтенләй үз иттерде.

## 12

Ә жил шәбәйгәннән-шәбәя барды. Менә инде вак иләктән кыеклатып яңгыр да сибәли башлады.

Әле кичә генә яңгырны Мәскәүдә дигәннәр иде. Шул арада монда да килеп җиткән.

Ярый әле, өмәләрен уздырырга өлгерделәр. Иртәгәсен «Яшьлек» паркына агач утыртырга чыгарга тиешләр, мөгаен, чыга алмаслардыр инде.

Урамда байтак кына буталып йөргәч, иптәш кызы Надяларга сугылды. Ләкин ул өйдә юк иде. Аның әнисе ни елмаерга, ни зарланырга белмәстән, бот чапкалап торды:

— Надюшамы? Ул акайганыбыз аннан-моннан гына капкалады да тагын чыгып сызды. Әллә киногa шунда, әллә танцыга... Ә синең, акыллым, ни йомыш иде? Ышансаң, үзем әйтермен аңа...

Надя, тәгаен, үзенең пожарнигы белән сүз куешкандыр.

Кичке мәктәптәге класстaшы Вералар өе турысыннан адымын да акренәйтмичә узып китте: боларның бар тәрәзәләре дә ял-якты, житмәсә тагы, эчтә радиола акырталар иде. Мәҗлес корып яталар, ахрысы. Бүген ял бит — күпләр күңел ача. Әнә Гассар клубы ягында джаз музыкасы яңгырап-яңгырап куйгалый, тегендә «Коммуна»да да танцыдыр... Анда аның Фуаты да килеп, тикмәгә генә аны күзли-эзли торгандыр әле...

Асияның химиклар каласында дус-ишләре аз түгел иде. Аларның кайсы да аны кундырып чыгарыр иде. Ләкин... тукта, үз өе, үз кунасы булган килеш, нигә инде менә шушылый нәүмизләнеп йөрергә соң? Адымнары үзеннән-үзе акренәя төште, зиһенендә бөтенләй бүтән төрле уй күпты. Өеннән дуамалланып чыгып китүе — ахмаклык, әлбәттә. Менә хәзер кире кайтырга да әтисе Корбанга үз хәлләрен иплэпнечкәләп төшендереп бирергә... Җаны тәмам катмаган булса, аны үз кызы дип таныса һәм, ичмаса, аз гына якын итсә, әтисе хәлне аңламыйча калмастыр, шәт... Тели икән, бик әйбәтләп сыйларлар, кунак итәрләр, ни сораса, кулына шуны тоттырырлар, аннан инде, билгеле:

«Мондагыларны, зинһар, борчыма инде син. Үз иреклэрендә тыныч кына торсыннар. Рәнҗесәң-рәнҗемәсәң дә, инде дүрт ягың — кыйбла»,— диярләр...

* * *

...Түр якларында ут янмый иде. Әнисе кухня өстәленә терсәк салып утырган җиреннән авыр гына кубып калкынды да ишек янагына килеп сөялде. Әүвәлен еш кырылгалавы сәбәпле, хәзер инде нык калынайган кашларын җыерып, кызының күзләренә түгел, түшенә төбәлде:

— Шәп сибәли, ахры: әйбәт чылангансың... Әйдә, чишен дә...

— Нәрсә, теге киттеме әллә?

— Синең арттан ук диярлек. Шешәсенең төбенә төшкәч, капыл гына җыенды да китте... Акча сорап алды. «Можгада бераз төшергән ием, кесәне бушатканнарын сизми дә калганмын, соңыннан җибәрермен», дигән булды. Җибәрмәгәе!.. Әй, ник кадалмый акчасы, име, кызым?

— Әйе. Ә кая китте соң ул?

— Кумертауга, ди.

— Аның анда да бармыни?

— Бар бугай... Ашыйсыңмы? Бөкәннәрне томалап, кире мичкә тыккан ием.

— Капкалармын... Ә ни пычагыма дип килгән соң?

— Ни... Зарарлы производствода эшләү стажы туларга ел да ике ай гына калган булган икән. Монда шуны тутырып булмасмы дип... Ул илленең теге ягында бит инде. «Шахтыга китәр идем, алмаслар дип куркамын», ди. «Их, шул зарарлыкны тутырып булса, эшләмичә дә әйбәт кенә пенсия акчасына үз көнеңне үзең күреп, түшәмгә текереп ятып булыр иде, ичмаса!» дип шапырына...

— Казанда җанына ярардай эш калмаган икән, алайсам. Бер кылгач кабаттан алмыйлардыр шул. Инде исенә килгән дә... Соң, син үзең дә, аның кебек үк, зарарлык стажын тутырмакчы булып, картая башлагач кына киредән күкерт кислотасына барып ябыштың ич.

— Ябышсам соң... Син миңа бәйләнмә. Яңа контактныйда ул хәтле үк зарарлы түгел кебек. Тик менә аппаратларының бөтенләй бүтән төрле булуы гына бераз комачау. Күнегеп җитә алмыйм әле.

Тышта эч пошыргыч яман тавыш белән җил сызгыра, тәрәзә өлгеләрен зеңгер-зеңгер китереп яңгыр тамчылары чыбыркылый иде.

— Һай, кызым, бу караңгыда, бу җилле яңгырда, кем... әйбәт хуҗа этен дә урамга куып чыгармас, ди... Можгага барасы юлында машина тиз генә туры килгән булса ярый ла... И ходай!..

Асияның да үз күңелендә әтисенә карата кисәк кызгану хисе купты, хәтта ниндидер сәер калтырау бар гәүдәсен кымырҗытып үткәндәй булды. Ләкин кыз шундук үзен кулга алды һәм, әнисе бөтенләй мәлҗерәп китмәсен тагы дип, моңардан да бигрәк үз бәгыренең йомшаруын басмакчы булып, мыскыл катыш шелтәле бер тавыш белән тешләре арасыннан сыгып кына:

— Инде җәлли дә башладыкмы? Аның синең белән мине берәр чакны шулай бер генә минутка булса да кызганып караганы булдымы икән соң? — диде.— Без дә җебеп төшмик. Гомере буена үзе эзләгән, үзе тапкан өлеш...

Йокларга яткач та әле Асияның күз алдыннан әтисе китмәде. Күңелен һаман да әрнетеп, пошындырып торды. Төшенә дә шул керер дип уйлады. Әмма көндезен дә, кичен дә алҗу-талуның чигенә җиткән тән һәм җан озакламый тирән йокыга чумды. Тик уяныр вакыты җитеп килгәндә генә бугай, бер төш күрде. Ләкин әтисен түгел, Фуатны...

«Имештер, кичен дәрескә килгәннәр. Кул биреп күрешteләр дә шулай кулга-кул тотышкан көенчә класска керделәр. Әле бер кем дә юк. Фуат гадәтенчә партага менеп кунаклады. Үзе һаман шул көрәнсу

костюмында, кардай ак күлмәгенең изүен ачып, якасын кайтарып салган. Коңгырт күзләре исә, ягымлы нурланып, бик сөйкемле карый.

— Нигәдер төсең юк кебек, Асия, авырмыйсыңдыр бит? — дип сорады хәлгә керүчән йомшак кына тавыш белән.— Өмәдә җил бәргәнме әллә үзенә?

— Нишләп бәрсен, ди. Үзем бер ни сизмим,— дип кеткелдәде Асия һәм, кинәт исенә килеп, уфтана башлады.— Син, егеткәем, алгебрадан теге мәсьәләнне чишә алдыңмы?

Фуат җилкә тартып сызгырып кына куйды.

— Уйламадым да. Вакыт тимәде.

— Минем дә... Соң нишлибез инде? Берәрсеннән күчермичә булмастыр, алайса,— диде Асия, тәмам хафага калып.

— Һе, әйттең сүз! Икеле алсак алырбыз, әмма ялынмабыз. Бергәбергә бит! — диде Фуат, аңа таба иелә төшеп.

— Әйе, бергә-бергә! — дип пышылдады Асия да һәм, кайнар иреннәрен дымландырып, егетенә таба үрелә башлады.

Ләкин класска, галәмәт шаулашып, кемнәрдер килеп керде — болар үбешергә өлгермичә калдылар.

Уянгач, бераз вакыт кузгалмыйча уйланып ятты. Төшен ничек юрарга да белмәде. Аннары иреннәрен җәйде: тәрәзәгә әле һаман да җил бәрә, шыбыр-шыбыр яңгыр сибәли иде — әнә ни өчен үбешә алмаганнардыр әле...

Капыл акылына килеп, йомшак түшәгеннән сикереп торды: бәй, алгебрадан чыннан да бик авыр мәсьәлә биреп җибәргәннәр иде ләбаса!

Эчке күлмәктән, чәчләрен иңбашларына тузгытып сибелдергән килеш, өстәл почмагында өелеп торган китап-дәфтәрләрен актарырга керешге. Бераздан, кулын маңгаена куеп, җиңел сулап җибәрде: алгебра иртәгә икән лә... Әмма, аның каравы, бүген... тригонометрия дә бар, немец теле дә... Ах, аллам!

Әнисе, әлбәттә, торган иде инде. Ул кухнядан бу якка чыкты. Кызының кай иртәләрне мендәрдән баш калкытуына, бичура сыман рәтләнмәс, юынмас борын ук, менә шушылай китап-дәфтәргә төртелеп утыруларына күнегеп беткән иде инде. Авыртынгандай аваз белән ярым пышылдап кына эндәште:

— Сиңа да беренче сменага бит, кызым, име?

— Әйе.

Мәүҗидә Таипова бу төнен, бөтенләй дә керфек какмыйча, ачы сызланып үткәргән иде. Ул кызына тагын нидер әйтмәкче иде дә әйтмәде, тик аның кипшенгән иреннәре генә бер мәл сизелер-сизелмәс кыймылдап торды... Хәер, бу иртәне, бу минутта Мәүҗидәнең үзе тудырган фәрештәсе алдында аз гына да сыкранырга хакы бар идеме соң?

*Дәвамы бар*

## Кадыйр Сибгатуллин

### Тагын ачарбыз күк

Континентлар ачык,
инде кеше
урап-урап чыккан Җир шарын;
беләбез дә,
белмибез дә әле
Җиребездә тагын ни барын.

Җиргизәрләр һаман туа тора,
яңа җирләр бик тиз ясалмый.
Ачылмаганнарын ачып була,
ачылганын һәркем ачалмый...

Яңаларын эзләп йөрү түгел,
шушысында бөтен гамебез.
Ничә кабат ачылган бу Җирне
тагын ачарбыз күк әле без!

### Замана

Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга.

*Р. Фәйзуллин*

Яшәгән бу халык,
заманнар кичергән.
Өмете кырык кат
ялганган, киселгән.
Ансатмы, кыенмы —
тормышын юллаган.
Хәсрәтле булса да,
ул мескен булмаган.
Күтәреп заманны
заманга ялгаган.
Син минем бәхет дип,
михнәтен алдаган.
Кемнәрдер егылган,
кемнәрдер үткәннәр.
Аякка чалынып
йөргәннәр бүтәннәр.

Борыннар каныйлар,
шуларга абынып.
Кем яши табынып,
кем яши тагылып.
Вакытлар аера
барыбер аларны.
Мескеннең зары бар,
халыкның — заманы!
Өметкә инанып,
төзелеп, ишелеп
егылган һәм торган
бүгенге кешелек.
Нык җелек, нык буын,
өрекмәс, тынмас җан,
киң офык — киң караш,
суынмас, кайнар кан
сыгылып, сыналып
яхшыда, яманда
ныгый һәм чистара
заманнан-заманга!

Заманга ябышып
зарлана мескеннәр:
«Ник сытып үтәсең,
кызганмый, без кемнәр?!»
Замана белә ул:
бик егет чаклары;
чабуга тотынып,
кем генә чапмады!

Кодрәтең зур икән —
җилкәңә салып бар.
Һич юкта таягын,
биштәрен алып бар.
Буш арба түгел лә,
ябышма, сырышма!
Без киттек, калсаң кал,
заманны орышма!
Әйбәт ул замана,
бик шәп ул замана.
Замана — без бит ул,
кем анда зарлана?!

## Кыя

Чаян чага үзен соңгы чиктә,
Бөркет ярдан түбән ташлана.

*М. Җәлил.*

Бөтен дөнья күренер иде моннан,
капламаса зәңгәр томаннар.
Хозурлыкка җаным тарткан чакта
еракларга карап торган бар.

Ташка басып түбән карый алсаң —
шырпы кадәр генә наратлар.
Әсәрләнеп куям бөркет кебек,
иңнәремдә гүя канатлар.

Кояш нуры башта монда төшә,
уянганда бөркет уллары.
Елга дулкыннары дулый аста,
тавышлары җитми югары.

Сәлам биреп үткән пароходның
тау-ташларда кала тавышы.
...Бу елгада аккан кайгыларның
кыяларда микән сагышы?

Үлем баржасыннан биш әсирне
чыгарганда бәйләп бер бауга,
җәй иртәсе булган бу кыяда,—
ярты гасыр элек бу тауда.

Ялан аяк менгән сукмаклары
өзелеп калган кыя очында.
Атарга дип тезгән биш әсирне
ак офицер менә шушында.

Күтәрелгән кулы офицерның,
аклар тынган команда көтеп.
Кычкырган ди шунда әсирләргә
оясыннан чыгып бер бөркет.

Ул команда булып яңгыраган,
аңлаганнар аны бу ирләр.
Еракларга соңгы караш ташлап
ташланганнар таудан әсирләр.

Кинәт шашып калган дошман сафы,
кем булды соң монда көчлерәк:
аталмыйча таудан төшкән аклар
җиңелеп кайткан гаскәр төслерәк.

Бөтен дөнья күренә кебек моннан,
бер таралып китсә томаннар.
Большевиклар, кыя бөркетедәй,
еракларга карап торганнар!..

## Үземә

Елларның көннәре,
төннәре үтелгән.
Берсендә сөенсәң,
берсендә үкенгән.

Яшибез икән бит
күптәннән, күптәннән:

яшьлегең аркылы
дәверләр үткәннәр!..

Сана да, сайла да,
мин яшь! дип юанма.
Киләчәк барын бар,
бу көннәр юк анда.

●

Шатлык сүзен кат-кат әйтәм бугай,
хәсрәт сүзен бик еш телгә алам.
Гаепләмә, дөнья,
урталыкта
бәреле-сугыла үсте бу балаң.

Шуңа күрә җаным мескен түгел,
икесен дә татып чыныккан.
...Туңган мәче,
эт баласы күрсәм,
изүемә алып җылытам.

Елар чаклар, бәлки, булыр әле,
елак итә күрмә гомергә.
Көлеп кенә йөрүләре рәхәт,
кеше елаганда көлдермә!

Гаепләмә күңелем нечкәлектә,
синнән җыйган, дөнья, барысын.
Мирас итеп бирдең Җиребезнең
шатлыклары белән сагышын.

Җир бәхеткә чумса,
бу сүзләрем
чүп-чар булып бетсен сибелеп.
...Мең шатлыктан,
мең хәсрәттән туа
тары бөртегедәй игелек!

Кайгылары бәгырьләргә сеңгән,
шатлык сүзен кат-кат телгә алам.
Хәсрәтләре аз булса да җитә,
шатлыкларга мохтаҗ бу балаң!

●

Карга оялары җирдә ята.
Җитмәгән күк дулый җил әле.
Бала кошлар тынган күккә карап,
томшыкларда калган җимнәре.

Җилләр белән очып китте микән
бу бичара бала кош җаны?
...Җилләр — алар үтәүчеләр генә
Үзләре дә язмыш кушканны.

•

Күзге күктә болыт бар,
әллә яңгыр, әллә кар?
Болытлар үтәр әле,
аяз калыр офыклар.

Болытлар авыр инде,
бер килгәч явыр инде.
Болыты үтеп китсә дә,
яңгыры калыр инде.

Күзге күктә болыт бар,
әүмәкләнеп агышы.
Кайгылар үтә-китә,
китәр микән сагышы?

## Мәхәббәт

Үзең коткар бәла һәм афәттән,
ярдәмчем бул,ниләр күрсәм дә,
Тик коткара күрмә мәхәббәттән,
учагында көлгә дүнсәм дә.

*Нури Арсланов.*

Без яратмый Җирдә кем яратсын,
чиге бармы матур хисләрнең?
Сөя алсам шашып яшәп булыр,
мәхәббәтем сүнсә нишләрмен?!

Йөрәгемә салкын су сипсәләр,
бер көнгә дә, бәлки, чыдамам.
Ярым өчен иң зур диңгез кичеп
тере чәчәк алып чыгалам.

Күңел тулса тулсын,
мөлдерәп торсын.
Тамчысына кадәр кадерле.
Без — табигать тажы —
бөре чыга,
чәчәк чыга
тишеп бәгырьне!

Җаным янып сөйсә күтәрермен —
бер бәхетем торсын мең газап.
Кол итсәм дә сиңа мин үземне,
мәхәббәтем бөек һәм азат.

Әкиятләрдә — ул без.
Без — поэма.
Мин ул очам шашкын атымда.
Поэмалар әле язарбыз без
Бөек ратулар хакында.

Таһирлар да, Зөһрәләр дә исән,
Мәҗнүннәр дә йөри табынып.
Мәхәббәткә Җирем батар иде,
бу йөрәгем китсә ярылып!

## Җәйге төн

Ай яктысы су кебек,
нурлар төшә бөркелеп.
Кызлар яна кочакта,
бер елмаеп, бер көлеп.

Килә шомырт исләре,
чәч исләре татлырак.
Күзләрендә ни икән
ай нурыннан яктырак?

Чыклар да төшеп килә,
әйтелмәгән сүз генә.
Күз белән күз сөйләшә;
бәхетледер без генә!

Капка тоткалары ак,
көмеш явып үткәндер.
...Шылтырады тимер бик:
сорамыйча үпкәндер.

●

Килерсең дә кебек,
килмәссең дә кебек.
Көтәм әле, көтәм
газапларга күнеп.

Ах, бу билгесезлек,
ах, бу көтүләре!

Яратулар үтмәс,
яшьлек үтәр әле.

Киткәннәр дә кайта,
юк, син алай итмә.
Тик бер генә кил дә,
Бер тапкыр да китмә.

## Куәт

Көч-хәл белән пычкы сабын тарта
чүкеч сабы хәтле ике малай.
Тамак кырып куәт биреп тора
тешен кысып туксан яшьлек бабай.

## Иске йорт тәрәзәсе

Үзе тузган, үзе кыйшык,
Ялгыз тәрәзе кыек.
Салам башын кыңгыр салып,
иске йорт тора оеп.

Нәрсә яшәртте кич белән
дисәм бу иске йортны...
Ут кабынды.
Тәрәзәдә —
япь-яшь кыз силуэты!

Хәниф Хәйруллин

# КАНАТЛАР ТАЛМАСЫН

ПОВЕСТЬ

## 1



Рамай идарә болдырына чыкты да кесәсендә йөреп таушалып беткән «Беломорканал» пачкасыннан соңгы папиросын алды. Буынланып торган юан бармаклары белән бөтергәләп, иреннәренә эләктерде. Ике-өч тапкыр шырпы сызды, тирән итеп суырды. Ләкин папирос очы, кызарып, ут элдергәндәй итсә дә, кабынмады. Рамай, ни хәл бу дигәндәй, папиросын авызыннан алды. Соңгы папиросы да сынык булып чыкты. Ул аны ачу белән җиргә бәрде. Папирос тәрәзә каршындагы чәчәк түтәле өстенә төште. Әнә ул шау чәчәк сарган яран гөленең нәфис сабакларына кысылып, клумбаның ямен җибәреп тора. «Чәчәк янына чәчәк кенә иш шул». Рамай шулай дип уйлап, болдырдан әкрен генә төште дә, сынган папиросны иелеп алды һәм аны баскыч төбендәге чүп савытына ташлады. Үтереп тартасы килеп китте. Гел шулай: кесәсендә папиросы беттеме, үч иткәндәй, тартасы килә, нәрсәдер җитми, үзе дә сизмәстән, куллары кесәләрен берәм-берәм капшый башлый.

Ичмаса, берәрсе килми микән дип, Рамай, болдырга менеп, йокыдан уянып килгән авыл өстенә күз атты. Әле Атлан тавы артыннан кояш та күтәрелмәгән. Рамай буа өстендәге томан пәрдәсенә карап кашларын җыерды...

Кичә райком бюросыннан соң гына кайтылды. Сәкинәсенә тәрәзә генә шакып, кайтканын белдерде дә идарәгә китте. Төн авышып барса да, колхоз бухгалтеры — мунча ташыдай кара Кәрам — әле һаман счет төймәләре биетеп утыра иде. Рамайның озын гәүдәсе ишектән күренү белән ул башын күтәрде һәм исни-исни:

— Я, тагын күпме бирделәр? — дип сорады.

— Өч мең...
— Күбрәк икән шул...
Бухгалтерга ул артык сүз дәшмәде, үз кабинетына үтте һәм күн итеген салып, күн диванга аякларын бөкләп менеп утырды да, куен кесәсендәге блокнотын алып, ашлык тапшыру буенча инде икенче тапкыр житкерелгән өстәмә планны ничек итеп үтәү турында озак баш ватты. Фуражга аз, бик аз калса да, бу өстәмә планны да үтәрлек рәт бар барын. Ләкин элекке секретарьны обкомга алгач, аның урынына килгән Шәймиевнең сүзе исенә төшкән саен күңеле сүрелә, ул житкергән планны үтәргә кулы күтәрелми генә бит. Барлык председательләр алдында, егерме елдан артык колхоз камытын бер көн дә салмый тарткан кешегә ни диде бит, ә!.. Югыйсә, Рамай киреле-мырлы сүз дә әйтмәде... «Планны да, өстәмә планны да арттырып үтәдек, монысын азрак киметеп булмыймы, Рәшат Галиевич? Кышласы да бар бит әле»,— дип кенә әйтте. Шуңа ни диде бит, ә!..
— Мин сезне хөрмәт итәм, Рамай Ибраһимович. Ләкин сез хәзер аягын үз юрганына гына карап сузган кешегә охшыйсыз. Килешми бу сезгә... Ил масштабында уйларга кирәк. Әллә дан күләгәсендә генә яшәп политик сизгерлегегезне югалта башладыгызмы? — диде һәм, житмәсә, бармагы белән чигәсен бораулап күрсәтте. Бик тә авырткан, бик тә изге жиренә кагылды аның яңа секретарь. Түзмәде, утырган жиреннән генә каршы дәште:
— Как-так политик сизгерлек булмасын минем?..
Әмма Рәшат Галиевич бу репликаны ишетмәмешкә салынды һәм берни булмагандай сүзен дәвам иттерде:
— Житкерелгән задание удар бишкөнлектә һичсүзсез үтәлергә тиеш. Шушы көннәрдә республика дәүләткә ашлык тапшыру буенча рапорт бирәчәк. Безнең район да ил алдындагы беренче изге бурычын үтәгән булырга тиеш. Район партия комитеты, барлык коммунистлар алдында торган кичектергесез бурыч әнә шул.
Ул шулай дип сүзен бетерде...
«Гомуми бурычны дөрес куясың. Ә шулай да нидер житми»,— Рамай күңелендә туган бу уйларын дәвам итә алмады, залдагылар урыннарыннан торып, ишеккә таба киттеләр. Коридорга чыгу белән аны бәтерчектәй бәләкәй генә гәүдәле оештыру бүлеге мөдире Тәлгат Шәяхметов эләктереп алды.
— Рамай Ибраһимович, сезгә калырга, диделәр. Рәшат Галиевичның боерыгы шундый... Үзең дә инде, әзрәк арттырыбрак жибәрдең,— диде. Яшь булса да холкы-фигыле, тыйнаклыгы, бигрәк тә гаделлеге өчен Рамай бу егетне үз итә иде. Аның колхозга беренче килүен әле дә хәтерли Рамай. Килде, танышты. Яз иде. Чәчү чәчәләр иде. Гөнаһ шомлыгына каршы дигәндәй, икенче бригада бригадиры Әхмәтзыянның кызын кияүгә биреп йөргән чагы. Үзе дә салмыш, житмәсә, төнге чәчүчеләрне дә сыйлаган. Кыз биргән көн бит. Тракторчылары иксе дә үз туганнары. Төне буе ике агрегат эшләмәгән. Жен ачуы чыкты Рамайның. Әхмәтзыяны, валлаһи, үзе кебек сау-сәламәт булса, жир башына салып таптый иде. Кулсыз кешегә кулы күтәрелмәде. Аннары, ни әйтсәң дә, янда райком вәкиле, ул белмәгән яңа вәкил бар... Райкомның оештыру бүлеге мөдире. Ул күп төпченмәде, Әхмәтзыяга йомшак кына:
— Кичке тугызларга партком утырышына киләсең,— диде. Планлаштырылмаса да, тәки партком утырышын жыйдырды. Ну, бирде Әхмәтзыяга партком утырышында мөдир. Әхмәтзыянның махмырлары ялт иткәндер. Шуннан соң Әхмәтзыя, уракны бетермичә авызга да капмадым бит, дип сөйләп йөрде. Бу «ЧП»ны Тәлгат райкомда бер кешегә дә әйтмәде, үзенә сеңдерде.
Рамайга бу юлы аның «арттырыбрак жибәрдең» дигән сүзе ошамады. Шулай да сүз куертып тормады. «Калырга дигән икән, калабыз»,—

дип, мөдир артыннан икенче катка күтәрелде. Кабул итү булмасында кеше юк иде. Рамай тәрәзә буендагы урындыкка барып утырды. Урамга күз ташлады. Шул чак кара дермантин белән тышланган ишек ачылды һәм аннан мөдирнең сары бөдрә чәчле башы күренде.

— Керегез, Рамай Ибраһимович,— диде ул һәм, көлемсерәп, бер күзен кысып куйды.

Яңа секретарь килгәч, бу кабинетка кергәне юк иде әле Рамайның. Хуҗа алмашыну белән кабинетлар да үзгәргәнен әллә ничә күргәне бар иде аның. Кабинет үзгәргән иде. Элекке озын, авыр өстәлдән җилләр искән. Күн диван да юк. Бюро уздыра торган өстәлләр тәрәзә кырыена күчерелгән. Секретарь үзе түрдә, тәбәнәк кенә кечкенә өстәл янында утыра. Уң кул ягында, стена буенда, өстәл төсендәге үк тумбочка өстендә — берсе кара, берсе ак телефон. Өстә — Ленин портреты. Стенада игенчелек, терлекчелек үсешен күрсәткән диаграммаларга коңгырт пәрдә эленгән. Районда сөт савып алу барышын күрсәткән барометр гына ачык,— ул элеккечә, үз урынында.

Секретарьны яшь кешедер дип уйлаган иде Рамай. Беренче карашка гына шулай икән. Кара чәчләрендә көмеш бөртекләре ялтырый. Бер як чигәсе бөтенләй көлсуланган. Калын кара кашларыннан да ак төкләр тырпаеп тора. Күз кырыйларын җыерчыклар каплаган. Йөзенә тимгел-тимгел кызыл йөгергән. Төз, юка, нәфис борыны өстендә алсулык тагын да күбрәк. Иреннәре юка, аксыл. Зур башы белән чагыштырганда кечкенә колаклары әллә ничек мәзәгрәк булып тора. Өстендә гадәти кара костюм. Капрон күлмәк якаларын ычкындырып җибәргән. «Трибунадан сөйләгәндә галстугы бар иде бит, кабинетына кергәч салып куйган, ахрысы»,— дип уйлады Рамай. Әһә, әнә, тумбочка өстендә, ак телефон янында ята.

Рамай, сүзсез генә, стена буена тезеп куелган урындыкларның берсенә утырды һәм сораулы күзләрен секретарьга төбәде. Рәшат Галиевич та шәйләп аңа беравык карап торды. Аннары җәһәт кенә урыныннан кузгалды һәм өстәл арасыннан чыгып, Рамайга таба атлый-атлый:

— Рамай Ибраһимович, икебез дә кыздык, без бергә эшлисе кешеләр, гафу итешик. Сез мине, мин сезне,— диде һәм аның янына утырып, сөякчел кулларын Рамайның кулбашына салды. Рамай моны көтмәгән иде, ул ни әйтергә белмичә аптырабрак калды.

— Соң, соң,— диде ул, әле исенә килеп җитмичә,— мин дә бит шул бер үк йөкне тартам...— Планың үтәлсен, аның өстенә планнан тыш ике мең центнер сат, шуның өстенә әле өч меңне дә җиткерсеннәр... Аны да үтәмим дигән сүз авызыңнан чыкмасын... Азрак киметеп булмасмы дигәнгә, иске авызга — яңа аш, менәтерә сиңа, кодагый, дигәндәй — политик сизгерлеген югалткан кеше исеме күтәр...

Рәшат Галиевич, бераз алга иелә төшеп, аның үпкә сүзләрен елмаеп тыңлап торды. Аннары кинәт урыныннан торды да, кабинет буйлап сузылган паластан йөри-йөри, болай диде:

— Сезнең турыда, Рамай Ибраһимович, мин монда килгәнче дә күп ишеттем. Газетадагы портретларыгыздан да таныш сез миңа. Тәҗрибәле оста җитәкче итеп күз алдына китердем мин сезне. Бу районга тәкъдим ясагач та иң беренче сез искә төштегез. Күп язды бит сезнең турыда журналист халкы. Ә менә беренче очрашу... Болай танышырга кирәк түгел иде безгә. Икебез дә тәртәне зиректән бөгеп җибәрдек бугай. Онытыйк бу инцидентны...

Ул кулын сузды. Аның нечкә салкын бармаклары Рамайның көрәк кебек куллары эчендә күмелеп калды. Рәшат Галиевич ялтырап торган өстәле артына барып басты. Рамай да урыныннан кузгалды.

— Менә бу кешечә танышу, югыйсә, күңелгә төер утырган иде... Ярар, сау булыгыз, Рәшат Галиевич,— диде ул, ишеккә таба атлап. Секретарь кулын күтәрде һәм аны туктатып:

— Рамай Ибраһимович, ә нигә теге, әзрәк киметүне сорамыйсыз? — диде. Рамай секретарьга таба борылды:

— Нигә сорарга? Үтибез без аны. Тик кышлыйсы бар, кышлыйсы,— диде ул, авыр көрсенеп.

— Мең ярым центнерны ташларбыз, канәгатьме?

— Канәгать булмаган кая! Ай ярымлык фураж ич ул.

Секретарьның сүзе бетмәгәнен абайлап, Рамай яңадан урындыкка утырды. Рәшат Галиевичның чыннан да сүзе бар иде. Ләкин ул бу турыда тел тибрәтергә ничектер читенсенде, райком секретаре эш стиленә муафыйк булырмы дип уйлады. Ахырда ниятләде:

— Колхоз председательләре турында үз фикерегезне әйтсәгез икән, Рамай Ибраһимович? — диде. Рамайның озын керфекле соры күзләре зур булып ачылды. Мондый сорауны көтмәгән иде ул.

— Рәшат Галиевич, гаепләмәгез, мин пәйгамбәр түгел, аларга бәя дә бирә алмыйм. Аннары сөйлисем дә килми. Һәр председатель үзенчә эшли, расмы? Бер төрле эшләгән бер генә председатель дә юк, максат бер булса да — аңа килү юлы төрлечә, рас, һәр председатель үзенчә килә аңа,— диде ул. Рәшат Галиевич аны, юка иреннәрен кысып, игътибар белән тыңлады. Аннары нечкә ак бармакларын өстәл өстендә биетеп:

— Дөрес. Әмма мин кеше буларак нинди.ләр дип сорыйм,— диде.

— Барысы да кеше. Кешелексез кешене председатель итеп тотмыйлар хәзер. Ул заманнар үтте. Ай, үзгәрде хәзер кешеләр. Рәшат Галиевич, колхоз җитәкләве, рас менә, ай, авырайды. Баштан сыйпап, «апаем, гөлием» дип кенә эшләтәбез хәзер. Элек команда гына бирә идең, попробуй үтәмәскә!

Секретарь көлеп җибәрде.

— Их, Рамай Ибраһимович! Сез бигрәк тагын, элекке белән хәзергене чагыштырасыз. Мин дә ул чорларда эшләгән кеше бит, күктән төшмәгән, беләм. Нәрсәсе бар иде колхозның 1953 елга кадәр?

— Юк иде. Үзем эшләгән кеше ул чорда. Бүгенге көнгә кадәр килүе авыр, ай, авыр булса да, председатель өчен хәзер эш аеруча кыен. Эшләмәгән кеше генә белми аны.

Рамай салам эшләпәсен кулына алды. Яңа секретарь аны ишеккә чаклы озатты. Аңлаштылар да, аңлашмадылар да кебек тоелды Рамайга бу сөйләшү. Ул икенче каттан йөгерә-йөгерә төште һәм урамда үзен көтеп торган «Волга»га таба ашыкты. Шофер Дамир «Чаян» журналын битенә каплап, арткы утыргычта йоклый иде. Бер дәшү белән ул сикереп торды һәм авызын тотып исни-исни:

— Озак тордың, башкалар күптән китеп беттеләр инде,— диде.

Юл буе беренче секретарь белән булган әңгәмәне уйлап кайтты Рамай. Артыгын ычкындырмадыммы дип һәр сүзен искә төшерде. Ул күзләрен йомды. Шундук күз алдында Рәшат Галиевичның гәүдәсе пәйда булды.

«Нәрсәсе бар иде колхозның 1953 елга кадәр?.. Нәрсәсе бар иде?»

Колакта аның әнә шул сүзләре яңгырап киткәндәй тоелды. «Нәрсәсе бар иде?» — Рамайның алсу иреннәре әнә шулай дип пышылдады һәм тигез юлдан җай гына элдергән «Волга»да бишектәге сабый кебек йокымсырап, ул уйлар дәрьясында тирбәлә башлады.

...Иске мәчет бүрәнәләреннән укмаштырып салынган клубта җыелыш бара. Ике-өч җирдән терәү салынган матчадагы ыргаклы тимергә эленгән җиделе лампа, һава җитмәүдән, еш-еш күз кысып ала. Халык ялыккан, кайсы керә, кайсы чыга. Арттагылар, стена кырыена чүгәләп, тәмәке пыскыта. Менә җыелышны алып баручы райком вәкиле — чәчләре керпе энәсе кебек тырпаеп торган бәләкәй генә кеше — мәгариф бүлеге мөдире трибунага күтәрелде. Залдагылар бер мәлгә тынып калдылар. Тик артта Заман карт кына корык-корык ютәлли.

— Иптәшләр,— диде райком вәкиле, орчык буе гына булса да, тамак төбеннән гөрелдәп чыккан калын тавыш белән,— Шәехзада абзый картайды. Председатель камыты инде аңа авыр. Соңгы мәсьәлә — яңа председатель сайлау. Я, кемне тәкъдим итәсез?..

Беравык сүз катучы булмады. Президиумда, өстәл артында утыручы Шәехзада абзый урыныннан торды, залдагыларны берәм-берәм бөртекләп карап чыкты да:

— Җәмәгать, авылдашлар, сез нәрсә әйтерсез, тедгенне Рамайга тоттыру хәерле булмасмы? Булдырырга охшый. Ферма мөдире, партоешма булып начар эшләмәде, күз алдыгызда... Ә иң самые — яшь, энергичный кеше, ут-суын да кичкән иптәш,— диде. Ул урынына утырырга өлгермәде, зал, оясы туздырылган умарта күчедәй, гөжләргә тотынды:

— Дөрес, Шәехзада абзый!..

— Ибраһим малае тартачак!

— Атасы мәрхүмгә охшаса, ил җанлыклы булыр...

— Ничу сузарга, әйдә сайлыйк та, вәссәлам!

— Бергә үскән читкә типмәс әле!

— Бәхил, әйдә тавышка куй!..

Райком вәкиле кулын күтәреп, инде тавышка куям дип авызын гына ачкан иде, шул чак ишек янында басып торучы Заман картның чәрелдек нечкә тавышы ишетелде:

— Җәмәгать, постой! Вапрус бар...

Шәехзада абзый утырган урыныннан кузгала төште. Ул арада райком вәкиле:

— Әйдә, бабай, әйдә, бир соравыңны,— диде. Заман карт, бүреген култык астына кыстырып, халыкны ера-ера алга үтте. Президиум өстәленә бүреген куйды да Рамайга күз кысып (ул да президиумда иде), пышылдап кына:— Быел аткан төлкедән тегелгән бүрек, кара аны, чәлдермәсеннәр,— диде дә залга борылып чәрелдәп җибәрде:

— Шундый вапрус, җәмәгатьләр! Ник өйләнми ул Рамай?

Залдагылар көләргә тотынды. Шәехзада абзый түзмәде, торып басты һәм җиз кыңгырауны чыңлатып алды да:

— Даман абдый, кәнкритрәк кил әле, кәмит ясама, болай да соңладык, иртәгә куярсың кәмитеңне,— диде. Заман карт аңа борылды, бер кулын президиумга, берсен залга таба сузып, тагын нидер әйтмәкче булган иде, Рамай кандидатурасын тавышка куйдылар. Куллар югары сузылды. Райком вәкиле:

— Ә каршылар? — гына дигән иде, тагын Заман карт чәчрәп чыкты һәм бүреген югары күтәреп:

— Принципиан каршы, пртакулга да шулай дип яз,— диде...

— Димәк, бер каршы белән, «1 Май» колхозының яңа председателе итеп Вильданов Рамай Ибраһимович сайланды,— диде. Аннары сүзне Рамайга бирделәр. Бик тә дулкынланып чыкты ул трибунага. Йөзләрчә күз аңа төбәлгән, өмет, ышаныч белән төбәлгән. Аклый алырмы ул буразнада бергә аунап үскән авылдашларының бу олы хөрмәтен?

— Ышанычыгыз өчен рәхмәт, авылдашлар,— диде ул, тамак төбенә төйнәлгән төерне көчкә үткәреп җибәреп,— көчемне кызганмам. Белмәгән җиремне өйрәтсәгез, ялгышканда сугып екмыйча ярдәм кулы сузсагыз, рас, бергә-бергә эшләрбез.— Ә Заман картка ул болай дип җавап бирде:— Заман агай, синең дә күңелең тынычлансын. Сәкинә белән безнең арадан җил дә үтмәс. Мондый сүзне беркем дә җыелышта, трибунага чыгып әйтми торгандыр. Ә мин әйтәм, сер булса да әйтәм: күп калмады инде, яңа елда туй ясыйбыз дип торабыз. Рәхим ит, Заман агай, баш кода бул, урының түрдән булыр, рас менә!

Ул сүзен бетерүгә, кемдер кул чаба башлады. Аңа Заман карт та

кушылды, култык астындагы бүреге идәнгә төшеп китүен дә абайламады.

— Вәт, маладис! Әй, сәркәтип, пртакулдан «каршы» дигәнен сыз! Мин каршы түгел хәзер! Кайтышлый ук Сабир яшьти янына сугылам! — диде.

Халык тагын бер күтәрелеп көлде.

Клубтагы җиделе лампаны Рамай үзе сүндерде. Соңгы кеше булып клубтан райком вәкиле белән ул чыкты. Бу 1949 елның декабрь төне иде.

Элекке председатель Шәехзада абзый белән алыш-биреш тиз ясалды. Хәер, сузарлык нәрсәсе бар иде соң аның? Утыз алты баш сыер малы, тугыз баш дуңгыз, бәрәннәре белән 90 баш сарык, ике дистә тавык, аннары хуҗалык саен таратылган ат, аз-маз фураж да чәчүлек орлык. Мал-туар колхоз оешкач та саман кирпечтән салынган абзарга шыплап тутырылган. Алыш-бирешне тәгәлләп, колхоз печәте салынган кара бәрхет янчыкны кесәсенә салып куйгач (Шәехзада абзыйның бу гадәте аңа да күчте), иртә таңнан шул ферма дип йөртелгән утарларга таба атлады.

— Булдырып булырмы?.. Гел болай яшәп булмый бит инде... Шундый михнәтләрдән соң адәм рәтле яшәмәсәң? Яшәргә кирәк... Их, ниләр күрмәдең син авыл, туган авыл!..

Әнә шундый уйлар Минзәлә елгасы буена сыенып утырган бәләкәй генә авыл, аның кешеләре язмышы төйнәлгән тарих йомгагын сүтеп җибәрде.

Революциягә кадәр дә, әле күмәк хуҗалыклар — колхозлар оешканчы, тернәкләгәнче алар авылы бөтен тирә-якка көтүчеләр биреп торган. Рамай үзе хәтерләми, атасы мәрхүмнең сөйләгәне әле дә колакта: «Ишек төбенә чыпчык эчәрлек су җыела башлау белән авыл өстендәге Ясмык тавы кардан ачыла торган иде. Шунда авылның барлык ярлыябагае — алтмыш-җитмеш кеше җыела торган иде. Аннан китә иде, мин сиңа әйтим, кыш буе үргән чыбыркыларны шартлату. Янәсе, кемнең чыбыркысы катырак шартлый. Аннары шобага салышып авыллар бүлешә идек тә, акчарлаклар кебек, төрлебез төрле якка тарала торган идек. Кара көзсез авылга кайту юк. Мирдән җыелган ашлык хут суыклары үтүгә бетә иде. Ничек яшәлгән?.. Хәзер, аллага шөкер, тамак әпәйгә туйды...»

Колхозлар оешкач, өйалдындагы балчык бураларга ипи кайтып тулгач, гел шулай шөкерана итә иде әтисе мәрхүм.

Тормыш дигәне рәтләнә башлагач, аны армиягә алдылар. Шуннан сугыш чыкты. Кайтыр көннәре дә якынлашып килә иде, югыйсә...

«Рамай!

Исәнме, бәгърем! Сезки Кызыл Армия сафларында хезмәт итүче бердәнберем, күз нурым, йөрәк сулышым, минем якты киләчәгем, матурым-багалмам! Безки монда авылда, сезнең нурлы йөзегезне бер күрергә, балдай татлы, тәмле телләрегездән агылган сүзләрегезне ишетергә зар-интизар булып йөзенә лимон сарылары коелган Сәкинәң дип белерсең.

Бәгърем! Бу хатларым инде соңгысы булсын, тизрәк үзеңнәр кайтсаң иде. Срогың туларга бер атна гына калды бит. Юлда ике-өч көн булсаң да, сабан туйларга өйдә булмассыңмы... Ничек тә сабан туена кайтып җитәргә тырыш... Белсәң иде, сабан туй көннәрендә баласын җуйган аккошлар кебек каңгырып йөрүләрнең читенлеген! Барысы да парлы-парлы, миннән дә бәхетсез кеше бармы дип, узган ел сабан туена да чыкмадым бит (бу турыда язган идем, беләсең инде).· Их, кайталсаң иде, бәгърем, сабан туйларына... Мин хәзер ялда, укытулар бетте. Укыткандa әле эш белән мавыгып, көннәрне ничек тә этеп-төртеп булса да үткәрә идем... Ә хәзер, хәзер бер минут истән чыкмыйсың.

Йөргән сукмакларыннан көн дә синең эзләреңне эзлим. Урамга чыгу белән капка төбендәге, без бергә утырып алсу таңнар аттырган, теге сандык чаклы ташка карап, күңелләрем тула. Кичләрен анда чыгып утырып, син утырган урыннарны иркәләп сыйпыйм, синең белән серләшәм.

Рамай!

Үзәкләремне өзгән бер яңалыкны әйтәм. Авылда ниндидер яңа җыр җырлый башладылар. «Рамай» дигән. Нәкъ минем өзгәләнүләремне, төпсез күл кебек тирән сагышларымны көенә дә, сүзләренә дә мөлдерәмә тутырган. Кичке уеннан егетләр җырлап кайтканда ишеттем мин аны беренче кат. Хәзер ул минем колак төбендә өзлексез яңгырый. Җырлап күрсәтимме:

Төнгә каршы берәү
Моңлы итеп, Рамай,
Айрылышу көен уйнады.
Тынга калды урман
Буйлары да, Рамай,
Чишмәләр дә акмый тыңлады.

Көчкә язып бетердем, күзләремне яшь пәрдәсе каплады... Юк, тыела алмадым, иреннәремне кан чыгарлык итеп тешләсәм дә түзә алмадым... Гаепләмә, сиңа язган хатыма күз яшьләрем коелды (юньле кәгазь тапмаган дип ачуланма). Их, Рамай, Рамай!»

Сәкинәсенең өзелеп-өзелеп язган менә шушы хатын ул сугыш башланган беренче көнне укыды.

Сәкинәгә аны бик-бик озак көтәргә туры килде.

Ул Минзәлә елгасы буендагы туган-үскән авылына Берлин аша гына кайта ала булып чыкты...

## 2

Бер очын электергәч, уйлар йомгагын сүтә-сүтә, авыл ягына карап торды Рамай. Әнә техника паркына да җан керде. Кайсыдыр, «Беларусь»ын кабызып, Атлан тавына таба китеп барды. Ниһаять, озын тыкрык башында бухгалтер Кәрамнең гәүдәсе күренде. Ул, таягына таянып, чатанлый-чатанлый бара. Рамай, болдырдан төшеп, аның каршысына китте. Бухгалтерның сәламенә ияк кенә какты да:

— Кая, тартырга бир әле, гел баш эшләми, коточкыч тартасы килә,— диде. Кәрам «Беломор» пачкасы сузды. Рамай берне алып, бармакларында әвәләгән иде, папирос тагын сынды.

— Нәрсә соң бу, сына да сына,— дип, сукранып, ул икенче папирос алып кабызды. Иркенләп бер суыргач, Кәрамнан сорады:

— Тапшырырдай күпме ипи бар?

— Ике мең тирәсе булыр. Әле тарыны сугасы бар.

— Да-а! Тагын такы-токы кала болай булгач...

Бухгалтер идарәгә кереп китте. Рамай болдырда басып калды. Кинәт тагын Рәшат Галиевичның: «Нәрсәсе бар иде соң колхозларның 1953 елга кадәр»,— дигән сүзләре исенә төште. Папирос башындагы көлне бармак очы белән җинелчә генә кагып җибәрде дә авыз эченнән генә: «Ә бит шул колхозлар булмаса, без җиңеп чыга алыр идекмени?.. Элекке, аерым хуҗалыклар заманы булса... Сугышка чаклы колхозларның аякка баскан иде шул. Сугыш вакытында да халык барлык икмәкне авызыннан өзеп фронтка бирде. Үлем дигәне белән әллә ничә кат күзгә-күз очрашса да, биш ел буе ачлык дигәнен күрмәде Рамай. Кем туйдырган аны? Менә шушы авылдашлар, шушы колхоз кешеләре!.. Юк, илле өченче елга кадәр дә колхозларның ние бар иде! Шул ел-

лардан ук ныклы нигез салып килдек без бу көннәргә. Илле өченче елда безнең колхоз, мәсәлән, чынлап торып аякка басты. Ипи ашамаган бер йорт та калмады. Шул көзне, Минзәләне буып, электр станцасы эшләтә башладык. Район колхозларында Ильич лампалары иң элек бездә кабынды...»

Аның уйларын бухгалтерның ачык тәрәзәдән кычкырган тавышы бүлде:

— Иптәш председатель, сине сорыйлар, райкомнан!..

Рамай папиросын сүндереп чүп савытына ташлады да йөгереп бухгалтер бүлмәсенә керде.

Трубкада райкомның беренче секретаре иде. Исәнлек-саулык сорашкач та Рәшат Галиевич:

— Әллә йокладыгызмы? — диде.

Трубкада әллә нәрсә чытырдый иде, Рамай, аңа өрә-өрә, кычкырып:

— Йоклый торган чакмыни хәзер, сезнең яннан кайткач монда гына черем иткән идем,— диде.

Секретарь беравык дәшми торды, аннары уенын-чынын бергә кушып һәм «сездән» «сиңа» күчеп:

— Кара, Рамай Ибраһимович, Сәкинәң колагыңны бормасын, үзең генә идарә сакладың микән? Төнге сәяхәтләрне ярата дигән хәбәрләр дә бар монда. Сак бул, инцидент чыкмасын!

Секретарьның сүзләреннән мәгънәсен әллә ни аңлап та бетермәде Рамай, яңа гына килүенә карамастан, хатынының исеменә чаклы белүенә исе китте.

— Кайтканны белдердем мин аңа... Кая безгә сәяхәт ди ул, Рәшат Галиевич, кызны кияүгә бирергә йөрибез инде хәзер,— диде ул секретарьның ишарәсенә каршы.

Трубкадан йөткереп алган тавыш ишетелде.

— Менә нәрсә, Рамай Ибраһимович, ашлык чыгару өчен өстәмә автоколонна килде. Сиңа егерме машина җибәрәбез. Ике көндә өч мең центнерыңны чыгарып бетер. Уңышлар телим!..

Рамай бу ни дип авызын ачарга өлгермәде, секретарь трубкасын шап итеп куйды. Председательнең калын кара кашлары ук җәяседәй киерелде, шома, киң маңгаена җыерчыклар өелде, җилдә, кояшта йөреп, бронза төсенә кергән бит очларына аксыл тимгелләр бәреп чыкты, телефон трубкасын тоткан кулы әкрен генә дерелди иде.

Председательнең яңа секретарь белән сөйләшүен тыңлап утырган Кәрам урыныннан торды.

— Нәрсә бар, Рамай? — диде ул йомшак кына.

Рамай, төшен кысып, телефон трубкасын ташлады.

— Иске авызга яңа аш, менәтерә, сиңа, кодагый!.. Кичә төнлә генә үзе мең ярымын ташларбыз диде, инде кояш чыгуга ул өч меңгә күтәрелсен. Обстановка үзгәрергә дә вакыт юк, обкомнан звонок булырга әле иртә,— диде ул Кәрамга. Аннары, заманында сумаладай кара бөдрә булган, хәзер исә чаларган чәчен биш бармаклап тарый-тарый, урам як тәрәзәсенә карап торды. Торды да капыл гына телефон трубкасын алды. Синең йөрәк янганда коммутатордагы кызларның йоклавын әйт әле син. Дәшмиләр генә бит. Рамай юан бармаклары белән мәче борыны кебек кнопкаларга ачу белән әллә ничә кат басып алды. Ахырда коммутатордагы дежурный җавап бирде.

— Әйе!..

— Кысталсаң, урыныңа кеше куеп кит, үскәнем...

— И-и-и! Рамай абый, көлмәсәнә!..

— Көләргә түгел, еларга да вакыт юк әле... Үскәнем, беренче секретарь белән ялга әле мине.

Рәшат Галиевич шундук җавап бирде.

— Беренче секретарь тыңлый.

— Рәшат Галиевич, бу мин әле, «1 Май»дан Вильданов,— дип ашыга-кабалана сөйләп китте Рамай.— Кичә генә мең ярымны ташлыйбыз дигән идегез. Бүген тагын өч мең дисез. Ялгыш ишетмәдемме, әллә кичәге сөйләшүне сез хәтердән чыгардыгызмы икән дип шалтыратуым әле.

Трубкадан кискен тавыш яңгырады:

— Рамай Ибраһимович, ул ипи миңа кирәк түгел, барысы да граммына чаклы дәүләткә! Аңлыйсызмы? Дәүләткә!

— Аңлыйм, Рәшат Галиевич...

— Аңласаң, бәхәсләшмә, кушылганны эшлә!

— Бәй, иртәнге акыл кичкә ярамаган, дия торган иде безнең эти мәрхүм...

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, телефон мембраналары бии башлады.

— Рамай Ибраһимович, хәлләр минутлап үзгәрә хәзер... Ашлык тапшыру чоры.

— Соң, килешкән идек ич... Безнең план үтәлгән, артыгы белән. Безне кысу дөрес түгел бит инде, Рәшат Галиевич...

— Нәрсәнең дөрес яки дөрес түгеллеген ачыклауны безгә калдырыгыз. Кушылганны эшләгез. Бюро алдына басасыгыз килмәсә, тапшыр әйтелгәнне. Кабатлап әйтәм, үземә сорамыйм, барысы да дәүләткә бөртегенә кадәр. Аңлашылдымы?..

Рамай үзен тыныч тотарга тырышты. Иренен кан чыгарлык итеп тешләп алды да:

— Аңлашылды, Рәшат Галиевич, партия, Ватан сорый икән, өч меңне генә түгел, бура тәбен себереп тә биреп бетерербез. Ә ашлык тапшыру белән районның да, республиканың да нинди хәлдә булуын мин шәйлим. Өч меңне миннән партия дә, хөкүмәт тә сорамый һәм сорамаячак хәзер. Сорардайлардан сорарга кирәк, Рәшат Галиевич... Ә бюро белән өркетмәгез, райком бюросы бөкәй түгел ул...

Тагын әйтәсе сүзләре бар иде әле Рамайның, ләкин секретарь аны тыңламый иде инде. Рамай микрофонга карап торды. Аннары трубканы, уалып китә торган әйбер кебек, әкрен генә рычаг өстенә куйды.

Шул чак күзләрен уа-уа Дамир килеп керде. Председательнең сөмсерләре коелганын күргәч, ишек янындагы урындыкка гына утырды да:

— Рамай абый, мин әзер, кая барабыз? — диде.

Рамай аңа дәшмәде, бухгалтер каршысына килде дә өстәл өстендәге счет төймәләрен тарта-тарта болай диде:

— Кәраметдин, мин Атлан басуындагы тары җиренә китәм. Син хәзер үк ындыр табагына элдер. Хәзер егерме машина киләчәк. Теге, амбар алдындагы бодайны берүк төятмә. Колхозчыларга ул. Аннан да әйбәт бодай калмады хәзер... Шуны тизрәк өләшеп бетерә алмадыгыз. Нишли соң сезнең бухгалтериядәгеләр? Бер атна элек әйттем, исәпләгез, исемлек чыгарыгыз дип...— Ул бухгалтерны да тиргәп ташлады.— Килгән машиналарга ындыр табагындагы, капканы кергәч тә уң яктагы көшелдән төятегез. Аның дымлылыгы 18 процент кына. Скидкасы аз булыр.

Кәрам папкалары арасыннан бер кенәгә алып, аны председательгә сузды.

— Менә, исемлек әзер инде, кул куй...

Рамай аңа кул куйды да Дамирга, әйдә киттек дип, башы белән ымлады. Ишектән чыкканда Кәрам туктатты.

— Рамай, алган кешегә ипине бүген үк җибәрә башлыйбыз, алайса. Тик күбесе вакыт юк ди бит әле аның, алмыйлар. Бигрәк тә механизаторлар.

— Механизаторларныкын амбарга тутырт. Үзең беләсең, ындыр табагында ипи чәчелеп ятмасын. Аңа кызыгучы күзләр күп булыр хәзер.

— Ярар, сводка гына бирәм дә шулар белән мәшгуль булырмын инде мин бүген.

Рамай белән Дамир чыгып киттеләр. Кәрам, капкач кебек кара сакал баскан яңагын ышкып, счет төймәләре тартырга тотынды. Район авыл хуҗалыгы идарәсеннән сораячак оператив мәгълүматларны туплады. Ул да булмады — телефон шалтырады. Кәрам телефонга үрелде. Сводка биреп бетергәч, култык астына ашлык өләшү кенәгәсен кыстырып, кәкре башлы таягын электерде дә ындыр табагына таба юл тотты. Каршысына зоотехник Һәнүз килеп чыкты. Аның күз кабаклары шешенгән. Кара күлмәгенең җиңнәрен сызганган. Чалбары бөгәрләнеп беткән, салмыйча гына йоклаган булса кирәк. Дулкынланып торган озын сары чәчләре тузгыган, тарап та маташмаган.

— Исәнме, Кәрам абый, кая чабасың? — диде ул, кирәктәй олы кулларын сузып. Кәрам аңа ияк какты, кул бирмәде. Бирсәң, сөякләреңне чытырдатып кыса — гадәте шундый. Аңа кеше кул бирми.

— Ындыр табагына, минә күрәсеңме, колхозчыларга ипи бирәбез,— диде.

— Ә, алай икән, болай икән, нигә түбәсе калай икән?..— Һәнүз шулай дип башына сугып алды һәм уйнап торган соры күзләрен кысып:— Кәрам абый, гүрләргә кергәндә дә онытмас идем. Ике сум гына сос әле. Кәгазь булса да, көмеш булса да ярый,— диде.

— Соң, ярлы кеше тавыгы кебек, иртүк әчкәнсең бит инде.

— Билләһи, валлаһи, Кәрам абыкаем, кичәге ул.

— Алдашма, исе бик яңа тоела.

— Менә инде!

— Я, йөрмә әле эч пошырып, таң яралмас борын!

— Үтермә, Кәрам абый, ипидер. Бер «Анап» кына бөклим дә Бөгелмәгә китәм. Дуңгызлар илтергә. «Жирный»га тапшырмасам шуларны, күрерсең!

— Дуңгыз тощой була димени, әкият! Җитмәсә, безнең дуңгызлар!..

— Я инде, Кәрам абый, сос инде. Иртәгә үк бирәм, акча алабыз бит иртәгә.

— Юк, бирмим, Нәсимәң бирмәскә кушты. Общем, зарплатыңны да хатыныңа бирергә кушты әле председатель.

Һәнүзнең күзләре зур булып ачылды, йөзенә гаҗәпсенү чыкты, кан качкан аксыл иреннәре дерелдәп куйды:

— Ничек инде ул?.. Мин эшләгәнне хатынга бирергә? Хакың юк! Үзе эшләп алсын.— Һәнүзнең йөзенә кинәт мескенләнү галәмәте чыкты, күзләре кысылды.— Ярар, чорт с ним, бирерсең лә. Я, сос инде ике тәңкәңне...

Бирмәсәң көне буе артыннан ияреп йөриячәген, янсә барыбер кассир кылу белән аннан алачагын белеп, Кәрам ахырда аңа ике сумын бирми булдыра алмады. Акча кулга керү белән Һәнүзнең йөзе кояш чыккандай яктырды. Ул ике бармагы белән салют бирде дә авыл ягына, кибетче өенә таба китеп барды.

Эчмәсә әйбәт кенә малай үзе. Башлы малай. Эш дигәндә үлеп тора. Әз генә буш вакыты булдымы — эчә, мәртәт, көн дими, төн дими. Нинди бәндәдер. Уянса, төнлә торып эчә ди Нәсимәсе, хак булса. Бер стаканны каплый да гырлап йокыга китә, ди. Айлар буе янымда да ятканы юк, ди Нәсимәсе, елый, мин дә ир белән торам инде, ди.

Кәрам ындыр табагына килеп җиткәндә былтыр гына файдалануга тапшырган ашлык чистарту агрегаты гүләп эшләп утыра иде инде. Капка төбендәге будкада, киез эшләпәсен күзенә төшереп, бишмәтен иңенә салып, Заман карт йоклый. Ындыр табагында тәнге каравылда

тора ул. Анда беренче олау кайткан көннән башлап, ашлыклар урнаштырылып бетмичә өенә таба борылып та карамый ул. Ун ел шулай. Иртә-кич Хупҗамалы төенчек белән ашарына китерә. Ә көндезен ындыр табагында эшләүчеләр өчен пешкән ашка катнаша.

Кәрам аның борын сызгырта-сызгырта меснәвенә карап алды да ачык ишектән үрелеп:

— Ашлыгыңны урлыйлар бит! — дип кычкырды.

Заман карт сискәнеп китте, башындагы киез эшләпәсе очып төште. Ясмык кебек яшькелт күзләрен челт-челт йомгалап алдында басып торган Кәрамга кулындагы озын таягы белән кизәнде.

— Чегән токымы, аксак җен! Шундый төшемне бүлдердең!.. Хупҗамал әбиең белән оҗмахка кереп бара идек,— диде, саргаеп беткән алгы ике тешен ыржайтып. Кәрам кәлә-кәлә амбар алдында өелеп торган бодай көшеләнә таба атлады. Шул чак ындыр табагы капкасы төбенә зәңгәр «Волга» килеп туктады. «Райком машинасы»,— Кәрам шулай уйлап, капкага таба юнәлде. Машинадан юка, озын гәүдәле кеше төште. Ул кара болоньи плащтан, ялан баш иде. «Яңа секретарь дигәннәре шушыдыр инде»,— диде Кәрам эчтән генә. Чыннан да шулай булып чыкты.

— Рәшат Галиевич Шәймиев — сезнең яңа секретарегыз! — дип, ябык, нечкә бармаклы кулын сузып исәнләште ул Кәрам белән.

— Кәрам Фәрхетдинов — колхозның баш бухгалтеры.

Алар күзгә-күз карашып тордылар. Ул арада алар янына Заман карт та килеп җитте. Ул, эшләпәсен күтәрә төшеп, секретарьга кулын сузды.

— Заман бабаң булырбыз без, ягъни мәсәлән, дөнья куучы,— диде ул, сирәк кәҗә сакалын сәлперәйтеп. Секретарьның зәңгәр күзләренә елмаю чаткысы чыкты.

— Шәймиев,— дип, ул Заман карт белән ике куллап күреште һәм:— нишләп йөрисең монда, бабай? — дип сорады. Заман картның авызы ачылды, алдагы ике теше ыржайды.

— Бәрәкалла? Рамай олан әйтмешли, менәтерә, сиңа, кодагый, иске авызга яңа аш! Заман карт нишләп йөри димени? Шуны белмәс кешеләр дә бар икән әле бу дөньяда,— диде һәм үпкәләгән кеше сыман йөзен читкә борды. Шәймиев чыннан да картның кәефен җибәрдем, ахрысы, дип, сүзенең итәкләрен җыярга теләп:

— Бабай, сез дөрес аңламадыгыз, ахры, минем сорауны... Мин: «Әле нишлисез соң?» димәкче идем,— диде. Заман карт секретарьга ялт итеп борылды һәм башын юләргә салып:

— Әңгерә шалканга әйләнгән инде баш дигәне, иптәш нәчәлник. Гаепләнмәссең. Аннары кайсы ничек сүләшкәнен шәйләп бетерәсең ул нәчәлникләрнең. Убуркы башлангач, кем килә дисәң, вәкил килә, кем килә дисәң, нәчәлник килә. Барысының да авызы әпәй белән ачыла. Ә мин берүзем. Пробуй барысының да уйнапмы-уйлапмы сүләшкәнен белергә. Тавык мие чаклы гына миле башың белән һәрберсенә әтвет тап. Ишшу, Рамай олан күңеленә ярарлык итеп тап. Ул бит миннән төннә кемнәр килгәнен, ипи турында аларның ничек сүз куертканнарын әбизәтелне сорый...

Заман карт тыңлап торучы табылганга куанып, әле тагын сөйли иде, Атлан тавыннан тары төяп кайткан машина сигнал бирде. Капка алдыннан өчесе дә читкә тайпылдылар. Машина эчкә үтте. Шәймиев, ындыр табагындагылар белән баш иеп исәнләшә-исәнләшә, машина артыннан китте. Кәрам белән Заман карт та аның артыннан ияределәр. Кәрам, күп теленә салынма син, дип, Заман картка йодрык күрсәтте. Тегесе исә аны бар дип тә белмәде. Үзбушаткыч машинадан шыбырдап җиргә коелган тары чиста ләйсән кебек елкылдап тора иде. Шәймиев

аның өстенә иелде һәм, дымлылыгын белергә теләп, шыбырдап торган өемгә кулын тыкты, бер-ике-өч бөртеген тешләп карады.

Аны карап торган Заман карт кинәт кеткелдәп көлеп җибәрде һәм Шәймиевкә эндәште:

— Ибдәш нәчәлник, әллә әчегәнме?

— Юк, бабай, нишләп әчесен ди, басудан әле яңа кайтты бит,— диде секретарь. Заман карт авызын ера бирде:

— Син аны, ибдәш нәчәлник, ныграк чәйнәп кара, нык пробит ит, тешләр амандыр бит әле,— диде ул, Шәймиевнең алдына ук килеп, үзе керфексез күзләрен челт-челт йомды. Шәймиев тары бөртеген алып, тагын аны авызына якын китерде, ләкин капмады, иснәп карады да елмаеп:

— Бабай, свежий бу, нишләп әчесен! — диде. Заман карт озын кулларын болгап җибәрде һәм:

— Әпекәй исен иснәгән кешегә охшыйсың олан, молодчина! — диде.— Ату монда кемнәр генә килми. Бу бәбәкләрем кемнәрне генә күрмәде инде минем! — Ул кәкрәеп каткан бармаклары белән күзенә төртеп күрсәтте дә, аяк астында аунап яткан ындыр себеркесен иелеп алып, ике куллап аңа таянды һәм кырында торучы Кәрамга акаеп карады. Тегермән кавызынны яп дип, Кәрам аның бишмәт итәгеннән тарткан иде, Заман карт шым булды.

Шул вакыт ындыр табагы алдына автомашиналар колоннасы килеп туктады. Шәймиев Заман картка кулын сузды да машиналарга табан китеп барды. Аның артыннан, кулэгә кебек, Кәрам да нярде. Машина рулендә солдатлар иде. Алдагы машина кабинасыннан кояшта каралып беткән бер өлкән лейтенант чыкты. Безнең як кешесенә охшамаган, грузинмы, әрмәнме. Ул Шәймиев белән нәрсәдер сөйләште. Кәрам секретарьның:— Әйе, шушыннан төйисез,— дигән сүзен генә ишетеп калды. Шәймиев Кәрамга таба борылды да:

— Рамай Ибраһимовичны табасы иде бит. Машиналарны көттерергә ярамый, кая, нәрсә төятәсез? — диде.

— Рамай Ибраһимович тиз генә булмас, ул каян төяргә икәнен миңа әйтеп китте. Менә шушы көшелне озатабыз,— диде Кәрам, капка алдында өелеп торган бодайны күрсәтеп. Машиналар борылып кергәнче, ашлык төягеч тә эшли башлады. Гәрәбәдәй бөртекләр белән кузовлар бер-бер артлы тулып торды. Машиналар, автоулчэгеч аша үтеп, Чаллы юлына да чыга башладылар. Егерменче машинаны төягәндә көшелдә ашлык аз калган иде инде. Ындыр табагында кешеләр белән сөйләшеп йөргән Рәшат Галиевич та моны шәйләде. Ул автоулчэгеч янында торган Кәрамга таба атлады. Килеп җиту белән кырыс кына:

— Икенче рейска тагын каян төйисез? — дип сорады. Кәрам аңа сораулы күзләрен текәде һәм:

— Шул көшелдән башка төятер әйбер юк инде,— диде.

— Ә бу нинди бодай? — Секретарь амбар алдындагы бодай көшеленә төртеп күрсәтте.

— Анысы, иптәш Шәймиев, симәнәгә.

— Беләм мин сезнең симәнәләрегезне, барлык машиналар да кире монда кайтачак. Аңлагыз, бернинди инцидент чыгарлык булмасын. Төятегез, иртәгә көндезгә уникегә өч мең центнер озатылган булсын. Рамай Ибраһимовичка да шулай диегез!

Кәрам авызын күтәреп бер сүз әйтә алмады, Шәймиев кызу-кызу атлап машинасына таба китеп барды. Заман карт, секретарь машинасы кузгалып киту белән, озын таягын сөйрәп Кәрам янына килде һәм кәҗә сакалын сыпыра-сыпыра:

— Ник бик кырт китеп барды ул? Кем ул? — дип сорады.

— Яңа секретарь шушы бит инде, райком секретаре... Тагын өч мең центнер ипи чыгарырга куша, көшелдә калганы 500 центнердан артмас.

Калганын каян алырга? Менә шул турыда ми черетү,— диде аңа Кәрам һәм амбар алдындагы көшелгә төртеп күрсәтеп,— моңа тотынмый булмый, Заман абзый, ни дисәң дә диярсең,— дип сүзен дәвам иттерде.

Моны ишетү белән Заман картның чырае бозылды. Ул, таягын югары күтәреп, Кәрам өстенә килә башлады, чәрелдек тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Монымы?.. Монымы?.. Аллаһе тәгалә үзе килсә дә бирмим мин бусысын! Әллә Рамай олан иртән монда кагылмадымы, миңа әйтмәде дип беләсеңме син? Бирдерермен, төятермен мин синә бу көшелне! Үдебеднеке бит аның бусысы. Халыкны кышлатыр әпәй!.. Якын гына килеп кара, каланчага менеп бөтен авылга каравыл салам. Тегеш, синә ни, үзеңә чут төймәсе тарткан саен акча килеп торгач та! Без бит әпәйне, акчаны көн-төн эшләп, пустта торып алабыз. Иман җук синдә, камил акылым белән ант итеп әйтәм, әйтсеннәр генә, төятеп җиппәрәсең дип, симәнәңне дә җиппәрәсең, җәлләмисең. Үзем исән чакта якын йогындырамны соң мин бу көшелгә! Пустымда үләм, әмма ләкин, бу көшелгә тигермим. Колхозчыныкы, безнеке ул!

Кәрам, кет-кет көлеп, чыгырыннан чыгып барган Заман картның җиңеннән тартты һәм колагына гына пышылдап:

— Теге машиналар борылып кайтканда мин моннан таярмын, син килгән шоферларга моннан төятмә, кәмитләп, полный право, яме?.. Ә аңарчы мин килгән кешегә ашлык җибәрә торам,— диде.

Бу сүзгә Заман картның кәефе килде булса кирәк. Ул күкрәген киерде, башын югары күтәрде һәм Кәрамга серле генә итеп күз кысты да амбар алдындагы әлеге көшел өстенә менеп утырды.

Өйлә вакытлары узганда Чаллыга киткән машиналар икенче рейска кайтып життеләр. Икешәр күчәрле зур хәрби машиналар көшелдәге бодайны ялмап кына алдылар. Әле тагын алты машина буш тора иде. Солдат шоферларның командирмы,— теге әрмәнме, грузинмы лейтенант,— ындыр табагында чапкынлап йөрергә тотынды. Әле бер, әле икенче кеше янына килде, каян төяргә дип сорады, ындыр табагы мөдирен эзләде. Ләкин берәү дә аңа рәтле җавап бирмәде. Кайсыдыр Кәрамны төртеп күрсәтте. Механизаторларга дигән ашлыкны амбарга салдырып, ара-тирә ашлык алырга дип килгән колхозчыларга бодай җибәреп мәж килгән Кәрам башта лейтенантның ни сораганын абайлый алмый торды. Аннан, сүзнең ни турыда барганына төшенгәч:

— Председательдән башка бер сүз дә әйтә алмыйм,— диде русчалап. Лейтенант, карга канатыдай кара мыекларын кул сырты белән сыпыра-сыпыра:

— Райком секретаре шушыннан төяргә кушкан иде, соң ни эшләргә? — диде.

— Белмим шул, председательдән башка...

Лейтенант кызу-кызу атлап машиналар янына китте, шоферларны жыеп, нәрсәдер киңәште дә йөк төялмәгән машиналарның берсенә кереп утырды. Буш машиналар, бер-бер артлы, ындыр артлатып кына күрше совхозга таба кузгалып киттеләр. Кәрам аларны үр артына кереп югалганчы карап озатты. Машиналар күренмәс булгач, иркенләп сулап җибәрде.

## 3

Ашлык төялгән машиналар ындыр табагыннан чыгып китүгә, «Иж-планета» мотоциклына атланып партоешма секретаре Яхья Курмашов килде. Какча яңаклы, тузгыган сары чәчле бу кешене авыл халкы ихтирам итә. Менә ничә ел инде ул партоешма секретаре камытын тарта. Бер үк вакытта мәктәп директоры да. Быел, житмәсә, сигезьеллыкны урта мәктәп иттеләр. Анда да эш муеннан. Колхоз председателе

белән бик тату эшлиләр, берсе сүзеннән берсе чыкмый. Колхоз көче белән мәктәп салдылар. Районда юк андый. Ул интернаты тагын. Күрше авылларның барлык балалары шунда торып укый. Мәктәпкә нигез салып йөргәндә колхозга обком секретаре килгән иде. Курмашов үз планнарын сөйләп, мавыктырып, обком секретарен төзелеш мәйданына алып килде. Мәктәп салуны тоткарлаган кыенлыкларны әйтте. «Башкасын үзебез дә ерып чыгарбыз инде аның. Менә нарат, түбәлек, цемент белән ярдәм итсәгез икән»,— диде. Обком секретаре аның үтенечләрен блокнотына язып алды. Ул китеп атна-ун көн үтү белән, колхоз адресына разнарядка кайтып төшмәсенме! Колхозга аяк баскан башлыклар белән сөйләшергә иллә оста кеше инде.

Атлан басуына киткәндә Рамай ага да сугылган, хәлне аңлаткан һәм аңа төшкә кадәр сыерлар җәйләвендә булырга кушкан иде. Хәзер аның әнә шуннан кайтышы. Яхъя мотоциклыннан төште, озын кунычлы күн пирчәткәсен салып, аны мотоцикл бишегенә ыргытты да ашлык чистарту агрегаты янында кайнашучы хатыннар янына килеп кычкырып сәлам бирде:

— Саумы сез, беләкләрегез талмасын, йөрәкләрегез картаймасын!

— Әйбәт кенә әле, Яхъя.

— Йөрәкләрегезне май басмасын дисеңме?

— Кыш буе тик ятып май да басар.

— Урак өстендә эретәбез аны без.

Яхъяга хатыннар әнә шулай дип җавап бирде. Парторг алар белән бераз сөйләшеп торды да ындыр табагындагы агитпунктка юнәлде. Андагы «молния»ләрне, стена газеталарын карады. Урып-җыю, дәүләткә ашлык тапшыру барышын күрсәткән барометрның укларын күчереп куйды. Аннары, барлык халыкны ындыр капкасы янындагы озын колга янына җыйды һәм көзге кыр эшләре, урып-җыюның барышына кыскача гына анализ ясап, базык буйлы, юантык бер хатынга дәште:

— Җәмилә апа, кил әле, Җәмил абый хөрмәтенә, ирең өчен күтәреп җибәр әле флагны, бүгенге көндә аннан да алдынгы комбайнчы юк,— дип, Җәмиләгә колга башына флаг күтәрү бавын тоттырды. Җәмилә ояла-ояла аның янына килде һәм тын калган түгәрәк эчендә флагны күтәрде. Флаг, колга очына менеп, талгын җилдә җилферди башлау белән, барысы да дәррәү кул чабарга тотындылар. Кайсыдыр Җәмиләгә шаяртып сүз кушты:

— Җәмилә, бүген иртәрәк ычкын, кичкә мунчаң өлгерсен, ул чыгуга өстәлеңдә бер чебиең көтсен. Кадерен бел тәкәрлегеңнең.

Хатыннар көлеп җибәрделәр. Җәмилә, бурлаттай кызарып, түгәрәктән читкә чыкты да хатыннар артына басты.

Яхъя тагын туңга сөрү, салам җыю, сөт җитештерү алдынгыларын мактап телгә алды һәм ярыш алдынгылары семьяларына колхоз идарәсе, партия оешмасы исеменнән язылган тәбрикләү хатларын укыды. Аннары, болай да озын гәүдәсе өстеннән серәеп торган муенын як-якка борып болай диде:

— Апалар, җиңгиләр, сеңелкәшләр... Хәзер бирердә эш саегып бара. Үзегез дә сизәсездер. Моннан штатларны кыскартырга туры килер. Чөгендергә керешкәнче, салам эскертләргә кирәк. Туңга сөрергә җир җитештереп булмый. Бүген төнлә дә ике трактор тик торды. Я, иртәгә кем үзе теләп салам җыярга чыга? Имчәк баласызлар булса, әйбәтрәк...

Хатыннар бер-берсенә карашып алдылар. Аннары теләүчеләр үз исемнәрен әйтеп яздырды. Барысы уйбишләп кеше җыелды.

— Сез таң белән Атлан басуындагы бодай җиренә чыгарсыз. Кичтән наряд биргәндә бригадирга үзем әйтермен,— диде Яхъя, хатыннар белән саубуллашып.

Шул чак авыл башындагы Ясмык тау итәгендә өермә күтәрелде һәм, Галәветдиннең сихерле лампасыннан чыккан тотен сыман, тузан

баганасы, бөтереләбөтереләбөтереләбөтерелә, бу тарафка килә башлады. Әнә ул техника паркы өстендә айкалды, ниндидер калай кисәкләрен ялмап алып һавага күтәрде, аннары ул калай кисәкләре тирә-якны буш тимер мичкә тәгәрәткән сыман тавышларга күмеп, яңадан җиргә коелдылар, колак төбендә тимергә тимер бәрелгән чыңнар яңгырады. Хатыннар, башларындагы яулыкларын тотып, ашлык чистарту агрегаты артына йөгерделәр. Яхъя баскан урынында калды. Өермә күз иярмәс тизлек белән ындыр табагына килеп керде һәм, юлындагы һәр нәрсәне үз кочагына алып, һавага күтәреп, зил-зәбәр китерде: көшелләр буталды, амбарның бер башы салам белән ябылган иде, аның бер як түбәсе каерылып ташланды. «Иж-планета» тәгәрәп ята. Яхъя тиз генә барып аны аягына бастырды.

Ул мотоциклын кабызып, капкага таба борылган гына иде, олы юлдан авыл урамына кереп килүче райком машинасына күзе төште. Яхъя мотоциклын сүндерде һәм, кайсы икән дип, райком машинасын көтеп алды. «Волга»да Шәймиев иде. Ул, машина туктау белән, ишекне атып кына бәрде һәм туп-туры партоешма секретарена таба атлады. Аның кашлары җимерелгән, иреннәре кысылган иде. Шулай да кул биреп күреште.

— Сез нәрсә, иптәш Курмашев, инцидент чыгарасыз? — диде ул. Яхъя, берни аңламаганга салышып, секретарьның ачулы күзләренә тутырып карады:

— Нинди инцидент ул, Рәшат Галиевич?

Шәймиев Яхъяга арты белән борылды һәм кешеләр ишетмәслек кенә итеп, кемнеңдер газиз ата-аналарын искә алып сүгенде дә кире ялт борылды.

— Нигә машиналарны төятмичә совхозга җибәрдегез?

— Нинди совхозга?

Шәймиев Яхъя соравына җавап бирмәде, ындыр табагын яңгыратып, амбар янындагы үлчәү тирәсендә кайнашучы Кәрамга кычкырды:

— Бухгалтер, килегез әле бирегә!..

Кәрам башын югары күтәрде һәм үзенә кул болгап торган Шәймиевне күреп: «Менә давылның чыны килде»,— дип уйлады, тәне эсселе-суыклы булып китте. Ул, таягын эләктереп, титаклый-титаклый, Шәймиевкә таба атлады.

— Нәрсә дидем мин сезгә? — дип каршылады аны Шәймиев.

Кәрам сүзнең ни турында баруын шунда ук аңлады һәм:

— Бетте бит, иптәш Шәймиев, соңгысын төяттек, ә тегесе чыннан да симәнә бодае,— диде.

Секретарьның күзләре зәһәр ялтырады.

— Әллә сез мине бүген дөньяга килгән дип беләсезме? Симәнә бодаен нигә колхозчыларга өләшәсез?

Ул капкадан чыгып килүче олауны туктатты да йөк өстендә утырган үсмер егеттән:

— Каян төядегез моны? — дип сорады.

Авыл халкы хәйлә беләмени. Туп-турысын әйтеп салмасынмы!

— Әнә тегеннән, амбар буеннан,— диде, чыбыркы сабы белән төртеп үк күрсәтте егет. Шәймиев кул селтәде, олау китеп барды. Ул бераз ераклашу белән, Шәймиев тугарылып китте. Яхъяны да, Кәрамны да эт итеп сүгәргә тотынды:

— Саботажниклар, инцидент тудыручылар сез, республика масштабында уйлый белмисез! Үз туныгызны бөркәнеп яшисез, ашлыкның һәр граммы өчен көрәш барганда политик сукырлык күрсәтәсез! Өйрәтеп бетергәннәр иркәләп, назлы барышня кебек. Иптәш Курмашов, кичке алтыга составыгыз белән бюрога! Бу төлкене дә иртәгез. Күрсәтермен мин сиңа беренче секретарь күзенә ничек төтен җибәрергә!

Шәймиев Яхъя белән Кәрамны утлы табада биетте дә китеп барды.

Секретарь машинасы, тыкрыкны төшеп, урамга борылгач, Кәрам кулын селтәде:

— Адәм тиресенең базарга чыкканы юк әле,— диде.

Яхъя бер сүз дә дәшмәде. Мотоцикл кабызды да Атлан тавына таба элдерде. Колхоз председателен ничек тә эзләп табарга, бюрога барганчы киңәш-табыш ишетергә кирәк иде.

Күптән түгел явып узган яңгырдан соң көннәр кинәт утырып китте, эбиләр чуагы башланды. Тауга күтәрелә торган басу юлы асфальтына биргесез. Мотоцикл, канатлы кош кебек, Атлан тавына омтылып, оча гына. Колак төбендә җил сызгыра. Яхъя күн перчаткасын киярга онытkan иде. Җиң эченнән бөтен тәнгә җил өрә, комбинезонының арты мендәр тыгып куйгандай кабарган. Юлның ике ягында да бодай. Аның уңышы әллә кайчан дәүләт амбарларында. Шәп чыкты моннан, егерме бишәр центнер, житмәсә — ак бодай. Хәзер басу тулы салам чүмәләләре, жепкә тезгән төсле, бер генә турыга төшерелгәннәр. Алар арасына, урыны белән, сөрергә дә кергәннәр инде. Саламын басу читенә чыгарып бетермичә, бер сабан да кертмәскә дип килешкәннәр иде дә бит. Нишлисең, тракторларны тик тотасы килми, аннары, иртәрәк тунга сөреп калу да хәерле. Сентябрьгә чаклы сөрелгән җиргә ни житә. Басуларга күз йөртә-йөртә, Яхъя әнә шулай уйлады һәм мотоциклының үрне алдыра алмыйча ухылдап, тыкылдый башлавын сизенеп, икенче тизлеккә күчте. Атлан тавын бик җиңел менде мотоцикл. Алда өстәл кебек тигез басу башланды. Әнә, каенлык янында, комбайннар да күренде. Алар, кыр казлары кебек тезелешеп, болай таба киләләр. Шушы каенлыкта язгы чәчү тәгәлләнеп, чәчүлекләрне кабул иткәч, механизаторлар бәйрәме ясый алар: чәчү батырына, алдынгыларга бүләкләр тапшырыла. Тел ачкычлары ачыла механизаторларның. Рамай Ибраһимовичка, Яхъяга күңелдә йөрткән рәхмәт һәм үпкә сүзләрен әйтеп бетерәләр, эч серләрен чишәләр. Киләсе елда һәркем үзенең чәчү батыры булачагына ышандыра, ант итә. Шунысы кызык, әле беркемнең дә ике ел рәттән чәчү батыры була алганы юк. Елның елында чөеп кенә торалар чемпионнарны. Тырышырлыгың да бар: чәчү батыры уракка төшкәнче жылы якларга бушлай санаториягә бара, ул кайтуга ишегалдына ике машина каен утыны кайтарып аударылган була. Анысы да түләүсез. Ә бу кыр ягында утын дигән нәрсәнең нинди бәядә йөргәнен үзе шунда яшәгән кеше генә белә. Хәзер генә ул күп кеше өй җылытуны да газга көйләп бара.

Борчак чәчәк атканда яки кузакланганда терлекчеләрнең дә күңелләрен күрәләр. Ярты еллык йомгакны каенлык аланында ясыйлар. Бусына, сельпо белән сөйләшеп, хатын-кыз кызыгырлык товар белән әллә ничәшәр магазин китерәләр. Кичкә бөтен авыл халкы шушында менеп бетә. Башка бригадаларны автомашина белән ташыйлар. Бусы үзенә күрә бәләкәй бер сабан туена әйләнә. Бу көнгә хәтта читтән кунаклар да кайтырга гадәтләнеп киттеләр. Бер-ике бәйрәмнең ямен җибәрүчеләр дә булды. Аннары ансының да рәтен таптылар. Дежур машина куйдылар, тәртип сакларга нык куллы кешеләрне билгеләделәр. Тез буыны йомшаган, тугарыла башлаган кешене шундук авылга — өенә илтеп куя торган булдылар. Үзеңне тота белмисеңме — син бәйрәмнән мәхрүм!

Мотоцикл белән тигезләнүгә алдагы комбайн туктады. Штурвалда — чегән кебек каралган Җәмил абзый. Ул күперчектән төшүгә, башка комбайнчылар да килеп житте. Исәнлек-саулык сорашкач, Яхъя аларга район комбайнчылары, колхоз комбайнчылары ярышын чагылдырган ике бюллетень сузды һәм:

— Рамай Ибраһимовичны күрмәдегезме? — дип сорады.

— Иртәнге якта булды ул монда. Ләкин кая киткәнен әйтмәде,— диде Җәмил.

Яхъя эшләп торган мотоциклына таба китте. Ул кире борылганда комбайнчыларның берсе:

— Комиссарның нишләптер кәефе юк әле, йөзе сүрән,— диде.

Ә Яхъя башында бер уй кайный иде: кайда икән Рамай Ибраһимович? Ул салам эскертләүчеләр, камыл лущить итүчеләр янында, хәтта умарталыкта да булды. Аннары, аптырагач, сигез чакрым ераклыктагы Шыгай бригадасына китте. Бу арада председатель культуралы көтүлек белән җенләнеп йөри иде. Инеш буендагы, язын су баса торган сиксән гектарлы участокны киртә белән әйләндереп алып, шунда ясалма яңгыр яудыру установкасы да кайтарткан иде, мөгаен, шуны сынап йөри торгандыр, дип уйлады. Шыгайга таба, олы юл буйлап, очты гына Яхъя. Шыгай тавы башына житкән иде, аста, күпер буенда, председательнең «Волга»сы күренде. Яхъя, иркен сулап, сәгатенә карады. Биш туларга унбиш минут иде.

Рамай Яхъя сөйләгәннәрне тыныч кына тыңлап торды, ара-тирә аның куе кара кашлары ук җәяседәй киерелде. Алсу, чибәр битенә кызыл йөгерде. Күзләре уйчанлады. Яхъя сөйләп бетергәч, ул яңгыр яудыру агрегатын көйләүче СМУ эшчеләренә кычкырды:

— Бетерми китмәгез! Мин таң белән килеп җитәрмен, иртәгә әбизәтельне сыныйбыз! — Аннары Яхъяга:— Нишләп мотоцикл белән йөрисең? — диде.

— Болай җиңел бит, көн дә коры.

— Алайса, берәрсенә кертеп куй да әзрәк юынып ал, югыйсә, җен кебек булгансың.

Яхъя мотоциклын югары очтагы кырый йортка кертеп куйды да буада кулын-битен юды.

Барышлый идарәгә сугылып, Кәрамны да элэктерделәр. Район үзәгенә егерме минутта килеп җиттеләр. Әле вакыт бар иде. Беренче секретарьның тәртәне кинәт болай зиректән бөгүе Рамайның күңеленә шик-шөбһә салган иде. Ул, юк эшне бар итеп, гомер буе бергә эшләгән район Советы башкарма комитеты председателе Вәрәшовка сугылып чыгарга булды. Кабинет ишеген ачып, рөхсәт сораганда, Вәрәшов телефоннан кем беләндер сөйләшә иде. Рамайга, әйдә, әйдә, дип баш какты. Рамай, гадәтенчә, Вәрәшов алдына барып утырмады, ишектән керүгә туктап калды. Вәрәшов телефон трубкасын шап итеп куйды да Рамайга гаҗәпсенеп карады.

— Син нәрсә, Рамай Ибраһимович, балтасы суга төшкән оста кебек тораташ каттың? Кил, утыр, тыңлыйм ни йомыш?

— Сездән яшерен-батырын түгел, иптәш Вәрәшов, йомышсыз кердем әле бу юлы. Югыйсә, очрашабыз, йомышны йомышлыйбыз да вәссәлам. Менә ничәмә еллар дөнья камыты сөйрибез. Уйлап караганыгыз бармы? Безнең мундирларны салып, Рамай, Габделхак кына булып, һич югында, гап-гади коммунистлар булып, тугарылып, йөрәкләрне ярып салып кайчан сөйләшкәнебез бар? Уникe ел эшлибезме инде хәзер?.. Бер-ике тапкыр сөйләштекме икән?

Ап-ак чырайлы, чәчен кырдырып йөртүче, какча гәүдәле Вәрәшов урыныннан сикереп торды һәм Рамай янына килеп басты, аның йөзенә нелеп карады, елмаеп:

— Соң син инде байтактан уразада, әллә төшерденме, шайтан? — диде Рамай, кулындагы эшләпәсенең читен бөгәрли-бөгәрли:

— Төшергәннән дә хужы әле, коточкыч! — диде һәм Рәшат Галиевич белән ике арада килеп чыккан әлеге хәлне сөйләп бирде дә:

— Габделхак Шакирович, минем гомердә күп секретарьлар алмашынды, барысы белән дә уртак тел таптым. Нинди кеше соң ул Рәшат Галиевич? — дип сорады.

— Анкета данныйларыннан башка мин дә әллә ни белмим Рәшат

Галиевичны. Обком тәкъдим итте...— Вәрәшов кулларын җәеп җибәрде һәм:

— Син Маклаков кебек кеше көткән идең дә, андыйларны бездә күп тотмыйлар шул, хәзер югары үрләтәләр. Михаил Федоровичны ЦКга, авыл хуҗалыгы бүлегенә алганнар хәзер. Күрдеңме, обкомда да озак кунакламады. Баш та, тәвәккәллек тә, оештыру сәләте дә шәп иде аның... Ә син, борыныңны төшермә, Рәшат Галиевич, кешеләр, хуҗалыклар белән яңа таныша. Ул да җаен алыр,— диде.

— Соң, Габделхак Шакирович, бу очракта мин нишлим?

— Гаеп миндә диген, сүз куертма. Беренче секретарьларның мин дә ниндиләрен генә күрмәгән? У-у-у! — диде Вәрәшов һәм сигарет кабызды.— Бюро членнары алдында сүзен сүз итү өчен акны кара дип исбатлаучылары, әйткән һәр сүзенә бюро членнарын ярхәмикә алла дип әйттереп торучылары белән дә эшләгән бу баш... Ә мин сине ничек тә екмаска тырышырмын. Чөнки, үзеннең сөйләү буенча, дөреслек синең якта. Тагын, Рәшат Галиевич пластинканың кайсы ягын куя бит әле...

## 4

Рамай чыгып киткәч, Вәрәшов зиһенен җыя алмыйча, кояшка караган зур тәрәзәгә таба башын борып, беравык уйланып утырды.

Маклаков киткәннән соң, обкомның районга беренче секретарь итеп Шәймиев кандидатурасын тәкъдим итүен ишеткәч, дөресен әйтергә кирәк, Вәрәшовның күңелендә ниндидер ризасызлык хисе дә, шик-шөбһә дә туды. Михаил Федорович Маклаков Шәймиев турында сүз арасында, сүз җае белән Вәрәшовка сөйләгән иде. Михаил Федорович фикерләрен төптәнрәк тагын бер кат уйлаганда Шәймиев аның күз алдына әллә ничә төрле булып килеп баса. Бер карасаң, ул, ал-ялны белмичә, бер хуҗалыктан икенче хуҗалыкка чаба, эш өчен яна, дөрли. Икенче карасаң, вак кына мәсьәләләр белән мавыгып китә дә сәүдәгәргә, экспедиторга әйләнеп кала, киңәшмичә генә, уйланмаган нигезсез карарга килә, шуны көчләп бюро членнарына тага башлый. Әмма ул аны чын күңелдән, инанып, партия исеме белән, яхшылык кылам дип эшли.

Семья бәхете дә юк бугай.

Ләкин ни булса булды, Шәймиевне Вәрәшов киң күңел белән, бер йөкне бергә, әле төптән җигелеп тартырга тиешле кеше итеп каршылады. Коммуналь хуҗалык мөдиренә генә ышанмады, беренче секретарь яшәячәк квартирга тиз генә ремонт ясатуны да үз контролендә тотты.

Беренче килгән көнне, бюро членнары белән танышып сөйләшкәннән соң, Шәймиевне хатыны белән бергә кичке чәйгә чакырды. Рюмка кырына иреннәрен генә тидереп байтак сөйләшеп утырдылар. Шәймиевнең хатыны Сания — коеп куйган чибәр — күбрәк Вәрәшов хатыны белән сөйләште. Бераздан алар иркенләп сөйләшсеннәр дип, икенче бүлмәгә үк чыгып киттеләр.

Алар артыннан зал ишеге ябылу белән Шәймиев болай диде:

— Габделхак Шакирович, кайсы председатель нык утыра, гомумән һәркайсына характеристика биреп чыксагыз иде?

Яңа урынга җитәкче булып килүче өчен гадәти сорау булганга, Вәрәшовның моңа артык исе китмәде, ул һәр председатель, совхоз директоры, партоешма секретарьларының көчле, көчсез якларына тукталып, аларның эшчәнлекләренә үзенчә бәя бирде. «1 Май» колхозы председателе Вильданов кандидатурасына җиткәч кенә Шәймиев, килешергә теләмәгәндәй, башын чайкап куйды.

— Артык шапырынмыймы? Верховный Совет депутаты, райком члены... Еллар буе газет битеннән төшми... Башы әйләнмиме? — диде.

— Юк, Рамай Ибраһимович андыйлардан түгел.

— Карарбыз... Сез аңа просто гашыйктыр.
— Камытны нык тарта торган йөк аты.
— Арымаганмы әле, барыр чамасы бармы?
— Юк, әле ул тагын бер ун ел шул камытны тартачак.
— Күп куясың, ул бит инде кырык тугызынчы елдан бирле эшли.
Вәрәшов көлеп җибәрде:
— Рәшат Галиевич, беләсезме нәрсә, ул «1 Май»ны коммунизмга алып чыкмыйча камытны салмыйм, ди.
— Колхозлап чыкмыйлар коммунимзга, күмәкләп чыгалар. Шуңа күрә дә ул коммуна дип атала.
— Нигә, Рәшат Галиевич, минемчә, гади генә, безнең җирлектә алсак, мәсәләне, авыл хуҗалыгында, коммунизмга, именно, колхозлап, совхозлап чыгачаклар. Берсе алдан, берсе арттан, әмма барысы да берьюлы түгел.
— Ә минемчә алай түгел. Коммунизмның материаль-техник базасы бишьеллыклап тагын да ныгыймы, бу өлкәдә гигант адым ясаламы, ясала. Димәк, кайсыдыр бишьеллыкта без коммунизмның тулы тантанасына киләчәкбез һәм ил буенча. Бер генә илдә социализм җиңә алган икән, бер илдә коммунизм да җиңәргә тиеш.— Шәймиев тавышын күтәрә төште, Вәрәшовка зәңгәр күзләрен төбәде һәм:— Әллә теоретик яктан дөрес түгелме? — дип сорады. Вәрәшов өстәлдәге рюмкага кулы белән сузылды, ләкин ягылмады.
— Теоретик яктан дөрес. Мин бит практик кеше, коммунизмны практик төзүче кеше буларак әйтәм. Тәҗрибә минем яклы. Аннары, Рәшат Галиевич, менә болай да уйлап карыйк әле: җир шарындагы барлык илләр, һич югында, АКШ, Англия, ФРГ, Япония социализм юлына аяк басмыйча, бер илдә, конкрет алганда безнең илдә коммунизмның тулы җиңүенә килергә мөмкинме? Дөрес, без коммунизм төзү стадиясендә. Ә ул стадия мин әйткән чорга кадәр дәвам итсә? Һәм ул шулай булачак та. Җир шарындагы барлык хезмәт кешесе азат хезмәткә ия булганда гына алга киткән социалистик илләр башлап коммунизмга чыгачаклар. Ә капитал богауларын өзмәгән күпме миллионнар бар? Аларга ярдәм итү — бу безнең интернациональ бурычыбыз. Ул бурычның нииндилеген, күләмен һәм аның ничек тормышка ашырылуын сез үзегез әйбәт беләсез...
Шәймиевнең күзләре зур булып ачылды.
— Читләтеп булса да көнбатыш ревизионистлары исе килмиме моннан? — диде ул, нигәдер пышылдап һәм аннары болай дип сорады:— Партия сафында тагын бер чистарту кирәк түгел микән? Килде-китте интеллигенция күбәйде хәзер партиядә.
— Нигә андый чистарту? Партия сафына кабул ителүчеләргә таләпчәнлекне көчәйтергә, кандидатлык стажын озайтырга кирәк... Интеллигенция мәсьәләсенә килгәндә, мин принципиаль каршы: алар кемнәр? Шул ук эшче-крестьян балалары. Потомственный интеллигенция вәкилләрен хәзер бармак белән генә санарлык һәм аларның да күбесе революциянең беренче көннәреннән үк совет властен кабул иткән, аңа хезмәт иткән кеше балалары. Профессор Камайны гына алыгыз. Идел грузчигы улы, беренче профессор, ә үзе кызыл агитатор...
— Шулай да партия сафларын тагын да ныгыту кирәк.
— Бу инде икенче мәсьәлә, Рәшат Галиевич, чистарту түгел... Дөрес, әле партия сафына үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, бары шуның өчен генә керүчеләр дә бар. Ләкин алар партиянең олы тормышы адымына иярә дә, житешә дә алмыйлар. Иртәме, соңмы, андыйларның чын йөзе ачыла һәм алар, кем әйтмешли, борттан ыргытылалар...
Шәймиев Вәрәшовның бу фәлсәфәсенә кушылмады, аны куертырга теләмәде булса кирәк, өстәлдәге нечкә билле кечкенә генә хрусталь рюмкага үрелде дә:

— Соңладык та бугай, я, танышу хөрмәтенә,— диде. Алар, хатыннарына әйтмичә генә, рюмкаларын бушаттылар.

...Зеңгелдәп телефон чылтыравы аның уйлар җебен кинәт өзде. Вәрәшов телефон трубкасын алды. Рәшат Галиевич иде.

— Сәгать алты ноль нольдә бюрога! — диде ул кырт кына.

Алар өчен генә җыелган булып чыкты бу бюро. Өчесе дә бюро членнары белән аяк кагып кына исәнләштеләр. Стена буендагы урындыкларга утырышып бетүгә, Рәшат Галиевич аягүрә басты һәм өстәлгә ике куллап таянып сүз башлады:

— Иптәшләр, бюро членнары! Сезнең күбегез бу гадәттән тыш бюроның чакырылу сәбәбен белеп тә бетермисез булыр. Таныштырам, шуннан нәтиҗәне үзегез ясагыз. Үзегезгә мәгълүм, ашлык тапшыруның хәлиткеч көннәре. Бүген-иртәгә республика хөкүмәтебезгә рапорт бирергә тора. Соңгы центнерлар өчен көрәш бара. Әнә шундый көннәрдә безнең хөрмәтле Рамай Ибраһимович, аның кубызына биюче партоешма секретаре Яхъя Курмашов, баш бухгалтер Кәрам Фәрхетдинов райком бюросы тарафыннан җиткерелгән план-заданиене күрәләтә өзделәр. Аларга ярдәм йөзеннән бүген иртән колхозга егерме машина җибәрдем. Беренче рейс киткәнче үзем шунда булдым. Икенче рейсны да шуннан төяргә куштым. Ә бу акыллы башлар нишләде дисез? Икенче рейска килгән машиналарны буш җибәрәләр, ашлык була торып төятмиләр. Менә бу хәлне, иптәш бюро членнары, политик яктан ничек бәяләргә?

Рәшат Галиевич капыл гына урынына утырды. Нечкә ак бармаклары арасына кыстырган юан кызыл карандашны биетеп, бюро членнарына күз йөртеп чыкты. Авыл хуҗалыгы производство идарәсе начальнигы Урмакаев башын Рамайга таба борды, күзенә төшеп торган чәчен бер якка сыпырып куйды да:

— Председательне тыңлап карыйк, ни дип акланыр икән? — диде.

Рамай исәп-хисап блокнотын кулына тотып утыра иде инде, шуны алга табарак сузып урыныннан күтәрелде. Ул сүз башлыйм дигәндә генә, ак кәгазь битенә нәрсәдер сызгалап утыручы Габделхак Шакирович дәште:

— Икмәк балансын белән таныштыр әле. Шуннан бәлки берәр нәрсә ачыкланыр,— диде.

Рамай блокнот битләрен актарып, бүген иртәнгә булган оператив мәгълүматлар сводкасын алды (аны Кәрам һәр көн эшләп куя иде).

— Безнең бөртекле-кузаклылар,— дип сүз генә башлаган иде, тамак төбенә нидер утырды, авызын тотып йөткереп алгач кына бераз җиңеләйгәндәй булды,— бөртекле-кузаклылар барысы 1700 гектар, уртача уңыш 20 дән аз гына артыграк. Бөртекләләрне уру бетте. Валовой сбор 34.160 центнер, тагын 90 гектар тары урасы бар. 16 шар центнер чыгып бара. Аннан 1440 центнерлар чыгар дип көтәбез. Шулай итеп, барлык җыем 35.600 гә җыела. Икмәк тапшыру планы — 14 мең. Бүгенге көнгә тапшырылды 21 мең 200. Планнан тыш 7 мең 200. Бер гектардан дәүләткә тапшыру 12 ярым центнер тирәсе. Симәнәгә салынды 5100 центнер, колхозчыларга сатарга 2520 центнер, зачетный вес өчен 700 центнер китте. Чүпкә чыкты, өч проценттан, 1023 центнер. Фуражга кала 5 мең. Шартлы һәр терлеккә бер дә ике центнер... Бездәге терлекнең саны сезгә мәгълүм инде. Әнә шулай такыр кала быел да фураж...

Рамай сүзен әйтеп бетерә алмады, Рәшат Галиевич сикереп торды:

— Без сездән фураж күпме кала дип сорамыйбыз! — диде ул, күзләрен елтыратып.— Ни өчен райком тарафыннан җиткерелгән заданиене үтәмәдең? Райком кушкан сиңа закон түгелмени?

— Әлбәттә, закон, Рәшат Галиевич. Әмма дәүләткә ашлык тапшыру буенча мин партия алдында да, хөкүмәт алдында да коммунист, җитәк-

че буларак үз бурычымны үтәдем дип саныйм. Һәр гектардан 12 ярым центнерны кайсы хуҗалык тапшырганы бар?..

Рәшат Галиевич шапылдатып өстәлгә сукты һәм ысылдап:

— Постой, постой!.. Без сорыйбыз әле монда, сез түгел. Сез конкрет сорауга конкрет җавап бирегез! — диде.

— Конкретмы? Минем партиядән яшерен бер уем да юк. Конкрет булса менә шул: хәзерге заманда, мөмкинлекләр бар чагында, минем колхозны сугыштан соңгы беренче еллар көненә төшерәсем килми. Ай, авыр булды бу көннәргә аяк басуы, Рәшат Галиевич. Уйламыйча һәр бир дигәнгә мә дип торсаң... Ә колхоздан кемнәр, ниләр генә сорамый, әле дә түзә инде колхоз сырты... Ярык тагарак янында калуыңны көт тә тор. Ашлык тапшыру белән безнең вөҗданыбыз пакь. Туфрак бонитеты безнеке кебек үк булган колхозларда уңыш түбән, аларның дәүләт планнарын да тартып-сузып үтәүләренә, үти алмауларына без гаепле меле? Алар өчен без иза чигәргә тиешме? Эшләсеннәр алар да адәм рәтле итеп. Икмәк тапшыру белән без районга да, республикага да бурычлы инде. Соңгы чиккә кадәр.— Рамай блокнотын кесәсенә тыгатыга беренче секретарьның күзләренә текәлеп карады һәм сүзен дәвам иттерде:— Мин бит сезгә теге киңәшмәдән соң хәлне аңлаттым кебек, Рәшат Галиевич. Сез үзегез мең ярымын ташларбыз, дидегез. Ничек инде ул иртәнге акыл кичкә ярамый?

Аның соңгы сүзе Рәшат Галиевичны чыгырыннан чыгарды булса кирәк, ул, өстәл арасыннан узып, Рамай алдына килеп басты, күзләре белән Рамайны бораулады.

— Аңлашылды. Үзегезне генә акыллыга санып сыз, ә без, бюро членнары...— диде ул сузып. Аннары Яхъя Курмашевка дәште:— Ә сез нәрсә карадыгыз, партия житәкчесе?

Яхъя торып басты, житен кебек тыңламас чәчләрен сыпырды, бер аягын бөгә төште, костюмының итәкләрен тартып куйды.

— Рәшат Галиевич,— диде ул, тамак кырып,— Рамай Ибраһимович минем фикерләрне дә әйтте. Тик бер генә нәрсәне онытты бугай. Әле безнең шактый тары бар. Аның берәр мең центнерын сатарлык рәт булырга тиеш безнең.

Рамай аңа күтәрелеп карады һәм:

— Фуражга кертеп исәпләнгән бит инде ул. Комбикормага алыштырыласы фонд ул,— дип, аның сүзен шундук өзде.

— Монысын мин исәпкә алмаган идем. Рамай Ибраһимовичның бу фикере белән дә кушылам,— дип сүзен бетерде Яхъя. Рәшат Галиевич аңа нечкә озын бармаклары белән төртеп күрсәтә-күрсәтә көлә башлады.

— Карагыз! Ха-ха-ха!.. Типичный карманный секретарь!.. Колхоз председателе кесәсенә салып куйган бит үзеңне, башың да күренми! — Рәшат Галиевич кинәт Кәрамга дәште:— Я, син ни диярсең икән, хөрмәтле главбух? Син идең бит анда, ындыр табагында башкомандующий, кәмит күрсәтүче карт белән бергә! Ни өчен машиналарны кире бордың? Взвод командирына син әйткәнсең бит бездә бүтән икмәк юк дип. Совхозга да юлны син өйрәткәнсең... Кем хокук бирде сиңа ул машиналар белән командовать итәргә?

Кәрам мондый җил-давылларны шактый күргән кеше иде инде. Ул көр тавыш белән, куркып-нитеп тормыйча җавап бирде:

— Юкны юк диими, ни дисең инде. Ындыр табагында ашлык югын үз күзегез белән күрдегез. Симәнәне төягез дисәгез, төяттер идем. Шоферларның башлыгы кайда икмәк бар икән дигәч, ни дим, белгәнне әйттем. Совхозда икмәк күп әле, дидем. Шунда барыгыз дип лейтенантка команда бирергә мин үзем дә старшина гына, отставной.

Кәрамның бу сүзләрен ишетү белән секретарьның ак йөзенә тимгелтимгел кызыл йөгерде.

— Утыр!.. Утырыгыз!..— диде ул Яхъяга да, кулы белән ишарәләп. Аннары кан качкан аксыл иреннәрен биетеп сөйләп китте: — Мәсьәлә аңлашылды кебек. Ягез, бюро членнары, кем нинди тәкъдим кертә?

Башлап Урмакаев торып басты.

— Иптәш Вильдановның бу поступкасы миңа бөтенләй аңлашылмый. Райком члены, республиканың Верховный Советы депутаты шундый юлга бассын әле! Бик дөрес бәяли сезнең поступокны Рәшат Галиевич. Әйе, куралэтэ саботаж бу. Икмәк юк ди! Уборкасы бетмәгән. Биш мең центнерны фураж дип саклый. Акыллы баш! Монда башына чүбек тутырылганнар утыра дип беләсезме әллә сез! Икмәк ашатып кем дә терлек асрый аны! Менә сез аннан башка, терлекчелектәге алдынгы технологиягә таянып асрагыз терлекне! Һәм без моңа өйрәтербез. Тәкъдим шул. Житкерелгән планны сүзсез үтәтергә. Тагын 1400 калганмы әле?.. Менә шуны ике көндә чыгарсын, ә боларны коры жибәрү ярамый. Председательгә, партоешма секретарена шелтә бирергә кирәк. Аннары, иптәш редактор, башкаларга сабак булыр, боларны район газетасына саботажниклар дип язарга да кирәк булыр. Прәме башын шулай дип куеп, эре хәрефләр белән,— диде ул, кырында утырган редакторга иелә төшеп. Аның бу фикерен Рәшат Галиевич та хуплап баш иде.

Оештыру бүлеге мөдире Шәяхметов сүзен кыска тотты.

— Мин монда нинди дә булса партия җәзасы бирерлек әйбер күрмим. Шушында тикшерү белән канәгатьләнергә кирәк, Рәшат Галиевич,— диде ул.

Пеләш башын кулъяулыгы белән сыпыра-сыпыра, Габделхак Шакирович урыныннан торды:

— Мин Рамай Ибраһимовичның икмәк балансын язып бардым һәм үзебездәге оператив мәгълүматлар белән дә чагыштырдым. Дөрес алар. Сыгарлыгы сыгылган инде бу колхоздан. Тик мине бер нәрсә борчый: киләсе ел уңышы турында кайгырту җитми сездә, Рамай Ибраһимович. Кара инде туңга сөрүне. Урак бетеп килә. Әле 50 процент та туңга сөрелмәгән. Салам җыюның рәте юк. Бәрәңге алырга керешмәгәнсез...

Габделхак Шакирович сүзне агымдагы эшләр тирәсендә куертты, колхозның сөтнең майлылыгы түбән булу, терлекләрне җәйләүдән фермаларга күчерүгә хәзерлекнең начар булуы, йомырка алу кимү өчен дә тәнкыйтьләде. Сизеп утыра Рамай, бюро членнарының игътибарын төп мәсьәләдән читкә юнәлтергә тырыша. Карт төлке, хәйләкәр. Беренче секретарьның фикере белән килешмәсә, гел шулай эшли ул. Рамай кинәл сулыш алып куйды. Габделхак Шакирович җәза бирү мәсьәләсен кузгатмады, урынына утырды. Тик Рәшат Галиевич моны көтеп торган икән, нәзакәтле генә сорау бирде:

— Ә сез нинди партия җәзасы бирергә тәкъдим итәсез?

— Мин Тәлгат Шәяхметович фикеренә кушылам...

Габделхак Шакировичның бу җавабыннан соң беренче секретарьның йөзенә тагын кызыл тимгелләр бәреп чыкты. Ул тешен кысты һәм башын югары күтәрде.

— Тәк, ике тәкъдим булды. Берсе — шелтә, икенчесе — тикшерү белән чикләнергә.— Ул йөткереп алды.— Менә нәрсә дим мин сезгә, бюро членнары. Либеральләр без. Ә либерализмның, аеруча ашлык тапшыру чорында райком бюросының либерализмы партия өчен бик зыянмаслыкка төшә. Ашлык фронтында инцидент тудыручыга, куралэтэ саботаж юлына басучыларга выговор!.. Выговор!.. Тикшерү белән чикләнүен әйтеп тә тормыйм! Юк, килешә алмыйм мин сезнең белән, бюро членнары...— Ул йөзен каратут баскан озын буйлы икенче секретарьга карап сүзен дәвам иттерде:— Дәүләткә ашлык тапшыру чорында КПСС райкомы күрсәтмәләре белән исәпләшмәгән һәм куралэтэ саботаж, әйе, әйе, саботаж юлына баскан өчен колхоз председателе Вильданов, парт-

оешма секретаре Курмашев, баш бухгалтер Фәрхетдинов иптәшләргә учет карточкасына язып каты шелтә белдерергә! Тавышка куям, кем дә кем шул тәкъдимне яклыйбыз ди, шул бюро члениарының кул күтәрүен сорыйм.

Рәшат Галиевич бюро членнары өстеннән берәм-берәм күз йөртеп чыкты. Башлап Урмакаев кул күтәрде. Аңа башкалар да иярде.

— Каршылар? Юк... Ә сез?

Ул Тәлгат Шәяхметович белән Вәрәшовка дәште. Алар бер якка да кул күтәрмәделәр. Икесе өчен дә Вәрәшов җавап бирде:

— Без битараф калабыз... Андый хокук та бар бит әле безнең,— диде елмаеп.

Шул чак Кәрам урыныннан торды һәм кулын күтәрә-күтәрә сорау бирде:

— Рәшат Галиевич, ә ул каты шелтәне минем кайсы кенәгәгә язарсыз икән?

— Ничек?!.

— Тәк просто, мин бит партия әгъзасы түгел.

Кәрамның бу җавабыннан Шәймиев аптырап калды, авызы ачылды, ләкин сүзе чыкмый торды. Аннары, ишеккә төртеп күрсәтеп:

— Олагыгыз! — дип кычкырды һәм Рамай белән Яхъяга да кул болгады:— Барыгыз, бусы акыл булсын,— диде.

Алар чыгып китү белән Рәшат Галиевич оештыру бүлеге мөдире белән район Советы башкарма комитеты председателенә ташланды, аларны либерализмда, беренче секретарь тәкъдимен якламауда гаепләде. Шәяхметов та, Вәрәшов та бер сүз дәшмәделәр. Яңа килгән секретарь белән беренче көннәрдән үк конфликтка керәселәре килми иде аларның.

## 5

Башка районнарда эшләгәндә Рәшат Галиевич бюродан соң үзендә ниндидер бер канәгатьләнү, файдалы эш башкару хисе тоя иде. Бүген менә монда, яңа җирлектә үткәрелгән беренче бюродан соң ул канәгатьләнү тоймады. Киресенчә, авыр физик эш белән йончылгандай сизде үзен. Бюро членнары таралу белән башы авырта башлады, тамак төпләре чатнады. Графиннан салып су эчмәкче булды. Ләкин су көнозын торып җылынган иде, иренен генә тидерде дә, стакандагы суны ачык тәрәзәгә үрелеп карап урамга сипте. Ике чигәсен тотып, өстәл артында байтак утырды. Юк, Вәрәшов белән оештыру бүлеге мөдиренең бүгенге бюродагы кыланышлары ошамады аңа. Казан партия мәктәбендә бергә укыган дусты Иргиз Шәехович әйткән иде аңа: «Авыр булачак сиңа, Маклаков алымы белән синең эш стилендә күк белән җир кадәр аерма. Үз тәртибеңне керткәнче авыр булыр. Иң мөһиме — бюро членнарың авызыңнан ни чыгасын көтеп торсыннар, шуңа кул күтәрсеннәр. Онытма, бюро членнарың Маклаков алымына күнеккәннәр. Алар һәркайсы диярлек үзенчә фикер йөртергә өйрәнгән кешеләр». Хәзер обкомның авыл хуҗалыгы бүлегендә эшләүче Иргиз Шәеховичның шул сүзләре әле кичә генә әйтелгәндәй колак төбендә яңгырап тора. «Урмакаевын бөгүе авыр булмас, тиз сыгыла торганнардан, редакторы да шундый кешегә охшаган, икенче, өченче секретарьларның эчендә ни барын әлегә аныклау авыр. Ә Вәрәшов белән Шәяхметов үзсүзле кешеләр булса кирәк».

Рәшат Галиевич барлык бюро членнарының уңай, кире якларын үз бизмәненә салып үлчәп карады, барысын да күз алдыннан үткәрде. Күпме уйласа да ике фигура — Вәрәшов белән Шәяхметов башкаларны күмеп китте, күз алдына калку булып килеп басты. «Күрербез. Нәкъ

беренче секретарь тарткан якка тартмаска башларына тай типмәгән аларның. Мин дә үземә пулат салу өчен тырышмыйм бит. Барыбыз да коммунистлар»,— диде үз-үзен юатып.

Шулай да зур, якты квартирына кәефсез кайтты ул. Ишек бикле иде. Инглиз йозагын ачып өйгә керде. Барлык бүлмәләрдә ялт итеп ут яна. Кер тимәгән, ялтырап торган мебельләр ниндидер кадерле кунакны көтеп зарыкканнар төсле, аларда ятимлек сизелә. Рәшат Галиевич өс-башын чишенеп, өстенә җиңел яшел бәрхет халат киде дә, бүгенге почтаны алып, диванга сузылып ятты. Тамагы да ачыккан иде, кухняга керәсе, буфетка таба үреләсе килмәде. Газеталар караштыра-караштыра: «Кая икән соң бу Сания?» — дип уйлады. Күңеленә шик тә төште: «Әллә монда да өлгергәнме?» Шул вакыт ишеккә кемдер кагылды. Рәшат башын диваннан күтәрде. Сания кайтты. Ул ишекне ябу белән өйгә, борыннарны ярып, затлы исле май исе таралды. Рәшат урыныннан тормады, бер кулына газета тоткан килеш, Саниянең залга үтүен көтте. Менә ул дагаланган биек үкчәле туфлиләре белән тык-тык басып залга узды. Рәшат аңа сокланып карады. Есенин гашыйк булып мәдхия җырлаган каен кызы кебек зифа иде аның Саниясе. Тәнлә салкынайтып җибәргәндер, ахрысы, аның битләре яңа пешкән кура җиләгедәй алсуланган.

Ул аны моннан унике ел элек күрде. Урта мәктәптә, чыгарыш кичәсендә. Рәшат, партия мәктәбен тәмамлап, алар районында идеология секретаре булып эшли генә башлаган иде әле. Сания урта мәктәпне тәмамлаучыларны чирәм җирләргә китәргә чакырып чыгыш ясады. ВЛКСМ райкомы исеменә язылган гаризасын мәктәп директорына бирде. Аңа карап, аның тау астыннан челтерәп чыккан чишмә төсле саф тавышына мөкиббән киткән Рәшат бер мизгел югалып калды. Шомырт кебек кара күзле, карлыгач канатыдай озын кыйгач кашлы, сөрмәләнеп торган озын кара керфекләре, тыйнак кына елмайганда бит очларының уймакланып чокыраюы, иңгә төшеп күпереп торган кара бөдрә чәчләре, һәр әйткән сүзе саен тулып пешкән алмадай зур, тыгыз күкрәкләренең дерелдәп куюы Рәшатның зиһенен бөтенләй чуалтты.

Ул да булмады, кыз итагатьле генә итеп башын иде дә, менә бүгенгедәй, кырт-кыр өздереп басып, урынына барып утырды. Рәшат аны күзләре белән озатып калды.

Мәктәп директорының колакка: «Рәшат Галиевич, сезгә сүз бирәбез,— дип пышылдавы гына аны фани дөньяга кайтарды. Ул сөйли белә иде. Бу юлы теле матур сүзләргә аеруча бай булды.

Чыгарыш кичәсе балына ул калмады. Мәктәп директоры белән, укытучылар белән саубуллашты да район үзәгендәге бердәнбер кечкенә кунак бүлмәсенә кайтып китте. Башка көннәрен соңгы сеанска кинога керә иде. Бу көнне шыксыз таш клубка таба аягы тартмады. Кайтып, бераз китап укып ятты, аннары йокы баса башлавын сизеп, утны сүндерде. Ләкин йокы алмады. Күз кабаклары авырайса да, ияу ятты. Күз алдында һаман шул кыз гәүдәсе... Сания, Сания... Ул ябык куллары белән үзен кысып кочаклады. «Нишләргә соң, нишләргә?» Башта әнә шул уй кайный, өзгәләнгән күңел шуңа шашынып җавап эзли. Ул торып утырды, аяклары буяулы идәнгә тиюгә сискәнеп китте һәм яңадан йомшак одеалы астына чумды, ике кулын да баш астына куеп күзләрен йомды һәм саный башлады. Бер, ике, өч... Әллә ничә тапкыр йөзгә кадәр санаса да, керфекләр җиңелчә калтыранудан туктамады. Әле Саниянең маңгаена төшкән бөдрә чуклар, көмеш кыңгыраулар моңы таратып, чынлап киткән төсле. Юк, алай түгел, көлә икән Сания. Әнә Сания ниндидер елга яры буенда су коену костюмыннан гына йомры янбашларын уйнатып басып тора, бит очларын уймаклandырып, ак тешләрен ялтыратып көлә, үзе Рәшатны чакыра: «Кил инде, кил, нигә куркасың?» — ди... Ул да аңа таба йөгерә, үзенең зур гына дәрә-

жәле кеше икәнен онытып, үсмер малай вакыттагы кебек аңа таба ашкына. Менә ул аны эләктереп ала. Сания, башын артка ташлап, аның беләкләренә ята, үзе, ике кулы белән йөзен каплап, никтер көлә, тыела алмый көлә...

Төне буе саташып чыкты Рәшат. Иртән юынганда да, ашханәгә тамак ялгарга барганда да күз алдыннан Сания гәүдәсе, аның көлүе китмәде. «Ә бит ул аның әле көлүен күрмәде, ишетмәде, чыннан да, ничек көлә икән ул кыз?» Шул исенә төшеп, үзе дә елмаеп куйды. Кабинетына кереп, берничә урынга шалтыратты. МТСларның үзгәртеп корылган, техниканың колхозларга сатылган чоры иде. Ремонт базасы булып кына калган РТСларда тәрбия, идеология эше аксап килгән вакыт. Элекке кызыл почмаклар онытылып, күп урында ул ремонтчыларның тамак ялгап алу, тәмәке тарту урынына әверелгән иде. РТС парторгы белән ул шушы хәлләрне рәткә салу турында тәфсилләп сөйләште. Ә Сания турындагы уйлар һаман тынгылык бирми иде. Әнә ул елмаеп басып тора. Рәшат кинәт кенә телефон трубкасына үрелде һәм ВЛКСМ райкомының беренче секретарен үзенә чакырды. Очып, җилләнеп йөрүче яшь кенә секретарь шунда ук килеп керде. Райком белән райкомол бер үк бинада иде.

— Менә нәрсә, иптәш Рәхимов,— диде ул, райкомол секретаре каршысына килеп утыру белән,— сез кичә инструктор кирәк диган идегез. Бик шәп кандидатура бар. Урта мәктәптән. Сания Вәлиева...

Кызның исемен әйтү белән Рәхимовның йөзенә кызыллык йөгерде.

— Беләм мин ул кызны,— диде Рәхимов йомшак кына.

— Белсәгез, шул кандидатурага ничек карыйсыз?

— Үзе риза булса?..

— Комсомолдыр бит ул...

— Билгеле.

— Бүген төштән соң минем янга керерсез, аңгамәгә.

Райкомол секретаре бер сүз әйтмичә чыгып китте. Шул көнне сәгать икеләрдә алар Рәшатның төшке аштан килүен кабинет ишеге төбендә көтеп торалар иде. Рәшат кызга кул биреп, нәзакәтле генә итеп исәнләште. Сания баштa бик уңайсызланды.

— Әле кичә генә барлык классташларымны яткын җирләр үзләштерергә чакырдым... Ә бүген?.. Килешеп бетәрме соң?

Рәшат күкрәк читлеген тарсынып типкән тынламас яшь йөрәген салкын акыл белән йөгәнләп, дулкынлануын кыздан ничек тә яшерергә теләп:

— Районның өч меңнән артык комсомолы өчен сезнең менә монда, без әйткән урында эшләвегез кирәк, иптәш Вәлиева,— диде йөзен житдиләндереп. Рәхимов та аның сүзен куәтләде. Саниянең сөрмәле керфекләре тирбәлеп куйды.

— Комсомол кушкач...— диде ул, алсу иреннәрен кыймылдатып. Сания белән Рәхимов ишеккә юнәлделәр. Шул чак Рәшат түзмәде:

— Иптәш Вәлиева, ә сез бер генә минутка калыгыз әле,— диде. Сания кире борылды. Рәхимов ишекне сак кына ябып чыгып китте.

Рәшат Саниягә урын тәкъдим итте. Үзе дә өстәл янына утырды, кызның алсу йөзенә тутырып, сокланып карады һәм:

— Сания, әгәр мөмкин булса, кыскача гына үзегез белән таныштырсагыз иде,— диде. Биографиясен сөйләргә өйрәнеп беткән булып чыкты ул. Сөйләндәй тезелгән тешләре арасыннан көмеш тәңкә чыңнары хәтерләтеп сүзләр агылды.

— Сугыш чыгасы таңда туганмын мин. Әти сугышка киткән. Указлы мулла була торып. Дин белән алыш-бирешен өзгән иде инде. Сугыштан имгәнеп кайткач кына тагын ни диептер шул кәсебенә тотынды. Әнием сугыш вакытында үлгән. Мине аның апасы карап үстерде. Ә әтием кабат өйләнмәде. Мулла диеп берүк кимсетә күрмәгез. Дөньядагы ин

зге кеше ул минем өчен. Үзем 1954 елдан комсомолда. Менә быел ута мәктәпне тәмамладым.

Ах, ничек гүзәл син, Сания! Теш арасыннан бөркеп чыккан һәр үзен күңелләрне сихри моң белән күмә, күзгә күренмәс тылсымлы ;епләр белән үзенә бәйли. Кемнәргә, нинди бәндәләр бәхетенә тудың, инди сулар эчеп үстең син, Сания! Рәшат тәкатьсез калды, күңелендә уган уйларга исем кушалмыйча теле көрмәлде, аңкавы кипте. Шулай а ул үзен кулга алырга тырышты һәм якында, менә монда, үз кабиетында, үз каршында утырган бу бәхет кошына омтылган, тартылган үңел ярсуын чак-чак тыеп:

— Сания, сезнең бүген ашыгыч эшегез бармы? — дип сорады. ның тавышы калтыранып чыкты. Кыз да моны сизде, алсу йөзе кызыл эмач кебек булды. Ул башын иде. Киң, ап-ак маңгаен бөдрәләр капады. Төз, матур борын өсләренә тир бәреп чыкты. Ул аны кулына эмарлап тоткан зәңгәр ефәк кулъяулыгы белән сөртеп алды.

— Юк, имтиханнар бетте инде... Ә нигә, абый? — диде ярым ышылдап.

— Бүген бик шәп кинокартина диләр. Бергә кино карарга чакырам.

Тамак төбенә төйнәлгән төерне көчкә йотып җибәреп әйтте бу экъдимен Рәшат. Саниянең сөрмәле керфекләреннән нурлар агылды, ул бер сирпеп каравы белән ул Рәшатны бөтенләй сихерләде.

— Килешерме соң, абый? Сез райком секретаре бит...

Бөрлегәндәй иреннәр әнә шулай дип тибрәнде.

Рәшат өстәл арасыннан чыкты, кыз янына килде, аның юка кофтаыннан беленеп торган йомры иңнәренә үзенең ап-ак нечкә бармакәры белән ягылды, бөтен тәненә кайнар ток йөгергәндәй булды. Ул лын, утлы тимергә тидергән төсле, кинәт түбән төшерде.

— Ә нигә килешмәскә? Мин әле семьялы кеше түгел,— диде ул эмшак кына.— Мин сезне 8 туларга 10 минутта кинотеатр янында этәрмен.

Сания, ризалык белдереп, башын иде һәм, ни өчендер, әллә дулынланудан:

— Рәхмәт, абый, сезгә,— дип ишеккә таба атлады. Рәшат ишек былганчы аның артыннан карап торды. Сания чыгып киткәч, кабинеті бары аңа гына хас татлы, исерткеч хуш ис аңкып калды.

Нәфис, йомшак куллар җылысы китмәгән ишек тоткасына тотынып, эшат Галиевич коридорга чыгып керде. Күңеле бөтен барлыгы белән ізрәк кояш баюын, кич булуын теләде. Эш сәгатен тизрәк үткәреп ибәрү өчен пропаганда бүлеге инструкторлары белән киңәшмә үткәр-. дөресрәге — алар белән җентекләп танышып чыкты. Алга таба шләү өчен бу да, билгеле, кирәк һәм зарури иде. Аннары район газеісы редакциясенә барып килде, андагы хәлләр белән таныштты. Редакәр вәкиллектә иде, журналистлар белән сөйләште, аларның кай тирәэрәк йөзүләрен, талантларын беләсе килде.

Зарыктырып көткән кич, ниһаять, житте. Күк шәфәкъ нурларына мелде. Ашханәдә булганнан соң Рәшат урамнардагы күргәзмә агиция материалларына күз йөртеп чыкты. Аннары район үзәгенең парк п аталган, шаулап чаган үскән бакчасына китте. Анда яшүсмерләр, усик-майкадан гына калып, футбол тибәләр иде. Бакча зур, яшел рәм белән капланган. Тик әйләндереп алган коймалары ауган-түнгән: түе белән сарык йөри, яшел чирәм өстенә яшькелт-сары каз бәбкәре сибелгән. Алар тирәсендә ата казлар каңгылдаша. «Комсомоллар лы тигәндә бер дигән күңел ачу урынына әверелдерергә була бит ны»,— дип уйлады Рәшат һәм кинотеатрга барырга дип бакча капсына таба борылды. Бераз гына барган иде, уң яктагы аллеядан іра плиссеровка, җиңсез ак кофта кигән, кулына ромашкалар тоткан ния килеп чыкты. Көтелмәгән бу очрашудан алар икесе дә каушап

калдылар. Рәшат аңа таба омтылды. Ләкин якын барырга кыюлыгы житми туктап калды. Сания сөрмәле керфекләрен түбән төшерде, аның кояш нурларын җыйган алма кебек битендә шәфәкъ алсулыгымы, әллә үзенең дулкынлану хисләреме балкып китте.

— Мин кинога кадәр йөрим дигән идем... Иртәрәк бит әле,— диде Сания. Рәшат аңа якын килде һәм иелә төшеп:

— Әйдә, миңа бакчагызны күрсәтегез әле, Сания,— диде һәм әллә яңа гына Сания килгән аллеяга таба атлады. Сания дә аңа иярде. Рәшат аны култыклап алмакчы булды. Ләкин Сания сак кына читкәрәк тайпылды. Беравык сөйләшми бардылар. Аллеяның куләгәлерәк урынында агач эскәмия күргәч, Рәшат Саниягә кулы белән ишарә ясады.

— Әйдә, бераз утырыйк, Сания.

Кыз итәкләрен җыеп әкрен генә утырды, башын түбән иде. Рәшат аның аккош муенындай коеп куйган муенына сокланып карады. Ләкин моны Саниянең үзенә сиздермәскә тырышты. Ул Сания кулындагы ромашкадан кәсә яфракларын як-якка сузган бер сабак алды да:

— Сания, әйдә сынап карыйк, дөрес әйтә микән? — диде һәм ромашка чәчәгенең кәсә яфракларын, ярата, яратмый, дип өзә башлады. Сания дә күзләрен Рәшат кулындагы ромашкага төбәде. Ә Рәшат һаман санады, ярата, яратмый, ярата, яратмый, ярата!..— Соңгы кәсә яфрагын ул әнә шулай дип өзде, ялт итеп Саниягә карады һәм:

— Хакмы, Сания, мин ялгышмыйммы? — дип сорады.

Бу кичне дә, аннан соң да алар кинога бара алмадылар.

Айлар буе бергә булганнан соң гына Сания үзен култыклап йөрергә рөхсәт итте.

Өйләнгәнче Рәшат аңа үз бәхетенә күктән иңгән бер изге зат итеп карады. Ә шаулатып туй ясаган кичне ул кулында мөлдерәмә тулы бәхет шәрабе урынына ачы мәхәббәт газабы тутырылган кәса булуын белеп тораташ катты. Ләкин моны Саниянең үзенә әйтмәде, бу турыда Сания дә сүз кузгатмады. Санияне беренче күрү белән туган хисләренә, үз антына хыянәт итәсе килмәде аның. Йөрәгендә мәңге эремәс таш утырса да, изге хисләрен юшкын сарса да, ул барыбер Саниясе белән горурланды. Аның белән кешеләр алдында күренүе үзе бер хозур, бәхет булып тоела иде аңа. Бергәләшеп кая гына барсалар да, күзләр аларга төбәлә, дөресрәге — Саниянең чибәрлегенә, сылулыгына кемнәр генә хәйран калмый иде.

Өйләнешеп алты ай торганнан соң аларның кыз балалары туды. Ләкин ул гомерле булмады. Шул кызчыкны җирләгән көнне Санияне беренче тапкыр кызмача хәлендә күрде. Баланы җирләп кайтуга, ул ишекләрне бикләп, йоклаган иде. Көчкә ачтырды. Килеп керүенә Сания аның иңнәренә сарылып елап җибәрде.

Алар беренче тапкыр икесе ике урында төн чыктылар.

Шуннан башланды.

Кеше алдында итагатьле, бер-берсе өчен үлеп торучы ир белән хатын булдылар алар. Юк, Саниягә укытучы түгел, артист булырга кирәк иде. Саниянең үз тормышын да талантлы артист кебек үткәрсен, Рәшатның үзенең дә шуңа әкренләп күнегүен кемнәр белгән! Семья тормышында ике төп рольне уйнаучылар булып калдылар алар: икесе бергә ялгыз бүлмәдә калырга, бер түбә астында йокларга читенсенә, ятсына, юк, курка башладылар. Рәшат килеп орыну белән Сания сискәнеп китә һәм сөрмәле күзләрен зур итеп ачып:

— Рәшат, кагылма, бәгърем! — дия. Канаты каерылган кош хәлендә кала андый минутларда Рәшат, ни уйларга белми гаҗизләнә һәм, салкын мендәргә башын төртеп, куырылып төн уздыра...

Ул Санияне атаклы невропатологларга күрсәтте, ял итсен, күңеле ачсын дип санаторияләргә җибәрде. Алай да рәт чыкмагач, ике арага эленгән кара пәрдә аша аз гына өмет бирерлек мәхәббәт нурлары

үткәреп булмасмы дип, аптырап, Саниянең этисе янына да барып кадлы. Кеше сизмәсен дип, төнлә барды. Инде нык таушалган, сакалы китен төсле агарган мулла абзый аны сүзсез генә тыңлады. Аннары, керфексез күзләрен челт-челт йомып:

Тән керләнсә, ана мунча бар,
Хәстәгә дә табыла дәвалар,
Сүнгән мәхәббәтне кабызырга
Нинди чара, нинди дәва бар? —

нде, башын игән килеш түр сәкедәге киез өстендә бер мизгел уйланып тырды. Рәшат аннан җавап көтте, яшь чагында, сабый вакытында Саниянең бирәр шаукымга эләгүе, куркуы турында сүз көтте. Ләкин карт авызыннан шуңа юрарлык сүз чыкмады...

Ә гомер йомгагы тәгәри бирде. Педагогия институтындагы танышлелешләре аркылы Санияне шунда укырга кертте. Сессияләрне көтеп лды ул. Сания имтиханнарын тапшыргач та унар-егермешәр көн айтмады. Акчасы бетсә генә шалтыратты. Ләкин җир астыннан йөргән ланны да сизәләр бит, үзе сизенеп йөргән, инде чынлап инанган нәрәләр халык теленә дә керә башлады.

Семьядагы низаг обкомга да барып ишетелде. Берсен дә яшермичә әфсилләп аңлатма язарга туры килде. Хәленә керделәр, аны икенче айонга күчерделәр. Авыл хуҗалыгы производство-территориаль идаәсе начальнигы итеп куйдылар, зур власть бирделәр.

Рәшат башта авыл хуҗалыгы производство идарәсендә эшләде, ннары, ел ярымнан соң, аны Кама буе районнарының берсенә райкомың икенче секретаре итеп тәкъдим иттеләр. Бирегә килгәнче шунда шләде. Сания дә берникадәр тәртәгә кергән кебек булды. Әйбәт кенә кытып йөрде. Ләкин ике арадагы боз һаман эремәде. Икесе ике дөнья ешесе булып яшәделәр алар. Сания квартирга кергән кеше кебек шәде. Рәшаттан акча сорамады. Ул кайтарып куйган акчага тимәде. атлы киемнәр алып бирсә, кире какмады. Елмаеп, рәхмәт,— диде. Эштән кайту белән дәресләрен хәзерләп, каядыр чыгып югалды. Ял өне өйдә кунмады. Рәшат, аптырагач, авылдан әнисен алып килде. Колхозда эшләүче ике энесе бик каршы килсәләр дә, хәлне сөйләп иргәч, күнделәр тагын. Энесе Ибраһим эт итеп сүкте сүгүен... «Шундый хатын белән торалар димени!.. Куып чыгар да икенчегә өйлән! Ир кеше бит син. Күрерсең абый, мин әйтте диярсең, ләкин соң булыр...» — иде. Энесенең бу сүзләреннән сискәнеп китте ул һәм шикләнеп тә уйды... «Әллә Вера Александровна белән бәйләнешне сизгәнме?» — ип уйлады.

Рәшат күзгә каршында чәчләрен төзәтеп торган Саниягә сокланып арады да күзләрен йомды. Очраклы рәвештә генә таныштыл ул Вера лександровна белән. Ниндидер киңәшмәдән соң «Казан» гостиницасы есторанында бераз утырып чыгыйм дип кергән иде. Менюны караштыргалаганда аның өстәленә, рөхсәт сорап, бер ханым килеп утырды. ур гына гәүдәле, коңгырт бөдрә чәчле, Саниянеке кебек бөрлегәндәй ренле,— тик аскы ирне бераз калынрак,— чалт аяз көнге күк йөзедәй аңгәр күзле, утыз-утыз биш яшьләрдәге хатын иде бу. Башта Рәшат аказ бирде, аннары ханым шуларны ук кабатлады. Йөзәр грамм оньяк икесенең дә йөзләрен алсуландырды. Рәшат ханымга сүз куша лмый гаҗизләнде. Сүтелергә торган әзер йомгак очын табарга ирәк иде.

— Командировка беләнме, кая килдегез? — диде ул, беренче блюда елән исәп-хисапны бетергәч.

— ГИДУВка, белем күтәрергә, безгә, врачларга, гомер буе укырга ирәк бит,— диде ханым, елмаеп.

Ходавәндә! Аның да бит очлары Саниянеке кебек уймакланып әра. Рәшатның йөрәге чәнчешеп алды.

Сүз шуннан ялганып китте. Өстәл артыннан кузгалганда алар инд бер-берсе белән шактый танышып алырга өлгергәннәр иде. Хәтерд салмак кына кар яуган караңгы төн. Рәшат аны Бауман урамы буйла озата барды. Икенче трамвайның «Вузовец» янындагы тукталышын чыкканда Вера Александровна кинәт таеп китте. Рәшат аның юк пальтосы аша сизелеп торган юан беләкләреннән эләктереп алды. Вер Александровна аңа сыенып, кат-кат рәхмәт әйтте һәм: «Мин егылсаң Казанда җир тетри иде инде, бәхете бар икән»,— дип урам яңгыратып рәхәтләнеп көлде. Маяковский урамындагы ике катлы агач йорт янын житкәч, Вера Александровна туктады һәм күн перчаткасын салы буынланып торган бармаклы кечкенә кулын сузды.

— Менә шушында яшим мин, онытмагыз, йорт номерын дим,— диде Рәшат аның йомшак кулларын җибәрмичә, йорт номерына күз төшер де дә:

— Квартирдамыни? — диде.

Вера Александровна кулын ычкындырмады, һавалы гына ите күкрәген киерә төште һәм елмаеп:

— Әйе, апам белән, мин бит Казан кызы,— диде, үзе Рәшатны ябык кулын кысты. Рәшатның хатын-кыз белән булмаганына күп, ә күп гомерләр үткән иде инде, ул бу якынлыкны үзенчә аңлады, бөте тәненә егет вакыттагы кебек ниндидер тылсымлы кайнар җылылы йөгерде. Ул Вера Александровнаның бераз дымыгып торган йомша нәфис бармакларын каты итеп кысты... Алар йорт каршында байта тордылар. Өсләренә ябалак кар сарды, ләкин алар аны сизмәделә Вера Александровна, салкын керә башлаган аякларын җылытырга те ләп, тыпырдап алды һәм:

— Әйдәгез, сез дә өшедегез бугай, җылынып китәрсез,— дип өйг чакырды. Аларга өлкән яшьтәге бер ханым ишек ачты.

Ул бу төнне шунда үткәрде. Гостиницага иртән генә кайтты д әйберләрен алып, аэропортка китте. Казанга һәр баруында ул Вер Александровна янында булды. Вера Казан больницаларының берсенд балалар врачы булып эшли. Ире дә врач булган, автомобиль аварис сендә үлгән. Ир кадерен белә торган акыллы, ягымлы хатын Вер Александровна. Рәшат аңа үз фаҗигасен түкми-чәчми сөйләде. Вер аны уйга калып, игътибар белән тыңлады һәм, нишлисең, мәхәббәтн закон юк, диюдән башка сүз әйтмәде. Нык иярәштеләр алар бе берсенә. Көн аралаш диярлек телефоннан сөйләшеп тордылар. Монд килгәч тә шалтыратты инде Вера. Яңа район, яңа шартларга ниче күнегәсең, авыр түгелме? дип хәлләрен сорашты. Ә Саниянең бу туры да ләм-мим сүз кузгатканы булмады. Аңа син эллә эшлисең, эллә ю Юк, яшәү түгел аның бу тормышы. Әнисе дә озак тормады, миңа ыш ныл, гомер буе шушылай хатынлы буйдак булып яшәр идең дип, те районда чакта ук, авылдагы малайларына кайтып китте. Әллә нич тапкыр Саниягә уралган өметсез мәхәббәт җепләрен өзәргә, күңеле мөлаем да, кадерле дә булган Вера Александровнаны, аның якты, м тур образын беркетергә теләде. Ләкин шул уй килү белән Саниян коеп куйган сылулыгы Вераның елмаеп, көлеп торган йөзен, аңа бу ган хисләрне, бөдрә болытларның җир өстеннән шуып барган күләгә төсле, караңгылый, каплап китә...

Рәшат уйларыннан арынырга теләп, башын селкеп куйды, торы утырды һәм әле һаман көзге янында бизәнеп торган Саниягә дәште

— Сания, әзрәк тамак ялгарга иде бит,— диде.

Сания, алсу иреннәренә эләктергән приколкасын да алмыйча, а таба борылды да:

— Кухняда, үзең җылыт инде,— диде.

Рәшат иренеп кенә кузгалды. Көндез үк пешереп куелган ашлары җылытып ашады. Ул чыгуга, Сания яңадан өс-башын алыштыры

тагын каядыр барырга җыена иде. Хатын ишеккә таба атлый башлау белән Рәшат аның каршысына төште һәм:

— Сания, бәгырем, соң бит инде, йокла,— диде. Сания сөрмәле күзләре белән сирпеп карады:

— Рәшат, каршы килмә миңа, үтенәм,— диде ул, сөттәй ак муенына элсу кимоно сала-сала. Рәшат тиз генә ишекне бикләп алды һәм йомшак кына итеп:

— Йокла, бәгырем... Беренче көннәрдән үк минем авторитетны сатма инде... Миңа эшләргә дә кирәк бит,— диде иңәнеп. Хатын бер сүз дәшмичә аның алдында басып торды. Аннары кырт кына борылды, өсбашын салып ыргытты һәм җыештырып куелган караватка өстенә шул килеш менеп ятты, ятты да үксеп, ачыргаланып елап җибәрде. Рәшат, бер кулына каяндыр эләккән газет тоткан килеш, аны карап торды. Ә Сания елый, сабый балалардай өзгәләнеп, үрсәләп яшь коя. Ул, ап-ак иендәр тышларын күз яшьләре белән юып, йокыга китте. Рәшат шуннан соң гына япмалары идәнгә шуып төшкән салкын диванга барып ятты... Күзен йокы алмасмы дип тагын саный башлады. Әллә ничә тапкыр йөзгә җитте, тагын, тагын башлап карады, ләкин керфекләр тирбәлүдән туктамады... Күз алдына әле Вәрәшов, әле «1 Май» колхозы председателе Вильданов, әле тешләрен ыржайтып, шул ук колхозның ындыр табагында очраган Заман карт килде. Вильданов каты чикләвек булырдай күренә. Ләкин ватылмый калган чикләвек юк... Шелтәне кабул итмәде, йөзе, кыяфәте шуны сөйли иде... Соң, миңа җиңел дип беләсеңме әллә син шелтә бирүләрне, Рамай Ибраһимович!.. Әйткәнне үтәргә иде. Минем урында үзең булсаң, син нишләр идең? Беренче секретарь үз сүзен үткәрмәсен әле!.. Ни була ул? Кая партия, кая дисциплина?..

Өлкә комитетыннан янадан звонок булуны, икмәк мәсьәләсенең кабыргасы белән куелуын белмисең бит син. Шуннан соң теге мең ярымга да барып ябышырга туры килде. Ә бит синдә ипи бар, бар... Хәллегә таянмыйча, гел беткәнне ничек бетерәсең?

Кинәт Сания ыңгырашырга тотынды. Рәшат торып аның янына барды. Йөзтүбән яткан, тыны кысыла. Ул Санияне сак кына борып яткырды, өстенә үз одеалын китереп япты.

## 6

Урам читындагы карт чаганнар күләгәсендә машинада гамьсез йоклап яткан Дамир, ишекне ачып, касыгына ике-өч тапкыр төртмичә күзен ачмады. Әмма исенә килү белән, шундук торып утырды һәм стартерга да басты, бер кулы белән күзен уа-уа, икенчесе белән тизлек рычагына тотынган килеш:

— Нәрсә булды, Рамай абый, бик соңладыгыз? — диде.

Яхъя белән Кәрам артка кереп чөңкәйделәр, Рамай ишекне каерып ачып кереп утырды да аны яба-яба:

— Нишләп ябылмый соң бу? Ничә әйттем замогын кара дип, берсен төшереп үтерәсең әле син моның белән. Ярар мин генә булсам, котылырлар иде,— диде.

Машина, район үзәгеннән чыгып, Чаллы трассасы буйлап чаба башлагач, «Менәтерә, кодагый, иске авызга яңа аш диген, ә... Күп йөрсәң шул була ул, чәпеделәрме яңа аш, бугаздан килерлек булды»,— диде. Аның сөйләшәсе, күңеленә төйнәлгән уйларны таратасы килә иде. Ә парторг белән Кәрам, авызларына су капканнармыни, буш чүлмәк кебек тирбәлеп кайталар. Рамай Кәрамга кычкырды:

— Кәраметдин, сиңа да строгач чәпәргә мәтәшәме?

Кәрам алгы утыргыч сыртына ябышып аңа таба иелде һәм:

— Гел чәпәрие! Кәрам абзаң белән шаярма, утта янмый, суда батмый ул!.. Мин судан коры чыктым, менә сез генә аяз көнне яуган яңгырга эләктегез...— диде.

Сүзгә Яхъя да кушылды.

— Рамай Ибраһимович, кайгырма, биргән әйберне алалар аны. Алырлар, ялгышсак, эш белән аклярбыз. Ләкин минем йөрәк тәки ул нәрсә белән ризалашырга теләми, очып чыгып китәм дип тилпенә.— Ул күкрәк кесәсеннән флакон алып, тел астына нидер кыстырды. Бераздан машина эченә валидол исе таралды.— Ә мин, Рамай, ул әйткән центнерны барыбер тапшырмаска, дим. Үзебез утырган ботакны үзебез кисәбез булып чыга бит алайса.

Рамай авыр сулап куйды.

— Юк, Яхъя, син әле яшьрәк, аңлап бетермисең... Беренче секретарь белән сөзешеп булмый. Тапшырабыз... Ул әйткән санны үтибез... Әмма бер әйберне кулдан ычкындырмаска кирәк. Районга кварталлап комбикорма җибәрелә, разнарядка белән. Өченче һәм дүртенче квартал разнарядкаларына кармак салырга кирәк. Тавыклар, дуңгызлар өчен ул барыбер кирәк. Бер ике-өч ел шулай кыланган бар минем. Иртәгә болай эшлибез: Рәшат Галиевич, менә әйтте диярсең, таң белән я үзе килеп житә, я тагын колоннасы белән машина җибәрә. Ә мин үзебезнең ике-өч машинаны райсоюзга озатам. Аларның товар кайтара алмый гажизләнгән вакыты хәзер. Күптән түгел райпотребсоюз председателе инәлә-инәлә ялынды. Беренче мөмкинлек белән дип вәгъдә дә бирдем. Аннан кимендә ике кварталга ике-өч йөз центнерны каерырга була. Аннары Вәрәшов аша идарәне кысам. Чаллы элеваторы директоры белән дә сөйләшенү бар: ул бер 500 центнер отход бирердәй әйтте. Бергә уйнап үскән малай бит.— Рамай йөткереп алды да сүзен дәвам иттерде: — Кыскасы, Яхъя туган, икмәк амбарга кереп беткәнче, аларның ишекләре пломбаланганчы икмәкне тотарга да, Шәймиевчә туздырырга да була. Бу заман председателенә бер кулың белән бирә, икенче кулың белән шуны ук ала белергә дә кирәк. Авырайды, үтә катлауланды хәзер эш... Әллә йокладыгыз дамы? Йоклатмыйм мин сезне бүген, тамырларымнан кара кан ага башлады, чамалагыз! — дип кычкырды. Яхъя белән Кәрамның: «Юк, юк, Рамай Ибраһимович»,— диюләрен әллә ишетте, әллә юк, Дамирга уң якта күренгән күпергә таба борылырга кушты: — Шәкүр абыйга кагылыйк әле! — диде ул, кычкырып. «Волга» Минзәлә елгасы аша салынган күперне чыкты да яр аслатып сузылган җәйге юлдан җай гына элдерде. Су буе тулы каз. Алар утрауутрау булып кунаклаганнар. Машина яктысына элэгү белән муеннарын сузып каңгылдашып алалар. Яр өстендәге әле яңа яшелләнеп килгән уҗымда ике ат йөри. Аларны күргәч, Рамай йөзен чытып куйды.

— Габдерәуф белән Миргасим атлары, әләктерермен әле мин сезне! — диде. Яхъя белән Кәрам да тәрәзәгә карадылар. Атлар тышауланмаганнар да иде, Дамир сигнал биргүгә, уҗым буйлап югарыга таба чаптылар.

Колхозның бер бригадасы булып калган бәләкәй генә авылга килеп керделәр. Капка төбе саен карт өянкеләр. Һәр йорт алдында диярлек колонка. Алты почмаклы, калай түбәле зур гына йорт янына килеп туктадылар. Күперне күрсәткәч тә Дамир председательнең кемгә баруын белгән иде инде, хак та шуңа — колхозның элекке баш бухгалтеры, хәзер пенсиядәге Шәкүр картка булып чыкты. Рамай машинадан төште, юлдашларына кул болгады, Дамирга да калмаска кушты. Капкадан ишегалдына керделәр. Рамай өй алды ишеге янындагы звонокка басты. Башта түр өйдә, аннары верандада ут кабынды. Менә кемдер кыштыр-кыштыр ишеккә килде, тамак кыра-кыра келәне ычкындырды һәм ишекне ачып:

— Кем йөри анда җиде төн уртасында, оя тапмаган әрвах кебек? — диде.

— Ач әле, Шәкүр абзый,— бу мин,— диде Рамай.

Карт бераз дәшми торды, әллә йокылы-уяулы иде — тавышны танып житкермәде. Юк, таныган икән, сукрана-сукрана өйалдына чыкты һәм:

— Үзе дә йокламас, кешегә дә тынгы бирмәс. Карт сөякләремне жылытыйм дип карчык янына гына менеп яткан идем... Син икәнсең әле, төн убыры. Нишләп йөрисең, иртәгә житешмәсиеңме? — дип, ишекне ачты. Рамай артында басып торучыларны да күргәч, сызгырып жибәрде: — Фи-у-у! Нигә аны кунаклар да бар димәдең, струкланмаган!

Рамай кулын селтәде дә:

— Нинди кунак ди, үзебезнекеләр генә алар,— дип, болдырга күтәрелде.— Һии, син, Шәкүр абзый, оятсызлар болар, төн уртасында басып керәләр дип гаепләмә инде. Өйгә кергәч әйтергә калдыр аларын,— диде һәм эре-эре атлап кереп тә китте. Барысы да аңа иярделәр. Өйгә кергәч, Рамай алдында ак ыштан, ак күлмәк белән генә басып торган Шәкүр картка күз кысты һәм тамак төбенә чиертеп күрсәтте.

Шәкүр карт көмеш тешләрен ялтыратып көлеп жибәрде һәм:

— Җиде төн уртасында юньле кеше йөри димени, әйттем бит, я оя тапмаган әрвах, я сезнең кебек оятсызлар,— диде. Үзе тыз-быз йөгерергә тотынды: олы табаны газ плитәсенә утыртып, Рамай алдына бер иләк йомырка куйды.— «Жәрки ясый тор, мин тозлы кыяр, казылык, сөт өсте апкерим әле»,— дип, аягына кунычсыз киез ката гына элдерде дә ялан өс, ялан баш тышка чыгып китте. Зур гәүдәле, эре сөякле, инде яше житмешнең өстендә булуга карамастан, Шәкүр карт барлы-юклы егетләреңә генә биргесез әле. Дөп-дөп басканда стенадагы сәгать телләре уйнаклап китә. Табә куырылуга өстәлгә казылыгы да, табагы белән тозлы кыяры да, мискисе белән янә аертылган сөт өсте дә менеп утырды. Көмеш тешләрен ялтырата-ялтырата, Шәкүр карт бер ярты да китереп куйды.

— Кабат сорамагыз! — диде бармак янап.

Яртыны бишкә бүлеп эчтеләр. Рамай ипи генә иснәде, башка ризыкка кагылмады, шытыр-шытыр кыяр чәйнәүче Шәкүр картның касыгына төртте:

— Бар әле, саранланып утырма, кабереңә алып китмәссең,— диде.

— Бусысы соңгысы, чамала аны!..

Шәкүр карт тагын түр өйгә кереп китте, жиң эченә тагын бер шешә тыгып чыкты.

— Әбиегез сиздe, башын күтәрде. Т-с-с-с!..— диде ул, авызын ерып. Дамир кабат тотмады, дүртесе шешәне ектылар. Шуннан соң гына Рамай ашарга кереште. Тамак ялгап алгач, эчендә кайнаган ут ялкыннарын сүндерергә теләп, Шәкүр картка зарланырга тотынды.

— Шәкүр абзый, әй белсәң хәзер эшләүләре ничек авыр икәнен... Синең белән эшләгән вакытта да жиңел булмады, ни тотсаң шул юк иде. Ни дисәң дә бер авыл. Бөтенесе күз алдында. Хәзер әлекке дүрт колхозны сөйрәргә кирәк...

Шәкүр карт Рамайның иңнәренә кәрәктәй кулы белән сукты һәм көмеш тешләрен ыржайтып:

— Җилкәң калын, сөйрә, синдәйләр сөйрәмәгәч, кем сөйрәр аны, зарланма!.. Хәзер баш дигәнеңдә дә мәкинә генә түгел. Техникум бетергәнсең дип ишеттем озын колаклардан, шуны юарга да кермәдең... Беләм мин сине, эшең тәгәрәп барса, Шәкүр карт нипочум, ә койрыгың бозга ката башласа,— каравыл, Шәкүр абзый! — дип төн уртасында булса да басып керәсең,— диде.

— Хак, пәйгамбәр сүзе сөйлисең, кем, Шәкүр абзыкайларым, вакыты белән баш эшләми башлый. Әлек ничек иде: нәрәт бирдең, үтәлеш-

не тикшерден и вәссәлам! Игенчелектә кайгың юк: МТС сөрә, чәчә, ура. Барлы-юклы терлекчелек белән мәж килә иден. Ә хәзер...

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, якаларын ычкындырып, костюмын җай гына җибәргән Яхъя сүзгә кушылды:

— Һәр чорның үз авырлыгы була инде анын, Рамай Ибраһимович. Элек идарә итәргә җиңел булган. Сәбәбе? Идарә итәр нәрсә юк. Техника синдә түгел, кулыңда вак-төяк инвентарь да кешеләр. Правление болдырына чыгып бер кычкырсаң, эш бетте диң.

Парторгның бу сүзләре Рамайның авырткан җиренә тиде, ахрысы, күзләре зур булып ачылдылар. Ул Яхъяга сәерсенеп карап торды да:

— Эш бетте бер кычкыру белән дисеңме? — диде ул пышылдап һәм Шәкүр картның касыгына төртте.— Шәкүр абзый, ни ди бит, ә? Чепуха булган икән элек. Эшләп йөрисе дә калмаган... Ну, брат, постой, хәзерге яшьләргә генә сөйләве җиңел... Каккан казыксыз калган, бөтенесен җиңү шәрәфенә биреп, җанын гына саклап калган колхозга тән кундыру, аягындагы чабатасын салдыру әллә җиңел булды дисеңме? Ә былтыр сез дүрт авылдан эзләп, музейга куярга да бер кием чабата таба алмадыгыз. Бәхетегез, Заман карт ясап бирде. Тамагы туйгач, өс-башын карарга, аннан йорт-җирне адәм рәтенә кертергә кирәк булды. Аннары гына башны күтәреп, башкалар нишли икән дип, тирә-юньгә күз салдык без... Аякка басуы авыр, аякка! Аннары атлап китәсең аны...

— Рамай Ибраһимович, сез мине дөрес аңлап җиткермәдегез бугай, мин ул чорда әнә шул идарә итәр әйбернең нигезе — кесә сай, тәпи кыска булу турында әйтмәкче идем.

Парторгның бу сүзенә Рамай кул селтәде һәм Шәкүр картка дәште:

— Шәкүр абзый, сөйлә әле шушы яшел борыннарга,— диде казылык чәйни-чәйни һәм Яхъя белән Дамирга төртеп күрсәтте.— «1 Май»ның тәпиен ничек озайтканны.

Шәкүр карт йомыры төбендә калган аракысын йотып куйды да кул аркасы белән иреннәрен сыпырды:

— Ниен сөйлисең инде анын, кем, Рамай туган? Булган — буявы сеңгән, барыбер Рамай белән Шәкүр карт эше димәсләр. Кем генә хәтерли аны хәзер,— диде, әмма бу турыда ул сөйләргә ярата, җае гына чыксын да тыңлаучы гына булсын. Яхъяның да, Кәрамның да, Дамирның да үзенә текәлеп карап торуларына һушланып, ул көрәктәй кулларын таза ботларына куеп сөйләп китте: — Шәехзадә картның җилеген сугыш еллары сыкты. Минем баш эшли дә бит, карт йөри алмый... Ярар, анысы калсын... Рамайны председатель итеп куйдык. Анда сугыла, монда сугыла, бәгырькәем. Моннан тартып ала, тегеннән бүселеп чыга. Шушы Рамай эшли башлаган елны мин Әлмәт районына кунакка бардым. Никифор дус янына, икебез бергә Азин дивизиясендә булган идек. Гомерлек ахирыләр булып калдык, сүләсәң, историясе күп инде анын. Ярар, анысы калсын. Шул акча сугу җаен тапкан бит, мин сиңа әйтим. Киндерчелек бригадиры булып эшли икән. Ул чакта киндер орлыгы бик кыйбат чак. Центнеры 800—1000 сум, иске белән. Мин барган елны гына бу карт колхозга 600 мең табыш биргән, унике ат, егерме хатын белән эшләп. Минем күз дүрт булды моны ишеткәч. Төне буе кәгеп, сүләшеп чыктык. Теләндем, ялвардым, ике центнер итәк астыннан, биш центнер колхоздан киндер орлыгы алмыйммы мин! Рамай белән киңәш-табыш юк әле. Кайткач, бу тоз күзгә сөйләдем. Куанды, центнерына ике мең белән ундүрт мең сум акча,— искечә инде,— хәстәрләргә кирәк булыр, хәзер үк өч олау чыгарып җибәрергә дигәч, тоз күзләре аларды. «Каян алыйм мин ул акчаны, болай да арестта утырабыз, бирәчәк муеннан!» — ди бит бу. Күп киңәшә торгач, мин дә, Рамай да үзебезнең сыерларны саттык, ун мең җыелды. Калганын кешедән үтечкә җыйдык. Озын сүзнең кыскасы, шул язны инеш буендагы су баса торган болынга чәчтек без моны. Хәзерге кебек

юньле агрономы бармы әле аның ул чакта. МТСның баш агрономы белән киңәштек. Аннан ике китап алдык. Берсе миндә, берсе менә монда. Чын фән кушканча үстердек бит моны. Гектардан уникешәр центнер орлык чыкты. Киндерен вак көлтәләргә бәйләп, яр өстенә тараттык,— кыш кышларга. Икенче җәйгә ул тапшырырлык була, анысын да сораштырган идем инде Никифор ахирыдән. Шул елны йөз гектарга җитәрлек симәнә салдык. Әле егерме центнер дәүләткә дә саттык. Теге үтечләрне түләдек. Икебез дә яңадан сыерлы булдык. Шуның акчасына, яшь булса да, үсә бит ул, нәсел үгезе алдык.

— Бозау диген,— дип бүлдерде аны Рамай.

— Үсә бит ул, дидем бит, бүлдермә әле. Шуннан китте бит безнең даннар. Беренче тапкыр йөз гектар чәчкән елны аресттан чыктык, төрле оешмалардан алган үтечләрне түләдек. Шуның акчасына электр станциясе корып җибәрдек, пилорам сатып алдык. Бәхеткә, ул елны ипие дә уңды. Ну, ул вакытта ярты ипи МТСка китә, дәүләткә сатудан да колхозга рәтле файда юк, ипи сатып тернәкләнү турында сүз дә йөртеп булмый иде. Колхозчыларның авызы ипигә шул елны туйды. Законлы итеп бер кило бирдек трудоденьга...— Шәкүр карт Рамайга карап алды һәм: — Бусын да сөйлимме? — диде. Рамай кулын болгады, сөйлә, янәсе. Рамайның хәер-фатихасын алган Шәкүр карт үткән көннәр истәлеген тагын яңартты.— Атлан басуында бер яр бар, хәтерләсәгез. Аны хәзер күмдерделәр, тигезләделәр, шунда салам сыдырттырып, ару гына ипи яшергән идек. МТСның ике комбайнчысын көйләдек тә, давай төнлә урырга. Берсендә мин, икенчесендә бу тоз күз. Бункер тулу белән, әллүр теге ярга, шунда агызабыз да тагын урырга китәбез. Шуннан тагын трудоденьга яртышар кило рәт чыгардык. Исәпсез генә шактый ярым фураж, ашлык калды. Исәпсез дигәч тә, биргәннәр икән кирәген икесе бер булып дип уйламагыз тагын. Кара кенәгәдә килосы да учетта. Ике данәдә, берсе монда, берсе миндә. Ашлык иң үтемле товар ул чак. Шуны төртеп, әле агачын, кадагын, пыяласын алдык. Хәзерге детсадны шуның белән җиткердек без, бик беләсегез килсә. Ул елларны бу детсадны Мәскәүдән дә килеп карадылар бугай әле.

— Казаннан диген...— дип мыгырданды Рамай. Аның башы кинәткинәт төшеп китә башлады. Шәкүр карт аңа күз генә төшерде дә Яхъяларга карап сүзен дәвам иттерде:

— Озын сүзнең кыскасы, икенче елны да чәчтек без теге акча янчыгын. Миллионер булдык. Районда беренче булып рәсемнәребезне гәҗитләргә бастырдылар. Мәскәүгә күргәзмәгә кадәр барып җиттек. Барган җирдән буш кайта торган гадәт юк бит минем. Чөнки барысы да учетта. Әллә никадәр юл расходлары тотып Мәскәү тинелте Мәскәүгә кил дә ди син, шуннан колхоз өчен берәр җай чыгарма, ди. Минем карактирга ябышмас ни бит ул. Күргәзмәдә тора, мин сиңа әйтим, безнең киндер көлтәләре! Петр патшаң буе да җитәрлек түгел көлтә бавы турына. Ничәмә миллион кеше авызын ачып карады аны. Мин дә кукыраеп торам шунда, сораучыларга сибәм генә борчак.

— Син мачтак инде аңа, иске авызыңа яңа аш түгел.— Рамайның шулай дип мыгырдануын Шәкүр карт сизмәмешкә салышты.

— Кичен эш юк. Ятам гостиннарында бүрек белән киңәшеп. Шәкүр, мин әйтәм, болай булмый бит, күрәсен күрдең, үзеңне күрсәттең, юкка ипи черетеп ята башладың түгелме? Кайткач ни диярсең колхозчыларга? Кунак булдым да вәссәлам, диярсеңме? Син бит отпускыда түгел, ял йортында да, дим. Кулда командировочный, күргәзмәдә катнашу мандаты — мондый хәтәр документлар белән әллә ниләр кырырга була, мин әйтәм. Ә портфельдәге безнең файдага җырлап тора торган кыгаз-мигазлар тагын күпме? Гәүдә бар. Күкрәк дигәнең дә хода ким-хур итмәгән, киттем бер көн шулай Авыл хуҗалыгы министрлыгына вәжний господин булып. Ул көнне исәнәеп йөрдем. Безнең кебек килүче-китүче-

нең чуты юк икән анда. Тик берсе дә мә дип кыймаган, барысы да минем кебек теләнүче. Пензадан бер мишәр картын очраттым. Аларда да киндер белән җенләнәләр икән. Председатель бу, шомарып беткән, пеләш башы кебек. Теге өйрәтте бит миңа юлларны. Икенче көнне кабул итәргә сорап, язу яздырып, кайтып киттем. Алла галәмәте, билгеләнгән сәгатькә мине Авыл хуҗалыгы министры кабул итмәсенме! Зур нәчәльник бит, башта тез буыннарының рәте китте. Әллә шуны сизеп, «Садис, старик», ди бит бу миңа. Кәнәфиенә барып утырдым. Әкрен генә сораштыра башлады бу, каян, ни йомыш белән? — ди. Минем дә тел ачылды, сөйләп бирдем. Мин әйтәм, менә шулай, шулай... Иң үтергәне — транспорт җитмәй. Без киндер сабагын Бакалыга — Башкириягә илтәбез. Ә ул йөз чакрымга җыела безгә. МТСтан, башка колхозлардан да алабыз машина аны ташыганда, алар белән генә дә чыгып булмый положениедән, машина кирәк безгә, мин әйтәм, кимендә өч машина! Арттырып җибәрдем бугай, министр көлеп куйды.

Дамир, Кәрам, Яхъя да көлеп җибәрделәр.

— Син бигрәк, сразы өч! — диде Кәрам, яңагына таянып.

— Өчне сорасаң, берне бирми тәкате юк аның дигәннең уе инде,— диде Шәкүр карт.— Киндернең сүсе әрәм була, дәүләткә күпме зыян, ничә машина чери шуның аркасында дип, хисаплап та күрсәттем, прәме, өстәле кырына килеп, сөяк төймәле счетында! Карап тора бу елмаеп, әһә, мин әйтәм, чит итми бу мине. Шуннан икенче зарларны сүттем. Әйбәтләп тыңлады бу мине. Өстәлендәге мәче борыны кебек бер нәрсәгә басып-басып алган иде, берьюлы ике кеше килеп кермәсенме! Министр тегеләргә ниндидер язулар язып бирде һәм: «Бабай, менә шушы иптәшләр ярдәм итәр, мөмкин булганның барсын да эшләдем»,— дип, кулларымны кысып, ишеккә чаклы озатты бу мине.

Министр язуын укыгач, теге кешеләрнең берсе: «Оһо!» дип куйды. Кичкә чаклы министерствоның мин ачмаган ишеге калмагандыр. Тәки ике машинага, Татарстан фондыннан 600 центнер сортлы бодайга, тагын 200 фесметр наратка язу алып, печатен, кулын куйдырдым бит. Министерствоның тышкы ишеген ябып, урамга чыккач кына авызга бер тәгам ризык капмаган искә төште. Кая ди ул тамакны уйлау... Әнә шулай йөри-йөри язва желудок эләктердем дә инде мин,— дип сүзен бетерде Шәкүр карт.

Рамай башын күтәрде.

— Ә шулай да хәзер авыррак тоела миңа, Шәкүр абзыкаем,— диде Рамай,— Ай, күп уйларга, әллә ничә еллар алга карап эш итәргә кирәк эшлим дигән колхоз председателенә. Ә минем эле эшлисе килә. Әнә шундый вакытта барасы юлларыңа, тәгәрмәчеңә таяк тыкмасыннар иде, бүгенге көн белән генә яшәүчеләр дим,— дип сыкранды Рамай, тешләрен шыгырдатып, һәм өстәлгә әкрен генә сугып алды.

Шәкүр карт сагая калды, Рамайдан:

— Я, ни булды? — дип сорады.

Рамай Яхъяга ишарәләде һәм:

— Әнә Яхъя сөйләсен, я мин бутап бетерермен,— диде. Яхъя өстәмә планны үтәү, яңа секретарьның сүзендә тормавы, бүген менә шуның өчен бюродан каты шелтә эләктереп кайтуларын сөйләде, Кәрам да аны тулыландырды.

Шәкүр карт аларны тын гына, күзләрен кыса төшеп тыңлады, аннары киң маңгаен кул аркасы белән кат-кат ышкыды:

— Әле андый секретарьларның һаман орлыгы корымаган икән, үз сүзенә хуҗа булмаучылар диюем. Ә планны үтә син, Рамай, беренче үтәвең түгел. Минем сүзне онытмагансыңдыр бит: колхоз шундый ул — бер кулың белән бир, икенчесе белән алу ягын каер. Әле ашлык урнашып бетмәгән...

Рамай сикереп торды, Шәкүр картны кочаклап алды, өстәл янында утырган иптәшләренә карап:
— Күрдегезме? Кайтканда мин сезгә ни дигән идем? Аңа ианаып житми, әле шикләнеп әйткән идем, сез дә авызыгызга су капкандай ләммим!.. Молодец, Шәкүр абзый, икебезнең дә бер төсле уйлый безнең башлар! — диде дә чөйдәге костюмын барып алды, аны кия-кия: — Аннары менә нәрсә, управлениедән безнең колхозда тавык фермасын бетерергә кушалар, быел ук, нишләргә икән, Шәкүр абзый, ә? — дип сорады.
— Ник бетерәләр?
— Кошчылык өч-дүрт колхозда гына кала ди бугай, специаллашты-ру йөзеннән бугай.
— Ә ул колхозлар специәлләшкәнме соң?
— Юк, кая ди әле.
— Алайса менә шул, Рамай улым. Ул колхозлар специәлләшсен, синнән йомырка сорамый башласыннар, шул чакта бетерү ягын карарсың. Булганны бетерергә мачтаклар күп булыр ул. Булганны бетермә. Аның нигезе бар, чүпрәсе салынган, әз генә акча төртү белән күперергә тора ул.
— Монысын да синеңчә уйлаганмын икән, рәхмәт, Шәкүр абзый, без китик, керделәр дә китә белмиләр, бу нинди оятсызлар, ди торгансыңдыр инде.
Рамай шулай дип ишеккә юнәлде. Башкалар да урыннарыннан кузгалдылар. Шәкүр карт кет-кет көлә-көлә:
— Үзегез дә беләсез икән оятсыз икәнегезне, әле таң атмады бит, утырырга иде бераз,— диде.
Рамай өйалдында борылып аның касыгына төртте һәм:
— Әллә картая-картая хәтерең дә чуала инде. Кая, юл аягына? — диде.
— Әнә, веранда тәрәзәсе төбендә, салып ук куелган, үземне дә кимсетмәдем әле... Минем хәтер белән ни шали син, брат,— диде Шәкүр карт...

## 7

Һәнүз фермага килгәндә ревизия комиссиясе председателе шунда иде инде. Ул дәүләткә озатыласы үгезләрнең сыртларына акбур белән сызып тамга салып йөри иде. Ник туганына үкенгәндәй, сөмсерләре коелып йөри торган бу кешене Һәнүз өнәми. Ләкин эшкә үҗәт үзе. Мал тапшыруны гына ал. Тапшырып кайткан квитанцияләрне кабул итү актларын икешәр кат күзлек киеп тикшереп чыга. Ике-өч кило аерма чыкса да, теш төпләрен суыра, не может быть мин ялгышырга, күзеңне ачып тормагансыңдыр, я тегеләйрәк булгансыңдыр, дип башын бармагы белән бораулап күрсәтә. Һәнүзнең ферма яңгыратып биргән сәламенә ул күтәрелеп кенә карады, ләкин иренен дә кыймылдатмады. Һәнүз тиз-тиз аның янына килде һәм:
— Нигә башны высшийга китәр дисең? — дип сорады. Ревком ике кулын җәеп күрсәтте. Бер кулының баш бармагы бөкләнгән иде.
— Тугызмыни?
Ревком ияк какты. Ул арада бер-бер артлы өч машина килеп туктады. Үгезләрне үлчәп, төяп бетерүгә, колхоз председателенең дә «Волга»сы күренде. Рамай шоферлар, терлекчеләрнең барысы белән дә кул биреп исәнләште. Һәнүзгә карап торды. Һәнүз дә аннан күзен алмады. Әллә ничек борчулы булып күренде аңа председатель. Рамайны бу яшь зоотехникның азып-тузып, тәртәгә керә алмый йөрүе күптән борчый. «Менә бүген дә саф түгел моның башы, ни житми бу малайга? Алма

кебек хатыны бар»,— дип уйлады ул. Аннары Һәнүзне житәкләп читкәрәк алып китте дә:

— Үскәнем, барышлый я сельпога, я райпотребсоюзга кагыл. Товарлары булмый калмас. Бер машина да буш кайтмасын, смотри! Һич тә булмаса, урау булса булыр, делянкага сугылып, көтүчеләргә утын алып кайтыгыз,— диде һәм тешләрен кысып Һәнүзне сүгә башлады.— Син, катык буяп эттән ялатасы нәрсә, ташлыйсыңмы бу элек-селек йөрүеңне! Үзең симпатичный, сөлек кебек егет. Бүген тагын өйдә кунмагансың. Кайда эт сугарасың? Койрыгыңа басам мин синең, чамала! Терсәгеңне тешләмәкче булырсың да, соң булыр. Управлениедән ничә әйттеләр инде сине алып ташла дип, ялан мин алып калмам сине!..

Һәнүзнең кинәт башы чатнап китте, сулышлары кайнарланды:

— Нишлим соң, абый?.. Үзем дә беләм дә бит,— диде кызарып.

— Ыштаныңны салдырып яручы юк синең, ыштаныңны! Әтиеңне чакыртам, бел, малай!

— Рамай Ибраһимович, берүк чакырта күрмә... Ифрат кызу кеше, мине дә, үзен дә харап итәр...

— Анысын карарбыз, тугарылма!...

Председатель китеп барды, Һәнүз аны машинага кереп утырганчы күзләре белән озатып калды. Зәңгәр «Волга», артыннан төтен алкалары сүтеп, ындыр табагына таба китте.

Авыл башындагы буаны чыгып, таш юлга күтәрелгәч тә, Һәнүзнең кинәт күңеле йомшады, председатель әйткән сүзләрне кабатлады: «Ни ди, үзең симпатичный, сөлек кебек егет»,— диме?». Әйе, төс-бит, буй-сын зарланырлык түгел аның. Әтисе кебек, беләкләре, буыннары нык. Сугыштан соң зарыгып, көтеп алган бала булып дөньяга килә ул. Әти-әнисе икесе дә колхозчылар. Әнисе инде эшләми, пенсиядә, ә этисе әле һаман төзелештә йөри. Ни тотса шуны коеп куя торган оста ул. Җилянгыр тигерми үстерделәр алар Һәнүзне. Ветеринария институтында укыганда стипендия өстенә ай саен илле сум акча җибәреп тордылар. Фронтовик малае дип тулай торактан урын да бирделәр. Башы да эшләде, җиңел укыды Һәнүз. Зоотехника факультетын бишлегә генә тәмамлады. Аспирантурага да тәкъдим иттеләр үзен. Риза буласы калган да бит. Тик Ася эшли торган районны тәкъдим иткәч, (икенче курста укыганда ук Һәнүз ул кызга үлеп гашыйк булган иде) аспирантурага кул селтәде... Тигез юлдан җай гына элдергән машина кабинасында тирбәлеп барган килеш, Һәнүз күзләрен йомды. Асяның шома биек маңгаен, үзенә бер матурлык биреп торган курнос борынын, ефәктәй йомшак коңгырт чәчләрен, шулар арасына кереп югалган юка, кечкенә колакларын күз алдына китерде. Әнә ул тигез тешләрен елтыратып көлә, йомры, ләкин егетләрнеке төсле каты кулы белән Һәнүзнең иңнәренә суга:

— Кайчан акыл керә инде сиңа, нигә бәйләнәсең син минем колакка?» — ди. Һәнүз аның колаклары белән шаярырга ярата һәм: «Менә тешлим дә, үземнеке буласың»,— дия иде. Колагын да тешләде, ләкин, ләкин аңа гына насыйп булмады Ася. Әле дә хәтерендә: студентларның тулай торагында Яңа ел бәйрәмен каршылаган төн. Һәнүз ул вакытта зәм-зәм суы белән тамак чылатырга яратып бетерми иде. Бүлмәдәшләре икенче каттагы залда бара торган маскарадка төшү өчен берәр стакан тотарга булдылар, кыюлык өчен, янәсе. Берәр сум җыешып алып кайттылар. Инде бүлмәне бикләп чыгабыз дигәндә генә Һәнүзнең курсташы Вася килеп керде. Кысык күзле, бөтен битен сипкел баскан бу чуваш егете алпамша гәүдәле булса да, бик тә юаш, сүзен дә кубрәк пышылдап сөйләшә торган егет иде. Ул исәнлек-саулык сорашу белән Һәнүзне култыклап коридорга алып чыгып китте. Ишекне япкач та Һәнүзнең колагына:

— Хануз, сиңа пер кыс влюбилась...— дип пышылдады.

Һәнүз кызыксынып:
— Китсәнә, кем ул, Вася? — дип сорады.
— Минем якташ, өченче курста укый, Асюта, Ася.
— Соң, соң?
— «Мине бүген шул егет белән, именно, минә синең белән, таныштыр әле», — диде. Үзе көлә. — Шәп кыз, чамала, ычкындырсаң, гомер буе үкенерсең — ди...
Каршыга ашлык төягән автоколонна килә иде. Район үзәгенә керәндәге тар күпер алдында туктап, шуны үткәреп җибәрделәр. Ә колакта һаман Васяның: «Чамала, ычкындырма, гомер буе үкенерсең... үкенерсең», — дигән сүзләре яңгырап торды. Машина тагын кузгалып китте.
...Маскарад башланган иде инде. Вася парлап биючеләргә күз йөртеп чыкты һәм түрдә ниндидер егет белән сөйләшеп торган кечкенә генә буйлы, ак күлмәкле, коңгырт чәчләрен тасмалап баш түбәсенә җыйган бер кызга күз кысты һәм ике бармагы белән аны үзенә чакырды. Кызның түгәрәк, мөлаем йөзенә алсулык йөгерде. Ул шундук аларга таба атылды. Күбәләкләр кебек әйләнешкән парлар арасыннан бөтерелеп кебек бөтерелеп, алар каршысына килеп тә чыкты. Вася, зур башын киеличә генә иеп:
— Таныш бул, Ася, Хануз, — диде. Ася Һәнүзгә кулын сузды һәм:
— Ася Митрофановна, — диде. Һәнүз аның кайнар, ләкин егетләрчә кебек каты кулын кысты, йөзенә текәлеп карады. Аның йөзе универмаг магазиннарында витринага куелган курчак кебек. Кашлары сызып киткән, ләкин каралтылмаган да, эскәк ише әйбер дә тимәгән. Татур борыны астында җиңелчә генә шыткан кара төкләр. Иреннәре иртәнге чык төшкән кура җиләгендә таң нурлары уйнап торган төсле. Чәч арасыннан күпереп торган кечкенә, юка колакларында тамчы алкалар. Кечкенә булса да, гәүдәсе сылу. Шул чак оркестр танго уйный башлады. Ася коеп куйгандай түгәрәк, тулы балтырлы аяклары белән ыпырдап куйды һәм Һәнүзне залга таба җитәкләп алып китте. Алар бии башладылар. Асяның һәр хәрәкәте килешле, җиңел. Ул кечкенә кулларын аның иценә куйды. Һәнүз, һәр әйләнеп алган саен, аны үзенә кысарак төште. Кыз тартынмады, юка күлмәге аша кайнарлыгы сизелеп торган гәүдәсе белән аңа елышарак төште. Гүзәллек белән мөлдерәмә тулы бу кыздан аңкыган яшьлек хисе исерттеме, Һәнүзнең башы җиңелчә генә әйләнә башлады. Ул Асяның колагына:
— Ася, ифрат кызу, әйдә, саф һава сулап керик...— дип пышылдады.
Ася күтәрелеп карады һәм аны бәхет нурлары белән коендырды.
— Әйдәгез!..
Алар, җитәкләшеп, залдан чыгып киттеләр. Бу сәгатьтә минутларга күп күзләр шаһит булып калды. Алар башта Һәнүзләр бүлмәсендәге балконга чыктылар. Тын гына тирбәнгәләп ябалак кар төшеп тора. Һәнүз Асяның иңнәренә үз пальтосын япты, үзе свитердан килеш, ялан баш кына һава алды. Һәнүз аны кочакламакчы булды. Ләкин Ася, кечкенә бармаклары белән янап, аны якын җибәрмәде.
— Ашыкма, егет, ут күбәләге булма, күрерсең, — диде.
Аннары бүлмәгә керделәр. Һәнүз аңа үзе турында, Ася үзе турында сөйләде. Таныштылар. Ася да колхозчы кызы икән. Чувашиядән. Батыр районыннан. Башта Буада ветеринария техникумын бетергән, аннан соң монда — Казанга укырга килгән. Әтисе — Бөек Ватан сугышы инвалиды — моннан өч ел элек, Ася институтка укырга кергән елны, дөнья куйган.
— Сыңар кулы белән алты пот күтәрә торган кеше иде... Сугыш яралары күпмегә сузыла. Егерме ел буе сыкрады... Үләргә тиеш түгел иде әле ул... Әни дә аның кайгысыннан хәстәгә сабышты. Әйдә бер

сеңелем белән яши... Укып бетерсәм, үзебезнең колхозга кайтырга кирәк миңа. Председатель белән дә сөйләштем. Әнине кем карар, сеңелемне кем укытыр? Хәзер дуңгыз карый, ә кичен урта мәктәптә укый, ничәмә еллардан соң да сугыш җиле кемнәргә генә кагылмый...— Асяның күзләре уйчанланды. Ул урыныннан торды һәм:

— Әйдә, Һәнүз, урамда йөреп керәбез,— диде. Алар төне буе йөрделәр. Яңа ел тууын хәбәр иткән Кремль курантлары тавышын, Үзәк Комитетның халыкны Яңа ел белән котлавын алар Максим Горький исемендәге культура һәм ял паркы янындагы Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар истәлегенә салынган, пьедесталендә мәңгелек ут янып торган обелиск янында тыңладылар. Ася Һәнүзнең куенына сыенды. Левитанның көчле тавышын ишетү белән дерелдәп куйды һәм:

— Йөрәкләр әллә нишли, бөтен гәүдә чымырдап китә шуның тавышын ишетсәм,— диде.

— Ә миңа алай түгел, Левитан да бер артист, сугышта гүя булмаган, киноларда гына булган кебек,— диде Һәнүз. Ася аңа тагын да елыша төште һәм:

— Их, Һәнүз, чыннан да син уйлаганча гына булса,— диде әрнеп.

...Машина райпотребсоюз правлениесенә килеп туктагач кына Һәнүз исенә килде. Шоферның, монда кереәсе бар дигән идең бит, дигәнен ишетү белән ул кабинадан сикереп төште. Йөк бетәме соң, өч машинага да шикәр комы төяргә «доверенность» алды. Район үзәгеннән чыгып, машина тәгәрмәчләре асфальтка эләккәч, Һәнүзнең күз алдына тагын Ася килде.

...Ул елны җәйге каникул вакытында Һәнүз Ася белән Батыр районына китте. Авыл хуҗалыгы идарәсенә кереп, Асяның танышлары аша, кызның туган авылыннан өч кенә чакрымдагы колхозга ветфельдшер штатына практикант булып урнашты. Ә Асяны үз колхозларына билгеләделәр. Җәй буе маллар арасында булды Һәнүз. Ә кич җитү белән Ася янына ашыкты. Һәр җәйне алар шулай үткәрделәр. Менә Ася институт белән саубуллашты. Үз колхозларына баш ветврач булып урнашты. Һәнүз дә инде соңгы курста иде. Дәүләт имтиханнары алдыннан Ася янында кунакта булды. Бик тә нияләшкәннәр иде инде берберсенә. Асяга ул гомер юлларын бергә бәйләргә тәкъдим дә ясады.

— Ашыкмыйк, Һәнүз, киңәшик, туганнар ни дип әйтер бит әле,— диде Ася. Шул килүендә алар Асяларның исәпсез-хисапсыз туганнарында, өйдән-өйгә йөреп кунакта да булдылар. Һәнүз өлкәнрәкләренә үз уйларын, теләкләрен дә чишеп карады. Ләкин аларның берсе дә туры җавап бирмәде. Ул турыда авыз ачу белән сүзне икенчегә бордылар.

Яхшы укыды Һәнүз. Аспирантурага калырга димләделәр. Ләкин эшкә билгеләү комиссиясендә Чувашиянең Батыр районында буш урын булуын ишетү белән бөтенесенә кул селтәде. «Батыр районына китәм»,— дип кырт кисте. Тиешле документлар кулга кереп беткәч, авылга кайтып, атна-ун көн генә булды да, әтисенең, әнисенең ах-ухларына карамастан, Батыр районына китеп барды. Аны авыл хуҗалыгы идарәсенең өлкән зоотехнигы итеп билгеләделәр. Анда терлекчелекне алып бару җиңел. Бөртекле ашлыкны республика дәүләткә аз сата. Күпьеллык, берьеллык үлән мул. Аннары өскә ишелеп торган урманнар күпме. Җиң сызганып эшлә генә иде дә бит. Дәртләнеп тотынган иде дә, ләкин Ася — өзелеп сөйгән кызы — барысын да челпәрәмә китерде.

Беренче танышкан көн истәлеге итеп, Яңа елда туй ясарга вәгъдәләштеләр алар. Һәнүз барлык хезмәт хакын шуңа җыйды. Район үзәгеннән әйбәт кенә квартир да вәгъдә иттеләр. Ася да шунда күчеп килергә булды. Эш ягыннан да хәстәрлек күрделәр.

Яңа квартирга күченеп, диван, өстәл, урындыклар урнаштырып йөргән кичне капка төбенә кара айгыр җиккән чана килеп туктады. Аннан

олыплы бер кеше төште. Толыбын салып чанага куйды. Караса, Ася! һәнүз йөгереп урамга атылды. Дилбегәне койма баганасына бәйләп торган Асяны арттан кочаклап алды, үрелеп аның салкын иреннәннән үпте. Ася аңа таба борылды... Аның иреннәре дерелди иде... Һәнүз берни аңламыйча тораташтай катты. «Ни булды, кем рәнҗеткән минем Асютканы?» — дип уйлады ул һәм, Асяны биленнән кочаклаган килеш, ярым пышылдап:

— Асютка, ни булды? — дип сорады. Асяның сөрмәле күз керфекләренә яшь тамчылары эленде, ләкин ул аны сөртмәде.

— Керик әле, Һәнүз,— диде. Кочаклаган килеш, ул аны үзләре туй ясаячак һәм аннары күгәрченнәр кебек гөрләп гомер итә башлаячак ике бүлмәле квартирына алып керде. Ишекне ябу белән Ася, буылып торган күз яшьләрен тыя алмыйча, үксеп елап җибәрде һәм юлда күшеккән йомры, кечкенә куллары белән аның муенына сарылды: — Әни, әнием риза түгел, Һәнүз!.. — дип үрсәләнде ул.— Син беренче тәкъдим ясаганнан бирле үгетлим инде... Юк, якын да килми... Чит канга ризалыгым юк, тыңламасаң, күкрәк сөтем тотсын, ди, каргый...

Һәнүзнең сулуы куырылды. Ул каушап калды. «Ася, Асютка! Ни сөйлисең син? Томана карчыкның шул сүзләре белән безнең икебезнең дә бәхетне җимерәсеңме? Син бит югары белемле кеше, комсомолка! Кая атлаганыңны беләсеңме син?» — дип уйлады, ләкин теле икенче әйбер сөйләде.

— Не может быть! — диде ул каударланып.— Хәзер элекке заманмыни ике мәхәббәткә алай каршы торырга! Бездә синең әниеңнең дә, туганнарыңның да ни хакы бар? Син алар белән, мин алар белән торасы түгел!.. Иртәгә үк язылышабыз!...

Ул, шулай дип, Асяның өсләрен салдырды. Кочаклап диванга илтеп утыртты. Асяның юлда туңганлыгын күреп, электр чәйнеген электрга тоташтырды. Аннан Асяны кочагына алып диванга утырды. Ася ислемай исе бөркеп торган башын аның күкрәгенә салды, кечкенә кулъяулыгын бөгәрләп, еш-еш күзләрен сөртте һәм: — Нишлибез инде, Һәнүз бәгырем? — диде пышылдап. Һәнүз аны тагын да ныграк кысып кочаклады, җылыда алсуланып киткән, тозлы күз яшьләре белән юылган иреннәрен шашып-шашып үпте, ак муенын, түгәрәк кул башларын иркәләп туктаусыз сыпырды.

— Язылышабыз, иртәгә үк язылышабыз,— дип пышылдады Һәнүз.

— Ә әни? Әни каргышын алыйммы?.. Ул бит бу кайгыны күтәрә алмаячак... Аннары бөтен авыл, туганнар әнисен үтерүче дип мине каргарлар, төртеп күрсәтерләр... Юк, безгә кавышу насыйп булмаган икән...

Ася Һәнүзнең муенына сарылды, яшьле күзләре белән аңа озак кына тутырып карады һәм сөлек кебек аның иреннәренә капланды. Бу кайнар сулыштан Һәнүзнең тыны куырылды, Асяның тыгыз, йомры күкрәкләренең еш-еш тирбәлүеннән бөтен гәүдәсенә ниндидер, тыеп тормаслык кайнар ташкын дулкыны таралды. Шушылай шашып яратып та үз бәхетеннән ваз кичүче бу кызга, я, ни дип әйтәсең? Һәнүзнең уйлары чуалды.

— Син, син, Асютка, чын күңелдән яратмагансың, яратсаң мондый сүзләр сөйләмәс идең,— диде ул калтыранган тавыш белән һәм Асяның яңакларыннан тотып, башын күтәрде. Асяның яшь пәрдәсе каплаган күзләре гаҗәпсенүдән зур булып ачылдылар.

— Минме, минме, Һәнүз бәгырем? — диде ул еламсырап.— Мөмкин булса йөрәгемне ярып күрсәтер, аны мәңгелеккә сиңа бирер идем,— дип, ул яңадан Һәнүзнең иңенә капланды.

Һәнүзнең үзенең дә йөрәге сулкылдап-сулкылдап куйды. Ул Асяны кочаклаган килеш тын калды. Беравык шулай, очар канатлары каерылган ике кош кебек, каңгырып, бер-беренә нинди сүз кушарга белмичә

гажизләнеп утырдылар алар... Парларын атып чәйнек капкачы чылтырый башлады. Ася башын Һәнүзнең иннәреннән күтәрде һәм чәйнек өстендә биегән капкачка бер мизгел карап торды. Аннары капыл гына сикереп торды. Чәйнекне электрдан чыгарды да:

— Һәнүз, чәй эчәрлек берәр савытың бармы соң? — дип сорады. Һәнүз сүзсез генә урыныннан торды. Өстәл тартмасы эченнән ике пар чынаяк, чәй савыты һәм бер кап шикәр алып бирде:

— Бөтен байлыгым шушы, ипи дә юк... Мин бит столовойга йөрим, Ася,— диде. Ася аңа күзләрен мөлдерәтеп карады. Нидер уйлады, ахрысы, кинәт, бурлаттай кызарды. Чәй бөртекләрен чынаякларга салып, су агызды, шикәр тартмасын ачты да:

— Әйдә, утыр, бәлки, соңгы тапкыр утырып чәй эчүләрдер. Иртәгә инде утыз бере бит,— диде.

Ясалган чәйләрен алар көчкә эчеп бетерделәр. Ася ике чынаякны да чайкап, суын стена кырына сиптерде. Аннан Һәнүзгә дәште:

— Һәнүз, син атны урнаштыра алмассыңмы? Кумасаң, мин бүген кайтмас идем,— диде, үзе колак яфракларына кадәр кызарды. Моң, хәсрәт белән тулы күзләрен баеп барган кояшның тәрәзәдән сузылган сүрән нурларына төбәде. Һәнүз шундук киенеп алды һәм:

— Ветлечебницага илтәм, аның мөдире безнең институтны тәмамлаган кеше, ифрат акыллы бәндә,— дип чыгып та китте. Асяның атын урнаштыргач, ул ашханәгә сугылды, кәгазьгә төреп котлет, тавык ите, ярты икмәк алды. Тозына хәтле онытмады. Аннары магазинга керде, бер шешә кыйммәтле шәраб алды. Ул кайтып кергәндә квартир эче инде караңгыланган, Ася ут алып та маташмаган, диванга йөз түбән яткан да йокымсыраган. Һәнүз керүгә, ул башын күтәрде. Тагын елаган булса кирәк, яңакларында яшь эзләре бар иде. Ул кулъяулыгы белән күз төпләрен сөртте. Һәнүз чишенеп бетү белән, аны үз янына, диванга чакырды. Һәнүз аны кочагына алды. Ася аның куенына эреп югалырдай булып сыенды, Һәнүзнең чәчләрен биш бармаклап тарады, яңакларыннан иркәләп сыйпады һәм пышылдап:

— Һәнүз бәгырем, утны сүндер... Ишегеңне биклә... Берәү дә борчымасын,— диде. Үзе диван өстенә аякларын бөкләп менеп утырды, бер кулы белән диван башына таянды. Һәнүз өстәл өстендә торган кечкенә ризыкларга, шәраб шешәсенә күз төшерде, ишекне бикләде, утны сүндерде. Әле ул кадәр караңгы түгел иде. Зур тәрәзәләрдән өй эченә кар яктысы төшеп тора. Һәнүз диван янына килде. Аның читенә генә утырды һәм кулын Асяның йөргәндә уйнаклап торган йомры янбашына куйды. Ася сискәнеп китте, таза беләкле куллары белән Һәнүзнең муенына сарылды һәм күзләрен йомган килеш пышылдады:

— Һәнүз бәгырем, башкача кавышулар насыйп булмагач... нишлим, башка кешеләргә мәңге күңелем барачак түгел минем... Синең өчен, бары синең өчен үскән чәчәк бит мин...

Кызның куллары, бөтен гәүдәсе дерелдәде, яңа диван шыгырдап, сөйләшеп ала. Һәнүзнең миенә кайнар ут йөгергәндәй булды, ул Асяның уйларын шундук аңлады. Ләкин тиле яшьлек, аның минутлык дуамаллыгы, әле яхшы, аңын томаламады. Ул өстәлдә япа-ялгыз кукраеп торган шәраб шешәсенә күз төшерде һәм аңа кагылмавына сөенеп бетә алмады. Һәнүз Асяның колакларына иелде, аның башыннан сыйпады, уттай янган алсу яңакларыннан үпте һәм:

— Ася, Ася бәгырем, син бит минем өчен үтә кадерле, изге җан... Синең саф, пакь күңелеңә кер булып кунасым килми. Иртәгә, иртәгә... Язылышкач... Гомер китабының битләрен берәмләп актарганда моңдый көн очрамасын иде,— диде. Ася Һәнүзнең бу сүзләрен үзенчә аңлады булса кирәк, капыл гына торып утырды һәм башын артка ташлап, куллары белән йөзен каплады:

— Бу сүзләрне дә ишетәсем бар икән, ник бәхетсез, ник үз ирегендә түгел, үзе теләгәнне эшли алмый бу кыз бала? Әллә күңелләрең башкадамы, Һәнүзкәем?

— Ася бәгырем, әйтмә андый сүзләрне! Артык изге син миңа...

— Изге булгач?..

— Изгеләр гөнаһ кылмый, ярамый...

Ася урыныннан сикереп торды, чөйдәге киемнәренә ташланды:

— Ветлечебницада дидеңме әле атны? Китәм мин, Һәнүз,— диде ул, пальтосын кия-кия. Һәнүз утны яндырды, Асяны кочагына алды, иркәләп, юатып пальтосын салдырды. Өстәл кырына илтеп утыртты һәм үзләрен көткән ризыкларга, иясен таба алмыйча моңаеп утырган шәраб шешәсенә төртеп күрсәтте. Ася, башын өстәлгә салып, тагын үкси башлады. Һәнүз шешәне ачты, чынаякларга тутырып, бал кебек сыланып торган шәраб салды, Асяның дерелдәп-дерелдәп алган иреннәренә чак кына кагылды да:

— Ася, Асютка, тот әле, ясалма кайгылар баштан китсен, иртәнге таң белән безнең кояшыбыз чыксын!..— дип, кулындагы тустаганын югары күтәрде. Ася башын калкытты, Һәнүзнең елмаеп торган йөзенә карап, мөлдерәмә тулы чынаякка үрелде. Һәнүз үз өлешен тотты, күзгә-күз карашып чәкештерделәр. Икесе дә төбенә хәтле эчеп бетерделәр. Әнә шул татлы шәраблар кебек мәхәббәтне авызына кергәч тә йота алмады бит ул. Бер тамчы шәрабсыз исертә торган мәхәббәт хисләре дә аның өермәле уйлары белән тулы миен томалый алмады.

Ул төнне алар бергә үткәрделәр. Дөресрәге, Ася диванга йөзтүбән ятып, төне буе балавыз сыкты, Һәнүз аның янында утырып чыкты. Күпме генә үгетләсә дә, Ася икенче көнне язылышырга риза булмады. Каткан күңел, сүнгән рух белән озатты ул Асяны. Шуннан соң ул Асяны ике тапкыр районда үткәрелгән ниндидер киңәшмәдә күрде. Асяның йөзләре сулган, күз төпләре утырып калган иде. Һәнүз аңа ничек кенә якын килергә тырышса да, ул аны читкә тибәрде.

— Насыйп ярлар булмагач, нигә йөрәк яраларын кабат кузгатырга, йөрмә, Һәнүз бәгырем,— диде дә китеп барды.

...Сабан туй алды иде бугай. Аны күзләре ут уйнап торган, озын зифа буйлы, кара чәч толымнары ике иң өстеннән янбашына кадәр салынып төшкән Нәсимә белән таныштырдылар. Ул музыкаль училищены бетереп яңа гына эшкә килгән иде. Аның өздереп баянда уйнавына, тау башыннан, чуер ташлар арасыннан челтерәп аккан чишмәдәй саф тавыш белән җырлавына бик нык әсәрләнде Һәнүз. Кыз гел аңа карап җырлады. Соңыннан ул аны озата китте. Урамда шактый йөргәннән соң, Һәнүз уенын-чынын бергә кушып:

— Әйдә минем квартирга, мин өйләнә алмый калган тол егет,— диде. Кыз каршы килмәде. Иртән сабан туйга алар ир белән хатын булып чыкканнар иде инде. Моны ул беркемнән дә яшермәде. Дусларын, белешләрен сабан туенда кәләше белән таныштырды. Аны котладылар, тәбрикләделәр. Кичен кемдер аны яшел печән җәелгән арбага сузып салып квартирына илтеп куйды. Ә иртән күзен ачканда янында Нәсимә елап утыра иде.

Батыр районында эшләрлек әмәл калмагач, менә бу районга килеп чыкты. Колхозның шәһәрдәге культура сараена да биргесез клубына Нәсимәне директор иттеләр. Бөтен авыл халкын сихерләп бетерде, яшына басканыннан җитен сакаллысына хәтлесе үлеп тора, яраталар Нәсимәне. Менә Һәнүз берүзе, бер башы килеш күңелен утырта алмады инде Нәсимәгә.

Малларны тапшыргачны, Татсоюз базасыннан товар төяткәндә дә әнә шундый уйлар китмәде Һәнүз башыннан. «Ике җөмләлек гомер юлында да нинди хәлләр булмый»,— дип уфтанды ул.

## 8

Урып-җыю чорында ире Рамайның кайда ашаганын, кайда йоклаганын белмәүгә гадәтләнеп беткән иде инде Сәкинә. Бүген таң алдыннан кызмачарак кайтып авыы гына тәшвишкә салды. Сәкинә, эчке күлмәктән, буяулы салкын идәнгә ялан аяк баскан килеш, иренә аптырап карап торды. Аннары караватына барып ятты. Көтү куарга әле шактый вакыт бар. Аз булса да черем итим дип, ул күзләрен йомды, ләкин йокы алмады. Рамайның бу хәлгә төшүе аны борчуга салды.

«Дүрт елдан арткан иде бит инде, авызына да алганы юк иде, нәрсә булган? Тагын тотынса?..» Әнә шул уйлар, бер-берсенә чорналып туган уйлар аңа минут та тынгылык бирмәде. Инде яктырды. Күршеләрнең капкалары елап ачылды. Сәкинә урыныннан торды. Көтү куарга кирәк иде. Бура кебек куа сыерны иренеп кенә сауды, утардан сарыкларын чыгарды, кече капканы ачып, малларны урамга куды. Тирестә казынган чеби анасы кебек, ишегалдында юк эшне бар итеп йөрде, үзе һаман күзен ишектән алмады. Тик Рамай уянмады. Аптырагач, экрен генә басып өйгә керде, алгы өйнең пыяла ишегеннән карады. Рамай, йөзтүбән ятып, һаман йоклый иде әле. Бер кулы идәнгә салынып төшкән, авызы мендәргә капланган, авыр итеп тын ала. Сәкинә аяк очларына гына басып түр өйгә үтте һәм Рамайның инде чал кергән башын иплән кенә күтәрде, борып яткырмакчы булды. Шул чак Рамай күзләрен ачты һәм Сәкинәнең беләкләреннән сыйпады.

— Сәгать ничә әле? — дип сорады.

— Дүртенче китте инде.

Бу сүзне ишетү белән Рамай җәһәт кенә торып утырды, күзләрен йодрыклары белән уды.

— Баш чатный, кая, берәр эйбер юкмы, ичмаса,— диде ул аннары, башын селкеп. Сәкинә, бусы нәрсә инде тагын дигәндәй, аңа сәерсенеп карап торды һәм калтыранган тавыш белән:

— Ни булды соң, Рамай? — дип сорады.

— Шәп булды!.. Кичә строгач чәпеде әле яңа секретарь. Менә сиңа, кодагый, иске авызга яңа аш!..— дип мыгырданды Рамай.— Соң берни дә юкмыни? — диде.

— Булыр, булыр. Бар, юынып кер, хәл алырсың бераз... Шул кадәр ни эшләдең соң? — дип сорады Сәкинә, Рамайга текәлеп.

Рамай кулын гына селтәде дә ишегалдына чыгып китте. Веранда янында яткан гантельләрне әләктереп, егерме бишкә кадәр күтәргәч, алмагач төбендәге юынгычта биленә чаклы юынды, башын да юды. Тәннәрендә буй-буй кызыл калганчы ышкынып сөртенде. Кәефе шактый әйбәтләнде. Өйгә кергәч, киенә-киенә, Сәкинәгә ни өчен строгачка юлыгуын сөйләде. Аны тыңлагач, Сәкинә уйга калды.

— Минемчә, синдә хилафлык булмаган кебек, аңламыйм,— диде, калын иреннәрен турсайтып.

— Минемчә дә шулай да бит. Рәшат Галиевич алай түгел икән шул,— диде Рамай, үрсәләнеп.— Ну, баш авырта, җитмәсә! — дип мангаена сугып алды.

— Кайда эчтең соң?

— Шәкүр абзыйда ла...

— Шулайдыр дип уйлаган идем аны, гәүдәңне күрү белән... Рамай, берүк ычкына күрмә инде. Олыгаеп барабыз. Бүген-иртәгә бабай булырга торганда, килешми.

— Нәрсә, әллә Сәвиянең хәбәре бармы?

— Кичә хаты килде.

— Кая, бир әле.

Сәкинә Рамайга яшел конверт китереп тоттырды, үзе табын хәзерли башлады. Рамай бик тә үлеп ярата кызын. Бердәнбере бит ул аның.

Хатны ул тиз укып чыкты. «Киләсе атнада кунакка кайтам, практикабыз бетә. Укулар башланганчы бераз хәл алып калырга кирәк. Әти, Дамир абый килеп ала алмасмы икән?» — дип язган. «Дамир абый, Дамир абый!.. Юк, кызым, ул бармас, бара алмас, ә барса ни булган соң? Юк, аның синнән читтәрәк йөргәне хәерле». Чәй эчкәндә дә уе гел Сәвиясе, аның хаты, Дамир турында булды. Төпле бер фикергә килгәнче, үч иткәндәй, әнә Дамиры да килеп җитте, өзек-өзек итеп өч тапкыр сигнал бирде. Рамай кабалана-кабалана, яна-пешә өч стакан чәй эчте. Маңгаеннан кайнар тир бәреп чыкты.

— Вәт, булды, карчык, пәхмил, махмырларың очты,— диде ул, урыныннан кузгалып. Тик Сәкинә аңа яңадан утырырга ымлады, үзе көлә. Рамай утырды да:

— Я, нәрсә бар? — диде.

— Махмыр дигәч исемә төште әле,— дип сөйләп китте хатыны.— Кичә Һанүзнең Нәсимәсе елап килгәние. Тагын йөгәненнән ычкынган бит егет. Зар елый, эчмәгәндә дәшми, эчсә йоклый, мин дә яшим инде ир белән, ди. Укыт әле шуның арт сабагын...

— Булмый, карчык, мин Һанүзнең ник эчкәнен беләм. Яратмый ул Нәсимәсен, тегесе үлеп тора да бит, нишлисең... ул бит җаваплы эш тапшырганда авызына да алмый, эшен эш итмичә. Я үзен, я Нәсимәсен югалтып кына котыла ул эчүдән. Андый типларны күргән бар инде.

Сәкинә кинәт көлә башлады. Рамай, салам эшләпәсен кулында әйләндерә-әйләндерә:

— Әллә пәри кияүлиме, иске авызга яңа аш дигәндәй? — диде.

— Махмыр дигәч исемә төште дигән идем бит. Нәсимәсе дә бер катлы инде аның,— диде Сәкинә һәм көлә-көлә сүзен дәвам иттерде: Бер көн бик нык махмырлаган Һанүз. Душта коенып та кергән. Аягын юарга оныткан. Нәсимәсе тазга җылы су таманлап биргән, ятар алдыннан, кич ди инде бу. Һанүз ике аягын да тазга тыгып иДәнгә утырды да күзен йомды, ди Нәсимә. Мин дә, суы да бик мул, юыйм әле дип, бер аякны тазга тыгып торам ди. Һанүз башта бер аягын юды, ди, аннары минем аякны югарга тотынды, ди, эчсә дә күңеле изге шул аның дип куанып, канатланып торганда, Һанүз башын күтәреп миңа карап тора бит. Күзләре кысык. «Минем аяк түгел икән лә бу»,— дип, бер аягын юмаган килеш кузгалып китте, ди. Үз аягы белән кеше аягын да аермас хәлгә кил әле син...

Рамайның да йөзенә елмаю чыкты. Ул башына эшләпәсен киде дә:

— Махмыр әллә ниләр эшләтер, ышанам, көлмә кешедән,— дип ишеккә юнәлде.

Әнә машина кузгалып китте. Сәкинә түр тәрәзәне ачып җибәрде. Өй эченә көзгә тартым салкынча һава таралды. Сәкинә эшкә киткәнче дип урын-җирләрне, өйне җыештыра башлады. Аннары, күптән кулы тигәне юк иде, китап шкафын тәртипкә китерде. Рамай күп укый, Казангамазарга барса, һәрвакыт яңа чыккан китапларны төяп кайта. Үзе укып чыккач, ошаганнарын Сәкинәгә бирә. «Шәп китап, уйландыра торган, кешеләр дә укысын, китапханәңә алып кит. Рамай абыегыз укырга кушты моны дип әйт»,— ди. Ул укыган китаплар еллар буе кеше кулыннан кайтып керми. Китаплар арасына, нишләптер, Рамайның егет чакта ук төзи башлаган альбомы килеп кергән. Гади генә, юка катыргы тышлы бу альбом аларның икесе өчен дә кадерле, бәхетле яшьлек еллары көзгесе ул. Сәкинә альбомны алып өстәлгә куйды да китапларны тезеп чыкты, шкаф пыялаларын дымлы чүпрәк белән сөртте. Стенадагы сәгать суга башлагач, аңа күтәрелеп карады. Иртә икән әле, җидене суга. Сәкинә альбомны алып диванга утырды. Аны тез өсләренә куеп беренче битен ачты.

Анда елмаеп, егет дисәң дә, малай дисәң дә хәтере калмаслык кеше басып тора. Бер кулы белән урындык аркасына таянган, чалбар балаклары киң, аяк йөзенә төшеп тора. Өстендә — кыек якалы кара сатин күлмәк. Муеннан чалбар каешына кадәр, баян сәдәфләре кебек ак сәдәфләр тезелгән. Бөдрәләре чукланып маңгаена төшкән башын һавалы гына итеп артка чөйгән. Янәсе, менә кем ул абзаң. Күзләре чекерәеп тора, иреннәре килешле генә кысылган, өске ирене карчыганың канатларын какмый очкандагы чагы кебек. Аның очлары, ялкынланып торган яңакларына сузылып, эзсез генә югалгандай. Рәсемнең астына латин хәрефләре белән «Вильданов Рамай — 1938 ел, сентябрь» — дип язылган. Сәкинә рәсемнең күзләренә тутырып карады. Анда һавалык та, юксыну да, моң да чагыла кебек. «Сине уйлап, синә бүләк итеп бирү өчен төшкән рәсемем ул, Сәкинә»,— ди Рамай бу фотосы турында. Армиягә китәргә каралып йөргән чакларында төште ул аны. Сәкинә альбомында да бар бу рәсем. Ул икенче битне ачты. Менә Сәкинәнең район үзәгендә тугызынчыда укып йөргән вакытта төшкән рәсеме. Эре зәңгәр парчалы күлмәге зифа гәүдәсенә сыланып тора. Ул күлмәген хәзер дә саклый әле Сәкинә. Яшьлеген сагынып, анда бер генә минутка кайтып киләсе килгән чакларында аны сандык төбеннән иплән кенә ала, күзгә каршына басып иңнәренә салып карый.

Фотодагы зәңгәр парчалы күлмәге Сәкинәне яшьлегенә алып кайтты. Ул күлмәген урындык башына элеп куйды, диванга утырды һәм, альбом битләрен актара-актара, уйлар бишегендә тирбәлә башлады.

Рамай белән бергә укыдылар алар. Ул укуын дәвам итте, ә Рамай җидене бетергәч тә колхозда ат җигеп эшли башлады. Аннары учетчик иттеләр. Сәкинә тугызынчыда укыган чакта җәйләрен кайтып йөрде, квартирда кунмады.

Май ае иде, шомыртлар, катык белән коендыргандай, шау чәчәктә чак. Сәкинә авылга якынлашкан, тегермән буасына җиткән иде. Ул елны яз иртә килде. Шомырт чәчкә атканда пыр тузып су коеналар иде. Җәяү кайтып Сәкинә бик нык эсселәде. Тегермән буасына җитү белән бөдрә таллар арасына кереп китте. Гел үзе су керергә ярата торган урынга килде. Чишенде, киенер өчен дә бик кулай җир иде ул. Күгелҗем-яшелләнеп торган чирәмле ярны өч яктан таллар урап алган. Сәкинә як-ягына карангалап экрен генә чишенде, тирләве беткәнче, тәне бераз сулу алганчы, аягын суга тыгып утырды. Аннары, толымнарын башына урап, суга сикерде, рәхәтләнеп йөзде, әллә ничә тапкыр чумарга омтылды, ләкин чәчен чылатудан курыкты. Су коенып туйгач, ярга чыкса, исләре китте: киемнәре дә, сумкасы да юк. Ул, нишләргә белмичә, җиргә чүгәләде, үзе дер-дер калтырый. Озак керде шул суны. Инде нишләргә дип торганда таллар арасыннан кемдер: «Сәкинә!.. Сәкинә!..» дип эндәште. Сәкинә сискәнеп китте, гәүдәсен турайтты һәм тавыш килгән якка таба карады. Агачлар арасында Рамайның йөзе күренде. Ул Сәкинәнең зәңгәр косынкасын башына бәйләгән, авызы ерылган иде.

— Ничек кайтасың инде, Сәкинә? Киемнәреңне тилгән апкитте бит,— диде ул көлә-көлә. Сәкинәнең йөзенә алсулык йөгерде, ул күкрәкләрен кулы белән каплады һәм ачуланып:

— Рамай, бир күлмәкләремне, катып үләм бит,— диде.

Рамай башта косынканы сузды һәм:

— Бер биесәң бирәм,— диде. Сәкинә аңа телен чыгарып күрсәтте. Рамайга бу җитә калды, ул таллыклар артыннан атылып чыкты. Күлмәкләрне, сумканы култыгы астына кыстырган иде.

— Әле син алаймы? Хәзер әнә шул телеңнән үптерсәң бирәм,— дип, Сәкинә өстенә килә башлады. Сәкинә күп уйлап тормады, суга сикерде. Рамай култык астындагы әйберләрен җиргә куйды да җәһәт

кенә күлмәген салып ташлады һәм чалбар каешын ычкындырды. Ләкин, нидер исенә төште булса кирәк, ялт итеп кире эләктереп куйды. Хәзер дә исенә төшкән саен тыела алмый көлә әле Сәкинә. Рамай да суга сикермәкче булган, ләкин трусигы юклыгы исенә килгәч кенә тыелган... Тундырып үтерә язды Рамай Сәкинәне суда. Сүзен сүз итмичә тәки китмәде, судан чыгармады. Шул көнне кичке уенга чыгарга вәгъдә биргәч кенә китеп барды. Инеш буендагы карт өянкеләр арасындагы аланлыкта кичке уен була иде ул чакта. Яшьләр җәй житсә иске мәчеттән укмаштырып салынган клубка таба борылып та карамыйлар иде. Шул кичне Рамай аны беренче тапкыр озатты. Аннан соң еш очраштылар алар. Сәкинә Рамайга гашыйк булды. Акылдан шаша барган кебек тойды ул үзен башта. Күз алдында гел Рамай гәүдәсе йөрде. Үзен Рамайның хатыны итеп күз алдына китерә дә бурлаттай кызара иде. Аның шулай кинәт-кинәт ут янып китүен әнисе дә, әтисе дә сизделәр. «Әллә чирлисеңме, кызым?» — дип, теңкәсенә тиеп беттеләр. «Их, әни, әни! Әти, әти! Чир генәме соң, чирләрдән дә яман минем хәлләр»,— дип уйлый иде ул андый минутларда. Җәен кояшлар баемас, кичләр җитмәс кебек тоелды аңа. Аптырагач, көн тизрәк узар, ичмаса, дип, әнисе белән ындыр артындагы яшелчә бакчасына эшкә йөри башлады...

Стенадагы сәгать сугып алды. Сәкинә аңа күтәрелеп карады. Сигезенче ярты иде. Ул тиз генә урыныннан торды. һәм башына зәңгәр косынкасын бәйләп, ишеккә юнәлде. Өйалды ишеген бикләгәч, ачкычны куяргамы, юкмы дип икеләнеп торды. Аннары, миңа чаклы кайтмас әле дип, ачкычны үзе белән алды. Китапханә ишеген ачып кергәнче Сәвия се турында уйлады. «Дамирның колагына тагын бер кат төшерми булмас әле, барып алырга онытмасын»,— дип пышылдады иреннәре.

*Дәвамы бар.*

## Зиннур Насыйбуллин

### Яшәү өчен!

Бу гомерем өчен мин муеннан
Бурычлыдыр сиңа, ихтимал,
И табигать,
Нигә бу кадәр үк
Аяусыз соң синең ихтыяр?
Ничә миллиард еллык хезмәтеңнең,
И табигать, кая кадере? —
Кеше өчен шушы туфрак — ана,
Шушы туфрак — аның кабере...
Җан өргәнсең безгә, аң биргәнсең,
Җир йөзенә хаким иткәнсең;
Тик дөньяга килгән һәр кешеңне
Үлемгә дә хөкем иткәнсең.
Тик һәр гомер — мәңгелеккә тамчы,
Ташлар тишеп килә тамасым.
Үлемсезлек бирмәсәң дә,
фәкать
Үлем өчен тудырмагансың.
Язгы ташкын булып, ташып тулып,
Яшәү көче кайный күңелдә;
Аңым, җаным, эшем — яшәү өчен,
Тәнем генә калыр үлемгә.

### Бер күрерме кеше...

I

Кешелекнең кимчелегеме бу,
Әллә инде авыр хатасы:
Ифрат камил үтерү кораллары —
Бармак кына кыймылдатасы.

Бер күрерме кеше Җир шарында
Атыш тавышлары тынганын?
Хиросима,
Син үткәне микән,
Киләчәге микән дөньяның?

Ничә Нагасаки, Поломорис
Төшәр сыман башка ишелеп!
Шушымыни синең куәтеңнең
Тантанасы, әйтче, Кешелек?

Сугыш чукмары да адәмдер бит,
Ник шашына, кая ашкына?
Абыныр да Кеше
Барып төшәр сыман башы белән
Таш гасырның ерак ташына.

Шайтан белсен бер кешегә җирдә
Ничә үлем әзер торганын.
Хиросима,
Син үткәне микән,
Киләчәге микән дөньяның?

II

Куәт тә бар, изге ният тә бар,
Акыл да бар хәзер Кешедә,
Гаҗәп түгелмени: кайберәүләр
Кешеләргә йөрәк күчерә.

Өметләр зур, ләкин бер уйласаң,
Нинди аз бу, нинди аз әле!
(Кешеләрнең тән ярасы сызлый,
Минем җанда шуның газабы.)

Кешеләр бит бүген берсен-берсе
Чакма тартып кына үтерә,
Ә юк кына чирдән терелтергә
Айлар, еллар сарыф итеlә.

Бу — кешелек җитлекмәүдән микән,
Көчсезлекме безнең, гаепме?
Кнопкага басып кына бүген
Кем кайтара ала үлгәннәрне,
Кем терелтә ала гарипне?

●

Тыгыз сафлар уза урамнан.
Ышанычлы солдат адымы.
Җир йөрәге типкән шикелле
Солдатларның салмак адымы.

Өйләр каушап читкә тайпыла,
Тәрәзәләр зыңлап калалар.
Сафка басып кая баралар
Яшел кигән газиз балалар?

Ник аналар сертә күзләрен?
Ник ир-атлар болай көрсенә?
Ник кушылып бала-чагага
Кычкырмыйлар «ура» берсе дә? —

Дошман түгел, безнең егетләр —
Солдатларның атлап узганы.
Артларыннан тузан ияргән —
Нинди чорның соры тузаны?

## Чынлап килә

Барысы да миңа соңлап килде.

*Нәҗар Нәҗми*

Һәрнәрсә үз вакытында
Кирәк тә бит бу кешегә,
Ләкин көткәнең күп чакта
Нигәдер һаман кичегә.

Чәчеңә чал кергәч кенә
Көткән чын мәхәббәт килә,
Үзе белән кайгы-сагыш,
Газаплар җитәкләп килә.

Иң кирәкле сүз телеңә
Инде бәхәс беткәч килә,
Акыл, тәҗрибә дигәнең
Көч-куәтең киткәч килә.

Кайберәүләр еллар буе
Яла-ялганнан ачына,
Йөрәгенә каннар саугач,
Асыл хакыйкать ачыла.

Бары әрсез үлем генә
Һәр кешегә алдан килә.
Тик күпләргә үлгәч кенә
Хөрмәт килә һәм дан килә.

Их, күп нәрсә кешеләргә
Ни өчендер соңлап килә;
Барыбер килә,
Чынлап килә!

## Кино караганда

Экранда — җигүле атлар.
Чабалар ярсып тәмам.
Тик сәер: тәгәрмәчләре
Тәгәри артка табан.

...Мин дә чабам.
Алга табан
Гомер атында чабам.
Ә хәтер тәгәри һаман,
Кинодагы тәгәрмәчтәй,
Артка — үткәнгә табан.

●

Тынычлан, дим, йөрәгемә,
Ярсыма, дим, ярсыма;
Барыбер, дим, син дигәнчә
Булып бетми барсы да.

Җитәр, димен, тыныч кына
Бер яшим әле мин дә;
Син барыбер тоткынсың, дим,
Күкрәгем читлегендә.

Юк, тыңламый. Гомер буе
Тарткалашып көн итәм,
Мин аның әсире микән,
Ул минем тоткын микән?

## Үзебез камил булмаганга

Без — киләчәк көннәрнеке,
Бүгенге без, кичәге без;
Дөньяның бер бизәге без,
Дөньяның бер кисәге без.

Безнең күзгә карый дөнья,
Безгә өмет баглый дөнья;
Яхшысын да, яманын да
Бездән ала фани дөнья.

Үзең сына: уй-теләкнең
Яманы да чынга чыга.
Үзебез камил булмаганга,
Камил түгел дөньясы да.

Рафаил Төхфәтуллин

# БӨТНЕК ҮЛӘНЕ ИСЕ

хикәя



Төш диген инде шуны... Төне буе ниндидер бер үлән белән саташып чыкты Җаббар. Куе яшел яфраклы, аксыл сабаклы бер учлам үлән күз алдында гына тирбәлә дә тора бит. Әллә сукыр кычыткан, әллә... Исемен шайтан белсен, әмма тирбәлепме-тирбәлә бу. Үзсүзләнеп, үчегеп тирбәлә. Гүя Җаббардан нидер сорый, үтенә. Әйе, үтенә — колак төбендә тавышы да чыңлый. Чикерткә зыңыдай нечкә генә, агымлы гына, моңлы гына бер аваз.

Җаббар әллә ничә уянып, әллә ничә әйләнеп ятты. Күп тә үтми, күз алдында тагын шул ук яфрак пәйда була, колак төбендә тагын шул ук ягымлы-моңлы зың яңгырый башлый...

Ниткән әкәмәт төш булды соң әле бу?

Алай бер дә яманга юрарлыгы да юк инде үзенең. Гөнаһсыз бер учлам үлән, моңлы гына аһәң... Күңел нидер көтә, кемнедер, нәрсәнедер сагына, күрәсең. Анысы, дөньяда гел кемнедер, нәрсәнедер сагынып яшисең. Бигрәк тә буш вакытларда, эшсез сәгатьләрдә. Бу — өндә шулай. Ә нигә инде төштә дә көтәргә, сагынырга?

Иртән юынырга ванныйга керде. Кып-кызыл җиләк сабынына үрелде. Бик әчкелтем булса да, чын җиләк исе дә килә иде сабыннан. Шунда кинәт исенә килеп төште. Сукыр кычыткан да түгел, кыргый киндер дә түгел, ә бөтнек үләне кергән бит аның төшенә. Бөтнек үләне...

Вахта машинасында әллә ни сөйләшмичә генә бардылар. Гадәттәге шаярту-үртәшүләр дә булмады.

Соңыннан Җаббар үзе дә бик уңайсызлана бу хәлгә. Бораулаучының кәефсез чагын сизеп алдыларммы вахта егетләре, әнә шулай ничектер боегып, юашланып калалар. Эштә дә вахта башының һәр сүзе шундук үтәлә. Сүзе генә түгел, һәр ымы, һәр күз карашы бик тиз җиренә җиткерелә. Бөтерелеп кенә йөриләр егетләр. Рәхмәт кенә әйтәсе инде үзләренә. Юк бит, ник кенә бер җылы сүз ычкынсын Җаббардан. Бары тик тозлы-борычлы, утлы-яшенле әр-бакырулар гына сибелә. Ә егетләрдән каршы сүз ишетмәссең. Каш астыннан

гына бер-берсенә карашып алалар да йөгерә бирәләр. Хәтта ялагайланалар да бугай әле үзенә. Монысын сизенү Җаббарның ачуын тагы да кабартып җибәрә. Кулына ни эләксә, шуны бәрәрсенә төбәп тондырырга да күп сорамый. Бигрәк тә, әнә, Зиннурга эләгә мондый тәпәчләр. Нилектәндер инде, анысын Җаббар үзе дә белми, мондый чакларда гел шул әзмәвер егеткә каныга ул. Гәүдәгә иң олысы булса да, яшькә арада иң кечесе — Зиннур. Төскә дә бик чибәр. Аз гына яшькелтрәк-коңгырт күзләре үткен итеп, усал итеп, шул ук вакытта моңсу да карыйлар. Дулкын-дулкын шомырт кара чәчләренә карлыгач кереп адашырлык. Бөдрә яңак сакаллары, ыспай гына кара мыек җибәргән — алары да бик килешеп тора үзенә. Әйтәсе дә юк, бу чибәрлеге, бу таза-зифалыгы белән кызларның башын әйләндерә торгандыр ул.

Табигать егеткә бик мул тамызган әнә шул бәһасез бәхет күңелен ярсыта микән әллә Җаббарның?

Дөрес, заманында Җаббар да кордашлары арасында иң тазалардан иде. Җилкәсе белән тоеп йөргән озын-озын карашлар, оялчан гына алсу елмаюлар санын исәпли башласаң, алай кызлар күзе төшмәслек егет түгел иде. Ләкин... Кая инде ул елларның тозсыз бәрәңге белән алабута шулпасыннан оешкан көч-зифалыгын хәзерге Зиннурларның муллык-туклыкта сипләнгән, кояш тулы стадионнарда чарланган куәт-тазалыгына чагыштырасың?!

Яшь булса да, инде шактый гына дөнья күреп өлгергән Зиннур. Унны бетергәч, Уфа нефть институтына имтихан бирә алмаган да, авылына да кайтып тормастан, Себер ягына сыптырган. Аннары Казагыстан ягына юл тоткан. Кавказ, Кырым якларын әйләнгән. Урман кискән, ташчы булган, юл салган, йөк ташыган һәм, әгәр үзенең сөйләвенә ышансаң, ресторанда официант булып та йөргән.

Инде елга якын биредә эшли. Өйрәнчек булып кына кергән иде, хәзер бораулаучының икенче ярдәмчесе. Элеккечә әйтсәң, верховой. Ләкин Җаббар сизеп тора: барыбер күп эшләмәячәк ул монда. Китәчәк. Институт хыялын да ташламаган шикелле, әүвәл анда барып керер, керә алмаса, тагын ил гизәргә чыгып китәр. Барыбер китәр. Ул китәр, Җаббар калыр. Китәр дә — йөргән таш күк шомарыр; укыр да — әллә нинди гыйлемлекләр өстәр Зиннур. Җаббар инде шомарасын шомарган, аласы гыйлем-һөнәрен алган. Бишенче дистәне куганда, тагын нинди гыйлем-һөнәр өстисең дә, итәк тулы балачаганы төяп, кая чыгып китә аласың? Ә Зиннурның, очар коштай, канатлары нык, һавасы биек. Җаббарның күк гөмбәзе исә түбәнәя бара: ул буровойның менә шушы рычагларына, краннарына ябышкан да шуннан ычкына алмый инде. Иртәгә дә, берсекөнгә дә. Ихтимал, пенсиягә чыкканчы...

Әллә инде әнә шуны тою күңелен кузгатамы Җаббарның?.. Зиннур очачак, ул җирдә торып калачак. Җиргә иелгәннән-иелә генә барачак. Ләкин бит... Кояш байый, ай калка. Умырзая сула, миләүшә чәчәк ата. Ландыш ак таҗларын коюга, янар чәчәк үзенең уткызыл таҗларын ачып җибәрә. Бодай башаклары тулып, комбайнчыны көтеп утырганда, карабодай әле шау чәчәктә була. Каен җиләге кызарып пешкәндә, җир җиләге әле яшел бөре генә була. Берберсеннән көнләшәләр микән соң алар?

Ни генә булмасын, бүген тагын эләгешеп алдылар алар.

Асфальттан урман юлына борылуга, машина кинәт туктады.

— Егетләр, тәпиләргә туры килә. Бу җәһәннәм чокырларын үтеп булмастыр. Тормозым бик начар,— диде шофер.

Чыннан да, урман юлы коточкыч иде. Болай да үр төшеп, үр менәсе, өстәвенә, вышкачыларның, электрчыларның тракторлары,

бульдозерлары юлны актара алган кадәр актарган. Адым саен муеныннан кереп чумардай ерым-чокырлар, сынган-чәрдәкләнгән агачлар, бүрәнә юанлыгы кәкре-бәкре тамырлар.

Юл бик иләмсез, ә көне гаҗәп матур иде. Күтәрелеп кенә килгән кояш нарат кәүсәләрен алтыннан, имәнне яшькелт-кара бәрхеттән, зелпе куакларын үтә яшел ефәктән киендергән, яфракларга, үләннәргә мул итеп энҗе-зәбәрҗәтләр сибеп куйган. Чык-энҗеләр юл өстендәге ауган-сынган ботакларда, тапталган үләннәрдә дә күзләрне камаштырып җемелди иде.

Алданрак киткән Зиннур туктады да юлга аркылы сыгылып төшкән бастырык юанлыгы бер агачны күтәреп торгызды, төбен таптарга, тамырларын ныгытырга тотынды.

— Ни ачулары булгандыр миләшкәйдә,— диде, бүтәннәр килеп җиткәч.

Җаббар аңа иңбашы белән төртеп узды.

— Бүлмәңә алып кайт та кочаклап ят син аны, яме?

— Сиңа да файдасы тимәсме дим, Җаббар абый. Миләшне кайнатып эчсәң, бөерләргә бик тә шифасы тия дигән идең бит.

— Әй, сантый! Синең шифаңа калган ди монда! — Җаббар җәһәт кенә бер кантар алып егеткә ыргытты. Зиннур иелеп калды, иелгән шәпкә үзе дә каты балчык алып тегеңә җибәрде. Балчык Җаббарның яньчек кепкасына килеп тә тиде.

— Әле син абзаңа кул күтәрәсеңме! — Җаббар, йөгереп килеп, егетнең беленнән эләктереп алмакчы иде,— Зиннур аның кулларын тотып калды. Кулларын тартып алып, тагын беленнән эләктерергә итә Җаббар, егет исә «абзыйның» үз беленнән кысып алырга чамалый. Тартышыпмы-тартышалар.

Буровой, гадәттәгечә, үз көенә гәрли, дөберди, тырылдый, зыңгырдый. Гәрли-дөберди, тырылдый-зыңгырдый да кинәт кенә яңгыратып бер пошкырып куя. Өй биеклеге корыч торба җир астына төшеп бетте; инде автомат ачкыч, шулай ярсып, потлы-потлы бармаклары белән икенче бер пәһлеван торбаның муеныннан кочып алды дигән сүз бит бу. Күп тә үтми, ул торба да җир куенына чума, потлы бармаклар өченче торбага үреләә. Аннары дүртенчесенә чират җитә, бишенчегә, алтынчыга... әллә ничәнчегә.

Шулай торбага торба ялгап, бер чакрым тирәнлеккә төшеп җиткәч, астагы борау үз эшенә тотынып, метр артыннан метрлап девонга якынлашканнан-якынлаша барыр. Корычның үзеннән катырак токымнар, ишелергә торган комлыклар, мәкерле куышлыклар аша да үтәсе бар. Алары да булыр, алары күп мәшәкатьләр китерер. Әмма тиздән яңа метрлар, бүгенге метрлар башлана — бөтен эшенең көзгесе, төп максаты.

Бик яраталар бораулаучылар бу минутларны. Кем ничек кичерәдер андый мәлне, ә менә Җаббарның кычкырып бер җырлыйсы килә башлый. Кычкырып ук җырламый җырлавын. Тавышы үз яныннан китмәслек итеп кенә, моңын буровой шау-гөренә тәмам сеңдереп кенә барыбер шыңшый-көйли башлый. «Арча» көенә дә, «Җилләр, җилләр»гә дә берьюлы охшаган шундый бер көй.

Ләкин бүген нигә көйләми соң әле күңел шушы көйне?

Ул көйне көйләми күңел, аның урынына колак төбендә бүтән бер мон яңгырый. Буровойның бар шау-дөбердәве эчендә зәгыйфь кенә моңлы бер зың ишетелеп тора. Бүген таңда төшендә ишеткән зың бит бу! Бөтнек үләне моңы...

Юк, тикмәгә генә кергән төш түгел бу.

Бөтен отгулларын җыеп, бер атнага ял алды да авылына кайтып килде Җаббар. Исәбе — әнисен үз янына, Әлмәткә алып килү иде. Бу турыда әнисенә күптәннән, әтисе вафат булганнан бирле әйтеп йөри иде инде ул. «Тукта, улым, әтиеңнең елы тулсын, аннары уйлашырбыз»,— диде башта Мәхмүзә карчык. Елы түгел, инде өченче елы тула, Җаббарның һаман да әнисен кузгата алганы юк. Клуб чаклы өйдә бер ялгызы яшәп ята. Дөрес, гел генә ялгыз булмый, колхоз килгән-киткәнне фатирга аңа кертә. Кайтсаң, зарланып та ала үзе. «Картаймыш көнемдә кеше көе көйләп йөрүләре бик кыен. Каз өмәсен генә үткәрим дә, тәвәккәллисе булыр».

Соңгы хатында әнисе язды: «Карчык кешене бимазаларга теләмиләрдер инде, колхоз миңа кеше дә кертми башлады хәзер. Аллага тапшырып, тәвәккәллисе булыр, улым. Үз җаең белән кайтып алсаң икән».

Буровойда авария көннәре иде, Җаббар хатны алуга ук чыгып китә алмады. Кайтып, бусаганы атлауга ук күзе төште: олы як курчак өе күк җыештырылган, түрдәге өстәл өем-өем китаплар, газеталар белән тулган, бер почмакта бик пөхтә җыештырылган яңа карават тора иде.

— Әллә Фәрит кайттымы? — диде Җаббар әнисе белән ике куллап күрешкәндә үк.

— Кайтыр инде... Марҗасы җибәрәме соң аны! — Мәхмүзә әби моңсу гына елмайды.

Фәрит — аның төпчек улы, Кузбасста тау инженеры, ә «марҗа» дигәне — Фәритнең хатыны, бер авыз сүз татарча белми торган, шәһәрдә үскән татар кызы иде.

— Укытучылар фатир керде. Ире дә укытучы, хатыны да. Укып бетереп кенә килүләре. Яшь булсалар да, бик акыллылар. Бик иплеләр.

— Әйбәт булган, әни. Юкса, мин, тәрәзә-ишеккә такта кадаклап китәсе булыр микәнни, дип борчылып кайткан идем.

— Үзем дә шуны әйтәм. Шәһәрдә укысалар да, авылда туып-үскәннәр болар. Йорт-җир тота белгәнгә охшыйлар. Киленнең бигрәк тә инде йорт эшенә кулы ябышып тора. Казларны, тавык-чебешләрне дә бетереп тормам дим. Юкса, кайтылмый тормас ич. Тавыклар җырлап йөрмәгән, әтәч кычкырмаган ишегалды ишегалдымыни ул. Өнсез-җансыз сахра...

Ана кыштыр-кыштыр килеп юлга хәзерләнеп йөри башлады. Әллә нигә тиенчек төйнәлде. Укытучылар мәктәптә чакта өем-өем юды. Бу эшне кичкә калдырса, укытучы хатын: «Алҗып йөрмә, әби, үзем уармын», дип, аңа һич ирек куймый икән. Җаббар да әйтеп карады:

— Ике киленеңнән береннән-бер тәрбия күргәнең юк. Төйнә дә куй, Нәсимә юар әле.

Карчык кул гына селтәде.

— Чит бусаганы уылмаган кер белән атлыйммы кеше! Гомер булмаганны.

Иртәгә юлга чыгасы дигән көнне Мәхмүзә карчык бакча ягыннан бер кочак үлән күтәреп керде. Иплән кенә төенчекләре янына куйды.

— Әллә үлән төяп бармакчы итәсең инде Әлмәткә? — диде Җаббар көлемсерәп.— Җитәрлек алар анда да. Зәй буйлары, Миңлебай урманнары ерак түгел.

— Анысы шулайдыр да. Бөтнек үләне генә юк ул якларда дип зарлана идең бит.

Җаббар шунда гына әткелтем хуш исне тоеп алды.

Әйе, зарлава иде шул... Буровойлары нинди генә аланнарда, урманнарда, нинди генә инеш буйларында тормады аларның. Ләкин бөтнек үләнен очрата алганы булмады. Разведка бригадасында йөргәндә ничәмә өйдә бер гаиләдәй яшәде. Әмма аш янына беркайда да бөтнек куйганнарын хәтерләми. Бик сәер тоела иде бу Җаббарга. Бик сагына иде ул бөтнек сипкән ашны. Шул бөтнекле ашны ашар өчен генә дә авылларына очып кына кайтып килергә җитешкән көннәре күп булды.

Мәхмүзә әби бөтнекне нәни-нәни көлтәләргә бәйләргә тотынды.

— Фәрит тә, синең күк, бөтнек сагына башлаган,— диде ул, үз алдына гына сөйләнеп.— Соңгы хатын укыдың микән? «Күп итеп бөтнек сибеп, син пешергән аш ашар идем, әни», дигән, бахыр. Исенә төшкән...

— Нигә кайтмый икән, алайса?

— Соң, хатыны бит... Отпуска алдымы, әле Кырымга, әле Кавказга өстери. Парижында, Прагасында да булып кайттылар. Яшь вакытта дөнья күреп калу да кирәк шул. Нихәл итәсең...

Иртән торгач, Җаббар күреп алды: өстәлдә ике яшел шешә тора, тагын ике яшел шешә тәрәзә төбендә. Күрәсең, кичтән мичкә ягып, бөтнекне киптерергә, уарга, шешәләргә тутырып куярга да өлгергән әнисе.

— Улым, онытканчы чемоданыңа салып куй әле боларны,— диде ул, өстәлдәге шешәләрне күрсәтеп. Үзе тәрәзә янына килеп утырды, андагы бөтнек шешәләрен сыйпап куйды.

Шул утыруыннан ул бик озак кузгалмады. «Мин укытучылар белән эчтем инде»,— дип, Җаббар янына чәй эчәргә дә утырмады.

— Улым, кайтуыңа бик рәхмәт,— диде ул, Җаббар чынаягын каплап куйгач.

— Машина килеп тә җитәр инде, әни. Син әзердер бит?

— Шуны әйтим дигән идем шул. Мин кузгалып йөрмәмдер лә, улым. Хәзер инде укытучылар белән, ялгыз башым да түгел. Алда тагын уйлашырбыз әле. Әлегесен, болай селкенеп йөри алганда, бер генә дә кузгаласыларым килми.

Җаббар шап итеп урынына кире утырды.

— Менә сиңа мә!..— дип кенә әйтә алды.

Мәхмүзә карчык тагын тәрәзә төбендәге бөтнек шешәләрен сыпырып куйды.

— Аннары менә... Фәрит тә кайтып килмәгәе. Күңелем сизә, кайтыр шикелле. Алай бөтнекле аш сагындыра башлагач, түзә алмас, кайтыр. Андыйга киткәч, түзеп булмый ул. Әниеңнең иләс-миләс сүзләрен дә җиргә салмыйча, мәшәкатьләнеп кайтып йөрүеңә бикләр дә инде рәхмәт.

Буровой хәзер бүтәнчәрәк шаулый. Колак тондыргыч даң-доңнар, тешкә тиярлек шыгырдаулар юк, тигез генә, көйләп кенә гөрләп утыра буровой.

Җаббарның рукоятка тоткан кулы кисәк-кисәк дерелдәп куя. Һәр дерелдәү саен Җаббар рукояткага я тагы да ныграк баса, я йомшарта. Бораулаучының шулай чакрымнан артык тирәнлектәге борау белән сөйләшүе бу. «Кыенлашып китте мәллә анда, бораукай, таш тишеп үтүләре? Мә, җанкисәгем, миннән дә көч ал... Бирешәме таш? Бирешер шул без барында. Син, бораукаем, бик ашыкма анда. Иплән кенә, җайлап кына...»

Көтелмәгән куышка гына юлыкмаса, әлегә бик әйбәт юллап бара борау. Булмаса, идарәне Мөҗәһиткә тапшырырга да бер әйләнеп керергә кирәк. Бораулаучының беренче ярдәмчесе — Мөҗәһит. Җаб-

бар күптән сизеп йөри: алай ярдәмче генә булуга канәгать түгел егет. Үзе идарәгә басып, үзе борасы, үзе вахта башы буласы бик килә.

Бераздан Җаббар — моны ул ничектер үзе дә сизми калды — Мөҗәһитне түгел, Зиннурны үз янына чакырды.

— Әйдә, бас, почык борын. Чын эшкә өйрәнергә вакыт сиңа.

Зиннур рукояткага ике куллап ук ябышты, үзе астан гына Мөҗәһиткә күз атты. Тегесе, аларга әйләнеп тә карамыйча, кулына ыргак алды да яңа торба тәгәрәтешергә төшеп китте.

Җаббар кычытканлы кура куаклыгын ерып үтеп, аланчыкка килеп чыкты, шундагы ялгыз каен төбенә килеп утырды, тәмәке кабызды.

Чыннан да, нәрсә булды соң әле аңа? Әнисен алып килергә дип китеп тә, шулай ялгызы гына әйләнеп кайтулары беренче генә түгел инде, югыйсә. Дөресен генә әйткәндә, бу юлы да әнисен кузгата алуына бик үк ышанып бетмәгән иде ул.

Нихәл итәсең, төпчек улын күтә әнисе. Инде алай, өйдә ялгыз башы гына булмагач, күтә бирсен. Дөрестән дә, кайтып килмәгәе Фәрит. Их, бу төпчек малайларны!.. Яшерен-батырын түгел, Җаббар үзе дә бит, берәр җиргә чыгып китсә, барыннан да элек, үлә язып төпчеген сагына башлый. Алай гынамы, эштән кайтканчы ук сагынып өлгерә ул аны.

Сагындыра шул... Күп нәрсәләр сагындыра бу дөньяда.

...Җаббар бу юлы да эчтән генә кабат-кабат җырлап кайтты:

Җырлыйм Арча көйләренә,
Шунда туып-үскәнгә...

Ләкин авыл аны бу юлы сәеррәк каршылады. Барыннан да бигрәк, авыл тын, артык тын иде. Бик гаҗәп тоелды Җаббарга бу тынлык. Ә бит элегрәк кайтуларында да шулай тын булгандыр инде ул авыл. Әмма бер дә болай сәер тоелмый иде. Рәхәт кенә иде. Шәһәр шау-шуына, буровой гөрелтесенә колаклар инде тәмам күнегеп бетте микәнни?

Хәер, болай бит... Җәй көне авылда һәркемнең үз мәшәкате муеныннан. Утын, печән, бакча... Җаббарның үз кордашлары әнә шул мәшәкатьләргә чумган, ә клубка керсәң, яшьләр, аңа бөтенләй таныш булмаган яшьләр генә... Күрәсең, әнә шул ялгызлык тынлыгы булгандыр әле ул.

Бер кичне, шулай, кинодан кайтышы иде. Клубтан ераклашкан саен, урамнар тына барды. Инде тып-тын. Утлы тәрәзәләр дә сирәк күренә. Җаббар акрын гына атлый да атлый. Кайтып җитәргә дә вакыт түгелме соң?

Шомырт ботаклары тәбәнәк койма аша урамга салынып төшкән бер өй янында туктальп калды. Тәрәзәләрдән зәгыйфь кенә яктылык сирпелә, ут эчкәре бүлмәдә иде бугай.

Кинәт челтәр пәрдәле тәрәзәләр ялт итеп балкып китте. Күрәсең, хуҗалар бу якка чыкты. Җаббар, корт чаккандай, читкә атылды.

Ах, карт тиле, карт тиле! Менә кая килеп чыккансың ич син. Рәмиләләр өенә. Дөресрәге, кайчандыр Рәмилә торган өйгә. Инде ничәмә еллар үткәч. Менә син, карт тиле... Дүрт бала анасы хәзер Рәмилә. Үзеңнең дә җитеп беткән кызларың, малайларың бар. Нәрсә калган сиңа монда?

Кайдадыр капка шыгырдап куйды да, «кем анда вакытсыз йөри?» дигәндәй, ачы итеп ана каз кычкырып җибәрде. Бәбиләре аңа йокы аралаш гөгелдәшеп җавап бирделәр.

Ә баш очында коңгызлар жуылдап оча, инеш ягыннан бакалар

аваз сала, аргы якта кызлар көлешә, тагы да арырак ялгыз гармун моңлана иде.

Карачы, алай ук тын түгел икән ич урамнар.

Челтәрле тәрәзәдә ниндидер күләгә чалынды. Җаббар коймага тагы да сыена төште.

Әй, карт җүләр! Һәрхәлдә, Рәмилә күләгәсе түгел бу. Кайтмаган Рәмилә. Кайтмаган... Элеккерәк елларны, ничек шулай туры килеп торгандыр, Җаббар кайтканда еш кына Рәмилә дә өйдә була торган иде. Бу юлы — юк.

Бәлки, әнә шуңа күрә, Рәмилә кайтмаганга күрә, шулай артык тын тоелгандыр әле аңа авыл урамнары.

Алай ук тын түгел икән.

Алар аерылышкан кичне дә менә шулай баш очында коңгызлар жуылдый, кайдадыр кызлар көлешә, кайдадыр ялгыз гармун моңлана иде.

Бигрәк әллә ничек кенә булды инде аларның аерылышулары...

Якында гына шартлап ботак сынды, агачлар арасында Зиннурның әзмәвер гәүдәсе күренде.

— Син! Нишләп йөрү бу? Нигә урыныңда түгел син?

Зиннур тиз-тиз бире атлады. Бер кулын артына яшергән иде.

— Син китүгә үк мине куып җибәрде ул Мөҗәһит абый. Үзе басты.

— Вәйт, карга! Шулай булыр дип уйлаган идем аны.— Җаббар мыек астыннан гына елмайды. Бу елмаю Зиннурга да йогып өлгерде.

— Ә мин, Җаббар абый, кызыл бөрлегән таптым. Менә!

— Һе! Мин сине әллә кош тоткансыңмы дип торам.

— Кызыл бөрлегән бу, Җаббар абый. Мин аны әллә бу якларда үсмиме дигән идем. Кара бөрлегән күп бу якта, ә кызыл бөрлегәнне беренче күрүем. Сезнең якта бармы ул, Җаббар абый, кызыл бөрлегән?

— Иләкләп-чиләкләп җый. Аннары, кара җиләк күп бездә. Бу якта тоже күренми ул кара җиләк. Руслар голубика диләр. Ашаганың бармы?

— Бар. Ләкин үзебезнең якта түгел, Себердә. Безнең якта тагын юа бик күп була. Ну, кыргый суган. Бармы ул сездә?

— Очраштыргалый. Әмма ләкин син миңа шуны әйт. Бөтнек бармы сездә, бөтне-ек?

— Ашка сибә торганмы? Бар. Әни кайдандыр җыеп кайта иде. Ә юа бик күп бездә. Болын тулы. Әй, тәмле дә була соң! Беркайда юк ул бездәгедәй тәмле юалар. Күпме җирләрдә булдым.

— Юа!.. Бөтнек табып кара син менә! Ә син юа да бөрлегән дисең. Аның ишеләр бакчада да үсә. Ә бөтнек...

— Һәр якның үз үләне, үз көе, Җаббар абый. Безнең якның да бар үз көе — «Актаныш басмалары».

— Ну, ярар, Актаныш басмасы! «Арча» көенә җитми барыбер. Ярар. Ирек ачарга килмәгән без монда. Марш буровойга! Сальникларны тартырга вакыт. Насосларны карарга... Живо!

Җаббар Зиннурны куып җибәрсә дә, үзенең әле урыныннан кузгаласы килми иде.

«Һәр якның үз үләне, үз көе...». Дөрес сукалый егет. Ә бәлки, алай гына да түгелдер әле. Һәркемнең, һәр күңелнең үзенең генә үләне, үзенең генә көе дә була торгандыр?..

...Сәеррәк иде ул кичне Рәмилә. Авыл урамнарына гына сыймадылар, ындыр артлары тар тоелды, Ашыт елгасы буена ук төшеп киттеләр. Башка көннәрне алай ерак-аулак китә башласалар, Рәмилә егетне җайлап кына кире бора иде. Бүген алай итмәде, гел көлде дә көлде ул, Җаббарның һәр сүзеннән кызык табып көлде. Бүтән кичләрне алай ук онытылып көлгәне дә юк иде бугай.

Яр буенда кемдер чабып-җыеп куйган кечерәк кенә чүмәлә төбенә килеп утырдылар. Җаббар шашып-шашып кызны үбә башлады. Битләреннән, күзләреннән, муенынннан.

— Җаббар, тыңлале...— Рәмилә ике куллап егетнең башын арткарак каерды.— Тыңлале мине, Җаббар. Ташла әле син ул шабашник булып йөрүеңне.

— Минә сиңа! Нигә шабашник булыйм ди мин? Әтигә генә булышам бит.

— Булса да... Ошамый миңа синең гел балта гына тотып йөрүең, Җаббар. Укырга да китә алмый калдың.

— Укуы да качмас.

Кайнар иреннәр, бөтен тәнне рәхәт кытыклаучы каты-йомшак күкрәкләр, кызның чәченнән бөркелгән хуш ис Җаббарны тәмам исерткән иде, башы әйләнә иде аның. Рәмиләнең сүзләренә аз гына да игътибар итмәде ул. Хәер, игътибар итәрлеге дә юк, бу турыда аның үз исәбе, үз нияте иде. Менә тагын күп дигәндә ике ай балта чабып йөрер дә аннары — җитәр! Усадка тракторчылар курсына китәр. Юкса, колхоз идарәсе дә бик кырын карый аның болай йөрүенә. Ләкин йөрмичә дә ярамый. Хәзергә ярамый. Әтиләре артельләре белән Кышкарда ике өй, өч мунча салырга килешкәннәр. Шунда барып кайтмый булмый. Акча кирәк. Йорт саласы бар. Зур итеп, якты итеп, кешечә итеп. Кием-салым да кешечә булсын. Аннары... Туйны да акчасыз үткәреп буламыни? Ул коры хезмәт көннәренә генә ышансаң...

Ә Рәмиләгә нәрсә?.. Аңламый ул. Укытучы кызы, үзе дә укытучы. Аңа акча зарплатадан килә. Бүтәнен ул кайдан белсен?

Рәмилә кинәт үзе Җаббарны шашып үбәргә тотынды.

— Җүләркәем минем,— дип пышылдады ул,— бигрәк инде уйламыйсың киләчәк турында.

— Шайтан уйласын киләчәк турында,— диде Җаббар гамьсез генә. Кызның тыгыз-кайнар гәүдәсен бөтенләе белән үзенә сеңдереп бетерергә теләгәндәй, кысканнан-кысты. Бу фани дөнья каядыр еракта калды... Бәхет дигәннәре әллә шушы микән? Ләкин бераз гына тагын нидер җитми иде әле ул бәхет дигәннәренә. Җитсен иде...

— Рәмилә... Син бит инде барыбер үземнеке булачак... Рәмилә дим...

Кызның бөтен гәүдәсе кинәт хәлсезләнеп калгандай булды. Ләкин бу бер генә мәлгә. Икенче бер мәлдә ул тыелгысыз бер көч белән Җаббарның кочагыннан ычкынды.

— Юк, юк... Тия күрмә,— диде ул каушаулы пышылдап һәм кинәт йөгереп китеп тә барды.

Җаббар, миңгерәүләнгәндәй, чүмәлә төбендә ятып калды.

Ятып калды шул... Бәлки, шунда ук сикереп торырга да кызны һичшиксез куып җитәргә кирәк булгандыр аңа?..

Куып җитмәде...

Таң атуга, әтисе әле керфеккә-керфек тә какмаган Җаббарны уятырга өйалдына чыкты. Кышкарга, кемнәргәдер өй салырга, кемнәргәдер оя корырга чыгып китәселәре бар иде. Җаббар: «Авырыйм, башым бик авырта»,— дип, урыныннан кузгалмады.

Әтисе, тамак кыра-кыра, гел чыгып-кереп йөрде. Җаббар, ыңгырашкандай итеп, авыр-авыр сулады.

Инде радио да сөйли башлады. Шунысы бик истә калган: Мәскәүдән дә, Казаннан да Әлмәт нефтьчеләре турында сөйләделәр. Зур Татарстан нефтенең беренче, колачлы адымнары башланган көннәр иде бу.

Әтисенең капка төбендә кемнәр беләндер кырыс-кырыс сөйләшкәне ишетелде.

Җаббар, әнисенең күзләренә күтәрелеп карый алмыйча гына: «Врачка күренмичә булмый»,— дип мыгырданды да район үзәгенә китеп барды.

Шул китүдән ул авылга әйләнеп кайтмады. Нефть якларына юл тотты.

Шабашник, имеш... Бу шабашникның кем икәнлеген радиодан ишетеп, газеталардан укып белерсең әле син, Рәмилә!..

Соңыннан, еллар үткәч кенә ишетте. Ул көннәрдә гел Җаббарны эзләгән Рәмилә. Көткән... өзелеп-өзелеп елаган.

...Ә теге кечне Ашыт буендагы ул чүмәләдән мул булып бөтнек исе аңкый иде.

Буровой ниндидер ят тавышлар белән тырылдый, үкерә башлады. Җаббар сикереп торганын сизми дә калды. Нәрсәдер булган, юньлегә үкерү түгел бу.

Күперчектән менгәндә үк Җаббар мәсьәләне төшенеп алды. Прихват. Җир асты көчләре колонна торбасын ныклап торып кыскан.

Мөҗәһитнең юеш чәчләре маңгаена ябышкан, кызарып-бүртеп чыккан, үзе һаман рычагка баса. Калганнар башларын түбән игәннәр.

— Туктат хәзер үк! — дип кычкырып җибәрде Җаббар.

Буровой эче тынып калды.

Җаббар үз урынына басты. Приборларга күз йөртеп чыкты.

Мондый авариядән котылуның күп төрле ысуллары бар. Иң беренчесе һәм вакытны иң аз ала торганы — көчне һәм тизлекне арттыра барып, торбаны какшата-какшата тартып чыгару. Ләкин моны зур осталык белән, җаен-әмәлен белеп эшләсәң генә уңышка ирешәсең. Юкса, каш ясыйм дип күз чыгаруың да бик ихтимал. Аста торбаң өзелеп калуы, өстәге блоклар сынуы, тагын әллә нинди бәлаказалар чыгуы да бар. Гомумән, кешенең җир асты дуамаллыгы белән көч сынашуы бу. Әйтергә кирәк, таранга баруы.

Гадәттә, мондый вакытларда авария инженерын чакыралар. Әмма Җаббар кебек бораулаучылар өчен бу инде... өй салырга алынган балта остасының түбә кыегы утыртып бирүне сорап күршегә керүе белән бер.

— Чыгып бетегез хәзер үк. Живо!

Егетләр акрын гына күпердән түбән таба атладылар.

Җаббар ялгызы гына җир асты «диюләре» белән көч сынашырга калды. Күзгә-күз карашып. Җан-фәрманга. Кем кемне?..

1972. Март.

## Мансур Хәсәнов

# ЙӨРӘК СЕРЕ

*Булган хәл.*

Әйе, мондый хәлләр гел булып тормый...

Подполковник Галимов вак кына хәрефләр белән язылган дәфтәр битен кулында тагын бер тапкыр әйләндерде дә имзага күз төшерде. «Шул, тагын лейтенант Соломин хатыны»,— дип уйлады ул ни өчендер дулкынланып.— Әнә ич «Наташа. Минск» дип тә язылган. Бу кадәр дә тынгысыз җан булыр икән...»

Наташа җаны-тәне белән Байкал ягына омтыла, ә ире исә, төрле сәбәпләр табып, аны монда китермәү җаен эзли. Наташаның моңа ачуы килә. «Минем Ванюшама нәрсә булды, тизрәк хәбәр итегез»,— дип яза ул Фәрит Галимовка.— Әллә, югыйсә, мин аңа бөтенләй кирәк түгелме? Бәлки, ул чынлап та кыенлыклардан курка торгандыр? Бәлки, чынлап та сез яши торган җир шулай коточкычтыр, бәлки, тырпаганнан гайре җан иясе дә юктыр анда?..

Фәрит хатны ипләп кенә конвертына салып куйды да тәрәзә янына килде. Анда һаман да шул бер үк күренеш: таныш сопкалар һәм очсыз-кырыйсыз сары дала. Көне буе дулаган җил басылган; тирә-як ничектер оеп утыргандай, йокыга талгандай күренә.

Гомерне кара инде син. Ничек тиз уза. Әле кайчан гына Галимов та Соломин кебек яшь-яшь лейтенант иде. Эльвирасы белән бергәләп язгы шәфәкъка карап торулары, сопкаларга менеп йөрүләре, дала гарнизонында тополь утыртулары бүгенге кебек хәтерендә Галимовның. Ләкин инде аннан соң күпме вакыт узган. Ким дигәндә егерме ел. Егерме ел! Җилдәй исеп кенә узды түгелме соң ул егерме ел?! Язмыш Фәритне яңадан шушы якларга китереп ташлар дип кем уйлаган. Кунакка гына түгел бит. Хәрби хезмәткә. Язмыш гаепле микән әле монда? Бу якларга подполковник Галимов үз теләге белән килде ләбаса. Һәм бу юлы лейтенант Соломин кебек япаялгызы бер чемодан тотып килде...

Йөрәк серен теләсә кемгә сөйләп булмый. Ни өчен син теге очракта тегеләй эшләгән дә, ни өчен бу очракта болай эшләгән? Моңа җавап табу ансат түгел. Гарнизонда үзе хакында төрле хәбәрләр йөрүен подполковник Галимов бик яхшы белә иде. Кайберәүләр, имеш, ул семьясы белән тату яшәмәгән икән һәм шуңа күрә Байкал

ягына күчерүләрен сорап рапорт биргән икән дип, ә кайберәүләр исә, Фәрит Назарович хәйләкәр кеше ул, үзе монда хезмәт срогын тутыра, ә хатыны Казанда фатир саклап ята, дип сөйләделәр. Әлегә кадәр Галимов бу сүзләргә әһәмият бирми килде. Әмма ләкин Наташа хаты аның күңелен айкап салды. Хәтер чоңгылыннан мәңге онытылмаслык хатирәләр яңадан калкып чыктылар...

Эх, Наташа, Наташа!.. Хәер, Эльвира да нәкъ шундый иде бит. Кыю иде, шаян иде. Лейтенант Галимовның аңа беркайчан да елак хатлар язганы булмады. Хәер, алар беркайчан да бер-береннән аерым яшәмәделәр. Аннары аларның танышулары да бөтенләй көтмәгәндә, кызык кына килеп чыкты.

Галимов ул чагында Горький шәһәрендә ял итә иде. Аны, күк төсле ачык зәңгәр күзле кызны, очратканда Фәритнең ялы тәмамланып, китәр вакыты да җитеп килә иде инде. Ә кыз исә нәкъ менә яшь лейтенантларның башын әйләндерә торган сылу иде. Галимовның да аңа күзе төшми калмады. Бер мәртәбә сөйләшкәннән соң ук егет үзен инде Эльвира белән әллә кайчан танышкандай хис итте һәм аннан башка беркая да китә алмаячагын аңлады...

Бер атнадан алар өйләнештеләр.

Ашыккан ашка пешкән, диләр. Бәлки, бу сүзләр дөрестер. Әмма Фәрит белән Эльвира бу хакта уйлап тормадылар. Алар шул кадәр бәхетлеләр иде, хәтта ЗАГСка барырга да оныттылар. Киләчәктә алар кая китәчәкләр, кайда яшәячәкләр — бу хакта берсе-бер сүз кузгатмады. Фәрит Эльвираны ком бураннары белән дә, кырыс җилләр белән дә, зәмһәрир салкыннар белән дә куркытмады. Юлга чыккач: «Биш-алты көннән барып җитәбез; эх, безнең сопкаларны күрсәң син»,— дип елмаеп кына куйды. Ә үзе Эльвира күрмәгәндә: «Өйләндем, хатын белән барабыз, землянка казып куегыз»,— дип, иптәшләренә кыска гына телеграмма сукты...

Данлыклы утызынчы һәм кырыгынчы еллар... Ул елларда кешеләр кайларда гына һәм ничек кенә яшәмәделәр. Тик ничектер һәркем үз тормышыннан канәгать иде. Хәер, күңелеңдә кояшлы җылы яз булгач, кайда яшәүдәмени хикмәт!..

Фәрит белән Эльвира ул чагында гарнизонга аяз бер сентябрь иртәсендә килеп төшкәннәр иде. Яңа землянканы Эльвира бик ошатты. Бәләкәй генә булса да, җыйнак иде ул. Түрдә тимер мич. Түшәмдәге пыяла «күз» тәрәзә хезмәтен үти. Гарнизонда барысы да шундый землянкаларда яшәгәч, ни өчен Фәрит белән Эльвирага яшәмәскә ди!

Аннан соң күп сулар акты. Күп нәрсәләр үзгәрде. Тик саман йортта мәктәп ачылуы да, Эльвираның беренче мәртәбә шул мәктәпкә балалар укытырга китүе дә, июнь уртасында яуган карлар да онытылмый. Бигрәк тә яңа өйгә күчүләре хәтергә нык сеңеп калган. Бу вакыйга алар өчен зур бәйрәм булды. Яңа фатирга күчүнең икенче көнендә үк Эльвира өй каршына топольләр утыртты. Алар бик тиз яшәреп, тулыланып киттеләр. Әмма ул елны җәй коточкыч эссе һәм коры килгәнлектән, тополь ябалдашлары утта янгандай кара көйде. Көз көне алар корыган агачлар урынына яңаларын утырттылар...

Эльвира һәрвакыт каядыр атлыгып, ашкынып яши торган иде. Мәктәп диер, спорт мәйданы диер — һәрвакыт нәрсәне булса да кайгыртып яшәр, беркайчан да күңелсезләнеп, уйланып утырмас. Иркутскига китәргә боерык килгәч кенә бераз күңелсезләнгән иде ул. Чөнки торган җир аларга туган җир кебек якын һәм газиз иде инде.

Фәрит Галимов кайда гына яшәсә дә, кайларда гына хезмәт итсә дә, Байкал ягын онытмады. Ә егерме биш ел эчендә, кем әйтмешли,

аңа бөтен Россияне гизеп чыгарга туры килде. Әлбәттә, аңа хәзер ял итәргә дә мөмкин иде инде. Ләкин сау-сәламәт килеш 43 яшеннән запаска чыгарга теләмәде Галимов. Дөрес, кайберәүләр әйткәләделәр, имеш, ни пычагыма тагын шул караңгы якка китәсең? Тик Галимов нык карар кылган иде инде. Яшәде ич, Мәскәү янында да, Одессада да яшәде Фәрит. Сүз дә юк — матур урыннар. Әмма бер генә җир дә аның күңеленә Байкал ягы кебек мәңге онытылмаслык булып кереп калмады.

Подполковник Галимов октябрь аенда Читага очып килде. Көн коры һәм тын иде. Күкнең яктылыгы күзләрне чагылдыра. Моннан егерме ике ел элек тә күк нәкъ шулай якты, нәкъ шулай зәңгәр иде. Ул чакта монда аэропорт юк иде бугай әле. Әнә тимер юл вокзалы. Арырак агач барак булырга тиеш. 1943 елны алар Эльвира белән шул бинадагы ашханәгә кергәннәр иде. Ул чагында ризыкны талон белән генә бирәләр иде әле. Аннары заманында иң зур урам саналган Калинин урамы буйлап йөргәннәр иде. Ә хәзер шәһәр танырлык та түгел — үскән, яңарган. Тик Кенон дулкыннары гына элеккечә салмак, ә Ингода дулкыннары исә һаман да ярсу, йөгерек. Кая карама анда тау-урманнар зәңгәрләнеп күренә. Юк, бу инде теге чактагы япан сахра түгел. Монда хәзер бөтен тирә-якта хезмәт шау-шуы, гаҗәеп җанлылык хөкем сөрә. Күксел сопкалар итәгендә яңа поселоклар, совхозларның ап-ак биналары җәйрәп ята, югары көчәнешле электр линияләре сузылып киткән.

Поезд Борзя станциясенә якынлашып килә. Әнә анда ике катлы таш бина. Ә кайчандыр бу тирәдә агач йорт тора иде. Эльвира белән Фәрит поездтан шушы станциядә төштеләр. Икенче поезд уникe сәгатьтән соң гына килгәнлектән, алар идәнгә шинель җәеп, ял итәргә генә җыенганнар иде, кинәт ишек ачылды да вокзалга бер солдат килеп керде һәм Н. ягына машина китәчәген, әгәр дә теләүче булса, утыртып барачагын әйтте... Берничә минуттан Фәрит белән Эльвира машина кузовында тирбәләләр иде инде...

Мәскәүдә яшиме кеше, Улан-Удэдәме, Украина далаларындамы, Байкал буендамы — яраткан эше булса, аңа кайда яшәсә дә барыбер. Фәрит тә үзенең яңа эш урыныннан бик канәгать иде. Аны һәркем ярата, хөрмәт итә. Тик бу юлы аның янында Эльвира гына юк. Ә бит бу якларда барысы да, барысы да Эльвираны, ике бәхетле җанның яшьлеген сөйли. Менә хәзер ишек ачылыр да бүлмәгә мәлдерәмә чиләк күтәреп Эльвира килеп керер һәм сулышын көчкә-көчкә генә алып: «Цистерна китеп бара язды... сусыз кала идек»,— дип әйтер сыман.

Ул елларда гарнизонга суны мичкәләр, цистерналар белән китерәләр иде. Ә хәзер бөтен җирдә суүткәргечләр. Яңа мәктәп, офицерлар йорты... Эх, боларны Эльвира күрсә икән!.. Туктале, ни турында гына уйласа да, Фәритнең уйлары гел Эльвирага барып тоташа. Дөньяда Наташа да бар бит әле. Наташа бар, аның ире Соломин бар...

Соломинны Фәрит әле күптән түгел генә клубта күргән иде. Чигә сакаллары җибәргән. Чамадан тыш киң балаклы чалбар кигән. Йөреше дә ничектер бөтенләй хәрби кешеләргә хас булмаганча, бөтен гәүдәсе белән чайкалып атлый. Кайдан килгән аңа мондый сыйфатлар. Үзе Суворов училищесында тәрбияләнгән бугай инде. Начар кешеләр белән дә чуалмый. Әйтеп кара аның үзенә бу хакта. Акланырга кырыкмаса-кырык сәбәп табар. Наташасы турында сүз кузгатсаң: «Ә сез соң, сез үзегез, иптәш подполковник, ни өчен гаиләгезне алып килмәдегез?» — диячәк.

Иске яраларга кагыласы килмәгән иде Фәрит Назаровичның. Тик аңа Соломин кебек кырын күз белән караучыларга кайчан булса да

барыбер җавап бирергә туры киләчәк. Әмма көн артыннан көн үтә тора һәм яшь лейтенант белән әңгәмә сузыла килә...

Май чүлмәге тышыннан билгеле, дисәләр дә, тышкы кыяфәтенә карап кына кешегә бәя бирүе шактый читен. Лейтенант Соломин да подполковник Галимовның тышкы кыяфәтенә карап кына фикер йөртә, күрәсең. Моны Фәрит Наташа хатларыннан аңлады. Очрамады түгел, байтак очрады Соломин шикелле ашыгып фикер йөртүче кешеләр Фәрит Галимовка. Ләкин алар соңыннан үзләре үк гаепләрен танып, Фәриттән гафу үтенделәр. Ә Соломинга дөреслекне подполковникның үз авызыннан ишетергә туры килде.

Бервакытны ул ниндидер йомыш белән Фәрит Назарович фатирына килеп чыкты. Галимов аны өстәл янына чәй эчәргә чакырды. Әкренләп сөйләшеп киттеләр. Подполковник узган гомерен, яшьлеген сөйләде. Байкал ягына беренче мәртәбә хәрби хезмәткә килгән көннәрен, Эльвирасын, дала гарнизонын искә төшерде. Сүз арасында Соломин Фәрит Галимовтан:

— Сер булмаса, әйтегез әле, иптәш подполковник, сезнең хатынгыз кайда, ни өчен сез аны үз яныгызга алдырмыйсыз? — дип сорады. Яшерен-батырын түгел, бу сорауны көткән иде Фәрит Назарович. Тик ни өчендер Эльвираны югалту кайгысыннан яраланган йөрәк тагын да ныграк чәнчешеп, сыкранып куйды. Әйе, ул Эльвирасын Үзбәкстанда җирләп калдырды. Тик үзе ни өчендер шул якларда яши алмады. Күңеле аны һаман да Байкал якларына тартты. Һәм ул яңадан беренче мәртәбә хәрби хезмәтен башлаган җиргә әйләнеп килде. Эльвира да ничектер аның белән бергә яши сыман иде монда. Клубтамы, казармадамы, хәрби уеннар вакытындамы, өйдәме — ул һәрвакыт Фәритнең күз алдында торды. Һәм менә бүген шушы бәләкәй бүлмәдә Соломин белән сөйләшеп утырганда Фәритнең күңелен тагын Эльвира турындагы хатирәләр биләп алды. Соломин аның сүзләрен ничек кабул иткәндер, Фәрит моңа бөтенләй игътибар бирмәде. Фәкать сөйләде дә сөйләде генә. Аннары кинәт тынып калды. Урыныннан торып, тәмәке кабызды. Өстәл өстендәге бәләкәй сәгатьнең яңгыравыклы тавышы ачыграк ишетелә башлады.

— Мин китим инде,— диде, ниһаять, Соломин ишетелер-ишетелмәс кенә.

Фәрит Галимов баш какты.

— Ярый, бар... Әле клуб та ябылмагандыр...

— Юк, нишләптер бүген клубка күңел тартмый. Кайтам әле... Уйлыйм,— диде Соломин көрсенеп...

Фәрит Назарович, ялгызы гына калгач, тәрәзә аша ерак сопкаларга карап торды. Аңа менә хәзер ишек ачылыр да бүлмәгә мөлдерәмә су тулы чиләк күтәреп Эльвира килеп керер һәм сулышын көчкә-көчкә генә алып: «Цистерна китеп бара язды... сусыз кала идек»,— дияр сыман тоелды.

Куйбышев.

1971.

Марсель Зарипов

# ТЫЛСЫМ ИЯСЕ

Химиклар шәһәре Түбән Каманың анкетасы белән кыскача гына танышсак, мондый мәгълүматларны белер идек: туган җире — Татарстан, Кама буе; аңа әле ун гына яшь; халкының 43 проценты эшли; дөнья күләмендә танылган чит ил фирмалары белән бәйләнеш тота. Мондый мәгълүматларны безгә шәһәрнең баш архитекторы Морат Юсупов әйтте. Хәер, ул үзе Түбән Камада шәһәрнең беренче казыгын каккан чактан ук эшләми. «Түбән Камага нигез салучы» — дигән значогы булмаса да, аның бу калага килгәненә җиде-сигез ел инде. Белеме буенча ул — дипломлы инженер, ә табигате, холкы-фигыле белән, Түбән Камадагы барлык кешеләр кебек, хыялланa да, эшли дә белә, бик тиз ялкынланып эшкә тотына, энтузиаст. Укыган чагында ук ул «Волжский комсомолец» газетасына үзенең рәсемнәре белән катнашкан, аннары ерак төньяктагы Норильск шәһәрен төзешкән, Түбән Камага өлкән прораб булып эшкә килгән. Иртәнге сәгать алтыда килеп җитеп, автобустан төшкән, ике сәгатьтән соң инде объектларны кабул итеп алган.

Прораб булып ел ярым эшләгән, аннары аны чакырып алганнар да:

— Калабызның баш архитекторы булырга телисеңме? — дигәннәр.

Шәһәр чаклы шәһәрнең архитекторы булу, Кама буенда өр-яңа кала салу бик зур, бик җаваплы эш бит. Әлбәттә, эшләп карыйсы килә!

Без Кама ягы өстендә, шәм шикелле төз наратлар арасында басып торабыз. Бөек рәссам Шишкин атаклы наратларын шушы тирәләрдә иҗат иткән. Көн кояшлы, аяз; Кама өсте моннан уч төбендәге кебек күренеп тора. Сыек кына күксел-зәңгәр томан эченнән әнә Соколки күренә,— аның саллар рейдында өсләренә су үткәрми торган спецовка кигән осталар Вятка һәм Каманың югарыгы башыннан агып төшкән бүрәнәләрдән зур-зур саллар бәйлиләр; уң як ярда Алабуга каласындагы борынгы чиркәү гөмбәзләре күренә. Су өстеннән, акчарлаклар төсле, тиз йөрешле «Метеор»лар үтеп китәләр. Менә безнең турыда гына аста — киң култык бар, анда атау-атау булып камышлар, тал-өянкеләр үсеп утыра.

— Нинди матур җир! Сокланып туймассың. Ә ауга килсәң? Үрдәге, казы, башкасы...

Юсупов,— башына ак киндер кепка кигән,— яр читендә үк басып тора; бу матур җирләр — мең гектарлап нарат урманы, Кама елгасы — шәһәрнең иң зур кварталы, халык ял итә торган урыны, ди.

— Әле күптән түгел генә шушы култыктан төзелешкә вак чуерташ алмакчы булганнар иде. Өч тапкыр Казанга Совминга бардым, култыкны барыбер саклап алып калдык,— ди.— Ташны аны башка җирдән дә алып була, ә менә шәһәр янындагы матур табигатьне бозсаң, аны яңадан ясап булмый инде. Бу төшләр — тоташ ял урыны, биредә — пионер лагерьлары, балалар бакчасы, дәвалану профилакториясе урыннары. Автобус белән нибары унбиш минутлык кына юл — урманы, суы,— рәхим ит! Искиткеч җир! Мондый матур табигать Мәскәү халкының төшенә дә кергәне юк.

Түбән Кама, гомумән, бәхетле шәһәр. Аның узганы бик аз әле — ун ел гомер гомермени! — аның бөтен барлыгы бүген туа, тагы да күбрәге — киләчәктә булачак.

Тропик якларда елга буйларында яшәүче кара тәнле таппер-лар каучукны каргап: «Кешенең әҗәле ул!» — диләр. Чөнки алар иртә таңнан алып караңгы төн җиткәнче каучук агачыннан ак сыекча җыялар, хәлдән тайганчы эшлиләр.

Түбән Кама шәһәре үзенең дөньяга туу өчен әнә шул каучукка бурычлы.

Моннан йөз ел чамасы элек әрсез, тырыш инглиз эшкуарларыннан берәү кыргый Амазонка елгасы буенда каучук суын «күз яше урынына түгеп утыра» торган гевея агачыннан җитмеш меңләп орлык җыя, хуҗалардан яшереп, аны Бразилиядән Англиягә алып кайта.

Британия атауларының туфрагы бу агачның орлыгына килешми, нибары дүрт меңләп орлык кына исән кала. Әнә шул калган орлыклардан инде Африкада, Цейлонда һәм Малайзиядә меңнәрчә гектар каучук плантацияләре үрчеп китә. Эссе тропик кояшы астында бу искиткеч зур каучук агачлары үсмәгән бер генә дә буш урын калмагандыр хәзер, әмма кешегә һаман да каучук җитми. Каучуктан хәзер кырык меңләп әйбер ясыйлар. Экономистлар исәбе буенча, 1980 нче елда 1960 нчы елдагыдан өч тапкыр артык каучук кирәк булачак. Уйлап карагыз: «Волга» автомобиленең генә дә ике йөз кырык биш детале резиннан ясалган, ТУ-104 самолетының, тәгәрмәчләреннән башка, тугыз мең детале резин — болар үзләре генә дә ике ярым тонна авырлык тарта. Ә бер гектар каучук плантациясе, бик әйбәтләп үстергән-караган чакта да, нибары 1800 килограмм каучук бирә. Ихтыяҗ шундый зур булганда мондый уңыш белән генә каучук җиткереп буламыни?!

Табигатьне ничек кенә алдарга тырышмыйлар — каучук агачын уртача климатлы җирләргә күчереп карыйлар — ләкин файдасы булмый. Дөрес ансы, табигатьтә каучук күп очрый. Мәсәлән, безнең болыннарда үсә торган тузганак сабагында да каучук бар. Каучуклы өч меңләп үсемлек барлыгы билгеле. Ләкин аларда каучук шул хәтле аз, аны җыю иң кыйммәт алтыннан да кыйммәткәрәк төшәчәк, аннары, башка бернинди каучук та гевея каучугы белән тиңләшә алмый. Тузганак каучугыннан автомобиль көпчәге түгел, гади галош та ясап булмый.

Түбән Кама химиклары изопрен каучугы эшлиләр. Бу каучук натураль каучуктан ким түгел, кайбер яклары белән: ныклыгы, сыгылмалылыгы һәм температура үзгәрешләренә чыдамлы булуы белән аны хәтта узып та китә. Аларыннан да бигрәге шул — тропик-

ның каучук сыекчасын иң күп бирә торган агачлары да химик реакторлар белән ярыша алмый. Шәһәр үзе, химия комбинаты меңгектарлап урын биләп торса, анда эшләнә торган каучук бирәр тропик илнең бөтен дәүләте җитештергәннән дә артык.

Өстәвенә, бу әле — эшнең башы гына. Изопрен каучугының өченче чираты эшли башлагач, продукция дүрт тапкырга артачак.

Аннан да бигрәк, бу бик табышлы эш булачак, комбинатның рентабельлелеге 43 процентка җитәчәк, дәүләткә ул көненә бер миллионлап табыш бирәчәк. Барлык чыгымнар ике елда кайтачак.

Түбән Кама комбинаты — заман ачышларының дәвамы, бүгенге фәннең күп еллык тәҗрибә белән кушылуы, үз илебез һәм бөтен дөнья практикасындагы казанышлардан акыллы, кыю рәвештә файдалана белү нәтиҗәсе. Моннан кырык ел элек доктор Лебедев дөньяда беренче тапкыр азык спиртыннан ясалма каучук китереп чыгара. Бу хәлгә бөек галим Эдисон да ышанмый, «ялган» ди. Шуннан соң инде кешеләр каучук ясау өчен чимал итеп техник спирттан файдаланырга өйрәнәләр. Башта каучукның чималын ясарга кирәк, аннары — үзен.

Түбән Кама химиклары каучук ясаганда һәртөрле арадаш стадияләрне читләтеп үтәләр. Аны нефтьнең үзеннән, тагы да төгәлрәк әйтсәк, җиңел углеводородлардан ясыйлар. Безнең илдә иң бай чимал базасы — Татарстанның нефть промыселлары һәм химия комбинаты. Европа күләмендә моңа тиң бер комбинат та юк. Бу комбинат — бердәм промышленность комплексы, катлаулы производство системасы, химия патшалыгы ул. Анда күккә чаклы сузылган озын-озын металл сигаралар эчендә тылсымлы үзгәрешләр хасил булып тора; җитди кыяфәтле, җыйнак-пөхтә аппаратчылар, кодрәтле тылсым иясе кебек, иплэп-җайлап кына эшлиләр, промыселлардан килгән газны состав матдәләренә аералар: этан, пропан, бутан, изобутан, пентан, гексан, изопентан һәм башкалар... Ялгышмыйча санап чыгарлык та түгел. Шуннан соң инде эш реакторларга, полимер батареяларына күчә. Каучук әнә шунда барлыкка килә.

Партиябезнең XXIV съезды директиваларында Түбән Кама химиклары турында: «Түбән Камада нефть химиясе предприятиеләрен төзүне тизләтергә», дигән сүз бар. Комбинатның составында бик катлаулы полиэтилен, полистирол ясау, «Жигули» машиналары һәм Кама заводы автомобильләре өчен көпчәк җитештерү, нефть эшкәртү булачак. Тугызынчы бишьеллыкта дәүләт экономикасында бик зур урын тоткан бу комбинатның продукциясе ун тапкырга артачак.

Предприятие өчен эш әһәмиятлерәкме, әллә эшне башкаручы кешеләрме? — дигән бәхәс әле хәзер дә дәвам итә.

Социалистик системадагы хуҗалыкның иң зур өстенлеге дә шунда — без билгеле бер өлкә, край һәм кечкенә генә бер авылның да экономикасын кешеләрнең ихтыяҗлары белән яраштыру кебек бик мөһим процессны идарә итә, җайлый алабыз.

Түбән Кама каласының башка шәһәрләрнеке кебек үткәне, тарихи юлы юк. Аның каравы, бу каланың зур киләчәге бар. Бу шәһәр үзе туганчы үтеп киткән заманнарда төзелергә тиешлесен дә бүген эшли кебек. Җир йөзендә Түбән Кама каласы кебек ватман кәгазенә архитектор төшергән беренче сызыгыннан алып бүгенге һәм алдагы язмышы анык сызып куелган бер шәһәр дә, авыл да юктыр. Иртәгәсе нинди буласын бүген күз алдына китермичә, кварталлап, урамлап кына үсә торган шәһәрләрнең язмышы аңа кагылмады. Түбән Камада вакытлы торак йортлар салынмады, ул башта ук бүгенге күп катлы йортлары, квартал, проспектлары, балалар бакчасы, мәктәпләре, клуб һәм кинотеатрлары, институтлары һәм техникумнары

белән барлыкка килә башлады. Ул үзен дөньяга китергән химия гиганты корпуслары белән бергә үсә. Бу йорт бирегә салынган икән — аның урыны инде мәңгегә шунда булачак, бу урам — шәһәрнең киләчәк йөзендәге бер сызык, бу квартал — рәссамның зур бер картинасындагы төгәлләнгән фрагмент кебек. Түбән Кама каласын һәм аның промышленность комплексын төзүгә ике миллиард ярым акча тотылачак — легендар КамАЗныкыннан аз гына кимрәк. Бу шәһәргә әле ун гына яшь, аның биографиясендә әле беренче сәхифәләре генә язылган.

Биредә беренче булып күзгә ташлана торган нәрсә шул — һәр эш әйбәтләп, җиренә җиткереп эшләнә. Бик яхшы сыйфат бу — ашыгып эшләгәндә китә торган ялгышлыклар кабатланмый.

Ашыгу дигәннән, Түбән Кама шәһәре икенче бер яктан эшне кызу тота — бүтән шәһәрләр, хәтта кайбер атаклы башкалалар йөз еллар буена әкренләп, бөртекләп булдырып килгәнне бик аз вакыт эчендә эшләргә тырыша. Ул бүген үзенең эшендә ашкынуы белән, тагы да ачыграк әйтсәк, башкалар бер атна, бер ай эшләгәнне бер көн эчендә башкарып баруы белән мәшһүр.

Әйтик, менә төзелешләрдә була торган гадәти бер күренеш: төзүчеләр эшләрен төгәллиләр, эксплуатациячеләр әзер объектны кабул итеп алалар. Тантаналы бер бәйрәм ясыйлар, бер-берсенә чәчәкләр бирешәләр, яхшы теләкләр телиләр; төзүчеләр яңа хуҗаларга зур ачкыч тапшыралар, музыка уйнатып, кызыл тасманы кисәләр; объект сафка баса, эксплуатациячеләр аны эшләтә башлый.

Кайбер очракларда объект зур һәм катлаулы булмаганда, болай эшләү, бәлки, табигыйдыр һәм кирәктер дә, әмма хәзерге заманның бик катлаулы һәм төгәл технологик системалы гаять зур завод-фабрикаларын төзегәндә «туктап бер карап алу» өчен генә дә айлап вакыт китә, проектта билгеләнгән графикны үтәү еллар буена сузыла.

Түбән Кама комбинатының изопрен каучугы комплексында, җиһазны эшләтә башлаганчы, әллә ни рәвешле үрелеп-аралашып беткән мең ярым километр озынлыгындагы торбаларны тикшереп чыгарга, ун меңләгән тоташтырманы карарга, йөзләгән агрегатны, бөтен бер технологик линияләрне күздән кичерергә кирәк... Монтажчылар эшне «отлично»га башкарсалар да, производствоны энәсеннән-җебенә чаклы белүче эксплуатациячеләр объектны кабул итеп алсалар да һәм бу җиһаз инде элегрәк төзелгән заводларда әллә ничә тапкыр сыналган булса да, заводны иң кыска вакытта эшләтә башлаганда да беренче продуктны чыгарырга ярты ел срок бирелә. Аннан соң инде тагы да катлаулырак эшкә тотынырга — проектта билгеләнгән күләмгә ирешергә кирәк була.

Ә Түбән Кама комбинатында күп нәрсә үзенчә эшләнә: каучук ясау технологиясеннән башлап, урнаштырылган машиналарга чаклы, аларның моңарчы химия предприятиеләрендә тору-тормавына карамастан, һәркайсына профессиясен өр-яңадан үзләштерергә туры килә. Комбинатны эшләтә башлау, планлаштырылган эш күләмен тизрәк үзләштерүнең никадәр катлаулы бурыч икәнлеге күренеп тора. Мәсәлән, Тольяттида шушындый ук изопрен каучугы ясау производствосында проектта күрсәтелгән эш күләменә кызыл тасманы кискәннән соң утызынчы айда гына ирешкәннәр.

Бу утыз ай әле кызыл тасманы кискәннән соңгысы гына. Алданрак, төзүчеләр комбинатының бинасын торгызган, монтажчылар җиһазны җыйган, аппаратураны урнаштырган көннән башлап санасаң? Төзүчеләр объектка эш комиссиясен китерткәнне көтмәстән, эшне барышында ук кабул итә торырга — Түбән Кама комбинатында әнә шундый ысул белән эш итәләр: Корпусның бер башында

сварка очкыннары чәчрәп тора, анда монтажчылар эшли, икенче башында инде, безнең ил практикасында беренче тапкыр, аппаратчылар, слесарьлар, приборчылар, булачак цехларның башлыклары, тәҗрибәле белгечләр З. Ибраһимов, А. Даниленко һәм Ф. Третьяк җитәкчелегендә агрегатлап, блоклап, линияләп тикшерү эше алып баралар, аерым узелларны көйлиләр. Төзүчеләр белән эксплуатациячеләр, заказчы белән подрядчы гына булмыйча, үзләрен бер үк эш кешеләре кебек тоеп, комбинатны тизрәк эшләтә башлау, тизрәк продукция алу максатын күздә тоталар.

Эшнең иң кыен ягы — болай шактый катлаулы булуында гына түгел: бу очракта төзүчеләр белән эксплуатациячеләр арасындагы гадәттәге җаваплылык дигән нәрсә үзгәрә. Монда инде ялгышлар да, уңышлар да уртак. Алга карап эшләү, бүгенге зыянны гына түгел, иртәгәге файданы күздә тотып эшләү — бу каланың төп сыйфаты ул.

Әлбәттә, бер цех кеше җыеп, алардан әлегә файда алмыйча, ел буе хезмәт хакы түләү «шушы минут» файдасыннан гына караганда кулай эш түгел. Хезмәт хакы белән хезмәт җитештерүчәнлеге дәрәҗәсе арасындагы билгеләп куелган пропорцияләрне саклавы кыен, вакыт-вакыт аны бөтенләй саклап та булмый. Әгәр бүгенге зыянны гына түгел, иртәгәге файданы да исәпләсәң? Бүгенге оттырыш иртәгә барлык зыянны артыгы белән капларлык отыш булмасмы? Инде тәмам төзелеп беткән комбинатта меңләгән эшченең, продукция чыгармыйча, төзүчеләр эшләгәнне тикшереп ятулары, аннары проектта күрсәтелгән эш күләменә еллар буе эшләп кенә ирешүләре файдалымыни?..

Түбән Камалылар берәр производствоны эшләтә башлаганчы ук, төзү эшен тикшереп баручы гадәттәге инженер-кураторлардан тыш, барлык белгечләрне — технолог, машинист, аппаратчы һәм слесарьлар алып нәрсә оттылар? дигән сорауга иртәгә алачак файданы оттылар дияр идек.

Зур химия — халык хуҗалыгының иң яшь индустриясе, изопрен каучугы җитештерү — бүгенге заман химия производствосының иң яшь тармакларыннан. Гевея агачының бер яфрагы барлыкка килүдә дүрт миллионлап углерод двуокисе молекуласы катнаша, яфрак эчендәге бик катлаулы үзгәрешләр нәтиҗәсендә ак каучук сыекчасы — латекс барлыкка килә. Агач — серле бер химик реактор икән! Кешеләр тропиктагы тылсымлы агач яфракларында була торган әчке матдә үзгәрешләрен кабатлап эшләү серен тик моннан ун еллап әлек кенә ачалар, табигать каучугына бәрабәр торырлык каучук ясарга өйрәнәләр. Шуңа күрә әле бу эшнең белгечләре юк, бүген «белгечләр кирәк» дип игълан язып әлдең дә, кирәкле кешеләр иртәгә үк килеп тулар дип өметләнеп булмый. Моңарчы химия предприятиеләрендә эшләүчеләр полиэтилен ясаганнар, нефть аерганнар, пластмасса койганнар. Изопрен каучугын ясау — бөтенләй башка эш. Бу яңа производствога кеше никадәр алданрак килсә, бу эшне шулкадәр тизрәк, яхшырак үзләштерә. Төзүчеләр белән бергә эшләгән вакыт эчендә кешеләр катлаулы технологик системаларны нечкәләп белеп кенә калмаганнар, Тольяттига барып ай ярым-ике ай торып кайтырга, андагы комбинатта эшләп тәҗрибә алырга да өлгергәннәр, бүген үк эшкә керешергә әзер булып торганнар.

Серле химия дөньясында бер нәрсә дә мәңгелек түгел. Хәзер, зурзур завод-фабрикаларны ике-өч елда төзеп өлгертә торган бер заманда, төзелешне башлаганда иң әйбәт, иң кулай дип уйланган эшләрне дә ахырга таба төзәтергә, аныклый төшәргә туры килә. Төзүчеләр,

монтажчылар эзер проектлар белән бик яхшы төшенеп эш итәләр, ләкин технологиядәге, техникадагы үзгәрешләрне күзәтеп бара алмыйлар — монысы инде химиклар эше. Тольяттидагы химия комплексында (каучукны анда да Түбән Камадагы технология буенча алалар), кызыл тасманы кискәннән соң, комбинатны эшләтә башлаганчы ике йөзләп төзәтмә кертәләр. Түбән Кама комбинатында да андый үзгәртүләр булмый калмаган. Түбән Кама химиклары, илдә беренче буларак, изопренны зарарлы ацетилен катнашмаларыннан арындыру эшенә керешәләр — электролит водороды урынына алдан әзерләнгән метан-водород фракциясе кулланалар (чималда йөздән бер процент кына ацетилен булса да, каучук ясаудагы технологик цикл мең сәгатькә тоткарлана). Түбән Кама химиклары полимерзитны урталалау эшен дә ачык мәйданда гына башкаралар, моның өчен үзенә бер корпус төзүдән баш тарталар. Алар шулай ук шактый кыйммәтле бер «җайланма» эшлиләр — каучук ясалу процессына катнаша торган эреткечнең сыйфатын яңарту өчен махсус колонналар куялар.

Бу зур, катлаулы эшләрнең күбесе комбинат эшли башлаганчы башкарып чыгыла. Түбән Кама химикларының идеяләре теркәлгән барлык сызымнарны җыйсаң, 1400 битле зур бер том булыр иде. Шунсын да әйтеп китик, төзелештә «Гипрокаучук» кебек танылган институтның махсус проектчылар группасы эшли. Һәртөрле җитешсезлекләр эш барышында хәл ителә.

Технология турында күп сөйләдек бугай инде. Катлаулы, зур производствоны үзләштерү, аны эшләтә башлаудагы Түбән Кама эш системасының никадәр отышлы икәнлеген күрсәтә торган берничә дата һәм санга гына тукталып китәсе килә. Каучук өчен чимал әзерли торган изопрен-мономер комплексында февраль аеның соңгы көнендә «эшкә керешәләр». Уфада, яки Куйбышевта, Себердә шундый ук катлаулы производствоны төзегән тәҗрибәле белгечләр: «Көзгә кузгатып булса ярый инде»,— диләр. Иң беренче продуктны, сигезенче мартка багышлап, тәгәл бер атна эчендә җитештерәләр. Төп конвейерга чималны 1 октябрьда бирәләр — моңарчы мономер производствосы читкә эшли, продукциясен башка предприятиеләргә җибәреп тора,—18 октябрьда инде транспортер тасмасыннан Түбән Кама комбинатының беренче каучугы төшә.

Беренче продукция, беренче уңыш — үзенә күрә бер бәйрәм булса да, сөенергә әле иртәрәк икән. Химия индустриясендә тылсымлы үзгәрешләр дөньясының кеше ихтыярына буйсынмый торган үз законнары бар. Комбинатта беренче изопрен каучугын 18 октябрьга җитештерәләр. Проектта күрсәтелгән продукция күләмен машиналар 10 февральдә бирә башлый. Тагы дүрт ай вакыт уза — предприятие проектта күрсәтелгән продукция күләмен җитештерүгә кабат икенче тапкыр ирешә, тагы бер айдан соң — өченче тапкыр...

Түбән Кама химикларының каучукны иң гади схема буенча ясауларын әйткән идек инде. Изопрен каучугын гадәттә «демитилоксан аша» эшлиләр. Соңгысын формальдегидтан аералар, ә монысы үз нәүбәтендә техник спиртны эшкәртү нәтиҗәсендә алына, спирт исә... Бу эшнең һәр стадиясе — катлаулы технологик производство, һәр төрле аппаратлар, колонна, реакторлар комплексы. Шуларның бер генә стадиясеннән башка эшли алсаң да, зур отыш ясыйсың!

Түбән Каманың «каучук плантациясендә» бер мәйданда промыселлардан килгән углеводород фракциясен состав өлешләренә: бутан, пропан, изопентан, сыек һәм коры газга аералар; шулардан изопентанны алып, төсе белән дә, сыйфаты белән дә гевея агачының

суын хәтерләтә торган изопрен-мономер китереп чыгаралар, шул сыекчадан инде махсус аппаратларда каучук ясыйлар.

Хезмәтне яхшы оештырырга, аппаратлардан күбрәк продукт алырга мөмкинлек бирә торган бу гадилек шул ук вакытта бик зур пөхтәлек, микроскопик төгәллек тә сорый. Технологиядәге гадилек практикада файдага булуы да, бәла китерүе дә мөмкин.

Бер мичкә балны бер кашык деготь боза дигән афоризм бар. Аны кайвакыт киресенчә дә әйтәләр. Бер мичкә балны бер кашык деготь кенә бозмый, диләр.

Түбән Кама химикларының проектта билгеләнгән эш күләменә графиктагы сроктан бер ел алдарак ирешүен әйтеп киткән идек инде. Моның төп сере шул: бөтен эш процессын күзәтеп торучы аппаратчы һәм технологларның төгәллектә үз үлчәмнәре бар: бер мичкә балны бер тамчы деготь тә боза, диләр алар. Бер кашык түгел, бер тамчы!..

Гевея агачы тылсымының бөтен сере молекулаларны үзенчә кушуында гына. Меңләп, миллионлап алар — бу молекулалар. Химик реакторлар батареясендә бер үк чималдан уналты төрле продукт китереп чыгарырга мөмкин. Унбишенең сыйфаты табигый каучукныкыннан түбән, уналтынчысыныкы — яхшырак. Әнә шул иң кирәкле уналтынчы төрне ничек китереп чыгарырга соң?

Комбинатта бу технологик процессны ел буе эшкәртәләр, табигать эшен реактор эчендә төгәл кабатларга тырышалар. Каучук — бик четерекле нәрсә. Аның чималында чит кушылмалар ун меңнән бер процент кына булырга тиеш икән. Аз гына артык булдымы — полимерлашу процессы «утыра», бер сәгать урынына тәүлек буе дәвам итә, хәтта продукт брак булып та чыга.

Комбинатта беренче тапкыр проекттагы эш күләменә ирешкәннән соң, калган дүрт айны уңышсызлык чоры дип атарга кирәк. Машиналарның смена буена каучук бирмәгән чаклары була. Каучук ясый торган составның микроскопик төгәллегенә ирешкәннән соң гына эш җайга салына, продукция арткannан-арта бара.

Реакторларда чит кушылма ун меңнән бер процент кына булырга тиеш — Түбән Кама комбинатындагы оста аппаратчылар әнә шундый төгәллеккә ирешәләр. Бу безнең заман алхимиклары гади кешенең зиһене җитмәслек серле, катлаулы процесска идарә итәләр, молекулаларның тиешле кушылмасын китереп чыгаралар. Бер тонна чималда нибары бер генә грамм чит катнашма була.

Арттырып әйтү түгел: бары тик алмаз, энҗе шомартучылар гына мондый төгәллек белән эш итәләр. Аз гына ялгыштыңмы — эшләгән эшең әрәмгә китә. Мәсәлән, бөтен дөньяга билгеле «Бөек могол» алмазы белән мондый хәл булган диләр. Әлеге кыйммәтле ташның хуҗасы Есган шаһ Венециядән таш шомарту остасы Гортензий Боргисны китерткән. Бу кеше иренмәгән, килгән, хезмәтем өчен зур бүләк алырмын дип өметләнгән, күрәсең, ләкин алмазны бозган! Шаһ моның өчен аңардан 1000 рупий акча түләткән (ул заманда бер мең рупий бик зур акча булган), останы тәмам хәерче иткән.

Алмаз белән бик сирәк кешеләр генә эш итә, алар тары бөртеге чаклы гына таш кисәген бик нечкәләп шомартып утыралар. Ә бирәдә йөзләгән, меңләгән кешенең осталыгы кирәк, йөзләгән тонна продукция белән эш итәләр. Предприятиенең бер тәүлектә ясаган брагын түләр өчен дөньядагы барлык ювелирлар байлыгы да җитмәс иде.

Без саннар белән юри эш итмәскә тырыштык, аларны азакка калдырдык. Түбән Кама химикларына проектта билгеләнгән эш кү-

ләменә ирешүдәге үз системалары, үз ысуллары менә нинди файда биргән: каучук ясау буенча бишьеллыкның беренче елына билгеләнгән производство программасы 42 көнгә алданрак үтәлгән. Бер эшченең эшләп чыгаруы 1,6 мәртәбә арткан, предприятиенең табышы 9,2 миллион сумнан 19 миллионга җиткән. Бу акчаның бер миллион сумлабы материаль кызыксындыру фондына күчерелгән...

Бик мәгънәле саннар бит! Аннан да бигрәк әле шул — тупланган тәҗрибәнең киләчәк өчен бик зур әһәмияте бар. Кама буенда КамАЗ автомобильләренә күпчәк өлгертеп торачак шин заводы корпуслары калкып килә, каучук ясый торган тагы да куәтлерәк икенче чират сафка басачак, полистирол, этилен, дивинил чыгара башлаячаклар. Бу бишьеллыкта комбинатның продукциясе ун тапкыр артырга тиеш.

Тупланган тәҗрибә, әлбәттә, яңа производстволарда бик кирәк булачак. Моннан тыш, конкрет шартларны, үзенчәлекләрне исәпкә алып эш иткәндә бу тәҗрибәнең төзелеп килгән башка объектларда да бик файдалы булуы мөмкин.

Түбән Кама каласы кебек бөтенләе белән бер эшкә — химия эшенә бирелгән башка берәр шәһәр бар микән?

Биредә бөтен кеше: сизгер приборлар белән эш итүче аппаратчылар да, авыруларны дәвалаучы врачлар да, бала-чагага белем бирүче укытучылар да, повар, тегүче, сатучылар да — барысы да химик. Эшенең зурлыгы — кечкенәлегенә карамастан, химия каласына, аның кешеләренә алар барысы да кирәк.

Шуңа күрә Я. Хәйруллин бригадасындагы оста монтажчылар да (томанлы юеш бер көнне алар 60 метр биеклегендә, 400 тонна авырлыгындагы колоннаны болытлар астына күтәреп, анкерлы болтлар белән беркетеп куйганнар), тулы реакторлар янында авыр вахта хезмәтен үтәүче С. Гатауллин, А. Котов, Р. Имаев кебек төгәл аппаратчылар да, модалы чәч конкурсында җиңеп чыккан О. Мингушева, Г. Рыбаковалар һәм комбинатның чәчәк үстерүчеләре дә бер үк дәрәҗәдә хөрмәт ителәләр.

Чәчәкләрне аерым әйтеп китәсе килә. Комбинатның беренче продукциясе оранжереядә үстерелгән чәчәкләр була. Шәһәр үзе әле төзүчеләрнең хыялында гына гәүдәләнсә, энтузиастлар инде, шулар арасында иң ялкынланып йөрүче, комбинатның генеральный директоры Николай Васильевич Лемаев, химия производствосыннан бик ерак торган бер эшкә — чәчәк үстерүгә өйрәнәләр. Тышта февраль бураннары котыра, һавада самолетлар оча алмый, ә болар комбинат теплицаларында чәчәк үстерәләр. Балконга куяр өчен дә, килгән кунакларга бүләк итү өчен дә түгел, бәлки бөтен шәһәрне, аның урамнарын, халык яши торган квартираларын бизәү өчен. Махсус ясалган унҗиде мең ящикта өч миллионлап чәчкә үстерәләр.

Түбән Кама каласы елның һәр фасылында да матур. Кыш көне мондагы карны завод морҗаларыннан чыккан корым каралтмый, чөнки андый морҗалар да, чит-ят исләр дә юк монда. Урамнарга ике рестораннан һәм дистәләгән эшче ашханәләреннән тәмле ит исе генә тарала. Яз көне шәһәрнең бер ягында нарат урманы яшелләнеп тора, икенче ягында каланың үзен комбинат корпусларыннан биш километр киңлегендәге полосасы белән аерып торган алма бакчалары чәчәк атып утыра. Июль, август, сентябрь айларында тагы да ямьләнә ул. Җәй башындагы чәчәкләр әле шиңеп-корып та җитмәгән, бу чәчкә келәменә инде георгин, гладиолус, астра бизәкләре өстәлә башлаган.

Кама буенда без май азакларында булган идек. Алмагачлар инде чәчәкләрен атып бетеп килә. Каланың урамнарында эш кайный:

чактэп балалары, хатын-кыз, вахтадан бушаган ирлэр газоннарга чэчэк утырталар. Һэр карыш буш җиргэ берэмлэп-берэмлэп утырталар, шундук су да сибэлэр иде. Без шэһэр буйлап йөрдек, бу каланың йорт артыннан йорт салып, квартал артыннан квартал үстереп, куэтле зур елгага таба килэ барганын, халкының ничек яшэгэнен, эшлэгэнен, ял иткэнен күрдек, аның кызу эш темпын, зур исэпле, кыю рикерле булуын күреп сокландык.

«Смелость города берет» дигэн җыр бар. Ул җырны тау илендэге Чуректа да, бала чагыбызда безнең хыялдан чыкмаган Комсомольск шэһэре янындагы Солнечный поселогында да җырлыйлар. Э ул җыр Түбэн Кама каласында туган. Башта аның конкрет бу шэһэрне телгэ алган мондый бер куплеты була:

Может, где-то на Нижней Каме
Вспомнит кто-нибудь стариков,
Кто закладывал первый камень
Нестареющих городов.

Композитор Александра Пахмутова Түбэн Кама яшьлэренэ язган хатында,— бу хат шэһэр газетасында басылып та чыкты,— җыр авторларының җырны аерым бер шэһэргэ генэ багышларга телэмэүлэрен әйткэн, андый җыр барлык төзүчелэргэ, Ватаныбызның яңа калаларын — Түбэн Каманың яшьтэшлэрен салучыларга багышлансын, дигэн.

## Валентина Гудкова

# ГОМЕР БУЕ УКЫТУЧЫ

Урамнан озын буйлы бер кеше бара. Таякка таянган. Бер аягы бөгелми. Мәктәп ишеге төбенә килеп җиткәч, ул кинәт туктап калды.

Малайлар малайлар инде. Әнә алар өелешеп ишектән чыктылар да, чыр-чу килеп, бер-берсен портфельләре, ранецлары белән тукмый башладылар. Ә берсе — чип-чиста ак күлмәк кигәне — муенына таккан ал галстугын чишеп алды да йомарлап чалбар кесәсенә тыкты. Ул да булмады, портфелен үзеннән өскә ыргытты да, төшеп җитәр-җитмәс, аягы белән тибеп җибәрде. Портфель янда торган малайның аягына килеп тиде. Китте дөмбәсләшү...

Әлеге кеше таягын кузгатты, исән аягын да кузгатырга теләгән иде, протезлы аягы сызлап, чыраен сытты... Юк, бу кешенең малайлар чыр-чу килгәнгә, үзара дөмбәсләшкәнгә ачуы килмәде, әлеге малайның галстугын йомарлап кесәсенә тыгуына кәефе кырылды аның.

Квартирасы ерак түгел иде. Кайтып керде дә хатынына:

— Кара әле, Зәйнәп, күргәнең бармы синең пионер галстугын кулъяулык шикелле кесәгә йомарлап салганны,— диде.— Зу бит, беләсеңме...

Зәйнәп апа иренең хисләрен аңлады. Ире әйтеп бетермәсә дә: без бит андый пионерлар түгел идек, малайда романтика юк, киләчәккә омтылу юк, дөньяга үз карашы юк, дигән мәгънәне аңлата иде аның борчулы карашы.

Шулай да урамда ни күргәнен ире аңа сөйләп бирде. Зәйнәп апа аның сөйләгәннәре белән килеште, чөнки ул яхшы белә: аның Мансурына пионер галстугы иң изге әйбер булган.

...1923 елда, унбер яшьлек вакытында, пионерга керергә бик күп хыялланган ул. Бу вакытта мәктәпләрдә пионер отрядлары булмаган. Балалар әти-әниләре эшләгән урыннарда гына пионерга языла алганнар. Ә Мансурның әтисе дә, әнисе дә юк.

Әтисе, Ибраһим солдат, беренче бөтендөнья сугышында башын салган. Мансурның һәм аның энесе Мәсгутьнең «әти» сүзен әйткәннәре дә юк. Әниләре Рабига апа аларның икесен дә үзе үстерә — байларның идәннәрен, керләрен юа, ә инде революция булып, гражданнар сугышы башлангач, кызылармеецлар өчен кием тегә.

1921 елгы ачлык. Алабута яки имән чикләвеге онынннан пешерелгән күмәч ашата улларына Рабига. Әмма үзенең сәламәтлеге күпкә бармый. 1922 елның башында Мансур белән Мәсгуть бөтенләй ятим калалар. Мансурны Казандагы туганнары тәрбиягә ала, Мәсгутьне энисенең ахирәт кызы авылга алып китә.

Мансурны башта татарча укыталар. Аннары рус мәктәбенә бирәләр. Аның белән бергә укучыларның күбесе ал галстук тагып йөри. Мансурның да пионерга бик керәсе килә. Әмма аның әти-әнисе юк. Алай гына түгел, туганнары сәүдә белән шөгыльләнә, аларга һәр кызыл нәрсә дошман.

Классташлар ярдәм итә аңа. Менә ул пионер антын бирә:

— Мин, Советлар Союзының яшь пионеры Мансур Абдрахманов, иптәшләрем алдында үземнең Совет Ватанымны кайнар яратырга, Коммунистлар партиясе өйрәткәнчә яшәргә, укырга һәм көрәшергә тантаналы рәвештә ант итәм,— ди ул башка пионерлар белән бергә. Ә зур күзләреннән шатлык, горурлык очкыннары бөркелә. Хәзер ул да, иптәшләре кебек үк, пионер. Ә өйдә галстукны күрсәтергә, үзенең пионер икәнеңне әйтергә һич тә ярамый. Җитмәсә, апа да, абый да биш вакыт намаз калдырмыйлар. Ә унбер яшьлек Мансурны аллasызлар оешмасына язганнар...

Ул елларда пионерлар шундый эшләр дә башкарганнар: мәсәлән, Куйбышев мәйданына трамвай туктый. Тукталышта — пионерлар. Кулларында — кружка. Күкрәкләрендә — «Забастовка ясаучы Англия эшчеләренә ярдәм» дигән язу эленгән. Алар арасында, әлбәттә, Мансур да бар.

Кыскасы, иң актив пионерларның берсе була Мансур. Алай гына түгел, «һәрвакыт әзер!» — дигән сүзләр аның өчен девиз булып әверелә. Менә ул, унбиш яшьлек егет, каникул вакытларында — Төзелеш мәйданында. Хәзер бөтен дөньяга атаклы мех комбинаты төзелешендә аның да өлеше бар. Ул анда бетон коючы булып эшләгән.

Казан шәһәренең В. И. Ленин исемендәге дүртенче мәктәбен Мансур унҗиде яшендә тәмамлый. Чыгарылыш кичәсен тантаналы итеп оркестр белән үткәрәләр алар. Мансур Абдрахмановны берничә иптәше белән бергә президиумга утырталар. Һәм иң яхшы укучылар рәтеннән ун көнлек курска җибәрәләр. Комсомол Үзәк Комитеты чакыруы буенча, ул культармеец булып әверелә.

Беренче май районы үзәгендә аңа:

— Культура эшләре белән укытучы буларак шөгыльләнерсең,— диләр.— Безгә укытучылар кирәк. Аны Яңа Ибрай авылына җибәрәләр. Зур авыл бу — 800 йорты бар. Укучылар да күп. Ә мәктәп кечкенә, бары башлангыч мәктәп.

Менә беренче дәрес. Алтмыш ике пар күз яшь укытучыга текәлгән. Буйлары белән дүртенче класста булырлыклары да бар, беренче класска килгәннәре дә күп. Соңыннан директор уңайсызланып кына серне чишә, бер класста берничә ел утырып калучыларны җыйганнар икән Мансур классына.

— Нормаль балалар түгелме әллә алар? Авыруларммы?..

— Курыкма, нормаль балалар. Алар белән шөгыльләнергә кеше булмады, ә ата-аналары укый-яза белми...

Унҗиде яшьлек укытучы директорга бүтән сорау биреп тормый, эшкә керешә. Ярдәм көтәр урын юк, баш тартырга да хакы юк. Җитмәсә, бирeдә татар мәктәбе, ә ул рус мәктәбендә укыган... Язу яңалифкә күчкән вакыт. Үзе дә укый, балаларны да укыта.

— Кайчан ял итә икән соң ул? — дип гаҗәпләнә авыл халкы бу яшь мөгаллимгә.

Чыннан да ял бик аз эләгә аңа. Яшьлек дәрте һәм спорт аңа кыенлыкларны җиңәргә ярдәм итә. Чирмешән елгасын боз каплау белән балаларны үзләре агачтан ясаган «тимераякта» шуарга өйрәтә. Бу хәл аны балалар белән бик якынайта, дусландыра. Аны бирелеп, күңел салып тыңлыйлар. Балаларның белеме күзгә күренеп үсә. Һәм, ниһаять, алтмыш ике баланың барысы да икенче класска күчү турында табель ала.

Уку елы тәмамлану белән аны Казанга чакырып, иптәш егетләре килеп җитә.
— Юк, егетләр, Казанга кайтмыйм мин,— ди Мансур аларга.
Культармеец егетләр гаҗәпләнеп бер-берсенә карашалар. Ничек инде? Аларны бер генә елга районга җибәргәннәр иде бит. Казанда аларны урта мәктәпне тәмамлау турында таныклык көтә.
— Мәктәптән хәзер һич тә китә алмыйм, егетләр. Безнең мәктәпне киңәйтәләр. Миңа бишенче классны бирәләр,— ди Мансур.
Шул вакыт бүлмәгә зифа гәүдәле яшь кенә бер кыз килеп керә.
— Таныш булыгыз, егетләр, минем иптәшем Зәйнәп.
— Күптән шулай диләр аны,— дип көлешәләр егетләр.— Димәк, авылга тамыр җибәргәнсең.
Яшь кияү белән яшь киленгә каникул вакытында да ял итәргә туры килми. Мансур яңа мәктәп салу эше белән йөри башлый, районда аның тәкъдимен хуплыйлар. Яңа уку елын яңа мәктәптә башлыйлар. Шунда ук — интернат. Анда 35 бала яши.
Колхоз оешкан еллар. Мансурның көен дәфтәрендә шундый юллар саклана. «Сыйнфый көрәш. Колхоз төзелешенең беренче җитәкчеләре: Федор Беркутов, Шәрифулла Хәмидуллин, комсомолка Фатыйма Газизова, Филипп Пушкарев кулаклар кулыннан һәлак булды».
— Колхозыгыз таралам ы, мөгаллим? — дип көлә кулаклар, Мансурны урамда очратып.
— Иртә шатланасыз. Таралмас, үсәр,— ди Мансур, иренен кысып.
Һәм тырышлык бушка китми. Колхоз көннән-көн ныгый. Мәктәпкә дә 25 гектар җир бүлеп бирелә. Аны укучылар үз көчләре белән эшкәртәләр. Уңышны да үзләре җыеп алалар. Өстәвенә, башак җыеп колхозга да ярдәм итәләр.
«Балык бистәсе районында куш йодрык тикле помидорлар үстерәләр икән»,— дип ишетә Мансур. Барып карый. Дөрес. Тәҗрибәләрен өйрәнеп кайта. Чыннан да бик хикмәтле. Помидор үсентеләрен камыштан үргән матылар белән каплыйлар, ә матының бер читен канаудагы суга батыралар. Кырау да сукмый, дым да җитәрлек. Мәктәп бакчасында август аенда эре-эре помидорлар өлгерә. Тирә-күрше авыллардан да килеп карыйлар. «Шул рәвешчә карбыз үстереп карасак?..» Әйткән сүз — аткан ук. Яңа уку елы алдыннан укучылар карбыз төялгән йөкләр белән базарга юнәләләр.
Базар халкы гаҗәпләнеп йөкләрне сырып ала.
— Кайдан килгән карбыз бу? Әстерханнан дисәң, безгә су юлы ерак инде?..
— Үзебез үстердек,— ди озын буйлы егет горурланып.— Яңа Ибрай мәктәбеннән без...
«Үсәр» колхозы 1930 елда ук республиканың алдынгы хуҗалыклары рәтенә баса. Һәм шул елны социалистик кырлар ударникларының Татарстан съездына делегат итеп колхозчылар мәктәп директоры Мансур Абдрахмановны да сайлыйлар.
Цирк бинасына җыелган ударниклар йотлыгып Бөтенсоюз старостасы Михаил Иванович Калинин речен тыңлыйлар. Кара чәчле, озын буйлы егет, укытучы гадәте буенча, аның һәр сүзен блокнотына язып барырга тырыша. Ә утырышлардан соң Черек күл бакчасында оештырылган күргәзмәне карап йөри. Дранча ясый торган станок янында озак кына басып тора ул.
— Үзебездә булдырасы иде шундый станокны,— дип уйлана ул.— Илья Дмитриевич шатланыр иде.
Хөрмәт итә бу кешене Мансур. Кызыл агач остасы Илья Куреевны директор күрше авылдан чакырып китерә. Менә ул хәзер укучы-

ларны агач эшләренә өйрәтә. Укучылар аның җитәкчелегендә мәктәпкә кирәк булган барлык мебельне ясадылар. Бу станокның да мәктәпкә кирәге бар. Һәм Мансур, төрле оешмаларга йөреп, бу станокны мәктәпкә кайтару чарасын да күрә.

— Ну, Мансур Ибраһимович, рәхмәт сиңа,— дип каршы ала аны Илья Дмитриевич.— Эшләр рәтләнә безнең болай булгач...

Алтын куллы, олы йөрәкле бу кеше 1941 елга кадәр мәктәптә эшли. Бөек Ватан сугышыннан да Яңа Ибрай авылына кайта. Авыл кешеләренә дә, мәктәп өчен дә бик кирәкле кеше булып кала бирә. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр Мансур Абдрахманов белән дуслыгын өзми...

Ударниклар съездыннан соң Абдрахмановлар семьясы Яңа Ибрай авылыннан китәргә мәҗбүр булалар. Мансур Кызыл Армия сафларына чакырыла, ә Зәйнәп халык мәгарифе бүлегендә эшли башлый.

Мәктәп елларында Мансур математика фәннәре белән нык кызыксына. Бу фәннәр буенча белеме программа күләменнән дә ашып китә. Шуңа күрә контроль эшләр вакытында классташы Рәшит Нәҗметдинов белән икесенә укытучы:

— Барыгыз, яраткан шахматыгызны уйнагыз. Биредә сез комачаулыйсыз гына,— дип, дәрестән үк чыгарып җибәрә торган була.

Яңа Ибрай мәктәбендә дә ул математика укыта. Шулай да аны җәмгыять фәннәре буенча курсларда укытып кайтаралар. Армиядә хезмәт иткәндә Мансур тарихчы булу турында хыяллана.

...1936 елның җәе. Арча кырындагы матур бинаның ачык тәрәзәләреннән юкә яфраклары исе бөркелә. Аудитория эчендә институтка керергә теләүчеләр бик тырышып инша язалар. Араларында зур кара күзле, җитди карашлы, киң җилкәле, төз гәүдәле (оста спортчы икәне әллә кайдан күренә) бер егет тә бар. Яше белән дә ул башкалардан аерылып тора — аның иптәшләре инде күптән кесәләрендә югары белемгә ия булулары турында диплом йөртәләр.

Вестибюльдә дүрт күз белән Зәйнәбе көтеп тора. Мансурның тыныч йөзеннән күренә: беренче имтиханны уңышлы тапшырган!

— Әйдә Казанкага! Көн бик эссе...

...Институтның соңгы курсы. Әмма дәүләт имтиханнарына хәтле зур тормыш сынавын үтәсе бар икән әле. Институтның иң яхшы чаңгычылары үзләре теләп ак финнар белән сугышка китәләр...

...Үзәк культура һәм ял паркы. Профсоюзларның республика кроссы бара. Мең метрга старт. Иң оста җиңел атлетлар соңгы әйләнештә. Финиш тасмасын Мансур иң беренче булып өзә. Курсташлары котлыйлар, фотога төшерәләр, кочаклыйлар, һавага чөяләр. Институт директоры да шунда. Ул да килеп котлый.

— Әйдә, Мансур, сыра эчәбез...

Директор булып директор спортчыны эчәргә чакыра... Мансур гаҗәпләнеп күзләрен аңа текн. Директорның йөзе каралып киткән, күзләр кайгылы.

— Сугыш, Мансур. Фашистлар басып кергән. Әле яңа гына радиодан тапшырдылар. Институтка ашыгыйк, халык митингка җыела...

Беренче булып партбюро секретаре, институт китапханәсе директоры Мансур Абдрахманов фронтка китәргә языла. Бергә ак финнарга каршы сугышкан чаңгычылар да аңа иярә.

Куйбышев шәһәрендә хәрби-политик училищеда укыганда Мансур элеккеге комсомол газетасы редакторы Саттаров белән дуслаша. Озак еллар үткәч кенә ул дусты Рәхим Саттарның, герой-шагыйрь Муса Җәлил оештырган яшерен патриотик оешманың актив члены булганы хәлендә, антына тугрылыклы калып, һәлак булуын ишетә.

Еллар үткәч, һәлак булган дустының улы — Иль Саттаров профессор Абдрахмановның шәкерте булып әверелә.

Абдрахмановның үзе өчен сугыш 1943 елның 4 июлендә тәмамлана. Белгород шәһәрен фашистлардан азат итү хөрмәтенә Мәскәүдә салют яңгыраганда пулемет ротасы командиры Мансур Абдрахманов команда пунктына чыга. Күзенә бинокль китерергә дә өлгерми, якында гына мина төшеп шартлый. Өлкән лейтенант ерак Әрмәнстан шәһәрләренең берсенә госпитальгә китерелгәч кенә аңына килә. Төрле госпитальләрдә сигез ай дәвалана ул. Казанга култык таякларына таянып кайтып керә...

...Мансур Абдрахмановны мин беренче тапкыр 1946 елда күрдем. Ул вакытта университетның барлык факультетлары өчен икенче курс студентларына марксизм-ленинизм буенча лекцияне Мансур Ибраһимович Актлар залында укый иде. Зур зал тулы студентлар, кырыс йөзле, җитди зур күзле, ябык гәүдәле бу галим ишектә күренү белән, тынып кала торганнар иде. Кереш сүзгә вакыт әрәм итмәстән, фәннең асылын студентларга сөйләргә керешә. Ике сәгать лекция укыганнан соң, еш кына аның йөзе агара, кафедра урнашкан сәхнә баскычыннан аксый-аксый акрын гына төшә. Кай көннәрдә лекцияне башка укытучы укый. Сорамасак та беләбез: димәк, Мансур Ибраһимовичның яралы аягы тагын борчый башлаган.

Без өченче курста укыганда Мансур Абдрахманов «Крестьяннар хәрәкәтен оештыруда РСДРП Казан комитетының роле» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклады. Хәзерге студентлар философия фәннәре докторы, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, профессор Мансур Абдрахмановның лекциясен генә тыңлап калмыйлар, ә ул язган «Диалектик материализм» дәреслеге буенча имтиханнарга әзерләнәләр.

Күп еллар дәвамында Мансур Ибраһимович университетның фәнни эшләр буенча проректоры булып эшләде, бик күп фәнни тикшеренүләргә җитәкчелек итте. Бүлмәсендә үзен генә очрату кыен аны. Рәсми эш буенча гына түгел, шәхси эшләрендә киңәш сорап та керәләр аның янына. Чөнки ул Татарстан Верховный Советы председателе.

Шәкертләре дә күп аның. Мансур Абдрахманов җитәкләгән философия кафедрасында хәзер унөч аспирант. Виктор Комаров аның җитәкчелегендә докторлык диссертациясен тәмамлый. Доцент Марат Садыйковның да хезмәте тәмамлану алдында. Кыскасы, аның шәкертләре Казанның һәрбер югары уку йортында диярлек бар. Аларның инде күбесе үзләре кафедра җитәкли.

Шәкертләре өчен Мансур Абдрахманов зур галим, остаз гына түгел, кеше буларак та үрнәк.

Үзенең коммунистик бурычыңа тугрылык. Үзеңә тапшырылган эшкә җаваплы караш. Кешеләргә карата игътибарлылык. Болар — матур сүзләр генә түгел. Ул сыйфатлар барысы да Мансур Ибраһимович характерына тулысынча хас. Менә шуңа күрә дә 1972 елның гыйнварында үткәрелгән аның алтмыш яшь тулу юбилее шәкертләре, дус-ишләре, хезмәттәшләре өчен зур бәйрәм булды.

Профессорлар, министрлар, зур предприятие җитәкчеләре котлады аны. Менә трибунага колхоз председателе күтәрелде. Әйе, Яңа Ибрай авылында үзе оештырган «Үсәр» колхозы кешеләре дә онытмаган аны. Колхозның исеме җисеменә бик туры килгән — ныгыган, зурайган ул. Яңа мәктәп — ике катлы таш мәктәп салганнар...

Юбилейдан соң берничә көн үткәч, мин Мансур Ибраһимовичның өендә булдым. Өстендә спортчылар костюмы, күзлеген салып куйган. Бу кыяфәтендә ул яшәреп киткәндәй күренде. Фоторәсемнәр карап утырабыз. Еллар үтүдән алар инде саргая төшкәннәр.

Менә Мансур авыл малайлары, кызлары арасында. Куе кара чәчләр, кыю караш, калын кара каш. Әле балалык сизелеп торган калын иреннәр кысылган. Ә менә бу рәсемдә ул салдырган мәктәп бинасы.

— Ягымлы йөз, иркә карашлы бу чибәр кыз кем соң?

— Зәйнәп ул,— ди Мансур Ибраһимович.— Туй алдыннан төшкән идек.

Зәйнәп апа көлә. Яшьлеген искә төшерү аңа да күңелле.

Инде олы яшьтәге Мансур Ибраһимовичка һәм Зәйнәп апага карыйм да эчтән уйлап куям: кайгыларны һәм шатлыкларны уртаклашып, гомер буена бер-береңә тугры булып калу нинди бәхет ул! — дим.

Кайчандыр алар мәктәп чарлагындагы бер кечкенә генә бүлмәдә тормыш башлаганнар. Кечкенә генә киштәдә балаларны укыту өчен кирәкле китаплар гына булган. Ә хәзер менә Мансур Ибраһимовичның зур бүлмәсенең стеналары китаплар белән тулы. Бу зур китапханә Яңа Ибрай авылында укытканда колхоз бүләк итеп биргән китаплардан — В. И. Ленин әсәрләре томнарыннан башланган.

Аның кайсы гына рәсемен карама — барысында да ул китап белән. Китап аның өчен бик кадерле. Шуның өчен дә шул ул, госпиталь өчен педагогия институтын бушатырга кирәк булгач, бүгенгеләргә сугышка китәргә торганда, берничә көн эчендә институт китапханәсен университет китапханәсенә тапшырып өлгерә.

— Бер генә китап та югалмады,— ди ул горурланып.

Икенче көнне мин Мансур Ибраһимовичны консерваториянең концерт залында күрдем. Чехословакия белгечләре куйган органны тантаналы ачуга багышланган җыелышка килгән иде ул.

Менә сәхнәгә ал галстук таккан пионерлар чыгып басты. Алар җыр башладылар:

Кузгал, урн, ләгънәт ителгән
Коллар һәм ачлар доньясы.
Кайный ачу белән безнең кан,
Соңгы сугышка ул ярсый.

Беренче куплетны җырлап бетергәч, хормейстер залга борылырга мәҗбүр булды. Залдагы кешеләр барысы да аяк өсте баскан иде. Партия гимнының икенче куплетын XXIV съезд делегаты Мансур Абдрахманов башлады. Аңа бөтен зал кушылды. Пионер антына гомере буена тугрылыклы булып калу, комсомол, партия эшенә чын күңелдән бирелгәнлек җыры булып яңгырады бу гимн.

М. ХӘМИТОВ тәрҗемәсе.

## Марат Әмирханов

# ШАХТА ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

## Донбасс кайдан башлана?

„Лисичанскуголь» тресты бинасының купьеллык акацияләр белән уратылып алынган чәчәклегендә бронзадан коелган мәһабәт һәйкәл тора. Пьедесталда баһадир сынлы рус кешесе. Аның бер кулында ташкүмер кәса, икенчесендә — кәйлә. «Донбасста ташкүмер ятмаларын беренче ачучы Григорий Капустин» дигән сүзләр язылган һәйкәл ташына.

Петр I нең замандашы Г. Капустин Россиянең көньягына файдалы казылмалар эзләү буенча ике мәртәбә экспедиция оештырган. Ниһаять, ул 1724 елны хәзерге Лисичанск шәһәре территориясендә, Төньяк Донец елгасы буендагы Төлке чокыры дип аталган урында, 114 метр егәрлекле ташкүмер пластына юлыга. Әмма крепостной крестьян улы Г. Капустинның бу бөек ачышы чит ил белгечләренең, Петербург чиновникларының җитди каршылыгына очрый. 70 ел үткәч кенә биредә беренче шахта төзелә. Бу шахта урынында хәзер мемориаль такта куелган.

Даны бөтен дөньяга таралган Донбасс нәкъ менә шушыннан башлана да инде.

Хәзерге Донбасс, мәгълүм булганча, берничә өлкәне берләштерә. Ворошиловград өлкәсе шуларның берсе. Ворошиловград шахтерлары илебез кочегаркасының танылган осталары. Алар ел саен 75 миллион тонна «кояш ташы» чыгаралар. Бу — СССРда табыла торган һәр сигезенче тонна ташкүмер дигән сүз. Биредә ташкүмер ятмаларын үзләштерү предприятиеләреннән тыш химия, металлургия, машина төзелеше промышленносте дә нык алга киткән.

Безнең группада шагыйрьләр Ш. Галиев, Р. Харис, язучы Ш. Рәкыйпов, артистлардан Н. Теркулова, И. Галимов һәм украин язучылары Ф. Вольный, И. Назовой, М. Малатуха йөрде. Маршрутның шушындый тарихи якка туры килүе белән чиксез шат идек. Лисичанскида беренче очрашу «Черноморка» шахтасында булды. Элек-электән Кара диңгез флотилиясен ягулык белән тәэмин итеп торган бу шахта коллективы хезмәт традицияләренә бик бай. Тугызынчы бишьеллыкның беренче елында коллектив планнан тыш 5000 тонна күмер чыгарган. Шахта начальнигы Николай Галедко безне предприятиенең данлы узганы, матур киләчәге белән таныштырды.

Такыялы украин кызы милли бизәкле подноска салып делегациягә традицион ипи-тоз тапшырды. Ренат Харис калачның бер кисәген сындырып алды һәм тозга манып авызына капты.

— Иң зур сый — ипи,— диде ул,— ипидән өстен булып булмый. Бу ритуал шахтерлар күңеленә хуш килде. Елмаеша-елмаеша озак

итеп кул чаптылар. Аннан соң өлкән шахтер Трофим Гандибула сүз алды:

— Язучы хезмәте белән шахтер хезмәте арасында уртаклык зур дияр идем мин. Ни өчен дисәң, без, шахтерлар, җир астында тылсымлы ташка әверелгән кояш ташын кешеләргә бүләк итәбез. Сез, язучылар, безнең йөрәкләргә кояш нурларыдай җылы хисләр өстисез.

Кунаклардан беренче булып Тукай премиясе лауреаты Шәүкәт Галиев чыгыш ясады. Залга тигез агым булып Шәүкәт юморы таралды. Кешеләрне күзәтәм. Ихлас күңелдән тыңлыйлар.

Шахтерларга Н. Теркулованың җырлары да бик ошады. Наҗия — киң диапазонлы, бай репертуарлы җырчы. Ул украин, рус халык җырларын да оста башкара. Әмма халык җыры «Төймә»не Наҗия аеруча яратып җырлый. Күп очрашуларда башкарды ул аны. Һәр аудиториядә җырның кушымчасына тыңлаучылар алкышлар белән кушылдылар.

Донбасс үзәге Лисичанск күмердән бигрәк техник пыяла, химия заводлары белән дан тота. Пыяла заводының титул битенә 150 төрле пыяла язылган. Анда көзге пыяласы да, лак белән каплатылган армирлы пыяла да, телевизор, автомобиль пыялалары да бар. Завод продукциясенең хәтсез өлеше экспортка китә. Адреслары: Болгария, ГДР, Польша, АКШ, Канада.

Завод директоры Э. Энгвер коллектив ирешкән уңышлар турында сөйләгәндә шундый мисал китерде. М. В. Ломоносов пыяладан 310 төстә эретмә койган. Завод алдынгылары хәзер аларны 526 га җиткергәннәр. Бу — Социалистик Хезмәт Герое А. Новиков, А. Лавренко, Г. Рафиков, И. Межинский кебек хезмәт алдынгыларының иҗади хезмәт җимеше. Татар егете Г. Рафиков 10 елдан артык эшли заводта. Аны быел цех коммунистлары партия оешмасы секретаре итеп сайлаганнар. Фидакарь хезмәтләре белән шөһрәт казанган татар егетләре заводта шактый. Пыяла өрү мастеры Г. Галимовны «алтын куллы» дип йөртәләр бирелә.

Лисичанскилылар күптән түгел шәһәрнең 250 еллыгын бәйрәм иткәннәр. Ул элек вак поселокларга бүлгәләнгән булган. Совет власте елларында бу поселоклар үскәннәр, бер-берсе белән кушылганнар, 140 мең кеше яши торган хәзерге заман шәһәре хасил булган.

Пыяла заводы төзелгән поселокта шахтерлар җырчысы шагыйрь В. Сосюра туган. Халык үз җырчысын ихтирам итә, ярата. Заводның культура сарае В. Сосюра исемен йөртә. Анда шагыйрьнең музее бар. Паркта шагыйрьгә мәрмәр һәйкәл куелган. Паркның яшел чирәм белән түшәлгән кайсы гына сукмагына килеп чыксаң да, ул сине һәйкәл янына алып килә. Минемчә, шагыйрьгә булган ихтирамның иң олы чагылышы бу. Чөнки халык сукмагы — йөрәк сукмагы.

Лисичанскида тагын бер музей оешып килә. Монысы — легендар полководец К. Е. Ворошилов туган йортта.

Саный китсәң, Донбасс, үзәк Лисичанскида күңелләрне дулкынландырырлык вакыйгалар, исемнәре Ватан тарихына кергән кешеләр күп булган.

## Буыннар эстафетасы дәвам итә

Украина язучысы Вениамин Мальцев әле кайчан гына Донбассны «Бөтенләй урмансыз, ялангач, кырыс дала» дип сурәтләгән иде. Хәзер бу эпитетлар, мөгаен, бүгенге Донбассны тасвирлау өчен яраксыздыр. Ворошиловград өлкәсенең аркылысын-буен иңләдек

диярлек. Әмма кая гына барсак та, яшеллеккә чумып, гөлләргә күмелеп утырган авыллар, поселоклар, шәһәрләр күрдек. Ворошиловград шәһәренең тирә-ягында 580 гектар мәйданда парк күкрәп утыра, урамнарда фонтаннар бөрки.

Юллар йомгак тәгәрәтердәй шома, тигез. Бүген без Кадиевкага юл тоттык. Соры тасма булып сузылган асфальт буйлап автобус алга чаба.

Федор Вольный гадәттәгечә зәңгәр күзләрен челт-челт йомып алгалады да:

— Егетләр, эссе дип тормагыз, галстукларыгызны тагыгыз, бүген тантаналы маршрут,— дип сүз башлады.

— Моны чираттагы шаяру дип аңларгадыр инде, атакай, тик мәгънәсенә төшенеп җитеп булмый.

Ренат Харисның бу сүзләренә Ф. Вольный сүзсез елмаю белән генә җавап кайтарды.

Ф. Вольный уенчак һәм күңелле кеше. Кем әйтмешли, йөзендә һич болыт әсәре күрмәссең. Такыр башын сыпырып куя да ирен кырыйлары белән генә көлемсерәп гәпкә керә. Сөйләргә ярата. Хәер, күпне күргән язучы ул. Донбассны бик яхшы белә. Үзе дә шахтер булып эшләгән. Гомумән, «аяклы энциклопедия».

Шулай да аның бу шаяруы чын булып чыкты. Автобус утызынчы еллар стилендә арка һәм колонналар белән бизәлгән зур бина янына килеп туктады. Бина түбәсенә эре хәрефләр белән: «Биредә стахановчылык хәрәкәте башланды», дип язылган.

Менә кайда булган икән чикләвек төше. Бөтен илебез хезмәт иияләре тарафыннан күтәреп алынган бу бөек башлангыч юл алган шахта турында моңа кадәр мәктәп дәреслекләреннән укып кына белә идек.

Хәзер менә без исеме дөньяга билгеле шахта территориясендә басып торабыз. Ул хәзер «Партиянең XXII съезды» исемен йөртә. Кемдер Шәүкәт Галиевкә мөрәҗәгать итте.

— Шигырь сорый бу тема, Шәүкәт, шигырь.

— Иң элек хисләрне рәткә кертергә ирек бирегез, егетләр,— диде Шәүкәт.

1935 елның 31 августына каршы төндә Алексей Стаханов дөнья рекорды куя. Ул 6 сәгать эчендә 102 тонна күмер чаба, норманы 14 мәртәбә арттырып үти. Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүнең яңа формасы менә шулай туа. Аны бөтен совет халкы күтәреп ала. А. Стаханов кебек беренче бишьеллык геройларының хезмәт традицияләрен аннан соң килгән буын дәвам иттерә. Донбасс шахтерлары яңадан-яңа рекордлар куялар. Алтмышынчы елларда, мәсәлән, «Краснодонуголь» трестының Николай Мамай җитәкчелегендәге бригада коллективы күмер чабуда хезмәт җитештерүчәнлеген берничә мәртәбә арттыруга ирешә. Бер комбайн айга 25 мең тонна күмер чаба башлый. Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое Н. Мамайның инициативасын безнең ил шахтерлары гына түгел, халык демократиясе илләре шахтерлары да күтәреп ала. Соңга таба Социалистик Хезмәт Геройлары Григорий Моцак, Анатолий Таценко, Юрий Кричевский иптәшләр «Тәүлеккә бер забойдан 1000 тонна күмер чабарга!» дигән девиз астында эшли башлыйлар. Хәзер бу рекорд та үтелгән этап. Юрий Кричевский бригадасы егетләре, мәсәлән, предприятиеләргә көнгә 1500 тонна күмер озаталар.

Беренче бишьеллык геройлары П. Кривонос, М. Виноградова, И. Гудов, А. Бусыгин иптәшләр белән бергә атаклы шахтер Алексей Стаханов Кама автомобиль заводын төзүче алдынгы бригадаларга хат белән мөрәҗәгать иттеләр. КамАЗчыларны хезмәт рекордлары куярга чакырдылар. Төзүчеләр бу мөрәҗәгатькә удар хезмәт белән

җавап бирделәр. Р. Сәләхов, В. Филимонов, Л. Шәмсетдинова, В. Мәүликов, Н. Карпенко җитәкчелегендәге бригадалар заданиеләрне көн саен, атна саен, ай саен арттырып үтиләр.

Тарихи шахтада барыбыз да әнә шушы бөек башлангычның матур язмышы турында уйландык.



## Егет сүзе бер булыр

Кировск шәһәрендә олы язмышлы ике дус яши. Икесе бер мәктәптә укыйлар, бер техникумны тәмамлыйлар, бер шахтага эшкә керәләр. Бер кызны сөяләр. Ватан күген сугыш сөреме каплагач, бергә ил тынычлыгын сакларга китәләр. Бергә кан коялар. Бер Указ белән икесенә дә Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Һәм... бергә һәлак булалар. Аның берсе — татар егете Гыйлфан Батыршин, икенчесе — украин Иван Чернопятко.

Моннан ике-өч ел элек Ш. Рәкыйпов Донбасста шушы ике дусның тормыш сукмаклары буйлап сәяхәт итә: аларның туган-тумачалары, бергә эшләгән дуслары, танышлары белән очраша.

Калын дәфтәргә тупланган материалларны күреп бер өлкән шахтер язучыга төрттереп куя:

— Дәфтәрең калын күренә күренүен. Тик повестеңны кайчан укырбыз икән, энекәш?

— Ике елдан!

...Кировск шәһәренең Ленин исемендәге культура сараенда энә төртерлек тә урын юк. Бөтен шәһәр килгән диярсең. Трибунада — язучы Шамил Рәкыйпов.

— Вәгъдәмне үтәдем, дуслар. Сезнең якташлар турындагы «Таңнар һаман матурмы?» дигән повестемны язып бетердем.

Зал алкышларга күмелде. Язучы әсәрне кайчандыр ике дус эшләгән 40 нчы шахтаның партком секретаре К. Мартинюкка тапшырды.

Очрашу бик күңелле үтте. Минем урын күкрәгенә Алтын Йолдыз һәм Ленин ордены таккан бер иптәш белән янәшә туры килде. Ирексездән күзләрем аның кулларына төште. Мәҗит Гафури атаклы шигырен шушы кулларга карап язган диярсең. Сырланып, тиресе каештай ялтырап каткан, тимерче чүкечедәй зур һәм нык куллар. Илебез хезмәт елъязмасына күпме кабатланмас сәхифәләр язган бу куллар.

Күршем белән танышып, сөйләшеп киттек. Комплекслы бригада җитәкчесе, Социалистик Хезмәт Герое, Украинаның почетлы шахтеры Иван Владимирович Казаренко булып чыкты ул. Ул чирек гасыр буена шахтада күмер чаба. Аның бригадасы тәүлек саен планда каралган 500 тонна урынына 650—700 тонна күмер чыгара икән. Бригада членнары — дүрт бертуган Якуповлар, П. Коконов, Я. Марченко һ. б. лар айга 200 мең тонна кыйммәтле ягулык чыгаралар.

Яшьли канга сеңгәндер инде, шахта сүзен ишетүгә тән чымырдап китә.

Баксаң, шахта турында безнең караш 40—50 елга артта икән бит. Шушы көнне без 22 номерлы шахта идарәсендә булдык. Махсус ялтыравык плитәләр белән түшәлгән күп катлы зур бина. Янындан чәчәк аллеялары сузыла.

Ишектән карсак гәүдәле, йомры йөзле, шахтер киемендәге кеше килеп чыккач кына бу бинаның шахта идарәсе икәнлегенә тәмам ышандык. Безне озатып йөрүче, партиянең шәһәр комитеты секретаре Н. Игнатов әлеге шахтер белән якын дусларча ике куллап күреште, безне дә таныштырды.

— Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое Бойко,— диде ул.

Атаклы шахтер кыенсынып китте. Яшькелт брезент кружкасын сыпыргалап куйды, башындагы каскасын салып кулына алды. Зур дәрәҗәле, танылган шахтер тормышта гаять оялчан кеше икән. Аны бу «кыен хәл»дән коткару өчен җәһәт кенә саубуллаштык та наряд залына уздык. Зал искиткеч зәвык белән бизәлгән. Алдагы стенаның буеннан-буена мозаик панно ясалган. Як-якта эш алдынгыларының майлы буяу белән язылган портретлары тезелеп китә. Икенче катында стеналарга уелып аквариумнар урнаштырылган. Шунда ук — зур-зур гөлләр, фонтан. Сул якта шахтерларның эш күрсәткечләрен тасвирлаган стендлар сузыла. Кемнең ничек эшләгәне, көзгедәй, менә мин дип тора. Башкарылган эшкә көнлек нәтиҗә ясалып барыла икән. Шахтаның эш мәйданы шактый катлаулы. Пластның егәрлеге 0,35—0,40 сантиметр гына. Машинист комбайны белән ярым яткан хәлдә идарә итә. Шуңа күрә эш процессын тулысынча механикалаштыруга зур әһәмият бирәләр. Хәзер күмерне җир өстенә традицион вагонеткалар түгел, әйләнмә-конвейер алып чыга.

Кул хезмәтенә генә нигезләнгән ярым җимерек, куркыныч шахталар күптән бетсә дә, шахтер хезмәте һаман батырлар хезмәте булып кала. Менә ни өчен бирегә шахтерларның ялын оештыруга зур әһәмият бирәләр.

Өлкәдә шахтерларга ял итү өчен бөтен мөмкинлекләрне тудырырга тырышалар. Беренче көнне делегацияне партиянең Ворошиловград өлкә комитетының беренче секретаре В. В. Шевченко кабул итте. Ул хезмәт ияләренең ялын оештыру хакында бик тәфсилләп, горурланып сөйләде.

Донбасста бөек язучы А. П. Чехов ял итәргә яраткан. Хәтта аның Төньяк Донец елгасы буенда дачасы да булган. Бу тирәне ул «Дон Швейцариясе» дип атаган. А. П. Чехов дачасы урынында балалар санаториясе үсеп чыккан. Бу төбәктә хәзер шахтерлар өчен 23 санаторий-профилакторий төзегәннәр. Теләгән һәр шахтер семьясы белән ял итә ала.

## Җыр—кадерле сый

Украин халкы элек-электән үк җыр-музыка яратуы белән дан тота. Җырның урыны, кадерле кунак кебек, түр башында. Кунакка да беренче сый — җыр. «Кадиевуголь» трестының 100 нче шахта начальнигы Владимир Андреевич Князев бу яктан аеруча кызыклы кеше булып чыкты. Ул Донбасста туып үскән. Шахтер профессиясенә мәхәббәт, җырга һәвәслек кебек үк, ата-бабадан килә икән. Владимир Андреевичның ачык йөзе, зур кара күзләре, тулы калын иреннәре һаман елмаеп тора. Ул оперетталардан арияларны яратып җырлый. Владимир Андреевич Наҗия Теркулова белән Дунаевский, Кальман оперетталарыннан дуэт башкардылар. Якыннан танышып киткәч, яңа дустыбызның башка күркәм сыйфатлары да ачылды. Аның инициативасы белән шахта эшчеләр өчен сарык көтүе асрый, ясалма күлдә амур һәм карп балыклары үрчетелә, шахтада гөмбә үстерәләр.

Владимир Андреевич Князев кебек югары культуралы дусларыбыз алдында югалып калмаска кирәк иде. Дөресрәге, тыйнак кунак була белергә кирәк иде. Бу җәһәттән группа җитәкчесе Ренат Харис турында аерым әйтәсе килә. Ренатның тирән фикерле фәлсәфи шигырьләрен һәр очрашуда алкышлар белән каршы алдылар. Аның ес-

тәвенә, ул менә дигән оештыручы да икән. Миңа калса, чит өлкәләрдә татар әдәбияты, татар язучысы абруена Ренат кебек киң карашлы сүз осталары яңа бизәк өстиләрдер. Арабызда мондый әдипләрнең, сәнгать осталарының булуы бик шатлыклы. Артистлардан А. Арсланов, Э. Җәләлетдинов, В. Шәрипова, Н. Теркулова, әдәбият белгече Р. Мостафин үзләрен киң планлы мастерлар итеп таныттылар. Ворошиловград педагогия институтында булган очрашуда ул аерата күзгә ташланды. Залда — дуслык фестиваленә җыелган студентлар. Алар илебезнең 13 союздаш республикасыннан килгәннәр. Укытучылар, галимнәр күп. Безнең программа Муса Җәлилгә багышланган. Аны Р. Мостафин алып барды. А. Арсланов шагыйрьнең әсәрләрен укыды, Э. Җәләлетдинов, В. Гыйззәтуллина М. Җәлил сүзләренә язылган җырлар башкардылар. А. Арсланов «Ышанма» шигырен укыганда беренче рәттә утыручы урта яшьләрдәге бер кешегә игътибар иттем. Күзләре мөлдерәмә яшь белән тулы. Ул аларны сөртми дә, яшерми дә, зур әчке омтылу белән артист авызыннан чыккан һәр шигырь юлын йотып бара.

— Кем ул? — дип сорыйм янымда утыручы институтның партком секретаре Владимир Иванович Потаповтан.

— Вильнюс галиме.

Соңыннан киенү бүлмәсенә Украина әдәбияты кафедрасы мөдире доцент И. Белогуб керде.

— Муса Җәлил иҗатын моңа кадәр дә яхшы белә идек, әмма герой-шагыйрь белән бүгенге очрашу — зур бәйрәм булды. Рәхмәт сезгә, дуслар,— дип, ул барыбызның да кулларыбызны кысты.

Күңелле һәм файдалы очрашу булды бу. Татар язучылары һәм сәнгать осталары хөрмәтенә фестивальгә килгән казакъ кызы яшь бала вакытында күршеләреннән отып калган «Күбәләгем» җырын башкарды.

## Соңгы сүз

Л. И. Брежнев партиянең XXIV съездында сөйләгән отчет докладында: «Социалистик төзелеш елларында безнең илебездә кешеләрнең яңа тарихи гомумилеге — Совет халкы барлыкка килде»,— дигән иде. Донбасста бу гомумилек букеты кабатланмас матур чәчәкләрдән ясала. Ватан муллыгын төрле милләт халкы: руслар, украиннар, татарлар, белоруслар, әрмәннәр, үзбәкләр иңне-иңгә куеп тудыралар. Ворошиловград өлкәсендә 13 мең татар яши. Алар тугызынчы бишьеллык заданиеләрен тормышка ашыру өчен зур тырышлык куеп эшлиләр. Партиянең Ворошиловград өлкә комитетының беренче секретаре В. В. Шевченко татарларны хезмәт сөючән, намуслы кешеләр дип атады.

Кировск шәһәренең 22 номерлы шахтасында музей бар. Музейда тупланган материалларның хәтсезе Донбасс татарларының хезмәт уңышларына, сугыш елларында күрсәткән батырлыкларына багышланган.

Дүрт туган Бигишевларга тулы бер стена багышланган. Тырыш шахтерлар шәһәрдә татар үзешчән сәнгать коллективы туплаганнар. Хәтта Шекспирның «Отелло» драмасын да тамашачыларга күрсәткәннәр. Бу коллектив утызынчы елларда Донбасста иң күренекле труппадан саналган. Сугыш башлангач дүрт туган фронтка китә. Өчесе Ватан өчен һәлак була.

Гражданнар сугышы ветераны Ленин ордены кавалеры Гайнетдин ага Камалетдинов безне Зәйнәп ханым Такташева белән таныш-

тырды. Бөек Ватан сугышы ветераны Зәйнәп апа хәзер балалар бакчасында тәрбияче булып эшли.

Музейда Советлар Союзы Герое Гыйлфан Батыршинның тормыш юлы шактый киң яктыртылган. Кировскида бер урамга аның исеме кушылган.

Шахтер даны медаленең өч дәрәҗәсе белән дә бүләкләнгән Исай Кәримович Чернышев, Украинаның почетлы шахтеры Таһир Закиров, Тыяман Вәлиев һәм башка бик күпләр Донбасс хезмәт елъязмасына күркәм сәхифәләр язалар.

Татар язучылары 57 очрашуда булып, барысы 13 меңләп кеше алдында чыгыш ясадылар. Донбассның күп милләтле эшчеләрен тәрбия итүдә үзләреннән зур өлеш керттеләр.

Соңгы көн. Саубуллашу тантанасына партиянең Ворошиловград өлкә комитеты секретаре Ю. Ф. Пономаренко килде һәм чыгыш ясады. Җирле композитор В. Блехер төн утырып шагыйрь Зәки Нури сүзләренә «Торналар» исемле җыр язган. Филармония артистлары бу җырны беренче мәртәбә делегация алдында башкардылар. Шагыйрә М. Фәйзуллинаның украина һәм татар халкы дуслыгына багышланган яңа шигыре дә бик урынлы яңгырады. Атналык тәмам. Ил-18 самолеты безне Казаныбызга алып кайтты. Әмма дуслык элемтәсе дәвам итә. Украин дусларда булып кайтканга күп тә үтмәде, өлкә газеталары аша Красный Луч шәһәренең Октябрь революциясе орденлы «Коммунизм байрагы» шахта идарәсенең Ленин орденлы кавалеры, Украина ССР Верховный Советы депутаты Юрий Кричевский җитәкчелегендәге бригада коллективы тугызынчы бишьеллык гиганты — Кама автомобиль заводының В. Мәүликов җитәкчелегендәге ташчылар бригадасын социалистик ярышка чакырып мөрәҗәгать итте. Донбасс — КамАЗ кул кысышты. Дуслык дәвам итә.

Җәүдәт Фәйзи

# ҖЫРЛАР ЭЗЛИМ...

*Журналыбызның 1970 елгы беренче һәм 1971 елгы дүртенче саннарында укучыларыбызны композитор Җәүдәт Фәйзинең «Халык җәүһәрләре» исемле фәнни-популяр китабының кайбер өзекләре белән таныштырган идек инде. Хәзер сезнең игътибарыгызга композиторның халык арасында йөреп, аның җыр иҗатын җыйганда 1950—1952 елларда алып барган көндәлекләрен тәкъдим итәбез.*

*РЕДАКЦИЯ.*

**1950 ел.**

**10 декабрь.**

«Көндәлек»не язмаганга күп вакытлар узды. Ул арада «Идел буенда» музыкаль комедиясе язылып бетеп, сәхнәгә куелды, тамашачылар тарафыннан җылы каршыланды. Әсәргә карата рецензияләр дә әйбәт, хәтта ул, КПСС ның өлкә комитеты күрсәтүе буенча, Мәскәүгә Дәүләт премиясенә дә тәкъдим ителде. Премияләр Комитетыннан СССР халык артисткасы — Казагыстанның атаклы җырчысы Күләш Бәйсәетова килеп, комедияне карап та китте. Ләкин әсәр премиягә узмады. Алдан ук сизенгәнгә борчылмадык. Гамир Насрый:

— Безгә премия тиясе булган икән дә исемлектән фамилияләребезне төшереп калдырганнар,— дип, гадәтенчә, кычкырып көлде...

Күп айлар, хәтта еллар буе иҗат утында янып та, аның нәтиҗәсе синнән киткәч, үзең аз-маз пыскыган кисәүгә охшап каласың икән. Төтенең бар, ә утың юк төсле була.

«Идел буенда»ны язар өчен филармониядән эштән киткән идем. Чакырсалар да кире кайтасым килми. Артистларны көйли-көйли үзем көйсезләнеп барам инде.

Музыка язу белән генә мин эшкә сусавымны баса алмыйм. Тынычсыз, хәрәкәт итә торган эш сорый минем күңел.

Филармониягә сәнгать җитәкчесе булып Александр Сергеевич Ключарев барырга булган. Шуның белән минем алда торган мәсьәлә үзеннән-үзе бик җиңел хәл кылынды. Сәнгать эшләре идарәсе янындагы музыкаль фольклор кабинетына «директор» булып мин килдем. А. С. Ключарев белән урыннарыбызны алыштык булып чыкты.

«Директор» дигәч тә минем бер төрле дә штатым юк. Нибары бер ярым штат: бухгалтерым да үзем. Элек биш кеше булган. Кыскарта-кыскарта бары кеше ярымлык штат калган. Эшне чын-чынлап җәелдереп җибәрер өчен кимендә тагын ике кеше кирәк: музыкаль һәм әдәби сотрудник. Барысын да дәлилләп Мәскәүгә яздым. Бәлки яңа елдан кабинетның штатын арттырырлар дип өмет итәм.

Килүен килдем. Зур җаваплылык алдым. Эшне җайга салып җибәрә алырмынмы? Бу бит фәнни тәпченүне сорый торган эш. Миндә ул сыйфат бармы? Булырга тиеш. Мин бит юрист. Адвокат та, суд тикшерүчесе дә булып эшләгән кеше. Суд тикшерүчесе белән фәнни тикшеренүче арасында зур аерма юк, минемчә. Казынырга, эзләнергә яраткач, бу эшне дә башкарып чыгармын дип ышанам.

**23 декабрь.**

Күп уйлаганнан соң мин шундый карарга килдем. Алдагы биш ел эчендә, иң элек, татар халкының Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң чыккан музыкаль фольклорын җыячакмын. Эш планымны идарә начальнигы Ф. Я. Рәхмәтуллиннан раслаттым да инде.

Бердән — бу бик кирәк, икенчедән — минем өчен таныш өлкә, өченчедән — гөрләп тора торган үзешчән сәнгать көчләребез миңа зур булышлык күрсәтәчәкләр. Аның өчен алар белән элемтә тотарга, алдан ук хәзерлек алып барырга һәм үз тирәмә фольклор сөюче яшьләрдән актив оештырырга кирәк. Ә алар бар. Эшне Казан клубларыннан башлыйм. Киләсе җәйгә районнарга да барып килергә булыр. Хәзердән үк хат аша хәзерлек башларга исәп. Чаллыга — Хәмит Булатовка, Борды авылына — Раиса Тимофеевага, Бондюгка — Әшраф Ахуновка, Әтнәгә — Разия Хәбибуллина белән Зәкия Хәсәновага хатлар язарга булдым. Сүзләрен яза торырлар. Сүзләре булгач көйләрен искә төшерү җиңел була.

**26 декабрь.**

Фольклор җыюда үзешчәннәргә ориентация тотуның дөреслеге көннән-көн ачыклана гына бара. Клублардан кайбер иптәшләр үзләре минем кабинетка килеп яңа көйләр тапшыра башладылар. Мәсәлән: Киров районының җитен комбинаты культура сараенда күп еллар үзешчән көчләр белән җитәкчелек иткән Ярулла Әхмәдуллин, Горбунов исемендәге заводның культура сараендагы татар җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе Разия Бичурина, баянчысы Габдулла Халитов, Татарстанның X еллыгы исемендәге культура сараенда эшләүче Касыйм Мөхәммәтҗанов һәм Татарстан иҗат йортының инспекторы Разия Яруллина иптәшләрдән уннан артык яңа көй язып алдым инде. Алар арасында «Казан каласы», «Яңгыр», «Комбайн» кебек төрле жанрның матур үрнәкләре дә бар.

Кичә, һич көтмәгәндә, Чаллы районының Борды авылыннан хат алдым. Аны җәй башында Татарстанның 30 еллыгы уңае белән республика үзешчән көчләренә смотр уздырылганда Казанга килгән Раиса Тимофеева язган. Мин аңардан бер-ике көй язып алган идем инде. Хат эчендә шундый юллар бар:

«Мин, абый, күптән инде сезгә зур рәхмәтләр әйтергә тиеш идем. Бик күп кешеләр мине «Гөлләр үсә» көе белән котладылар. Бу эштә сез сәбәпче булдыгыз бит, абый. Минем тавышны радио өчен пленкага язып алу сезнең ярдәм аркасында гына булды бит. Хәзер аны бөтен район тыңлап мине җырчы итеп таныдылар. Хәзер мине концертларга һәрвакыт чакырып торалар.

Абый, нишләп минем җырым башкарылганда «Борды авылы уку йорты мөдире» димиләр, ә колхозны гына телгә алалар, аны да бутыйлар?..

Сезне быел Чаллыга киләсе дип ишеткән идем. Районда әйттеләр һәм көтәргә куштылар. Мин сезне пароходлар йөрүдән туктаганчы көттем. Вакытыгыз булмагандыр инде. Сез миңа: «Шушындый матур яңа көйләр хәзерли торыгыз», дигәч, мин авылга кайту белән бик дәртләнеп көйләрне үзгәртә башлаган идем. Бу арада тагын күңел бирми башладым. Әгәр киләсе булсагыз һичшиксез хәзерләнергә туры килер».

Бу хаттагы бер урын мине уйландырды. «Көйләрне үзгәртә башлаган идем». Ничек аңларга? Репертуарны яңарту дипме, әллә иске көйләргә таянып, аларны яңа сүзләргә яраштыру өчен үзгәрешләр кертеп, яңача яңгырый торган көй чыгару дипме? Бу соңгысы, булса да, гаҗәп түгел.

Көй бит ул — халыкның музыкаль теле. Көйнең аерым фразалары аның сүзҗөмләләре. Көй интонацияләре — образлы фикер яки тапкыр сүзләр.

Җыр текстларының да, Г. Тукай аңлатканча, җыр башлау, көйгә салыну өчен генә хезмәт итә торган «Әүвәлге ике юлы» бик күптәннән бирле җыр калыбы буларак халык телендә яшәп килә бит. «Кара урман», «Агыйдел», «Сандугач» кебек борынгы

образларга кайтып калган жыр башлары, хәзерге көндә дә яңа әчтәлек тудырырга хезмәт итәләр түгелме? Димәк, жыр сүзләре кебек үк халык көйләренең дә аерым элементлары көйдән көйгә күчеп йөрүе бик ихтимал.

**29 декабрь.**

Раиса Тимофеева хаты быел җәй башында, авыл үзешчән сәнгать көчләренә уздырылган смотр вакытында, минем өчен бик әһәмиятле булган очрашуларны искә төшерде.

Мин ул чакта күңелемә ошаган «Су юлы», «Шаярам», «Өзеләдер үзәгем», «Суда, суда», «Фазыл чишмәсе» кебек җыр көйләрен язып алган идем. Бу җырларны Әгерҗедән Салисә Мозаффарова, Норлат якларыннан Һава Харисова, Буадан Рәмзия Таҗетдинова һәм Бондюгтан Тәкъсирә Нәбиуллина иптәшләр тапшырганнар иде.

Бу кызлар смотрның йомгаклау концертында шушы җырлары белән искиткеч уңыш казандылар. Минемчә, аларның зур уңышлары матур яңа көйләре, ишетелмәгән җырлары өчен генә түгел, бигрәк тә үзенчәлекле башкару осталыклары аркасында булды. Матур тембрлы, табигый көчле тавышлары, сүзләрнең ачык әйтелешләре, башкаручылык нәзакәтлелеге барыбызны да таңга калдырды. Кайбер профессиональ җырчыларыбыз алардан үрнәк алсалар, үзләрендә булган ясалмалыкны бетерә төшәрләр иде.

Халык башкаручанлыгы да, фольклор кебек үк, профессиональ сәнгатебезнең нигезе булырга тиеш. Кызганычка каршы, халык иҗатының бу өлкәсе өйрәнелми. Вокаль сәнгатен өйрәтүче профессорлар да, халык арасына чыгып, эшләре өчен кирәкле мәгълүматлар җыеп, аларны гомумиләштереп, үз тәгълиматларын булдыра алырлар иде.

Бу ел да узып китте. Яңа ел яңа иҗади уңышлар китерсен иде!

## 1951 ел

**10 март.**

Соңгы вакытларда фольклор белән шөгыльләнергә туры килмәде. «Башмагым»ны русчага тәрҗемә итү эше белән Таҗи абый Гыйззәт белән Мәскәүгә барып бер айга якын торып кайттык. Мәскәү радиосы рус телендә аның монтажын хәзерли...

Быел җәйгә Чаллы һәм Бондюг якларына фольклор экспедициясе оештыруны планлаштырдым.

Кабинетны фәнни нигезгә кору эше быелга барып чыкмады. Сметаны расламадылар...

Бердәнбер киңәшчеләрем һәм минем инициативаларны яклаучылар — халык иҗаты йорты директоры Зәйни Шаһиморатов белән аның инспекторы Разия Яруллина. Без бер идарәдә эшләгәнгә алар гына минем эшем белән кызыксыналар. Мораль яктан терәк булмагач, материаль терәк кенә җитми шул иҗат кешесенә.

Идея ягыннан киңәшчем дә, таянычым да тел-әдәбият институтының фольклор бүлеге җитәкчесе Хәмит Ярми. Күңел төшкән чакларда аңа барып бераз батырланып кайтам.

Ул үзе дә музыка фольклорын җыеп өйрәнә алмавы өчен борчыла.

**3 июль.**

Радионың музыкаль редакторы Зәйнәп Хәйруллина Мамадыш районыннан килгән бер кызыклы хатны миңа биреп:

— Укып чык. Бергә җавап язарбыз. Синең фольклор эшеңә дә аның файдасы булыр,— диде.

Яңа Комазан авылыннан килгән ул хат. Хат эчендә мондый юллар да бар иде: «Радиодан бер дә ишетелмәгән егермеләп көй бар миндә. Кайсыларының исемнәрен үзем дә хәтерләп җиткерә алмыйм.

Мәсәлән, мин исемнәрен белә торган халык көйләреннән түбәндәгеләрне ишеткәнем юк: «Ай, дуслар», «Яшә, республикам», «Саба», «Чокырча», «Дөм-дөм» (Зифа

Басыйрова җырлый торганнан башка), «Гыйлминур», «Сәмәрканд», «Алтын кәмәш», «Тәшү буе», «Наган» һәм калганнарының исемнәрен белеп җиткермим».

Хатның авторы «Ай, дуслар» белән «Яшә, республикам» көйләренең сүзләрен дә китергән. Беренчесе Ленин турында, икенчесе — Татарстан АССРга багышланган. Бу көйләрнең 18—20 нче елларда җырланганлыгы да күрсәтелгән.

Менә бит нинди әһәмиятле хат язган хөрмәтле укытучы Мозаффаров! Бу бит фольклорчы өчен уйланмаган табыш! Безгә билгеле булмаган хәзерге заман халык җырларының да ниндиләре бит!

Мин, әлбәттә, аның белән хәбәрләшәчәкмен һәм янына барып, ул көйләрне язып кайтачакмын!

**16 июль.**

Ерак Көнчыгыштан авиация заводы инженеры Тәлгать Сәйфи[1] кайткан. Ул хатыны Зәйтүнә ханым белән безгә килеп чыкты. Килеп керү белән рояль янына утырып уйный башлады. Үзе дә көй чыгара икән. «Сайра, сандугач», «Хатлар язам» җырларын, ике вальс һәм бер бию көен уйнап күрсәтте. «Ай югары» исемле җыры, вальслары бик үк оригиналь да түгел, тезелешләре белән дә композиторларыбызның йогынтысын сиздерәләр. Ә менә «Хатлар язам» һәр яктан да игътибарга лаеклы. Үзе яңа, үзе ритмик яктан да таушалган түгел.

Тәлгатьнең музыкаль белеме юк. Шуңа күрә мин аның көйләрен нота кәгазьләренә төшереп алдым. Эшкәртеп үзенә җибәрергә дә вәгъдә иттем. «Хатлар язам», һичшиксез, халык көе булып китәчәк. Халык сүзләре белән файдаланып, аңа сюжет бирергә кирәк булыр.

Хәзер көйдән-көйгә күчеп йөри торган җыр сүзләренең бәһасе төшеп бара. Халык сюжетлы җырлар ярата. Шуңа күрә дә күп чагында яңа көйләр иҗат иткәндә шагыйрьләребезнең сүзләре белән файдалана да ул.

**29 июль.**

Яңа Комазандагы фольклор сөюче Рәшит ага Мозаффаров белән хат алыштык. Янына барачагымны белеп, ул бик шатланган. Бордыдагы Раиса Тимофеева белән дә, Бондюгтагы Әшраф Ахунов белән дә күзгә-күз очрашу турында сүз куештык. Көтелмәгән сәбәпләр аркасында авылларга чыгып китүне бераз кичектерергә туры килә.

**25 август.**

Утызга якын халык көен фортепиано белән җырлау өчен эшкәртеп бетердем. Җырчылар да сорый, үзем дә практика. Халык көйләрен эшкәртү ул бик нечкә эш. Иң элек фактура һәм гармонияне көйнең үзеннән табып ала белергә кирәк. Ясалмалык — халык көе өчен ят нәрсә. Музыканың бөтен компонентлары үзара тыгыз бәйләнештә булганда гына көй аларны кабул итә. Эшкәртү алымнары көй белән органик тоташканда гына зур художестволы нәтиҗәгә ирешергә мөмкин.

Шул күзлектән караганда, минем бу эшкәртүләрем бары каләм очлау өчен генә файдалы булып калулары да ихтимал.

**29 сентябрь.**

Иртәгә, җырлар эзләп, Казаннан чыгып китәм. Маршрутым — Мамадыш, Чаллы һәм Бондюг районнары. Башта сөйләшеп куелганга мин зур өметләр белән барам. Анда мине көтәләр.

Фонографны көйләдем. Валикларны үзем уйлап тапкан ысул белән чистарттым. Эдиссонның исен китерерлек булмады булуын, шулай да эшкә ярарлык булып чыкты.

---

[1] Тәлгать Сәйфи — техник фәннәр докторы булды. Соңгы елларда Горький шәһәрендә авиазаводның баш инженеры булып эшләде. 1966 елда эш постында кинәт кенә вафат булды.

**30 сентябрь.**

Мин Мамадышта. Автобуста тугыз сәгать селкенеп барганнан соң, моннан егерме ел элек практикант-судья булып эшләгән шәһәремә килеп җиттем. Мине Юныс Фарсин[1] каршы алды. Фатирга аңарга төштем.

Шәһәрдә бертерле дә үзгәреш юк. Һаман шул элекке Мамадыш. Бөек Ватан сугышы хәрабәләрен торгызабыз шул. Сугыштан читтә посып яткан мондый шәһәрләргә дә чират җитәр әле бер заман.

Райкомда булдым. Яхшы кабул иттеләр. Иртәгә Яңа Комазанга Рәшит ага Мозаффаров янына китәм. Эшне аңардан башлап җибәрергә булдым. Авылга барыр өчен райком машина бирергә вәгъдә итте.

**3 октябрь.**

Бу юлларны мин Ленин ордены белән бүләкләнгән Рәшит Диярович Мозаффаровның пөхтә җыештырылган кечкенә генә өендә язып утырам. Өстәлнең икенче башында Рәшит ага уйларга чумып үзе тапшырган көйләрнең сүзләрен дәфтәр битләренә терки.

Кичерәк буйлы, түгәрәк ачык йөзле Рәшит ага әйтеп аңлата алмаслык сөйкемле кеше булып чыкты.

Мин аңардан 15 кә якын искиткеч матур көйләр язып алдым. Шулар арасында, хәзергә хәтле бер дә ишетелмәгән: «Ай, дуслар», «Яшә, республикам!», «Казаннардан Мәскәү», «Алга, иптәшләр!», «Вятка буенда», «Мамадыш» кебек безнең совет музыка фольклорында уникаль исәпләнерлекләре дә бар. Алар бар да гражданнар сугышы елларында чыккан җырлар.

Мин бик шатмын. Мондый бәхет җырлар җыючыга сирәк килә торгандыр. Бу көйләрне беренче тапкыр ачучы мин булдым түгелме?

Рәшит ага мине авылның алдынгы кешеләре белән таныштырды. Шулар арасында колхоз парторгы Тимергали Зәйнетдинов бик уңган кеше һәм музыка сөюче булып чыкты. Ул миңа «Тынычлык җыры»н тапшырды. Матур көй.

— Сүзләрен үзем маташтырдым,— ди.

Рәшит ага бала чагында Казанда Касыймия мәдрәсәсендә укыган. Габдулла Тукайны, Фатих Әмирханны күреп, ишетеп белә. Тукай сүзләренә җырлана торган берничә көй дә тапшырды ул миңа. Шуларның берсе казакъ көенә тартым. Анысын Абай Кунанбаев көе түгелме икән дигән фикергә килдек. Тикшерергә булыр.

Кичә кич белән Рәшит ага мине Яңа Комазанга бик якын урнашкан Көек-Ерыкса авыл укытучылары янына алып барды. Максат: хәзерге көн лирик көйләре белән очрашу иде.

Бару бушка булмады. Укытучы Асия Вәлиевадан «Рамай», ә Әхкәм Мофакаровтан «Егет моңы» яки «Вәгъдә» исеме белән йөри торган, бер дә ишетелмәгән бик матур ике яңа көй язып алдым. Башка җырлары радиодан еш тапшырыла торган үз көйләребез булып чыкты. Шунысы гаҗәп: укытучылар була торып та көйләрнең авторларын белмиләр. Мин бераз шелтә белдергән идем: «Үзегез гаепле. Татар композиторлары турында бер генә китап та басылып чыкканы юк. Радио бит ул — колакка керә дә, икенчесеннән чыга. Ә без укып, күз йөртеп аңларга өйрәнгән», диделәр. Дөрес сүзгә җавап юк...

Рәшит ага арды булса кирәк. Киерелгәләп ала. Ни әйтсәң дә 56 яшь белән бара бит ул. Лампа да күз кысып куя. Керосины бетеп бара, ахры...

**6 октябрь.**

Татар музыка фольклорларын баетуда шактый зур өлеш керткән хөрмәтле Рәшит ага Мозаффаров һәм аның кунакчыл авылдашлары белән саубуллашып, Мамадышка кайттым.

Юныс Фарсин мине культура йорты каршындагы үзешчән коллективы белән очраштырды. Аңардан әллә ни кызык көйләр ишетә алмадым. Район элемтә бүлеге начальнигы Хәйдәр Вәлиев музыка сөюче иптәш булып чыкты. Эшемә булышлык

---

[1] Юныс Фарсин — күптәнге культура работнигы. Журналист Мөхәммәт Фарсинның туганы. Бер улы Республика күчмә театры артисты, икенчесе Казандагы балалар музыка мәктәбенең директоры. Үзе хәзер пенсиядә.

күрсәтү теләге белән кечкенә генә мәҗлес тә оештырды. Анда да, үзе җырлаган берничә көйне санамасаң, әһәмияткә ия булырлык көйләр очрата алмадым.

Иртәгә Чаллыга китәм. Хәйдәр үз конторасының катеры белән Соколкага кадәр озатып куярга булды. Истәлек итеп, миңа үзенең язу өстәлендә торган П. И. Чайковскийның кечкенә генә бронза бюстын бүләк итте. Мин андый бюстны Казанда түгел, Мәскәүдә дә очратканым юк иде әле.

**7 октябрь.**

Мин Чаллыда. Мамадыштан Вятка буйлап Соколкага килдем. Хәйдәр Вәлиев үзләренең катерларында озатып куйды. Көн яңгырлы, салкынча, моңсу иде. Бәлки шуңар гадыр, юл буенча минем күңелемдә «Вятка буенда», «Мамадыш» көйләре яңгырап, гражданнар сугышы елларындагы азинчыларның батырлыкларын искә төшереп бардылар. Шушы юеш ярларны, яңгырлы юлларны узып, Казанның азатлыгы өчен көрәшкәннәр бит алар...

Соколкада пароходны озак көтәргә туры килмәде. Кичен мин Чаллыда ветврач Хәй һәм Хаҗәр Нигъмәтуллиналарның җылы өйләрендә коймаклап чәй эчеп утыра идем инде...

Кичә Хәмит Булатов ярдәмендә музыка сөюче укытучылар белән очрашып берничә җыр язып алдым.

Хәмитова Ләлә һәм Гомәров Хәниф иптәшләр «Әлләләр-әле», «Бабай истәлеге», «Безнең илләр», «Алсу гөлем», «Ил сакчылары» кебек мин ишетеп белмәгән көйләрне тапшырдылар.

Иртәгә Бордыга, Раиса Тимофеева авылына китәм. Юлы ерак икән — 18—20 чакрымнар. Машина табып булмады. Хәй ветпункт аты белән озата чыгарга булды. «Юлда машина очрар әле. Шуңа утыртып җибәрермен»,— дип өметләндерә.

**9 октябрь.**

Менә ул «Гөлләр үсә» көе чыккан Борды авылы. Монда керәшен татарлары яши. Авыл зур гына. Кечкенә генә уку йорты һәм ике катлы җидееллык мәктәбе бар. Раиса мине күргәч бераз каушабрак калды. Беренче сүзе:

— Озакка килдегезме, абый? — дигән сорау булды.

— Җырларыгызны язып алу белән китәм,— дидем. Үзенең тупаслыгын аңлап булса кирәк:

— Мин болай гына сорыйм. Бездә сезне кабул итәрлек затлы урын юк шул,— дип әйтеп куйды. Күрәсең, урын тарлыктан уңайсызланадыр. Шулай да ул үз өйләренә алып китте. Әти-әнисе мине бик хуплап каршы алдылар һәм беркая да җибәрмәскә булдылар.

Мин Раиса Тимофеева янына килүемә шатланып бетә алмыйм. Берсе артыннан икенче көйне җырлап кына тора ул миңа. Күңелең нинди эчтәлекне тели — шунысын әйтә дә бирә. Уен җырымы? — Рәхим итегез! Такмакмы? — Була ул. «Рамай»нымы? Анысын да белә. Романска тартым көй кирәксә — Әхмәт Ерикәй, Фатих Кәрим сүзләренә чыккан яңа көйләр дә бар. Кыскасы, бер көн эчендә мин аңардан унга якын көй язып алдым инде.

Әле башка җырчылар белән дә очрашасы бар...

**12 октябрь.**

Борды еракта калды. Мин тагын Чаллыда. Бу кечкенә экспедициянең зур уңышларын йомгаклап утырам. Егермегә якын көй язылган. Шуларның ундүрте хәзерге заман халык көйләре. Калганнары керәшен татарларында гына сакланган туй-йола җырлары.

Арада кыйммәтле булган көйле җырлар итеп шуларны күрсәтергә була: «Роза дигән гөлләрем», «Яшьлек бит ул», «Ай, былбылым», «Тула микән чиләге», «Уйланам», «Кала яшьлек», «Безнең Кызыл армия», «Заем».

Бу җырлар үзләренең эчтәлекләре белән дә, жанрлары белән дә бик бай һәм бик төрлеләр.

Боларның барсын да Раиса Тимофеева тапшырды. Әгәр дә «Матур булсын»ны

санамасаң, Борды авылында башка кешеләрдән мондый яңа көйләрне ишетергә туры килмәде. Чөнки бөтен авыл шул «Раиса көйләрен генә» җырлый икән.

«Матур булсын» җыры, нигездә, укытучы Наилә Әхмәтовадан язылып алынды. Дөресрәге — Наилә җырлаган көйгә башка укытучылар белән бергә сүзләрен яздык, аңа сюжетлы әчтәлек бирдек.

Шуның белән миндә булган фикер ныгыды. Ул да булса: фольклор җыючы композитор пассив күзәтүче һәм һәрбер очраган көйне «изгеләрдән» санап язып алучы гына була алмый. Ул халыкның иҗат кылларын тибрәтә белергә тиеш. Шул чакта ул халык иҗатына өлеш кертә ала һәм аның киләчәк иҗаты өчен кирәкле орлыкларны сибеп калдыра. Халык иҗатына юнәлеш бирү профессиональ сәнгатьнең бурычы бит. Шуңа күрә фольклор җыючы халык талантларына актив йогынты ясарга тиеш.

Яшермим. Раиса Тимофеевадан язылып алынган көйләрнең кайберсен үзе чыгарган, кайберләрен минем алда, минем киңәшләремне истә тотып, җайландырып җырлады.

Минем бу чын күңелдән tanuым кайбер фольклорчыларга ошап та бетмәс. Янәсе, «Тимофеева чыгаргач, нинди халык көе булсын инде ул?»

Ә бит «Тәскирә», «Гөлҗамал», «Тәфтиләү»ләр дә үзләреннән-үзләре тумаганнар. Аларны кем дә булса берәү башлап җырлаган, үз күңелендә булган кичерешләрен көй аша халыкка җиткергән, димәк, көй чыгарган. Ләкин ул автор буларак билгесез калган.

Ә без халкыбызның культурасы гөрләп торган чорда яшибез. Шулай булгач, көйләрнең авторлары билгеле булу гаҗәпмени? Тимофеева кебек, безгә матур җырлар бүләк иткән иптәшләр «билгесез» булып калырга тиеш түгелләр. Чөнки алар халык иҗатының традициясен дәвам иттерүчеләр. Аларны халыктан аерып булмый һәм аларның иҗаты — халык иҗаты.

**14 октябрь.**

Бордыда мин бөтен валикларымны язып бетергән идем. Хәтта «Матур булсын»га да урын калмады. Аны ишетеп кенә яздым. Валикларны чистарту өчен ике көннән артык вакыт югалтырга туры килде.

Клубка барып язылган 10 валикны расшифровать иттем, аннан соң аларны чистартып яңа язмаларга хәзерләп куйдым.

Клубта драмколлективның ветераны Нурулла ага Гарифуллин белән таныштым. Р. Тимофеевадан язып алынган «Идел суы» көенең сүзләрен ул язган булып чыкты. Аларны үз кулы белән тулысынча язып бирде. Көе дә матур, сүзләре дә ярыйсы. Зөләйха Әхмәтова ансамбле өчен эшкәртеп бирергә кирәк булыр.

Бүген безне, ял көне булганга, Хәйнең апасы Гайшә Исхакова көндезге ашка чакырды. Утыра торгач дусларымның телләре ачылды бит. Бәхетемә фонограф та янымда иде (клубтан килдем мин аларга). Кәтмәгәндә репертуарым артты. Хаҗәрдән «Гомбагыш» исемле мәҗлес көен, Гайшәападан «Сәфәр авылы көе» һәм «Китәм инде» җырларын, Хәйдән «Призывниклар җыры»н язып алдым. Кайчакларда фольклорчыга кунакта утыру да файда итә икән.

Иртәгә пароход белән Бондюгка сәяхәт.

**17 октябрь.**

Моннан 75 еллар чамасы элек бөек рус галиме Менделеев оештырган химия заводы белән атаклы Бондюгка мин өченче көн төнлә белән килеп төштем. Әгәр дә юлдашларым булмаса, таныш булмаган, дөм караңгы текә яр астында күмелеп калган шәһәр пристанендә каушап калыр идем. Бәхетемә каршы, пароходта Бондюг райкомының беренче секретаре Бәдри Баһаветдинович Баһаветдинов белән таныштым.

Очрашуыбыз кызык кына булды. Мин салонга килеп кергәндә бер төркем ирләр ашап утыралар иде. Арадан берсе мине танып:

— Кая болай юл тоттың? — дип сорады. Мин, ул иптәшне хәтерләргә тырышып, әмма һич хәтерли алмыйча:

— Бондюгка,— дидем.

— О, алай булгач, безгә икән. Кил утыр,— дип, ул үз яныннан урын тәкъдим итте.

Утырдым. Мине иптәшләре белән таныштырды. Арада кара мыеклы, көләч йөзле өлкәнрәк иптәш күзен кысып миңа карап торды да:

— Тукта әле, тукта... теге, сугыш елларында безгә килеп, бер матур кызга өйләнеп, бер атна торгач, концертлар белән каядыр китеп югалган «Бондюг киявез түгелдерсең бит син,— дип әйтеп салды. Бар да хахылдап көлделәр. Теге мине таныган иске танышым мине уңайсыз хәлдән коткарды.

— Юк... бу ул түгел... бу — композитор,— дигәч кенә иптәшләре тынычландылар.

Бу өлкән абзый шул Бәһаветдинов булып чыкты. Мин тиз арада алар белән дуслашып та өлгерәдем. Уйнашып, җырлашып бара торгач, кич тә узды, озакламый Бондюгка да барып җиттек.

Бәдри абый, эшемдә авырлык килсә, үзенә мөрәҗәгать итүемне сорады.

— Бу барыбыз өчен дә кирәкле эш. Тарсынып торма,— диде.

Бондюгка килгәч мине үзләре белән яр башынарак урнашкан бер йортка алып менделәр. Миңа шунда көтеп утырырга кушып артымнан машина җибәрергә булып, ак «Победа» белән китеп тә бардылар...

Райкомның икенче секретаре — сары чәчле ханым мине көләч йөз белән каршы алды һәм, язу язып, завод гостиницасына илттерде. Мәскәүдән килгән ике инженер янына урнаштым. Ләкин алар, нәзакәтлелек саклап тормастан, иртәгә бу номердан китәргә тиеш булачагымны белдерделәр. Бер җаваплы иптәш киләчәк икән.

Икенче көнне, Әшрәф Ахундовны эзләп культура сараена барганда, Казанда культпросветта эшләүче Гариф Миңнуллинны очраттым. Ул мине «бик әйбәт» квартирага урнаштырырга булды.

Әшрәф бик җылы каршылады. Аның белән эш планын төзедек. Кичкә клубта очрашырга булып аерылыштык.

Гариф мине үзе төшкән квартирага урнаштырды. Тыйнак җиһазлы, чиста итеп җыелган бу квартира мәрхүм укытучы Җәмил Идрисовныкы булган. Хәзер монда хатыны һәм кызы Әнисә торалар икән. Ифрат сөйкемлеләр. Әнисә «Стахановец» газетасы редакциясендә эшли.

Кичен клубта яшьләр белән очраштым. Күбесе миңа Казанда уздырылган үзешчәннәр смотры буенча таныш. Кайберләрен 1948 елда Мәскәүгә дә алып барган идем. Шуның өчен безнең арада тарсыну юк. «Хәзер минем чират» дип җырларга гына торалар. Менә бит ул алдан ук хәстәрлек алып баруның нәтиҗәсе. Бер кич эчендә 6 көй. Әшрәф үзе, Клавдия Кашаева, Хәсән Алиев, Гөлчирә Гыйльметдинова иптәшләр «Аллария-лария», «Алларын алга манам», «Көймә килә», «Зирекле куак», «Өмәләрдә», «Утырма көе», «Эх, метро юллары» кебек яңа җырларны яздырдылар.

**22 октябрь.**

Кичә Бондюг районының ике авылына барып кайттым. Якшәмбе көн булганга иптәш Бәһаветдинов үзенең «Победа»сын минем карамакка тапшырды. Бер иптәш кызы белән Әнисә минем юл күрсәтүчеләрем һәм «секретарьларым» булдылар. Казанда уздырылган смотрларда үзенчәлекле чыгышлары белән зур тәэсир калдырган Клавдия Комарова житәкчелегендәге керәшен татарларының Иске Гришкино авылыннан икәнлекләрен белә идем. Башта шунда юл тоттык.

Комарова бераз аптырап калды. «Бездә бит бию такмагыннан башка көйләр юк» дисә дә, Мария Еримеева дигән урта яшьләрдәге бер хатынны клубка алып килде. Бу хатын туй җырлары белән мәҗлес көйләреннән башканы белми икән. Булганы белән канәгатьләнергә туры килде. «Дусларым», «Ак балык», «Сандугач» (Әкрен кирәк, иплән кирәк ишетергә сандугач сайрауларын) исемле җырларны гына яза алдым.

Бернична ел элек бу авылда консерватория студенткасы Фәүзия Бурнашева, балетмейстер Гай Таһиров һәм баянчы Габдулла Халитов булып, байтак кына керәшен татарлары көйләрен һәм биюләрен язып киткәннәр икән. Казанга кайткач, ул материаллар белән танышырга кирәк булыр.

Караңгы төшә башлаганда гына без Турай авылына барып җиттек. Клубта безне

котәләр иде инде. Аларга райкомнан шалтыратып хәбәр иткәннәр. Кыска гына кереш сүздән һәм сорауларга җавaплардан соң эшкә керештек.

Рәисә Галләмшина, Нурасма Кәримова, Рәхилә Мәхмүтова, Гайшә Сәгъдиевалар «Айдырдугая», «Комбайн», «Әлилә-мәлилә», «Эх, суның агулары» кебек уен җырларын һәм «Серле күзләр» исемле лирик җырны тапшырдылар. Безнең фольклорчыларыбыз арасында ялгыш карашта булучылар да очрый. Имеш, уен җырлары (ягъни хороводлы җырлар) керәшен татарлары арасында гына очрый һәм ул соңгы елларда руслар йогынтысы белән генә барлыкка килгән. Дөрес, керәшен татарларында уен җырлары күбрәк очрый. Чөнки бу хәл ислам диненең зарарлы кисәтүе белән аңлатыла булса кирәк. Ә хәзер аның йогынтысы юк. Татар авыл яшьләре дә борынгы традицияләрен яңарттылар. Керәшен татарлары авылы Бордыда язылып алынган уен көйләренең күбесендә саф татар аһәңнәре булган кебек, бу татар авылы Турайда язылып алынган уен көйләрендә «керәшен» алымнары да очрый. Бу исә аларның милли чыганагы бер икәнлеген раслый.

Тагын бер нәрсәне онытмаска кирәк. Татар халык көйләренең үзләренә генә хас пентатоник ладка корылган булулары кебек, бездә, бик борынгы вакытлардан ук халык көйләрен башкару үзенчәлеге дә булган. Чөнки ул үзенчәлек хәзерге көндә дә очрый әле. Халык көйләрен яратып башкаручы артистларыбыздан: «Бу көйне Арча, Дөбьяз якларында болай җырлыйлар», дигән сүзләрне ишетү юкка гына түгел.

Нәрсәдән гыйбарәт соң бу халык башкаручылыгының үзенчәлеге? Иң элек сүзләр белән көй арасында булган бәйләнештә. Безнең халыкта сүзнең иҗекләрен күп санлы музыкаль авазларга сузып җырлау гадәте бар. Бу хәлне озын көйләрдә еш очратырга була. Ә менә кыска һәм тотнаклы уртача кызулыктагы көйләрдә, бу хәл сүз иҗекләрен һәрбер музыкаль авазга туры китерер өчен өстәмә хәрефләр исәбенә башкарыла. Ә ул, һәрбер иҗеккә кушылып, яки иҗек уртасына кереп җырланган өстәмә хәрефләр бик күп төрле. Арада еш очрый торганнарыннан «һ» хәрефе. Мәсәлән: «Гармуннар уйный беләсең» җөмләсе бу төр башкаручыларда: «Гаһармуһыннаһәр уһуйныйһый беһеләһесеһең» дип җырлана.

Мондый алым тавыш чыгару ысулына да тәэсир итә, билгеле. Болай җырлаучы авызны ачып тел очын тибрәлдерергә мәҗбүр. Тел әйтерсең лә иреннәр арасыннан очын гына күрсәтеп дерелди...

Шушы яклары белән, бу «манер» халык җырчыларын тыңлаганда, башкорт халкының «тамак-курай» һәм якут халкының тамак төбе белән җырлый торган, «Ебыһах» дип аталган җырлау ысуллары искә төшә. Төбәп әйтү түгел, әлбәттә, ассоциация юлы белән генә.

Мин бу уйлануларны язып та тормас идем. Аларны язарга мине Турай егете Гәрәев Гаскәрнең шушы ысул белән җырлавы мәҗбүр итте. Аның җырлау манерасы исләреңне китәрерлек. Нинди сүзләр җырлаганын аңлавы бик авыр. Аның каравы, әйтерсең лә ул тамагы белән гармунда да уйный, шуңа кушылып җырлый да.

Бу халык ысулы белән җырлаучылардан безнең сәнгатьтә аеруча Галия Гафиятуллинаны күрсәтергә була. Бик үзенчәлекле матур вариантта, билгеле. Усман Әлмиев исә бу халык манерында җырлауны бик зур осталык белән күрсәтә белә. Сәхнәдә түгел, әлбәттә, үзара, шаярып кына.

Менә шушы ысулда җырлап Гаскәр Гәрәев миңа «Урам көе»н яздырды. Аның җырлавы тыңлаучыларга шул кадәрле ошады — гө[лт] килеп кул чаптылар.

— Кем өйрәтте сине болай матур итеп җырларга? — дигәч, ул оялып кына:

— Әллә тагы... Минем бабай яхшы җырчы иде...— диде.

Мин ул җырлаган валик өстенә: «Сөртмәскә, сакларга!» дип язып куйдым...

Үз алдыма бурыч итеп куйган «экспедиция» планым артыгы белән үтәлде инде. Тагын берәр көн эзләнәм дә Казаныма юл тотам.

**26 октябрь.**

Кичә иртә белән өемә кайтып кердем. Кунакчыл хуҗаларга рәхмәтләр әйтеп Бондюг белән дә саубуллаштым. Тагын килүемне сорап, озатып калдылар. Көзге җилле, яңгырлы су өстендә, җылы пароходта кайтуы аеруча күңелле икән.

Инде валикларга расшифровка ясыйсы бар. Ни әйтсәң дә 60 ка якын көй язылды

бит. Әле аның, Чаллыда ноталар кәгазенә төшерелгәннәреннән тыш, кырыклабы балавыз валик эчендә саклана!

Командировкамның нәтиҗәсе уңышлы булды. Шуңа күңел күтәренке. Инде булган материалларны эшкәртәсе һәм төрләргә бүләсе бар.

**10 декабрь.**

Консерваториянең студентлар фәнни түгәрәгенең җитәкчесе Олег Лундстрем[1] соравы буенча кичә алар белән очрашу уздырдым. Кулымда булган материалларга таянып, аларга татар халкының хәзерге заман музыка фольклорын сөйләдем. Зур игътибар белән тыңладылар, ләкин җыелыш бик сүлпән узды. Композиторлар да катнашыр дип уйлаган идем, бары Мансур Мозаффаров кына булды. Эшемне мактап берничә җылы сүз дә әйтте.

Җыелыштан соң без аның белән сөйләшеп утырдык. Халык иҗатының «вагая баруы» борчый икән аны.

— Ни өчен хәзер «Кара урман», «Зиләйлүк»ләр шикелле озын көйләр юк. Уен җырлары да такмаклар гына. Фольклорыбыз ярлылана түгелме? — ди.

Төрлечә фикер йөртеп карадык, ләкин аның бу соравына ачык җавап таба алмадым. Минем өчен шунысы ачык: халык иҗаты безнең көннәрдә яңа җырларны барлыкка китерде. Җырларның яңа эчтәлекле тематикасына карап, аның көйләре дә яңа ритмик төс, яңа форма алдылар.

Халык көйләрен җентекләп өйрәнгәч, Мансур абыйның бу соравына тулы җавап бирә алырмын дип уйлыйм.

**16 декабрь.**

Кичә сәнгать эшләре идарәсенең ярдәмчесе А. А. Прошина үз янына чакырып алды да көтелмәгән хәбәр әйтте. Яңа елдан башлап фольклор кабинеты бетерелә, фольклор җыю эше белән республика Иҗат йорты шөгыльләнәчәк икән.

Яңакка сугудан да авыррак булды миңа бу хәбәр... Мине бит эш хакым бетүе борчымый. Акылсыз карар белән килешә алмыйм мин. Мәскәү тарафыннан: «Эшләгез, үз фольклорыгызны җыегыз, өйрәнегез», — дип бирелгән акчадан баш тарту ул бит — ахмаклык!

**25 декабрь.**

КПСС өлкә комитеты секретаре Салих Гыйлемханович Батыевка бардым. Гадәттәгечә елмаеп каршы алды. Минем ачуымны чыгарган хәлләрне белгәч:

— Ник алдарак килмәдегез. Хәзер ел ахырында бер нәрсә дә эшләп булмый. Хәзер соң инде. — Әллә ни борчылырлык урын да юк. Ялгыз кустарь хәлендә яшәгәнсез бит. Киләчәктә чын фәнни нигезгә салып, филиалның тел-әдәбият институты каршында бер бүлек оештырып җибәрербез, — дип тынычландырырга тырышты.

Шулай итеп, кабинет ябылды. Миңа җәелеп эшләргә мөмкинлек булмады. Ләкин фольклорга булган мәхәббәтемне тагын да көчәйтү өчен аның миңа файдасы зур булды. Җыйган материалларым юкка чыкмас дип уйлыйм. Киләчәк күрсәтер тагын...

## 1952 ел.

**25 июнь.**

Композитор өчен халык эченә кереп, аның бетмәс-төкәнмәс иҗаты белән танышып, матур-матур фикерләрен кәгазьгә төшереп, үзеңне халык акылы белән баетып кайтудан да өстенрәк нәрсә бар?

Мин тагын халыкның музыкаль фольклорын җыяр өчен юлга хәзерләнәм. Бусы инде икенче тапкыр чыгуым булачак.

Бу юлы тагын да кызыграк һәм нәтиҗәлерәк булыр дип уйлыйм. Чөнки татар халкының этнографиясен, фольклорын яхшы белүче профессор Н. И. Воробьев һәм

---

[1] Хәзерге көндә Советлар Союзында үзенең эстрада оркестры белән атаклы Олег Лундстрем.

фән иярәре Г. М. Хисаметдинов белән Хәмит Ярмиләргә ияреп барам. Дәресрәге, алар экспедициясенә катнашам.

Хәмит Ярми тәкъдиме белән мине СССР Фәннәр академиясе филиалының тел-әдәбият һәм тарих институтына вакытлыча өлкән лаборант итеп алдылар.

**26 июнь.**

Х. Ярми белән профессор Богородицкий исемендәге экспериментал фонетика кабинетында булдык. Фонограф валикларын чистартырга кирәк иде. Андагы байлыкка исем китте. Нинди генә инструментлар, приборлар юк. Барысы да фонетика белән музыкаль фольклорларны өйрәнер өчен. Богородицкийның туган тиешлесе Александра Николаевна безнең килүебезгә бик шат булды. «Берәү дә килми, кабинеты белән файдалана белмиләр», ди. Пединститут җитәкчеләре үзләренең бу байлыклары белән кызыксынмыйлар икән. Алай булгач филиал институтына бирергә кирәк аны.

**27 июнь.**

Рояль пюпитрыннан «Тапшырылмаган хатлар» эскизларын алып җыеп куйдым. Күзгә хәтле аерылышып торырга туры килә. Аның каравы, мин үземне баетып кайтам.

**2 июль.**

Һаман китә алганыбыз юк әле. Ниндидер сәбәпләр белән Х. Ярмине җибәрмиләр. Н. И. Воробьевның саулыгы китнән. Ә мин эшлексездән гаҗизмен. Музыка яза алмыйм, чөнки күңелем юлда. Мәхмүт Хөсәен дә әллә кая югалды. Күрәсең, диплом алу шатлыгыннан күңел ачып йөриләрдер. Либретто өстендә утырган булыр идек.

**10 июль.**

Мин Чаллыда. Х. Ярмине җибәрмәделәр. Аның киңәше белән бер үзем экспедициягә чыгып киттем. 20 ләре тирәсендә Воробьев һәм Хисаметдинов белән Әлмәттә очрашырга булдык.

Үзем белән Чаллыга Мәсфирәне, ике баланы алып килдем. Ветврач Хәй Нигъмәтуллиннарга төштек. Семьям аларда бераз кунак булганнан соң Актаныш районына, Мәсәдә авылына ял итәргә барачак. Таҗи абый Гыйззәт һәм Мәликә ханым белән шулай сүз куештык. Алар минем семьяма дача өзерләп торачаклар.

**12 июль.**

Ял итә белмим мин. Эшлексездән авыруга сабыштым. Шуңа күрә бүген культура йортында лекция укырга булдым. Темасы: «Татар совет музыкасының үсү юллары». Кичә Чаллы үзешчән көчләрен җыеп репетиция уздырдым. Бордыдан Раиса Тимофееваны да китерттем. Үзешчән композитор-укытучы Хәмит Булатов миңа зур ярдәм күрсәтә. Җиде көйне язып алуда да аның ярдәме булды.

**14 июль.**

Машина көтеп утырам. 120 километр юлга чыгасым бар.

Лекция уйламаганча уңышлы узды. 350 дән артык кеше булды, электр уты бер сүнә, бер яна торгач, очрашу 3 сәгатькә сузылды. Безнең музыканы яшьләр яхшы беләләр икән. 20 дән артык әсәр башкарылды. «Артистларым» — Р. Тимофеева, С. Вәлиева, Р. Гарипова, М. Мөхәммәтҗанова, Х. Гомәров һәм Х. Булатов. Алар мин сөйләгәннәргә җыр һәм музыка белән иллюстрация ясадылар.

Бөтенләй таныш булмаган иптәшләр урамда көтеп алып бик күп рәхмәтләр әйттә. «Музыка турында» бездә мондый лекция булганы юк иде әле», диделәр. Бары культура йортының директоры гына үзенең ризасызлыгын белдерде. Янәсе, мин акчалы лекция укымадым, кассаны файдасыз калдырдым.

Кызганычка каршы, район җитәкчеләре, редакция работниклары — берсе дә булмады. Х. Булатов әйтүенә караганда: «Кызыксынмый алар сәнгать белән».

**15 июль.**

Мин Әлмәттә. Иске авыл кырыендарак яңа Әлмәт — нефтьчеләр поселогы үсеп килә. Берәр этажлы фин коттеджлары буй-буй булып тезелеп киткәннәр. Мин шун-

дый коттеджның бирсендә, инженер Зәфәр Курманаевта торам. Ул булмаса бүген дә монда килеп җитә алмый идем әле. Миңа билгеләнгән машинада урын булмагач (ни әйтсәң дә өч кисәк багаж — фонограф, валиклар һәм чемодан) Курманаевка шалтыратырга туры килде. Нефтьчеләр ич, бай халык, ялт итеп килеп тә җитте, җилтерәтеп алып та китте.

Казандагы иптәшләр килеп җитмәгәннәр әле.

**17 июль.**

Казан белән сөйләштем. Воробьев белән Хисаметдинов Чистайдан борылып кире Казанга кайтканнар. Профессор авыру сәбәпле экспедицияне дәвам иттерә алмыйлар икән. Х. Ярми дә чыга алмый. Үземә генә эшемне дәвам итәргә куштылар. Кызганыч.

Бүген кич үк халык көйләрен җыя башлыйм.

**19 июль.**

Иртә дә, кич тә яшьләр белән клубта очрашам. Бер-ике көй язып алганчы берничә сәгать уза. Биредә үзешчән халык талантлары белән тиешле җитәкчелек юк икән. Шуңа күрә алар сүлпәннәр һәм бик акрын кыймылдыйлар. Тиешле эзгә төшерер өчен бик озак-озак агитация ясарга туры килә. Әле ярый, ярдәмчеләрем табылды. Зәйсу Дәминов — адвокат, кайчандыр ул миндә юридик институтта укыган иде. Икенчесе — Әлфинур исемле нотариус. Очрашуларны алар оештыралар, җыр белүчеләрне алар табып китерәләр.

Өч көн эчендә унга якын көй язып алдым инде. Бик әйбәтләре берничә генә. «Ялгыз каен» белән «Сагынам» аеруча яхшы көйләр. Соңгысын Фәһимә Кудашева тапшырды.

З. Курманаев чакыруы буенча, бүген кич 25 чакрым җирдәге яңа нефть скважинасын ачканны карарга барабыз. Кара алтын чыккан җирне күрүе ни тора. Ул скважина бик борынгы Иске Суркино авылы янында икән. Мин шул авылда төпченергә уйлап, фонографны да үзем белән алып барырга булдым.

**20 июль.**

59 нчы номерлы скважинаны ачканнарын күрдем. Инженерларның, мастерларның кычкырышканнарын да ишеттем, кочакланышып үбешкәннәренә дә шаһит булдым. Төнлә белән башланган эш кояш чыкканда гына нәтиҗә бирде. Нефть фонтанын котлагандай кояш нурлары аеруча яктылык белән тирә-якны ямьләндерде.

Бу скважина үзенең төзелеше белән нефть табу өлкәсендә бердәнбер. Ике горизонттан чыккан нефть фонтанын бер труба аша күтәрү тәҗрибәсе шушы 59 нчы скважинада беренче мәртәбә сыналуы икән.

Кичкә таба гына мине Иске Суркино авылына озаттылар. Иртәгә кич иптәш Курманаев минем арттан машина җибәрергә булды.

**21 июль.**

Бу Иске Суркино авылы бик үзенчәлекле. Башка авыллардан күп ягы белән аерыла. Асылда ул чуваш авылы. Татарлар да күп кенә. Монда чувашча да, татарча да, русча да сөйләшәләр. Алар өчен барысы да үз телләре. Ә җырга килсәң бары татарча гына җырлыйлар. Көйләрә дә татар көйләре.

Аларда дин юк. Мөселман динен дә тотмаганнар, христианнар да булмаганнар. Бары гадәт законнарына гына буйсынганнар.

Картларның әйтүләренә караганда, аларның алты-җиде буын бабалары әби патша заманнарында татарларны көчләп чукындыра башлагач, Буа якларыннан монда күчеп килгәннәр. Бу тирәләрдә куе урманнар, күлләр булган. Алар аучылык белән көн күргән. Миссионерлар җәбер итсәләр дә, дин кабул итмәгәннәр.

Урамнар озын һәм киң. Акбур белән буялган өй алларында кәүсәсенә колач җитмәслек зур-зур агачлар. Урамнарда чишмәләр ага. Ак зур ташлардан салынган йортлар да бар. Төзелеше белән күзгә чагыла торган, аркаланып эшләнгән таш капкалар да еш очрый. Өй эчләре, йорт җиһазлары да бездәгечә түгел. Өй уртасында тәбәнәк мич. Морҗасы күренми.

Кешеләрнең исемнәре дә бик үзенчәлекле. Берничәсен исемлектән күчереп алдым: Сәрби Таймухина, Иркабай Хундиряков, Самандай Мурзакаев. Чуваш исемнәреме бу, әллә Болгар заманы истәлекләреме? Этнографларга, архитекторларга, лингвистларга бу авылда уйланырлык материаллар бар. Археологлар белән тарихчылар да өлешсез калмас иде.

Суркино яшьләреннән мин нибары дүрт көй яза алдым. Арада характерлысы «Ачма тәрәзәңне».

Авылдан киткәндә машинабыз ватылып төнне кырда уздырырмын дип уйламаган идем. Җилсез караңгы тынлык... Әллә нинди ят тавышлар... Йолдызлар. Беренче таң нуры. Дөньяларны ямьләндереп кояш чыгуы. Әле дә ярый, машина көҗәләнде. Никадәр моң алдым йөрәгемә...

22 июль.

Әлмәт больницасының баш врачы, РСФСРның һәм Татарстанның атказанган врачы Зифа Мостафовна Балакина — Татарстанның Верховный Советы депутаты белән танышуым турында язмый узганмын.

Үткән шимбәдә булды бу. Клубта танцылар игълан ителгәч, анда баруны тиешсез күрдем. Булыр-булмас биюләр алдында халык җырларын хур итәсем килмәде.

Йөри торгач, берничә зур, берәр катлы агач биналардан торган больница тирәсенә барып чыктым. Бәлки Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ындагы Галиясе дә шушындый больницада эшләгәндер, әле дә шундук булгандыр. Врачлар белән танышу зарар итмәс иде дип уйлап, больницага кереп чыгарга батырчылык иттем. Баш врачның ишегалдындагы йортта торуын күрсәттеләр. Парадный ишеген кактым. Бераздан ишек ачылды. Урта яшьләрдәге зәре сөякле бер ханым, кырыс йөз белән:

— В чем дело?! — диде. Каушап калдым.

— Гафу итегез. Мин авыру түгел,— дип сүземне башладым. Үземнең кем булуымны, ни өчен Әлмәткә килүемне һәм «Тапшырылмаган хатлар» операсын язар өчен материаллар эзләп йөрүемне әйттем. Ханымның йөзе ачылып китте.

— Гафу итегез... Рәхим итегез, узыгыз! — диде. Кухня аша үтеп, яхшы җиһазланган, фикус һәм пальма гөлләре белән оранжерея сыман күренгән зур бүлмәгә кердек. Зифа ханым кул биреп танышканнан соң:

— Сез белепме, әллә күңелегез белән сизепме миңа килеп яхшы эшләгәнсез. Минем тормышым белән Галия тормышы арасында бик күп уртаклык бар,— дип, мине алдан ук кызыксындырып куйды. Мин сораштыра башлагач ул, җавап сүзләрен бүлеп:

— Ашыкмыйк әле, иптәш композитор. Бүген бит шимбә көн. Мин кичкә дус врачларымны чакырып сезне алар белән таныштырам. Уларым белән дә танышырсыз. Безнең семья музыканы бик ярата, күңелле генә утырырбыз,— диде...

Сәгать ярымнан соң борылып килгәндә өй тулы кунаклар иде. Бары белән дә таныштык, үзлештек, җырлаштык, сыйландык. Зифа ханымның уллары аккордеонда яхшы гына уйныйлар икән.

— Көйләрне сүзләре белән генә отып алам — дигән булып, гадәтем буенча, салфетка кәгазьләренә алар җырлаган, үземә таныш булмаган җырларны язып утырдым.

Кунаклар киткәч, без Зифа ханым белән аның тормышы турында, минем булачак операм турында иркенләп сөйләшеп утырдык.

Зифа Мостафовна да Галия кебек ирсез ике бала тәрбияләп Казан мединститутын тәмамлаган. Әлмәт больницасына килеп эшли башлаган. Инде атаклы хирург булып танылган, баш врач булу дәрәҗәсенә күтәрелгән. Икенче кат тормыш кору теләге белән яңадан кияүгә чыккан, тик анысы да, бозык кеше булып, өметләрен акламаган. Чыдар хәле калмаган, берничә елдан соң аны үзе куып җибәргән. Хәзер дүрт бала анасы. Бер улы армиядә, берсе быел мединститутка керә, ике кечкенәсе үз янында. Өчесе дә тәрбияле — менә дигән балалар.

Нинди генә авырлыкларга да, күңел рәнҗетүләренә дә карамастан, аякта нык тора бит безнең бөек «ана» исемен йөрткән саф күңелле хатыннар!

Сизелер-сизелмәс таң атып килгән чакта Зифа ханымны ишек кагып чакырып алдылар. Якын-тирәдәге скважинада трос шартлап, бер нефтьчене имгәткән. Авыр

хәлдә больницага китергәннәр. Зифа ханым операция ясарга кереп китте. Мин аны эш вакытында күрәсем килгән иде, тик ул миңа рөхсәт итмәде.

— Андый тормыш куркынычларын сезгә күрергә ярамый. Ятыгыз. Тыныч йокы сезгә! — дип чыгып та китте ул.

Ап-ак йомшак урын. Уйланып ятам. Зифа-Галия. Берсе реаль образ, берсе Гадел Кутуй тудырган һәм операмда булачак, әле ишетелер-ишетелмәс кенә минем күңелемдә яңгыраган Галия. Уйларым берсеннән икенчесенә күчә. Галия-Зифа берсен берсе тулыландыралар... Әлбәттә, минем Галиям дә хирург булачак! Аның образы ачыклана башлады бугай...

Бу кадәр тәмле итеп йоклармын дип уйламаган идем. Зифа ханымның кайтып кергәнен дә сизмәдем.

Имгәнгән нефтьчене коткара алмаганнар. Операция өстәлендә үлгән. Баш сөякләре зарарланган булган... Зифа ханым күңелсез. Керсенә дә керсенә...

Якшәмбе көнне Зифа ханым чакыруы буенча, больница хезмәткәрләре белән Әлмәттән ун чакрым чамасы җирдәге болынлыкка барып, печән чабу өмәсендә катнаштым. Чалгы тота белмәгән кеше, тик чалгы тавышларын тыңлап утырды, билгеле. Фотога төшереп, файдалы эш эшләгән булдым үземчә. Эш беткәч тәмле кыр ашлары белән сыйландык.

Кинәт кара болыт килде. Күк күкрәде, көчле яңгыр китте. Шалаш эченә яшерендек. Баш врач командасы белән хатын-кызларны машина белән Әлмәткә озаттылар. Машина безнең арттан килергә тиеш иде, тик ике сәгать вакыт узса да, килмәде. Ялан тәпи калып, балакларны сызганып 10 ир, Зифа ханым белән бер сестра өкрен генә яуган яңгыр астында юлга чыктык. Караңгы. Юл пычрак. Зифа ханым үзенең көчле меццо-сопрано тавышы белән җыр башлады. Әллә белеп, әллә белмичә минем «Комсомолка Гөлсара»га бар да кушылдылар. Бер җыр бетә, икенчесен башлап җибәрәләр. Йөрергә җиңел булсын өчен марш характерындагы җырлар башкарыла. Татар җыры белән рус композиторлары әсәрләре аралашып яңгырыйлар. Алар үзләреннән-үзләре телгә килеп торалар. Мондый хәл күптәннән бирле безнең көндәлек тормышыбызда бер матур гадәт булып китте. Сәйдәшне дә, Дунаевскийны да бер үк осталык белән җырладык.

Бер-ике сәгатьтән соң без Әлмәттә идек инде. Җыр белән кайтуы озак юлны бик күпкә җиңеләйтте. Зифа ханымга рәхмәт. Безнең күңелләр күтәренке булуга ул сәбәпче булды бит.

Мине җибәрмәделәр. Өйгә кереп, электр яктысында өстемә күземне төшерсәм, исләрем китте. Минем ак полотно костюмым манма судан һәм балчыктан соры, пычрак бер капчыкка әйләнгән.

Иртә белән миңа чистарган, үтүкләнгән костюмымны бирделәр. Кесәмдәге кульяулыгыма кадәр юылган, хушбуй сөртелгән иде.

**РЕДАКЦИЯДӘН:**

*Җәүдәт ага Фәйзи сүзендә торды: әлеге көндәлекләрендә сүз барган елларда җыйган җырларын эшкәртеп, аларның тарихларын ачыклап, ноталары белән бергә китап итеп бастырып чыгарды. «Халык җәүһәрләре» исеме белән 1971 елда дөньяга чыккан ул җыентык музыка сөючеләрнең күңеленә хуш килер дип уйлыйбыз.*

## Зәйни Шаһиморатов

# ЭПИЗОДИК РОЛЬЛӘР АША

Актер югары тойгыларның мәгънәсен аңлатып бирүче дә, тамашачыны җитәкләүче дә, аны тәрбияләүче дә булырга тиеш, дигән Станиславский. Чөнки, театр сәнгате, коллектив сәнгать буларак, спектакль тудыруда катнашкан драматург, режиссер, композитор, художник һәм башка барлык компонентларның иҗат җимешләрен туплап, актерга бирә. Актер сәхнәгә чыккач, тамашачы алдында башка компонентлар югала, йотыла. Сәхнәдә актер гына басып кала һәм ул гына тамашачы белән турыдан-туры бәйләнешкә керә, сәнгать чаралары белән идея йогынтысы ясый. Шуңа күрә артистның эше гаять катлаулы һәм җаваплы, күп көч, иҗтиһат, кыска тезген таләп итә торган хезмәт. Эпизодик рольләрдә уйнаучы артистлар өчен ул тагын да катлаулырак, тагын да читенрәк. Зур, үтәли рольләр уйнаган артистлар бер күренештә күренмәсәләр, икенчесендә күренәләр. Алар өчен мәйдан да, мөмкинлек тә киң. Ә эпизодик рольдә уйнаучы, бөтен спектакльдә бер генә яки бер-ике генә тапкыр кереп чыгучы артист, кергән вакытында күренмәсә, бөтенләйгә күзгә чалынмый ук кала. Чөнки баш герой төп вакыйга артыннан күзәтеп утырган тамашачы аның кереп-кермәве турында уйлап та карамый. Шуңа күрә мондый рольләрне авторлар да берәрсәйле итеп язарга тырышалар. Артистлар да чарлап, шомартып, җиренә җиткереп уйнау өчен көчләрен кызганмыйлар. Эпизодик рольләрдә үскән, һәр рольне бөтен нечкәлекләре белән, зурайтып уйнарга гадәтләнгән чын артист, зур, үтәли рольләр уйнарга керешкәндә дә шул гадәте буенча эш итә. Шуңа аның зур рольләре дә кечкенә рольләре шикелле үк калку, күренекле, бөтен тирәнлеге белән ахырынача ачылган, коелып куелган скульптур образлар булалар да чыгалар. Юкка гына, эпизодик рольләр — артистларның осталыгын чарлау мәктәбе, димәгәннәр.

Артист Әнвәр Гобәйдуллин да сәхнәдәге зур иҗат юлын әнә шулайрак башлап киткән иде. Аның Татар дәүләт академия театры сәхнәсендәге иҗат юлы югарыда әйтелгәннәрнең җанлы шаһите булып тора.

## Беренче адымнар

Әнвәр Гобәйдуллин Бөек Ватан сугышыннан соң сәхнәгә килгән артистларның берсе. Татар дәүләт академия театры 1948 елны Ш. Камалның «Козгыннар оясында» дигән драмасын яңадан сәхнәгә күтәрә. (Шириязданов Сарымсаков постановкасы.) Әнвәрне Таҗи мулла ролен башкаручы Зәйни ага Солтановка дублер итеп куялар. Аңа малай башы белән Зәйни Солтанов кебек атаклы артист белән алмаш-тилмәш репетиция ясарга, Хәлил Әбҗәлилов, Хөсәен Уразиков, Камал III, Габдулла Шамуков, Нәҗип Гайнуллин кебек сәхнә осталары белән партнерлашырга туры килә. Аның театрда үз урталыгы, үз кешеләре, сугышырга өйрәнгән явы булмый әле ул вакытларда. Ул үзен чит кеше чанасына эләккән, менә-менә төшеп калырга тиеш булган юлаучы хәлендә сизә. Бигрәк тә репетиция вакытларында Хәлил Әбҗәлилов аның күзләренә карап, теңкәсенә тиеп бетә. Шахтерларны үгетләргә, вәгазьләргә килгән картинада Әнвәр үзен әеруча кыен хис итә. Ул үгетләргә дип авыз ачкан саен, Насрый-Уразиков, Хәлил Әбҗәлилов аны көлкегә күтәреләр. Әнвәр каушап,



югалып кала. Ә. Әбҗәлилов аны сәхнәдән типкәләп үк озата. Бу хәлне Әнвәр Таҗи мулла адресына эшләнгән эш итеп түгел, үз шәхсенә ясалган һөҗүм, кимсетү итеп кабул итә. Әле ул чакта Әнвәр Әбҗәлилов белән Уразиковның аңлы рәвештә үзенә ярдәмгә килүләрен аңламый. Алар үзләре дә аңлатып тормыйлар. Садри ролен уйнаучы Габдулла Шамуков кына:

— Сиңа бу юлы читен булгандыр, кәбәм! Син аны аңлы рәвештә уйный да алмагансыңдыр, канатым! Шулай да алар синнән ярыйсы гына мулла китереп чыгардылар бит, майгынам! — дип елмая.

Шул ук елны Н. Исәнбәтнең ун еллар буена сәхнәдән төшми килгән «Хуҗа Насретдин» спектаклендә яшь артистка Касыйм ролен бирәләр. Казый аларга урамда үлгән эт үләксәсен алып ташларга кушкан була. Алар аршинның йөзе белән дә, яны белән дә үлчәп карап, мәсьәләне чишә алмагач, яңадан Казыйга киләләр. Хуҗа Насретдин шунда: мәхәллә Казый карамагында булгач, этне дә Казый үзе алып ташларга тиеш дигән хөкем чыгара. Таҗи мулланы уйнаганда Әбҗәлиловның көлүеннән җәфа чиккән, аңа үпкәләп йөргән Әнвәр Касыймны уйнаганда Әбҗәлиловны бөтенләй икенче яктан тоя. Бу юлы да Әбҗәлилов аңардан күзен алмый. Ләкин аның яклаучысы, кушчысы булып карый. Хәрәкәтләре белән аңа уйнарга булыша, уенын күтәрә. Әнвәрнең йөрәген ниндидер рәхәтлек, уеныннан канәгатьлек, партнерына тирән рәхмәт тойгысы биләп ала.

1949 елны инде Әнвәр малайлар роле уйнап башлый. Аңардан башта «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясендә самоварчы малай Хәйретдин ролен уйнаталар. Аңа Зәйни Солтанов, Гөлсем Болгарская кебек сәхнә хуҗаларына партнер булып уйнарга туры килә. Зур, олы артистларның уеннарына сокланып туя алмаган Әнвәр Зәйни Солтановның Хаҗи әфәндене ничек уйнавын йотлыгып күзәтә. «Менә миңа да Таҗи мулланы шулайрак уйнарга кирәк булган икән бит! Ул да хуҗалар тирәсендә койрык болгап, яланып яшәүче бер шәхес булган лабаса!» — дигән уйга килә. Зәйни ага да, Гөлсем ханым Болгарская да үз уеннары белән аңа Хәйретдинне җанлырак, кызыклырак итеп уйнарга булышалар. Болгарская Хәйретдингә Галимә абыстайның аны кытыкларга, интим эшкә тартырга теләгәнен сиздерә. Хәйретдин-Әнвәр бу хәлдән уңайсызлана һәм самовар күтәреп керткәндә чүт кенә абынып егылмый. Зәйни ага Солтанов аның өстенә кычкырып салгач, ул үзен җинаять өстендә тотылган кебек хис итә. Аңа Хаҗи әфәнде Галимә абыстайның бозык уйларын сизгәндер һәм шуңа үз өстенә кычкыргандыр кебек тоела. Аны курку баса һәм ролен дә шундый каршылыклы тойгылардан чыгып башкара. Малай чын мәгънәсе белән тере кешегә әверелә.

1951 елны инде Хаҗи әфәндене Хөсәен Уразиков уйный. Әнвәргә бу юлы Шакир роле эләгә. Менә шул «Хаҗи әфәнде өйләнә» спектакле барганда Хөсәен ага Әнвәрне тагын бер мөһим сәхнә законына өйрәтә. Сәхнәдә никах мәҗлесе бара. Мөгаллим ролен уйнаучы артист Габдулла Фәтхуллин хөтбә укыганда «вәләззалин» диясе урында ялгышып «вәләлвәзилин» дип җибәрә. Бу көтелмәгән хәлдән барлык артистлар «ычкыналар». Аларның көлүләре гаять табигый һәм урынлы булганга, аларга игътибар итүче булмый. Ләкин түр башында халыкка каршы чекерәеп утыручы мәһабәт Хаҗи-Уразиков башкаларга кушылып көлми генә түгел, күзеннән яшь бәреп чыкса да түзә, үзен буып килгән көлү, хахылдау тойгысын авызлыклый һәм спектакльнең идея-эчтәлегенә зыян китерә торган хәрәкәт ясалмый кала. Андый кызыклы очракларда «ычкынырга» яраткан, яшь һәм тәҗрибәсез Әнвәргә бу нәрсә



Артист Энвәр Гобәйдуллин «Хуҗа Насретдин» спектаклендә — Ахун (сулда).

иҗат эшенә ничек җитди карарга, аны ничек хөрмәтләргә өйрәнү мәктәбе була. Шуннан соң Әнвәр сәхнәдә «ычкыну» гадәтен бөтенләйгә ташлый.

Театр шул елны А. Әхмәтнең Шөгердә нефть эзләүче геологлар тормышыннан язылган «Серләр» дигән драмасын сәхнәләштерә. Әнвәргә бу спектакльдә башта балыкчы малай ролен генә бирәләр. Ул аны уйный. Ләкин әсәрне сәхнәгә куючы режиссер Габдулла Юсупов Әнвәрнең Фәйзрахман ролен башкаручы Габдулла Шамуковка һәр вакыт сокланып карап торуын күрә һәм аны Шамуковка дублер итеп билгели. Әнвәр шунда беренче мәртәбә зур, үтәли роль ала. Фәйзрахман карт — колхозчы, семья башлыгы, тормыш, яшәү тәҗрибәсе туплаган, мәзәкчән, каты куллы, үз карашында нык торучы, ләкин карашы дөрес булып чыкмаса, дөрес якка кушылып, аны тормышка ашыручыларга бөтен көче белән булышучы кеше. Ул башта Шөгердә нефть табыласына да ышанмый. Соңыннан улы институт бетереп кайтып, юк нәрсәне җиң сызганып эзли башлагач, ышана һәм үзе дә шул эшкә җигелеп каравылчы булып китә. Фәйзрахманның хатыны булып Гөлсем ханым Камская, улы Газиз булып Фоат Халитов уйный. Бу хәл яшь артистны бик уңайсыз хәлгә калдыра. Ул алар янында яшь булып күренүдән курка. Ләкин аны бу бәладән тагын партнерлары йолып алалар.

— Гөлсем апа Камская безнең өлкән артисткаларыбыз арасында барлык актерларга бертигез караган, һавалану, масаюны белмәгән, спектакльнең уңышы өчен барысын да эшләгән оста иде. Фәйзрахманны уйнаганда, мин аңа бала гына булсам да, кимсетеп карамады. Киресенчә, чын-чыннан ире итеп, олылап, яратып мөгамәлә итте. Миндә бу образны иҗат итәргә зур ышаныч тудырды. Шуның аркасында мин дә аңа тартынмыйча, образымның хатыны итеп карый алдым һәм ышанып уйнадым,— ди Әнвәр.

Фоат Халитов та аңа малай-шалай итеп түгел, атасы итеп карый һәм аның өчен генә уйный. Әнвәргә алар белән уйнавы җиңел дә, рәхәт тә, ләззәтле дә булып

тоела. Фәйзрахман Әнвәрнең үз материалына капма-каршы килә торган бөтенләй яңа образ, яңа характер булып чыга, яшь артист өчен яңа дөнья, яңа йөрәк тибеше ача. Әнвәр Габдулла Юсуповның бу рольне үзенә ни өчен биргәнен дә, аңа нинди яңа ачкыч тоттыруын да аңлый. Бу — Әнвәрнең сәхнәдә атлаган икенче җитди адымы да, театрның аны үстерүгә юнәлдерелгән дөрес тәрбия алымы, кайгыртуы да була.

## Әле үз чанаңа утыргач та

1950—55 еллар Әнвәр Гобәйдуллин иҗаты өчен бер-берсенә капма-каршы характердагы зур җитди драматик һәм шактый кызыклы бәләкәй комик рольләр уйнау белән характерлана. Бу еллар арасында иҗат шатлыклары да, иҗат газаплары да кичерә Әнвәр.

1950 елны режиссер Ширияздан Сарымсаков Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар» трилогиясенең беренче әсәре «Шомлы көннәр» драмасын сәхнәгә куя. Трилогиянең төп герое Биктимер картны Хәлил Әбҗәлилов, аның хатыны Гөлнисаны Гөлсем ханым Камская, Биктимернең уртанчы улы Мирхәйдәрне Әнвәр Гобәйдуллин уйный. Әнвәр олы артистлар белән яңадан очраша. Әле үткән ел гына «Серләр» спектаклендә Әнвәрнең хатыны булып уйнаган Камская, бу спектакльдә аның анасына, «Хуҗа Насретдин»да гадел хөкем иясе Хуҗаны уйнаган Әбҗәлилов хәзер аның атасына әверелә. Алар Әнвәргә чыннан да балалары итеп яратып мөгамәлә итәләр. Мирхәйдәрне җиргә ябышкач, киләчәген җирдән көтүче крестьян, басынкы табигатьле юаш кеше итеп уйный. Әнвәргә бу рольдә тагын бер сәхнә остасы белән очрашырга туры килә. Бу Мирхәйдәрнең хатыны Зәмзәмбану ролен уйнаучы Галия ханым Нигъмәтуллина була. Галия ханым Зәмзәмбануны шундый бер чаялык, шундый бер җилкенү, мавыгу белән уйный ки, ул вакыт-вакыт Мирхәйдәрнең басынкы характерын да чыгырыннан чыгарып уйнаклатып җибәргәли һәм аны: «Тиле дигән саен, тиганәк буе сикермә әле син!» — дип, үзенә кычкырырга мәҗбүр итә.

Шул ук елны Әнвәр М. Кәримнең «Ялгыз каен» драмасында колхоз председателе Мирзахан Шәукәтов ролен уйнаган һәм спектакльне куйган Хөсәен Уразиков белән сәхнәдә кабат очраша. Уразиков аны чакырып ала да: «Энем, менә сиңа кызыклы һәм үз материалыңа капма-каршы характердагы роль. Ал да әзерлән!» — дип, Шәвәли карт ролен тапшыра. Шәвәли — председатель Шәукәтовның бакчасы. 15 еллар буена колхоз канцеляриясе тирәсендә председатель йомышларын гына йомышлап, халык арасында сөйләнгән сүзләрне, гайбәтләрне председательгә җиткереп торучы, әләкче, ялагай кеше була. Әнвәр бу рольдә ялагайның ялагайлыгын гына түгел, аның азау теш ярган вакытын да гәүдәләндерергә өйрәнә. Хөсәен Уразиков исә аңа бу рольне нәкъ менә шушы сыйфатларны уйнарга өйрәтү өчен бирә дә.

1952 елны Ширияздан Сарымсаков М. Әблиевнең «Шәмсекамәр» драмасын яңадан сәхнәгә мендерә. Әнвәргә бу спектакльдә янә дә үткән заманга кайтырга, янә бер мәртәбә мулла ролен уйнарга туры килә. Ләкин бу мулла ыргытылган сөякне көтеп ятучы, шул сөяк өчен хуҗасының мөлкәтен саклаучы Таҗи мулла кебек кенә булмый. Үз авылын кулында тотып торучы властьлы мулла була. Ул, Юныс картларның үтенүе буенча, хәйләи шәрыгъ ясап, ире тарафыннан өч талак ителеп аерылган һәм шуның аркасында башка берәр иргә барып кайтмыйча элекке ире белән тору бәхетеннән мәхрүм ителгән Шәмсекамәрне сукыр Суфига никахлый. Соңыннан Суфи, вәгъдәсен бозып, Шәмсекамәрне аермагач, аны ачуланырга да, үгетләргә дә бармый. Эш драма белән очлана. Әнвәр бу рольне артист буларак яратып, кеше буларак нәфрәтләнеп уйный һәм тамашачы нәфрәтен дә яулап ала. Ләкин шуны да әйтергә кирәк, бу роль дә Әнвәргә Хөсәен Уразиков ярдәме белән эләгә. Хөсәен Уразиков башта мулланы үзе уйный. Аннан Әнвәргә рольне тоттыра да: «Әзерлән, уйнарсың. Бу синең үсүең өчен бик кирәк!» — ди һәм аны армый-талмый роль уйнарга әзерли.

1952 елда Ш. Хөсәеновның «Профессор кияве» комедиясен сәхнәгә куючы Габдулла Юсупов Әнвәргә Сәлим ролен тоттыра. Сәлим — рифмалар чүпләп, шигырь

сыман нәрсәләр укмаштырып йөрүче авыл малае. Ул үзен зур шагыйрьгә санап, кешеләргә югартын карый, тәкәббер мөгамәлә итә. Хәтта авылдан шәһәргә терлекчеләр киңәшмәсенә килгән сөйгән кызын да кабул итми. Соңыннан кыз алдынгылар сафына басып, орден белән бүләкләнгәч, үзе аңа ялынып бара. Тик бу юлы кыз аның үзен кире кага. Моңа чаклы гел картларны, өлкәннәрне генә диярлек уйнап килгән Әнвәр беренче мәртәбә сәхнәдә яшь егет образына юлыга. Әнвәр Сәлимнең тәкәбберлеген наданлыктан, культурасызлыктан килә дип трактовать итә, авызы пешкәч кәнә өреп эчә торган кеше итеп уйный.

1954 елны Т. Гыйззәтнең «Мактаулы заман»ын сәхнәгә куйганда режиссер Равил Тумашев та Әнвәрнең комик рольләрне калку итеп чарлап уйный башлавыннан файдалана. Аңа Ярулла карт ролен бирә. Әнвәр бу рольне әзерләгәндә Мәрьям ханым Сульва кебек зур сәхнә остасының бөтен тамашачыларны сихерләп авызына каратып тора торган якты таланты белән очраша. Аңа Ярулла карт ролен уйнау бер бәйрәмгә әверелә. Ләкин 1955 елга чыккач, Әнвәр артист җанын әрнетә торган авыр сагатьләрне тагын бер кабат йөрәгеннән кичерә. Артист Касыйм Шамил белән Равил Тумашевлар К. Шамилнең «Мәлихә куаклыгы» легендасы нигезендә язылган «Аҗаган» драмасын сәхнәгә куялар. Әнвәргә бу драмада читекче Әхмәт карт ролен уйнарга туры килә. Әхмәт бердәнбер кызы Мәлихәне (Шәхсәнәм Әсфәндиярова) үзен рәхимсез эксплуатация белән интектергән хуҗа малаена бирергә теләми. Ә хуҗа малае Әхмәт пычагы белән бер карчыкны чәнчеп үтерә дә, Әхмәтне кеше үтерүче ясатып, төрмәгә яптыра. Сүз дә юк, чын драматик роль. Премьерадан соң аңа «яхшы уйнадың» дигән бәя дә бирелә. Ләкин Әнвәр үзе генә образының нәрсәсендер табып бетерә алмадым, Мәлихә ролен уйнаучы Шәхсәнәм Әсфәндиярова җәелеп уйнарга комачауладым гына дип әрни. Аңа автор да, режиссер да бер сүз дә әйтмиләр. Җитмәсә, матбугатта да спектакль турында бер сүз дә язылмый. Бу нәрсә Әнвәрнең кичерешләрен тагын да тирәнәйтә.

## Эзләгән табар, ташка кадак кагар

Әнвәр Гобәйдуллинның сәхнәдәге икенче бишьеллыгы К. Тинчуринның «Казан сөлгесе» комедиясендә Ибраһим дигән бер авыл томанасын уйнаудан башлана. Бу хәл 1956 елда була. (Режиссер Равил Тумашев.) Эзәрләүчеләрдән мәчеткә кереп качарга мәҗбүр булган һәм фанатиклар тарафыннан бикләнеп алынган егет белән кызга Ибраһим белән бер крестьянны сакка куялар. Авыл егетләре, сакчыларның берсе ашарга киткәч, ә Ибраһим йокымсырап торган арада, егет белән кызның киемнәрен бүрәнәләргә киендереп, үзләрен чыгарып качыралар. Ибраһим исә: «Мин беркая да китмәдем. Алар минем күз алдымда бүрәнәгә әверелделәр!» — дип, фанатикларны ышандыра. Әнвәр бу ролен мие дин сөреме белән томаланган, шул ук вакытта авылча хәйләкәр бер абзый итеп уйный.

1957 елны Татар дәүләт академия театры Мәскәүгә татар сәнгате һәм әдәбияты декадасына барырга әзерләнә башлый. Бу мәшәкатьнең шактый өлеше Әнвәр җилкәсенә дә төшә. Ул М. Әмирнең Габдулла Юсупов тарафыннан сәхнәгә куелган «Миңлекамал» драмасында Миңлекамалның якын киңәшчесе, туры сүзле, уен-көлке белми торган Әхмәдулла карт ролен; Нәкый Исәнбәтнең «Муса Җәлил» драмасында (режиссер Празат Исәнбәт) Бельгия антифашистлары вәкиле, Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»н безгә китереп җиткерүче Энгельман ролен башкара. Бу рольләр аны Бөек Ватан сугышы чорларына кире кайтаралар. «Миңлекамал»да Әнвәр совет халкының фронтны тәэмин итү, җиңүне якынайту өчен тылда үз-үзләрен аямый эшләүләрен, авырлыкка, мәхрүмлеккә чыдауларын бөтен тирәнлеге белән чагылдырса, «Муса Җәлил» дә доньякүләм масштабка чыга. Әнвәр Муса Җәлил ролен уйнаучы Фоат Халитов белән бу спектакльдә аеруча якыная. Алар икесе бер кешегә әверелгән кебек эш итәләр. Бер-берләрен сүз әйтүдән генә түгел, каш селкетеп куюдан ук тоялар.

Режиссер Ширияздан Сарымсаков декадага алып бару өчен Т. Гыйззәтнең «Шомлы кәннәр» драмасын яңадан сәхнәгә чыгара. Бу юлы Әнвәргә инде Биктимер

картның кияве Хөрмәтулла ролен тоттыралар. Хөрмәтулла — драмада бердәнбер комик роль. Урта хәлле крестьян. Патшага да «Зә царя, зә собака, душа ни жалка» дип кенә хезмәт итә. Уйлап та тормыйча, утка да, суга да сикерә торган кеше. Бабалары белән дә, Мирвәли белән дә югарырак сөйләшә, адым саен үзенең өстенлеген, хәллерәк кеше икәнен сиздерергә, мактанырга ярата. Образ автор тарафыннан да җиренә җиткерелеп язылган. Режиссер да аның кайбер якларын күпертеп күрсәтергә булыша. Нәтиҗәдә Хөрмәтулла үзенчәлекле чын кеше булып чыга. Ул Әнвәргә үз характерында булмаган сыйфатларны ачарга ярдәм итә.

Иран язучысы М. Ибраһимның «Көн туар» романы буенча Хөсәен Уразиков тарафыннан язылган һәм сәхнәгә куелган «Тау чәчәге» спектаклендә Әнвәр кызлар белән сату итүче Әрбабны уйный. Ул Әрбаб образында бер генә кешелек сыйфаты да тапмый. Аңардан бары тик нәфрәтләнә генә. Һәм үзенең шул ачы нәфрәтен тамашачыларга җиткерү өчен бөтен көчен, сәләтен куя. Һәм, чыннан да, аның уены спектакльдәге драматизмның көчәюенә, изүчеләргә карата юнәлдерелгән нәфрәтнең тагын да үткенәюенә китерә.

1958 елда Әнвәргә әч яңа роль эләгә. Аңа бу юлы «Хуҗа Насретдин» спектаклендә Казыйның үзен уйнаталар. Әнвәр Таҗи мулланы уйнагандагы кебек Әбҗәлиловтан өркеп, югалып калмый инде. Чын-чыннан Казый образына керә һәм хуҗаның Казыйга взятка бирү сценасын тагын да көлкелерәк итә. Хуҗа-Әбҗәлилов белән Казый-Әнвәр арасында чын иҗади дуслык, иҗади партнерлык пәйда була. Казыйдан соң Әнвәр М. Әмирнең «Гөлшаян» комедиясендә Гыймай бабай ролен уйный, «Зәңгәр шәл» спектаклендә чуваш халык вәкиле Пәтрәй образын иҗат итә.

1958—59 елгы сезонда Шириязданов Сарымсаков Р. Ишморатның «Серле моң» дигән комедиясен сәхнәгә чыгара. Бу спектакльдә Әнвәргә колхоз председателе Хәсән ролен тапшыралар. Әнвәргә Хәсән образы бик ошый. Ул аны аек акыллы, үтә эшлекле, үз дигәнен итми калмый торган, ләкин корырак характерлы кеше итеп уйный. Бу спектакльдә Әнвәргә Гали Надрюков, Вәкил Закиров, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Вера Минкиналарга партнер булырга туры килә. Ул аларның нинди ут белән сулауларын, нинди азыкны ниндирәк соус белән йоттыруларын ачык күрә һәм үзе дә алардан калышмый.

## Мич тулы пәрәмәч, уртасында бер калач

Әнвәрнең 1960—65 елларда үткән өченче бишьеллыгы, элек уйлап килгән рольләрен санамаганда, тоташы белән диярлек эпизодик рольләр башкарып үтә. Ул бу елларда М. Кәримнең «Җырланмаган җыр»ында яшьли сөйгән ярыннан аерылган һәм гомер буе шул кызны йөрәгендә яшәү символы итеп асраган картны; Г. Камалның «Банкрот» сатирасында Сираҗетдиннең талануын хәбәр итүче Гарәфине; А. Островскийның «Котырган акчалар»ында Савва Васильковның камердинеры Василийны; Н. Исәнбәтнең «Гөлҗамал» драмасында афишалар ерткалап йөрүче карагруһ сәүдәгәрләр вәкиле Габделвәлине; М. Горькийның «Дошманнар»ында генерал денщигы Коньны; Т. Гыйззәтнең «Чаткылар»ында атасыннан калган малын эчеп бетереп, хатынының көлмәк-сәлмәкләрен, шәнчекләрен сатарга калган, Сабир байга ялланып, Гобәй старостаның өенә ут төрткән Мочтакны; Х. Вахитның «Карлыгач канат кага» комедиясендә эчү аркасында машинадан төшерелеп, үгезгә утыртылган шофер Гыйлаҗны; Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр»ендә саф җанлы Исаак картны; Н. Исәнбәтнең «Һиҗрәт»ендә качаклар белән Себергә шылып та, ярты юлдан мулланың икенче хатынын эләктереп кире кайткан ялчы Хәләйне; Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә адәм баласы»нда балаларыннан алимент алып ятучы Сәмигулла картны уйный. Бу образлар барысы да Әнвәр иҗатына аерым бизәкләр өстиләр. «Карлыгач канат кага»да шофер Гыйлаҗ ролен уйнаганда Әнвәр сәхнәдә беренче мәртәбә Фатыйма ханым Ильская белән очраша һәм бу олы талант иясенең сәләт көчен, иҗади куәтен беренче мәртәбә тоя. Фатыйма Ильская Әнвәрне бер генә минутка да тезгеннән ычкындырмый. Өзлексез киеренке бер халәттә тота. Үзе ролен бик калкуландырып,



«Тиран тамырлар»да — Шәңгәрәй (сулдан беренче).

ачык буяуларга бизәп, чигешләп уйный һәм партнерына да уенын үстерергә, бөтен тирәнлегенә кадәр аңларга, яшәргә юл ача. Шофер Гыйлаҗны хатынын җиңә алмаган өчен эчкегә салышкан дип, хатынын гаепләү позициясендә торган Әнвәр, Фатыйма ханымның Кәүсәрия бу эшләрне ирен кимсетү, авызлыклау өчен түгел, аңа кешечә яшәү шартлары тудыру өчен эшли итеп уйнавын күргәч, җиңелә. Эчкегә сабышуына ханынын түгел, Гыйлаҗның үзен гаепли башлый.

1965 елны Габдулла Юсупов М. Әмирнең «Тормыш җыры» драмасын яңадан сәхнәгә күтәрә. Бу спектакльдә Әнвәргә колхоз председателе Закир ролен бирәләр. Закир сугышның иң авыр елларында колхозны җитәкләүче, сугыш тудырган авырлыкларның барысын да үз җилкәсендә күтәреп чыккан шәхесләрнең берсе. Ул сугыштан яраланып кайткан да җитәкчелекне үз кулына алган. Заманның авырлыкларын да, бурычларның зурлыгын, җитдилеген дә, кешеләрнең хәлләрен дә аңлый


торган кеше. Закир явым буласын белгәч, хәбәр итәргә төн уртасында басуга чаба. Ләкин арып-талып йоклап ятучыларны күргәч, ул заманның кайбер дуамал председательләре кебек: «Торыгыз тизрәк, лодырьлар!» — дип кычкырмый. «Кайчан яттылар?» — дип кенә сорый. Фатыйманың кайгылы хәбәр алуын белгәч: «Беләм, беләм, бөтен авырлыгын беләм. Ләкин нишлисең? Бөтен ил белән килгән бәла бит бу!» — дип юата. Әнвәр бу рольне уйнаганда «Ажаган»дагы гарьләнүле кичерешләрдән, «Серле моң»дагы рәсми мөнәсәбәтләрдән, «Тау чәчәге»ндәге ерткычларча мөгамәләдән соң, Фатыйма ролен уйнаучы Шәхсәнәм Әсфәндиярова белән чын иҗатчыларча очраша.

# Бөек даталар

Әнвәрнең 1966—70 еллардагы дүртенче иҗади бишьеллыгы Бөек Октябрь социалистик революциясенең илле еллыгына, В. И. Ленинның йөз еллыгына, Татарстанның илле еллык юбилеена әзерлек елларында туры килә. Бу елларда Татар дәүләт академия театры Әнвәр Гобәйдуллин катнашы белән Х. Вахитның «Соңгы хат», «Илһамия», Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», «Миркәй белән Айсылу», «Әбугалисина» дигән әсәрләрен, А. Расих белән Ш. Сарымсаковның «Ике буйдак»ын, Т. Миңнуллинның «Миләүшәнең туган көне»н, Т. Гыйззәтнең «Кыю кызлар»ын, К. Тинчуринның «Американ»ын, Х. Сәлимҗановның Галимҗан Ибраһимов романы буенча эшләнгән «Тирән тамырлар»ын, Н. Погодинның «Баһадирлар»ын, Н. Асанбаевның «Канат җәйгәндә»сен сәхнәгә чыгара.

1966 елда «Хуҗа Насретдин» сәхнәгә яңадан мендерелгәндә, татарның беренче атаклы Хуҗа Насретдины Хәлил Әбҗәлилов дөнья куйган, аның ролен Габдулла Шамуков белән Фоат Халитовлар алмаш-тилмәш уйный башлаган чак була. Бу юлы Әнвәргә Ахун хәзрәт ролен бирәләр. Ун елдан артык әле беренче Касыйм, әле Казый булып уйнап килгән Әнвәргә Ахунны уйнау авыр булмый, әлбәттә. Ләкин гомер буе Колый Тарханны уйнаучы Хәсәен Уразиковның репликаларына тиешенчә реагировать итеп бетерү дә ансат булмый. Аңа бу эштә дә Хәсәен Уразиков үзе ярдәмгә килә. Бер вакыт алар бәлак чыгарып, хуҗага яучы булып киләләр. Хуҗа баба шулпасы әзерләргә кереп киткән арада, стенада эленеп торган бикасәпкә күзе төшкән Тархан аны барып капшап карый. Шул чак бикасәп астында ышеренеп торган Хаммад шәкерт аның башына сугып җибәрә. Тархан башта башын тотып читкә ыргыла. Аннан әйләнеп Ахунга карый һәм, үзенә Ахун сукты дип уйлап, җиңнәрен сызгана башлый. Ул да булмый, колачын җәеп артка каерылып ала да томырылып Ахунга ташлана. Аңа чаклы Тарханның бу хәрәкәтләрен ничек кабул итәргә белми аптырап торган Ахун Тархан белән чынлап сугышырга ябыша. Хәсәен Уразиков шушы хәрәкәте белән Әнвәр эчендә бикләнеп яткан яшерен көчне тартып чыгара. Җиһангир янына вәли вәкил булып барып, өч сорау алып кайткан һәм аларга каян җавап табарга белми Тарханга киңәшкә килгән Ахунны тыңлагач, Хәсәен ага аны ымлап үз янына якынрак китерә дә кулы белән тамак астын ышкып күрсәтә. Ләкин ул аны шундый итеп ышкый, Әнвәр үзен гүр суыгы алган, менә-менә башы киселеп төшә кебек хис итә, туңып, калтырап китә һәм Ахун злаккән капкынның бүре капкыны гына түгеллеген тамашачыга бик аңлаешлы итеп җиткерә.

Шуннан соң Әнвәр Марсель Сәлимҗанов тарафыннан сәхнәгә куелган «Соңгы хат» драмасында бөтен гамәлен взятка бирү белән юлга салырга өйрәнгән больница завхозы Фәйзине фаш итә. «Миркәй белән Айсылу»да әфьюнчы Исхак шәкерттән көлә. «Ике буйдак» спектаклендә «выгода»сы тимәсә, туганын да өеннән сөрә торган вак буржуа калдыгы Габдуллаҗанның йөзен ача. «Миләүшәнең туган көне»ндә кайбер масайган хәзерге заман яшьләренең бәяләрен фронтташлар бәясе белән үлчәп күрсәтүче Әһлиулланы мактый. «Илһамия»дә колхозда счетовод булып та, мулла булып та яшәүче Галимулла дигән хәзерге заман паразитын дөмбәсли. «Кыю кызлар»да яңадан иске дөньяга кайта һәм кызлар күзләргә йөрүче авыл мәзинен чиста су өстенә калкыта. Ниһаять, режиссер Марсель Сәлимҗанов тарафыннан тискәре



«Тау чәчәге»ндә — Әрбаб.

типлар галереясе итеп сәхнәгә куелган «Американ» сатирасында Сәлим әфәнде ролен уйнап, татар буржуаз милләтчеләренең эчләрен-тышларын ачып сала.

1969 елда Марсель Сәлимҗанов белән Празат Исәнбәт, Татарстанның илле еллыгына багышлап, «Тирән тамырлар» спектакле чыгаралар. Бу җаваплы спектакльдә Әнвәр авыл Советы председателе Шаңгәрәй ролен башкара. Шәнгәрәй Михаил Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» романындагы Разметнев кебек аз белемле, ни белгән шуның белән, бигрәк тә сыйнфый сизгерлек белән эш итә торган кеше. Ул зур оештыручы, киләчәккә ышанучы, аның матурлыгын йөрәге белән тоючы. Бу уен Әнвәргә иҗат шатлыгы, эшләгән эше белән горурлану тойгысы китерә. Шаңгәрәй Әнвәр иҗат иткән иң саллы, иң якты һәм калку образларның берсе булып кала.

Бөек Ленинның йөз еллыгы уңае белән сәхнәгә куелган «Баһадирлар» спектаклендә Әнвәр завод мастеры Сухожилов ролен башкара. Сухожилов — илле яшьләрдән үткән кеше. Нәсел-нәселдән килгән, шул заводта гади эшчедән мастер дәрәҗәсенә күтәрелгән эшче. Үз эшен белеп, бирелеп эшли. Ләкин әле дә анык бер позициягә килеп җиткән кеше түгел. Ул һәр әйтелгән сүзне саф көмеш итеп кабул итә. Революциягә кадәр дә начальстволарны каршылап өйрәнгән. Ленин бөтен дөнья пролетариатының юлбашчысы булгач, аны тагын да зуррак хөрмәт белән каршыларга кирәктер дип уйлый һәм Ленин күренгәч, бу дөньяда Лениннан да зур кеше юк. Җәегез паласны! — дип әмер бирә. Ленин: «Калинин бар!» — дип җавап биргәч, шаккатып кала. Ул дәүләт белән халык түгел, укыган кешеләр идарә итәргә



«Акчарлаклар»да — Шәрәфи карт.

тиеш дип карый һәм Ленинга да: «Сез дәүләт белән һәр кухарка идарә итәргә тиеш»,— дигән идегез. Әлегә никтер алар күренмиләр?» — дип сорау бирә. Ленин аның эшләре белән танышкач, мастерны «карт тиле» дип атаган кешеләрнең гаҗәбенә каршы: — «Нинди баһадир кеше ул сезнең мастерыгыз! Без утырышларыбызны аның төсле итеп оештыра белсәк иде. Мин аның эшен караган чакта менә нәрсә турында уйладым!» — дип бәяли. Әнвәр Ленин образын иҗат итүче олы талант иясе Шәүкәт Биктимеров белән бу спектакльдә яңадан очраша. Шәүкәт Ленин ролен шундый бер нечкәлек белән эчекә кереп уйный ки, Әнвәр үзен Шәүкәт Биктимеров белән түгел, Ленинның үзе белән очрашкан кебек хис итә һәм чын Сухожиловка әверелә.

Әнвәрнең дүртенче иҗади бишьеллыгында аны җилкендергән тагын бер образына тукталмый үтеп булмый. Бу 1970 елда режиссер Празат Исәнбәт сәхнәгә куйган «Әбугалисина» драматик поэмасындагы сөрән салучы Авазбай. Авазбай, әкият герое, поэтик образ буларак, Әнвәрне бик нык үзенә тарта. Ул халыкка: мәгарә ачыла, белеп калыгыз, кереп калыгыз, керегез, укыгыз. Мәгәр һичкем кәгазь битә җыртып алмасын. Анда калмагыз. Калсагыз, киләсе елга сөякләрегез генә калыр! дип, Әбугалисина белән Әбелхарис кереп укып чыга торган тылсымлы мәгарә ачылачагын хәбәр итә. Ләкин Авазбай коры сөрән салучы гына да түгел. Ул дәүләт кешесе. Жандармга охшагач хәрби хезмәткәр. Әбугалисиналар мәгарәдән чыккач, аларга: «Патша исеме белән боерам, бирелегез!» — дип әмер бирә. Тегеләр әфсен куәте белән юкка чыккач, аларны сихерчеләр дип атый. Авторы Авазбайны бик таза гәүдәле, мәһабәт кеше итеп язган булса да, режиссер Празат Исәнбәт Әнвәрнең кечерәк гәүдәсе белән дә килешә һәм аңа хәрәкәт процессында дәвәергә булыша. Гомумән, Празат Исәнбәт Әнвәрнең талантына аеруча нык инанучы режиссер булды һәм ул алданмады.

1971 елдан Әнвәрнең бишенче бишьеллыгы башлана. Празат Исәнбәт А. Гыйләҗевнең хәзерге заман мещанлыгына, ирешелгәннәрдән канәгатьлеккә, тормышта бер урында катып калганлыкка каршы язылган «Эңгер-меңгер» сатирасын сәхнәләштерә. Әнвәр бу спектакльдә механика мастерскоенда мастер булып эшләүче Нәби исемле бер эшчене уйный. Ул кызы Зөһрә белән сөйләшкәндә: «Иң элек кешенең тамак туйдырырлык эше булырга, семьясы булырга һәм шул семьясы өчен ул утка да, суга да керергә әзер торырга тиеш»,— ди.

Әнвәр, артист буларак, Нәби ролен камил бер осталык белән башкара. Роленең асылын тотып алып, Гази Кашшаф сүзләре белән әйткәндә, автор ишарә белән генә калдырган урыннарны да тутырып, тәгәлләп уйный. Әнвәр уенында бертөрлелек юк. Аның сәхнәдәге һәр чыгышында аерым ачык задача һәм шул задачаны чишә торган аерым хәрәкәт үзгәлекләре ярылып ята. Бу спектакльдә Әнвәрнең уенын карагач, Таштимер белән Якуп Якупычны пугач шартлатып та качырып була, ә Нәби образын алган позициясеннән чигендерү яки алга ыргылдыру өчен авыр артиллерия кирәк булачак икән дигән фикергә киләсең. Әнвәрнең бу уенында, кайчандыр аның үзен Хәлил Әбҗәлиловлар, Хөсәен Уразиковлар өстерәп алып барган кебек, яшьләрне өстерәвен, яшьләргә ачылырга көч бирерлек итеп уйнавын күрәсең. Ул Алимның күзләреннән күзен алмый һәм Алим ролен уйнаучы яшь артист Илдар Хәйруллинның тавышын күтәрергә, үзенә дә каты итеп отпор бирергә мәҗбүр итә. Бик куанычлы һәм изге традициянең дәвамы бу.



«Американ»да — тарихчы Сәлим (сулдан икенче).

1971 елның көзендә Ш. Камал повесте буенча язылып, Празат Исәнбәт сәхнәгә куйган «Акчарлаклар» драмасында шундый бер легенда бар: борын-борын заманда анасыннан ятим калган бер яшь егет бәхет эзләп йөргәндә, бер Дәрвишка очрый. Дәрвиш аңа ярдәм итәргә була. Алар озак сәяхәт итеп эзләп йөргәннән соң, төнлә җеннәр җыелып, намаз укый торган бер мәчеткә барып җитәләр һәм эченә кереп качалар. Төн җитә. Мәчеткә җеннәр тула. Тегеләр намаз укырга тотынуга мөнбәр белән михрап арасындагы диварда бер тартма пәйда була һәм сихри нурлары белән бөтен мәчет эчен яктырта башлый. Дәрвиш барып тартма эчендәге нур балкытып яткан йөзекне алуга, җеннәр шаркылдашып чыгып качалар. Бәхет йөзеге Дәрвиш кулында кала. Таң атканын көтәсе дә, йөзекнең кашына язылган тылсымлы язуны укып бәхетле буласы гына кала. Ләкин таң атуга йөзеккә күз салсалар, йөзек кашсыз булып чыга. Җеннәр аның тылсымлы кашын куптарып алып киткән булалар. «Акчарлаклар» драмасына нигез ителеп нәкъ менә шушы «кашсыз йөзек» легендасы салынган. Монда да кешеләр Каспий диңгезе ярларына урнашкан балык промыслоларына бәхет эзләп киләләр дә кашсыз йөзек кенә табып китәләр. Бу — капитализм шартларында яшәгән хезмәт кешеләренең уртак язмышы, уртак өлеше.

Әнвәр Гобәйдуллин бу спектакльдә балык промыслосында балыкчы да, балык тозлаучы да булып эшләүче, утыз ел буена «сасы балык чокырында» ятарга мәҗбүр булган Шәрәфи картны уйный. Шәрәфи кирәк урында ут ягып сугыша да белә, кирәк чакта матур итеп киңәшен дә бирә белә торган ил агасы. Ләкин ул повестьның үзендә дә шулай икән дип уйларга ярамый. Повестьта Шәрәфи күбесенчә гырылдап йоклавы белән истә кала. Спектакльдә ил агасы итеп аны режиссер Празат Исәнбәт, артист Әнвәр Гобәйдуллин тудырдылар. Дөресен әйтергә кирәк, спектакль бик һәйбәт ансамбль булып туган. Гариф (Н. Әюпов), Газизә (Н. Ихсанова) караңгы, пычрак баракларга якты нур булып керәләр. Галимә ханым Ибраһимова күпне күргән ана образын аз сүз белән үтә дә ягымлы итеп уйный. Әмма шуларның барысын бергә туплаучы кеше Шәрәфи карт. Ул халык күңеле байлыгын җыйган шигъри образ. Ул давылда диңгездә балык тотканда суга батып туңган Гарифны өенә алып кайтып дәвалый. Балыкчыларны промысло хуҗасына каршы көрәшкә рухландыра һәм әкияттәге бәхет эзләүче егеткә ярдәмгә килүче легендар Дәрвишка әверелә. Ләкин Дәрвиш белән егеттән аермалы буларак, Шәрәфигә ияргүче балыкчылар, диңгез өстендә чар-чар килешеп, шаулашып, иртәме-соңмы, балык эләктерәселәренә ышанып очкан акчарлаклар кебек, киләчәктә йөзекнең кашлысын да табасыларына ышаналар һәм көрәшкә әзерләнәләр. Әнвәр башкаруында Шәрәфи карт әнә шундый тулы канлы, тирән сулышлы кеше булып гәүдәләнә һәм тамашачылар мәхәббәтен яулап ала. Бу — аның таланты киң колач белән ачылган гаять дәрәҗәдә табигый һәм олы образ.

## Әнвәр—сәхнә баласы

Әнвәрнең бу бишьеллыгы әле дәвам итә. Үткән еллар дәвамында уйналган эпизодик рольләр Әнвәрне кечкенә рольләрнең кемлекләрен бер күренүдә үк ачып салырга өйрәтсә, зур үтәли рольләр аны баштан ук нәтиҗәне уйнамаска, образның үсеше, вакыйганың күтәрелә баруы өчен дә, тамашачы өчен дә тотынып торырлык элмәк калдыра барып уйнарга өйрәтә. Әнвәр татар сәхнәсендә очраклы күренеш түгел. Ул Казанның Бишбалта бистәсендә эшче гаиләсендә туа. Урта мәктәптә һәм ФЗОда укый. Ватан сугышының ахырына чаклы заводта фрезерчы булып эшли. Аннан Татар дәүләт академия театры каршындагы театр студиясен тәмамлап, театрның үзендә калдырыла. Студиядә укыганда гына түгел, урта мәктәптә, ФЗОда укыганда да театрның көндезге спектакльләренә йөри. «Тартюф», «Профессор Мамлюк», «Бишбүләк», «Шәмсекамәр», «Тукай» һәм башка күп кенә спектакльләрне карый. Анда

уйнаган артистларның уеннарына чын күңелдән гашыйк була һәм театрга тартыла. Аның театрда картлар, өлкәннәр рольләрен уйнап башлавы да һәм уйнауда дәвам итүе дә очраклы түгел. Ул үз материалының өлкәннәрне уйнау өчен лаеграк булуын башта ук аңлый һәм һәр рольне бирелеп, мавыгып уйный.

Әнвәр Зәйни Солтанов, Хәлил Әбҗәлилов, Хөсәен Уразиков, Гөлсем Болгарская, Фатыйма Ильская, Гөлсем Камская, Галия Нигъмәтуллина, Хәким Сәлимҗанов, Габдулла Шамуков, Фоат Халитов, Галимә Ибраһимова, Рәшидә Җиһаншина кебек сәхнә осталарыннан, Ширияздан Сарымсаков, Габдулла Юсупов кебек режиссерлардан татар театрының үз тарихи традицияләрен, реалистик кичерелеш мәктәбен кабул иткән һәм хәзер шул мәктәпне заман сулышы белән баетып, дәвам иттерүче Марсель Сәлимҗанов, Празат Исәнбәт кебек талантлы яшь режиссерлардан яңа көч, яңа азык алып үскән һәм үсүдә дәвам иткән, шул мәктәпнең җимешләрен яшь буын артистларга тапшыра алырлык сәхнә остасына әверелгән якты талант иясе. Татар дәүләт академия театрының үзе тәрбияләп, үзе үстереп чыгарган сәхнә баласы. Үткән иҗат юлы бик күп сәхнә яшьләренә үрнәк була ала торган тыйнак кеше. Һәм без, язучылар, аның шушы көнгә тикле исем алмый яшәвенә гаҗәпләнәбез. Атказанган артист исеменә ул күптән лаек.

Шәрәф Әхмәдуллин

# ШИГЪРИЯТ МӘЙДАНЫНДА—СОНЕТЛАР

Сонет — күптәнге форма. Аның дөньяга килү, формалашу тарихы ерак үткәннәргә барып тоташа.

Билгеле булганча, Европа илләрендә озак еллар шигырьне чәчмәдән аерып торган төп чара булып сузык һәм тартык авазларның чиратлашуына нигезләнгән метрик система хезмәт итә. Бу чорда сонетлар бер әдәбиятта да күренми, чөнки алар өчен әле җирлек өлгермәгән була.

Ниһаять, шигырь төзелеше үзенең үсү, камилләшү юлында алга атлый. Италия шигърият мәйданында рифма барлыкка килә һәм ул 12 гасырда тулаем гамәлгә керә. Башта рифма ике юлдан торган куплетны бер бөтен итеп тоту вазифасын үти, шигырьләрдә парлы рифма урын ала. Ләкин тәҗрибә байый, осталык арта барган саен, шигырь техникасы һаман үсә, катлаулана. Әле кайчан гына бер ялгызы хөкем сөргән ике юллы куплетларга күрше булып өч юллы куплетлар — терцетлар килә. Аннары мәйданга дүрт юллыклар — катреннар күтәрелә. Соңгыларында инде я аралаш, я аркылы рифма кулланыла. Бу хәл шигырьдәге авазлар яңгырашын бермә-бер төрләндерә, баета, аһәңдәш иҗекләр гармониясен көчәйтә. Фикерләрне тәгъбир итү җыйнак, пөхтә форма ала. Нәкъ менә шушындый шартларда — рифмага нигезләнгән шигырь төзелеше җитәрлек камиллеккә ирешкән шартларда Гуиттоне Дель-Вива исемле шагыйрь беренче сонетларны иҗат итә. Бу — 13 гасырда Италиядә була. 300 ел буенча сонетлар Италия җирлегендә бик нык тарала, чәчәк ата. Бер генә шагыйрь дә сонетны игътибардан читтә калдырмый. Данте, Петрарка, Торквато Тассо сонетны камил дәрәҗәгә җиткерәләр.

16 йөздә сонетлар, Италия чикләрен үтеп, Европаның башка илләренә юл тота. Алар арасында сонет формасын поэзиядә үзләштергән беренче ил — Испания. Испаниядән соң сонетлар француз поэзиясендә күренә башлый. Башта Меллин, аннары меңләгән эре һәм вак шагыйрьләр сонет язуга алыналар. Петрарка традициясенә турылыклы Ронсар бу өлкәдә илһамланып эшли, Корнель үзеннән соң килгән буыннарга кыйммәтле мирас калдыра. Сонетлар таралу юлында чираттагы ил — Англия. Спенсер, Сидней, Шекспир, Мильтон, Вордсворд эшчәнлеге бу форманың дәрәҗәсен инглиз поэзиясе җирлегендә тагын да күтәреп җибәрә.

Ниһаять, тарихка яңа ачышлар өстәп, 17 гасыр атлый. Бу гасырда сонет формасы швед поэзиясенә үтеп керә. Моннан соң эстафета немец шагыйрьләре Мартин Опиц, Векерлин, Флеминг кулына күчә. Бюргер, Гете, Шлегел, Рюккерт, Платен немец сонетына алгарыш һәм камиллек китерәләр.

1735 елда шигърият кануннарына багышланган хезмәтендә Тредьяковский француз шагыйре Де-Барро сонетының русчага тәрҗемәсен китерә һәм шулай итеп беренче мәртәбә рус укучыларын сонет формасы белән таныштыра. Аннары бу формага Сумароков кагылып үтә, С. Нарышкин, А. Тиняков кебек вак шагыйрьләр сонетта көч сынап карый. Ләкин 18 йөздә эш шуннан узмый. Бары тик 19 гасырдан

башлап кына рус шагыйрьләре сонет формасының өлгергән үрнәкләрен бирүгә ирешәләр. Андыйларны без, барыннан да элек, Пушкин, Лермонтов, Дельвиг, аннары Бутурлин, шулай ук Брюсов, Бальмонт, Бунин мирасында табабыз. Бүгенге рус совет поэзиясе дә сонет формасына мохтаҗ түгел. Мәсәлән, танылган шагыйрь И. Сельвинский иҗат иткән әсәрләр арасында сонет үрнәкләре дә бар. Аннары Михаил Дудин бу өлкәдә шактый актив эшли. Ниһаять, илебездә яшәүче башка милләт вәкилләре иҗатында да сонет формасы игътибардан төшеп калмаган. Белорус шагыйре Нил Гиневич сонетларга үз иҗатында урын бирен килә, кыргыз шагыйре Смар Шимеев әледән-әле бу формага мөрәҗәгать итә. Зур талант иясе Рәсүл Гамзатов язган сонетлар исә бүгенге көндә тулы бер җыентык хасил итә. Шулай ук Украина шагыйре В. Сосюра калдырган әдәби мираста да сонет үрнәкләре шактый урын алып тора.

Нидән гыйбарәт соң сонет формасы? Аның эчтәлеге нинди? Ниһаять, ул нинди таләпләргә җавап бирергә тиеш?

Петрарка мирас иткән һәм классик форма дип танылган сонет — ул 14 юллык лирик шигырь. Һәр сонетның баштагы 8 юлы ике катрен булып тезелә һәм калган 6 юлы ике терцет (өч юллык) хасил итә. Менә Петрарка сонетының схемасы: 4 + 4 + 3 + 3.

Әлбәттә, 14 юлны шушы рәвештә урнаштыру сонет формасының бер ягы гына әле. Аның икенче ягы — юлларны рифмалаштыру. Бу яктан карaганда, Петрарка сонетларында катреннар, кагыйдә буларак, ике рифмага таяналар. Аларның берсе так, икенчесе җеп юлларны үзара бәйли.

**Схемасы шулай: а — б — а — б**
**а — б — а — б**

Яхшырак күзаллау, өчен, Петрарка сонетларыннан бер мисал китерик. Кыскалык өчен оригиналның рифмаларын гына рус хәрефләре белән күчереп үтәбез.

Катреннар:

1. ——————— **пиагне**
——————— **конзорте**
——————— **кампагне**
——————— **скорте;**
2. ——————— **м'аккомпагне**
——————— **зорте**
——————— **ми лагне**
——————— **морте**

Әйтергә кирәк, классик сонет формасында катреннарны билләүле рифмага кору да киң урын алып тора. Бу очракта да бары тик ике генә рифма алына һәм алар түбәндәге тәртиптә чиратлашалар:

**а — б — б — а**
**а — б — б — а**

Бөек немец шагыйре Гете сонетларында барлык катреннар фәкать шушы тип рифмалар системасына нигезләнәләр.

Инде килеп терцетларга күз салыйк. Классик сонетның бу өлешендә я ике, я өч рифма кулланыла.

Менә югарыда китерелгән Петрарка сонетының терцетлары:

1. ——————— **С оссекура!**
——————— **Чиари**
——————— **Оскура**
2. ——————— **вентура**
——————— **импари**
——————— **дура**

Күренә ки, биредә ике рифма һәм алар в — с — в, в — с — в схемасын хасил итәләр. Ләкин күпчелек очракларда өч рифмалы терцетлар кулланыла. Гете исә үз сонетларында һәр вакыт өч рифмалы терцетларга гына урын бирә. Һәм ул рифмалар, кагыйдә буларак, түбәндәге схемадагы кебек кабатланалар: в — с — д, в — с — д.

Классик сонет формасы турында сүзне очлаудан элек, тагын бер сыйфатны әйтеп үтәргә кирәк. Ул — иҗек мәсьәләсе. Һәр юлда иҗек саны тигез булырга тиеш. Әйтик, беренче юл 11 иҗекле үлчәү белән башлана икән, калган юлларда да ул шуннан артмасын. Бу — закон. Аннары классик сонет формасына кагылышлы тагын бер кагыйдә бар. Ул шуннан гыйбарәт: катреннардагы рифмаларның чиратлашу тәртибе терцетларда кабатланмаска тиеш. Икенче төрле әйткәндә, катреннарда билләүле рифма — а — б — б — а — икән, моңа капма-каршы буларак, терцетларда аралаш рифма кулланылырга тиеш (Гете мисалы). Һәм, киресенчә, катреннарда аралаш — а — б — а — б — рифма икән, ул чагында терцетларда билләүле рифма куллану зарури булып тора (Петрарка мисалы).

Әлбәттә, бу кагыйдә тикмәгә генә түгел. Ул авазлар яңгырашын төрләндерүгә, гармонияне көчәйтүгә хезмәт итә. Шулай ук аның икенче вазифасы да бар. Ләкин бусы эчтәлекне тәкъбир итүгә бәйле булганга күрә, башта классик сонетның эчке формасына кагылышлы мәсьәләләргә күчик.

Классик сонет — ул лирик кичерешләрне тәгъбир итү формасы. Һәр сонетта мәгълүм бер идея алына. Ул идея конкрет бер конфликтта гәүдәләнә һәм расланa. Шушы конфликт нәтиҗәсендә шәхестә туган кичерешләр, аларның хәрәкәте сонетның сурәтләү тукымасын билгели.

Алыйк Гетеның «Кыз зары» исемле сонетын. Тигез мәхәббәтне раслау — аның нигезенә салынган идея менә шул. Бу идеяне гәүдәләндерә торган конфликт сонетның беренче катренында калкып чыга: кыз үзенең сөеклесеннән риза түгел. Ул үз ярыннан җылы сүз көтә, аның иркәләнәсе һәм иркәлисе килә. Ә сөйгән яр, мәрмәр сын кебек, игътибарсыз һәм салкын. Икенче катренда кызның ризасызлыгы тагы да үсә, кискенләшә. Моннан соң килгән беренче терцетта хисләр икенче юнәлеш ала. Алда сурәтләнгән рухи халәткә чик куярга теләп, лирик герой бирегә баш күтәрә — конфликт үсешендә гүя «шартлау» барлыкка килә.

Югарыда әйтелгәнчә, терцетларның икенче тип рифмага корылуы нәкъ менә шушы үзгәрешне күрсәтүгә хезмәт итә дә инде. Ниһаять, соңгы терцетта конфликт чишелә. Төп идея үзенең тагын да баетылган, тирәнәйтелгән вариантында сонетны соңгы кабат яктыртып җибәрә.

Күренә ки, классик сонет — гаять таләпчән форма. Ләкин шулай булуына карамастан, ул һәр ил поэзиясендә якты чырай, ачык йөз белән кабул ителә. Франциядә булсын, Испаниядә яки Англиядә булсын, шагыйрьләр сонет язу белән бик мавыгып китәләр. Людовик XIII заманында, мәсәлән, бер Франциядә генә дә өч меңнән артык шагыйрь сонет язу белән шөгыльләнә.

Шул ук вакытта һәр илдә классик сонет формасына үзгәрешләр кертелә башлый. Мәсәлән, койрыклы сонет (4 + 4 + 3 + 3 + 3), башсыз сонет (4 + 3 + 3), икеләтелгән сонет (4 + 4 + 4 + 4 + 3 + 3 + 3 + 3), баштүбән сонет (3 + 3 + 4 + 4), чатан сонет (бер юл башкалардан иҗек саны арту я кимү белән аерыла) формалары барлыкка килә. Дөрес, классик сонет формасына кагылышлы андый үзгәрешләр нәтиҗәле булмый. Ә менә Шекспир тарафыннан кертелгәне бүгенге көндә дә тулы гражданлык хокукы белән файдаланыла.

Нидән гыйбарәт соң Шекспир яңалыгы? Барыннан да элек шуннан: Шекспир сонетларында терцетлар бөтенләй юк, алар урынын бер ике юллык алып тора. Аның каравы, катреннар саны өчкә җиткерелгән. Схемасы шулай: 4 + 4 + 4 + 2.

Икенчедән, Шекспир катреннарында рифмалар саны классик формадагы кебек 2 түгел, бәлки алты һәм соңгы ике юл парлы рифмага корылган. Менә алар:

1. ————————— тайм,
————————— найт;
————————— прайм,
————————— вайт;

2. ———————— ливз,
———————— һәд,
———————— шивз,
———————— бәд,

3. ———————— мейк,
———————— гоу,
———————— фәсейк
———————— гроу;

Ике юллык:
———————— дифенс
———————— һенс.

Схематик рәвештә күрсәткәндә, болай килеп чыга:

**а — б — а — б, с — д — с — д, е — в — е — в, к — к.**

Сонет эчтәлегенең асылына кагылышлы мәсьәләдә Шекспир классик сонет вәкилләре кебек эш итә. Аның карашы буенча да сонет нигезенә салынган һәр күренеш, факт, хис бер бөтенне хасил итәргә, һәм бу бөтенлек каршылыклы якларның синтезы булып торырга тиеш.

Ләкин эчтәлекне бирүдә Шекспирның үз юлы бар. Сонетның беренче катренында ул теге я бу идеяне куя, икенчесендә аның капма-каршысын бәян итә. Өченче катренда инде әлеге каршылыкларның синтезын бирә. Шулай итеп, соңгы катрен укучыны ике юллыкта тәгъбир ителгән төп фикерне кабул итүгә әзерли. Ачыклау өчен Шекспир сонетларыннан бер мисал китерик. Шәрәф Мөдәррис тәрҗемәсендә ул сонет түбәндәгечә яңгырый:

**Без телибез: саф гүзәллек арта барсын,**
**Шунда аның нәфис гөле һич тә шиңмәс,—**
**Җимеш пешеп, өзелеп төшсә — орлык калсын,—**
**Шунда аңар мәңге-мәңге үлем килмәс.**

Бу — беренче теза. Матурлык үлмәсен, мәңге яшәсен! Шекспир биредә менә шушы фикерне алга сөрә. Моннан соң әлеге фикер икенче планда дәвам итә — антитеза башлана:

**Әмма син — буш, үз-үзеңә гашыйк булып,**
**Дәрт утына гел үз маең салырсыңмы!**
**Муллыгыңны ачлык итеп, яшьли сулып,**
**Үз-үзеңә дошман булып калырсыңмы!**

Күрәсез, биредә Шекспир «син»не каты шелтәли. Чөнки «син» гамьсез килеш «үз-үзенә гашыйк булып» кына яши, үзенең дәвамы аша матурлыкны мәңгеләштерү турында уйламый.

Ниһаять, менә өченче катрен — синтез:

**Син — дөньяда бер саф бизәк, бәхет гөле,**
**Матур язның хәбәрчесе — үзең һаман.**
**Тик ачылмый, йомык тора синең бөре,**
**Чөнки җаның чүп төсле буш, дымга саран.**

Биредә инде Шекспир «син»не акылга килергә чакыра, каршылыкны матурлык һәм аның үлемсезлеге файдасына хәл итәргә димли. Хәзер укучы сонетның финалын кабул итәргә әзер:

**Табигатьне кызгансана, кылма җәбер,**
**Чибәрлегең йотар юкса тирән кабер**[1]**.**

---

[1] Шекспир. Сонетлар. Ш. Мөдәррис тәрҗемәсендә. Казан. 1961. 7 бит.

Бу — соңгы аккорд. Аңарда сонетның төп идеясе — матурлыкны раслау идеясе яңгырый.

Әйтергә кирәк, Шекспир тәҗрибәсе безнең көннәрдә татар совет шагыйрьләре өчен чын мәгънәсендә сонет мәктәбенә әйләнде. Бездә бу мәктәпнең беренче шәкерте Шәраф Мөдәррис булды. Дөрес, Ш. Мөдәррис 1954—55 елларда, үзенең беренче сонетларын язганда, Шекспир тәҗрибәсе белән генә чикләнмәде, бәлки сонет өлкәсендә дөнья әдәбияты казанышларына да таянып эш итте. Шуңа күрә дә аның мирасында, Шекспир керткән формадагы сонетлар белән беррәттән, классик үрнәктә язылган мисалларны да очратабыз. Алыйк менә бу сонетны: «Бер гаҗәп матур кыз гомер күгемдә» дип башлана ул. Аңарда классик сонеттагы кебек ике катрен, ике терцет. Катреннарда, тегендәге кебек, ике аралаш рифма. Бу — нәкъ Петрарка схемасы: а — б — а — б, а — б — а — б. Терцетлар рифмасында да классик сонет формасына хас күп төрле вариантларның берсе кулланылган: в — г — е, в — г — е. Бу вариантны Европа шагыйрьләрендә еш очратырга мөмкин. Гете исә терцетларда гел шушы схеманы файдалана.

Ниһаять, эчтәлекнең бирелеше ягыннан да әлеге сонет классик үрнәккә охшаган.

**Бер гаҗәп матур кыз гомер күгемдә,**
**Кояштай нур чәчеп, яктырып тора;**
**Көн димәс, төн димәс, һаман күңелдә**
**Мәхәббәт ялкынын яндырып тора.**

Бу хис икенче катренда тагын да үстерелә:

**Җемелдәп нур уйный сихри күзеңдә,**
**Әйтәчәк сүземнән яздырып тора,**
**Сизәдер, ут күп, дип йөрәк түремдә,—**
**Сабырлык яңгырын яудырып тора.**

Беренче терцетта инде борылыш туа — үзара ярашу, хисләр гармониясе бозыла.

**Ул кыз гел шул яктан аерылып тора:**
**Мин ярсып хисләргә артык бирелсәм,**
**Ул, охшап дулкынга, чигенеп китә.**

Соңгы терцетта исә яңадан татулык, бердәмлек урнаша, хисләр гармониясе яңара:

**Беркадәр ял һәм тын алдырып тора.**
**Шул вакыт назланып, мин дә чигенсәм,**
**Ул тагын артымнан йөгереп җитә...**[1]

Ләкин Ш. Мөдәррис классик сонет формасында озак тукталып калмады. Ирешелгән максат аны яңа эзләнүләргә этәрде. Дөрес, бу юлдан барганда, яңалык белән артык мавыгып китеп, шагыйрь ара-тирә сонет формасыннан читкә дә киткәләде. Әйтик, менә аның җыентыгында сонетлар исеме астында урнашкан бер парча бар. Ул болай башлана:

**Кышкы таң. Мин барам чыбык чанада.**

Менә аның схемасы — 3 + 3 + 3 + 3 + 2. Әйтәсе дә юк, бик оригиналь форма. Ләкин аңарда сонетка хас сыйфат — бары-ние бер генә. Ул — юллар саны. Сонет булыр өчен җитәрлекме бу сыйфат? Юк, билгеле. Хәер, киресенчә уйлаучылар да табылырга мөмкин. Әйтик, Шекспир сонетка 4 + 4 + 4 + 2 схемасын алган икән, һәм моны сонет дип таныйлар икән, ни өчен әлеге схеманы да татар шагыйре ачкан яңа сонет формасы дип карамаска ди? Юк шул. Чөнки мәсьәлә катреннарны терцетлар белән алыштыруда гына түгел. Төп мәсьәлә шунда: әлеге парчада сонет өчен зарури булып торган эчтәлек бирелеше — теза, антитеза, синтез юк. Шекспир сонетларында исә бу сыйфат саклanган.

---

[1] Ш. Мөдәррис. Минем яшьтәш. Казан. 1956. 196 бит.

Сонет формасыннан читкә китүен Шәрәф Мөдәррис үзе дә бик тиз аңлап алды булса кирәк, ул әлеге формага кабат әйләнеп кайтмады. Шул ук вакытта шагыйрь эзләнүләрдән дә ваз кичмәде. Ләкин хәзер аның игътибар үзәгендә торган нәрсә — Шекспир нигезләгән сонет мәктәбе иде. Тиздән Ш. Мөдәррҗснең Шекспир мәктәбендә әзерләнгән сызым буенча төзелгән үз сонет биналары бер-бер артлы күренә башлады. Алар, барыннан да элек, үзләренең эчке һәм тышкы формалары ягыннан сонет канннарына тулаем таңгал килеп торулары белән аерылып торалар. Ачыклау өчен, шагыйрьнең бер сонетын алып, анда эчтәлекнең бирелешенә игътибар итик. Менә теза:

Хатыным чыгарган, каяндыр табып,
Яшьлектә яраткан кызым ядкарен.
Һәм язган кыз шунда йөрәген салып:
«Мәңгелек ярлар без, иркәм, Әсгәрем!»

Менә антитеза:

— Мәңгелек ярлар без, фәлән-тегәнем,
Күрче син,— ди хатын,— әйтерлек түгел!
...Тик шунда сызлады минем йөрәгем,
Яшьлекне сагынып нечкәрде күңел...

Менә синтез:

— Юк,— дидем,— көнләшмә аннан, алтыным,
Соң бит ул яшьлегем, сафлыгым минем.
Багышлап шул кызга йөрәк ялкыным,
Мәхәббәт гыйлемен өйрәндем,— дидем.—

Ниһаять, менә финал — төп идеяне тәгъбир итә торган юллар:

Бу кызны уйлап гел, янып-көюем,
Ул — булды, карчыгым, сине сөюем!

Күрәсез, бирелә идея мәгълүм бер конфликтны — ир-хатын арасында көнләшү җирлегендә туган бәрелешне хәл итү аша тәгъбир ителгән. Бу инде чын сонет эчтәлеге дигән сүз. Чөнки сонет, лирик-фәлсәфи форма буларак, бәрелеш, көрәш, конфликтлылык хәлендә алынган хисләр, күренешләр, фактлар диалектикасын гәүдәләндерүне үзенә бурыч итеп куя. Нәкъ менә шушы вазифаны үтәү бәрабәренә ул, Буало әйткәнчә, озын поэманы алыштырырлык сәләткә ирешә дә.

Ниһаять, Шәрәф Мөдәррис сонетларының эчтәлегенә кагылышлы тагын бер сыйфатны әйтеп үтәргә кирәк. Мәгълүм ки, сонет мәйданы — тар. Ничек шушы тар мәйданда конфликтлылык хәлендә алынган хисләр диалектикасын калку итеп чагылдырырга? Ш. Мөдәрриснең осталыгы шунда ки, ул сонет мәйданына сыярлык бары тик бер хисне, бер күренешне, бер фактны гына ала һәм аны сәнгатьчә тәгъбир итә. Ир-хатын арасында көнләшү җирлегендә туган бәрелеш — сүз бара торган сонетның эчтәлеге менә шул. Аны бөтен тулылыгы белән ачу өчен, Шекспир үзенең «Отелло» исемле мәшһүр трагедиясен язган. Ш. Мөдәррис сонетында исә әлеге конфликтның бер ягы, бары тик бер ягы чагыла: беренче катренда ул формалаша, икенчесендә өскә бәреп чыга:

— Мәңгелек ярлар без, фәлән-тегәнем,
Күрче син,— ди хатын,— әйтерлек түгел!

Ләкин температура шушыннан артык күтәрелми, күз яшьләре дә коелмый. Чөнки алардан башка да укучы хатынның ярсуын, аның үртәү-мыскыл катыш «фәлән-тегәнем» дип әйтүендә хәләл җефетенә карата шелтә чагылуын яхшы чамалый.

Ш. Мөдәррис сонетларына тышкы форманың төзеклеге, ыспайлыгы хас.

Картаеп килгәндә яздым акылдан:
Йөрәккә бик хәтәр ялкын кабынды,—
Узганда кичкырын күрше авылдан
Бер чибәр, яшендәй, күзгә чалынды.

Бирeдә унбер иҗекле юллар иркен, табигый чиратлашалар. Аларны үзара бәйли торган аралаш рифмаларда һичбер көчәнү, ясалмалык эзе сизелми. Фикерләр анык һәм төгәл. Таләпчән форма эчтәлекне кысмый, имгәтми. Рифмалар җиңел, матур һәм тулы. Акылдан — авылдан, кабынды — чалынды. Болар, җиз кыңгырау кебек, бердәм аһәңдәшлек белән яңгырап торалар.

Шекспир сонетларын турыдан-туры инглиз теленнән тәрҗемә итү Ш. Мөдәррис талантын тагын да чарлады, камилләштерде. Аның алдында бөек Шекспир илһамы тудырган хисләр, образлар дөньясы ачылып китте. Тәрҗемәче буларак, ул менә шул шигъри дөнья байлыгын татар укучылары хәзинәсенә әйләндерде. Шагыйрь, үзенең бу хезмәтен йомгаклап, 1959 елның 8 ноябрендә болай дип язды:

**Әйе, Шекспир, әйбәт булды синең табын,**
**Авыз иттем өч йөз еллык хезмәтеңнән.**
**Бөекләрдән курка идем,— үзең тагын**
**Бер дә йөзең чөермәдең гадиләрдән.**

**Кичеп җилне, томаннарны, давыл шавын,**
**Йөзде шигъри диңгезеңдә минем каек,—**
**Үткән чакта тәрҗемәнең дулкын тавын**
**Маяк булдың, китсәм әгәр юлдан тайп.**

**Кайсы вакыт бәхәсләштем. Инде кичер!**
**Җитмәгәндер бәлки кайчан минем сәләт.**
**Кысан юлга сыймый калса титан фикер,**
**Халкым түгел, телем түгел, үзем сәбәп.**

**Пеште ләкин татар изгән шигъри камыр,**
**Инглиз салган төсле яңа икмәк калыр!**

Бирeдә шуны икърар итәргә кирәк: «инглиз салган төсле» итеп татар укучылары өчен «яңа икмәк» әзерләү авыр һәм катлаулы эш иде. Барыннан да элек, Шекспирга хас сурәтләү тукымасы буяуларга, мәгънә төсмерләренә ифрат дәрәҗәдә бай. Өстәвенә, Шекспир фикер тирәнлегенә, хисләр байлыгына ирешү өчен, кагыйдә буларак, бер сүзне бер үк вакытта төрле мәгънәдә куллана. Әйтик, менә аның беренче сонеты мондый сүзләр белән башлана:

— Фром феэрист критшә ви дизайә инкрис... [1]

Бирeдә «феэрист критшә» тезмәсе үз эченә берничә мәгънә төсмерен ала. Атап әйткәндә, аңарда «иң гүзәл яратылыш» мәгънәсе бар. «Иң асыл зат», «иң сылу ханым» мәгънәләре дә, шулай ук «керсез сафлык» төшенчәсе дә бар. Боларның кайсысын тәрҗемәдә чагылдырырга?

Кыскасы, Шекспир сонетларын турыдан-туры инглиз теленнән тәрҗемә иткәндә, шагыйрьне һәр адымда менә шушындый сораулар сагалый. Икърар итәргә кирәк, Ш. Мөдәррис Шекспирны дөрес аңлап эш иткән. Дәлил итеп, югарыдагы мисалга бәйләнешле мәсьәләне генә алыйк. «Феэрист критшә» тезмәсендәге мәгънә төсмерләре зерым мөстәкыйльлек белән файдаланылмыйлар. Киресенчә, алар сурәтләү тукымасында бер бөтеннең кисәкләре булып кына торалар. Димәк, тәрҗемәдә әлеге мәгънә төсмерләренең берсенә дә өстенлек бирергә ярамый. Икенчедән, сонетта сүз фәлсәфи мәгънәдә матурлыкны раслау, аны үлемсез итү турында бара. Шушы якларны исәпкә алып, Ш. Мөдәррис әлеге тезмәне «саф гүзәллек» дип ала һәм бик дөрес эшли.

Ниһаять, югарыда китерелгән юлда тагын бер «мәшәкатьле» сүз бар. Ул — дизайә. Иң көчле теләк, үтенеч, таләп, омтылыш, хыял, кайнар дәрт. Бу фигыльнең мәгънә төсмерләре менә шулар. Монысын татарчада тәгъбир итү өчен дә юлы та-

[1] Шекспир. Сәхнә әсәрләре, поэмалар, сонетлар. Инглиз телендә. 1906 ел. 802 бит.

булган. Җөмләне әндәү интонациясенә кору — көчле омтылыш хисен тудырырга җитәрлек булып чыккан:

**Без телибез: саф гүзәллек арта барсын.**

Күрәсез, җөмлә нинди дәрт һәм егәрлек белән агыла. Шул ук вакытта әлеге юлның тәрҗемә икәне дә сизелми. Ул үзенең бөтен асылы белән табигый рәвештә татарча яңгырый. Бу — барлык сонетлар тәрҗемәсенә хас сыйфат.

**Син — табигать ясап куйган затлы мөһер,**
**Токымнарга эзен бассын синең гомер.**
*(17 бит.)*

Яки:

**Кем үз-үзен дошман күрә, ул бәндә дә**
**Бүтәннәргә гашыйк булмый үлгәндә дә.**
*(15 бит.)*

Болар — һәр шагыйрьнең тел культурасын бизәрлек юллар. Аларда укучының эстетик зәвыкларын күтәрерлек матурлык бар, акыл эшчәнлеген кузгатырлык отышлы фикер бар.

Ләкин Ш. Мөдәррис хезмәтенең кыйммәте моның белән генә чикләнми әле. Мәгълүм ки, Шекспир иҗат иткән сонетләр дөньясы рухи хәзинәләргә бай. Анда бөек сүз остасы чын матурлыкны раслый, хакыйкатьне яклап тавыш бирә, яхшылыкны олылый. Боларның барысы белән дә бүген татар укучылары да ләззәтләнә алалар. Нәкъ менә шушы ягы — Шекспир сонетларын татар укучылары хәзинәсенә әйләндерүе белән — Ш. Мөдәрриснең бу хезмәте бүгенгә татар совет поэзиясенең сонет өлкәсендә ирешелгән югары казанышы булып тора.

Инде килеп бүгенге сонетларга күз салыйк. Хәзерге көндә сонет язу белән Мәхмүт Хөсәен шөгыльләнә. «Җир мәрҗәннәре» дигән исем астында 1967 елда басылып чыккан сонетлар җыентыгы бу юлда шагыйрьнең беренче адымы булса, 1970 елда инде ул үзенең икенче сонетлар гөләбен иҗат итте. М. Хөсәеннең югарыда исемләнгән хезмәтләре үз вакытында шагыйрьләребез тарафыннан уңай гына бәя алдылар. Мәсәлән, «Җир мәрҗәннәре»нең Ватан, Җир, Халык, Хезмәт, Намус кебек җитди темаларга язылуын билгеләгәннән соң, үз сүзен дәвам итеп, Нәби Дәүли болай язды: «Шагыйрь гүзәл мәрҗәннәрдән укучыны сокландырырлык муенса тезеп чыккан. Шигырьләрне бергә кушып укыганда, бу — Ватан турында, аның кешеләре, эшләре турында биографик поэма». («Социалистик Татарстан» газетасы. 1968 ел. 19 октябрь.) Менә «Ильич — мәңгелек!» исемле сонетлар гөләбе турында Г. Афзал сүзләре: «Аларда кайбер прозаизм элементлары булуга карамастан, сәнгатьчә оста табылган әдәби образлар ялтырап китәләр. Гомумән, бу сонетларны М. Хөсәеннең уңышы дип карарга була». («Социалистик Татарстан». 1971 ел. 28 март.)

Ләкин китерелгән өзекләрдә урын алган бәя, безнеңчә, бер яклы карашка гына нигезләнгән. Н. Дәүли, мәсәлән, бары тик тематиканың әһәмиятле булуына таянып, «сокландыргыч муенса тезеп чыккан» дигән нәтиҗә ясаса, Г. Афзал «әдәби образлар ялтырап китү» фактыннан чыгып үз фикерен гомумиләштереп куя. Шуңа күрә дә бу урында М. Хөсәен сонетларына җентекләбрәк күз салу урынсыз булмас шикелле. Башта сүзне шагыйрьнең үзенә бирик. Шекспир сонетларының татарча басмасына язган соңгы сүздә М. Хөсәен мондый сорау куя: Нәрсә соң ул сонет? һәм болай дип җавап бирә: «Инглиз сонеты, классик итальян сонеты кебек үк, ундүрт юлдан тора. Ул итальян сонетыннан шуның белән аерыла ки, инглиз сонетында беренче дүрт юлдагы рифмалар икенче строфада кабатланмый. һәм ул дүрт юллы өчәр һәм ике юллы бөрәр строфага нигезләнә, ягъни соңгы ике юлда бар әйтелгәннең каймагы-нәтиҗәсе бирелә». (170 бит.)

Барыннан да элек, китерелгән өзеккә кечкенә булса да бер төзәтмә кертәсе бар. «Инглиз сонеты» «итальян сонетыннан» аерыла дип гомумиләштерү дөрес түгел. Англиядә беренче сонет авторлары — Уайтт һәм Серрей нәкъ менә Петрарка кебек язалар. Алардан соң да классик сонет формасы Англиядә гамәлдән чыкмый. Шуңа күрә дә бу очракта сүз гомумән «инглиз сонеты» турында түгел, бары тик Шекспир сонетлары турында гына барырга мөмкин.

Ләкин безне кызыксындырган төп мәсьәлә — М. Хәсәенчең сонет турындагы аңлатмасы. Игътибар итик, әлеге өзектә ул сонетның тышкы сыйфатларын гына билгеләп үтә, атап әйткәндә, юл санын, рифмаларны. Ә инде сонетның эчке формасы турында, ягъни эчтәлекнең бирелеше турында ләм-мим юк. Әйтерсең лә сонетны сонет иткән нәрсә бары тик юллар саны да рифмалар гына. Кызганычка каршы, эчтәлек бирелешенә игътибарсызлык М. Хәсәеннең үз иҗат практикасына да күчкән. Аның күп кенә сонетларында без сонет формасына хас эчтәлек бирелешен күрмибез.

Гөрелдәүгә таүге трактор
Җилфердәде каен чуклары.
Киерелде иркен сулап кыр,
Хуш мәңгегә, мужик сукмагы!

Моннан соң без, сонет эчтәлеге таләп иткәнчә, әлеге теманың икенче юнәлештә дәвам итүен көтәбез. Әнә бит Шекспир ничек беренче катренда матурлыкны арттырырга чакыра да, икенчесендә инде «әмма син — буш» дип теманы икенче якка борып җибәрә. Мәхмүт Хәсәен сонетында андый борылыш юк. Ул беренче катрендагы эчтәлекне шул ук планда дәвам итә:

Кияүләрчә, кызыл күлмәктән
Комбайннар керде басуга.
Агылды җыр һәрбер төбәктән,
Бишьеллыклар ишек ачуга.
*(9 бит.)*

Күрәсез, фикер һаман бер юнәлештә ага, эчтәлеккә бары тик яңа детальләр генә өстәлә. Өченче катренда да үзгәреш күренми. Нәтиҗәдә конфликтлылык хәлендә алынган теге я бу хисне, күренешне, фактны чишү, хәл итү диалектикасын тәгъбир итәсе урынга, М. Хәсәен сонетларының эчтәлеге күп очракларда укучыга күптән таныш нәрсәләр турында иң риторик сүзләр белән информация биругә кайтып кала.

Укыйбыз:

«Кузгал, уян, ачлар дөньясы!..»
Кабатлый Җир шары бу җырны.
Ул — хөрлекнең таүге кояшы.
Ул җитәкли алга зур чорны.
Ул Потьеның йөрәк каныннан
Баррикадаларда кабынган.
Егәр алып Ирек таңыннан,
Көрәш гимны булып танылган...
*(6 бит.)*

Бу юллар алып килгән эчтәлек — ул сонет киемәнә төренгән гади информация, башка һич ни түгел. Дөрес, бик кыйммәтле информация. Ләкин информация. Эчтәлекне болай тәгъбир итү сонет канунына, димәк, шигърият канунына сыеша алмый.

«Җир мәрҗәннәре»ндәге сонетлар арасында тагын шундыйлар очрый, аларда үз мәгънәсен үзе сөйләп торучы шигъри чынбарлык юк, таркаулык, мәгънәсезлек дисәк инде, ул ташып тора.

Хис тезгенен нык тот, җебемә:
Тәгәрәрсең упкын төбенә.
*(72 бит.)*

Бу — 65 сонетның соңгы юллары. Аларга карап фикер йөрткәндә, алдагы катреннарда чын хисләр драмасы уйналган булырга тиеш. Әйтик, кемдер хис тезгенен нык тотмау, җебегәнлек күрсәтү аркасында бәлагә тап булган, упкын төбенә тәгәрә-

гән, яки, һич кимендә, хур булә язган. Әлеге юллар алда нәкъ менә шундый контекст булуын таләп итә. Ләкин катреннарда андый хисләр драмасы юк.

**Түбә тирән гыйшык төненең,**
**Гыйшык газаплары — чын яра,**
**Асылташын диңгез төбеңең**
**Сөсеп егет ярга чыгара.**

Бармы бирегә тезгенсез хисләр, җебегәнлек? Юк. Укуны дәвам итәбез:

**Сапферларның сафлык сибүе**
**Сөендерә аның сөйгәнен.**
**«Чын булса,— ди кызый,— сөюең,**
**Учыма сал әнкәң йөрәген!..»**

Бусында да андый драма сизелми. Киресенчә, бирегә егет белән кыз арасында татулык, хисләр гармониясе хөкем сөрә. Ниһаять, менә соңгы катрен:

**Чынга аша кызның теләге,**
**Юлда егет таеп егыла...**
**Шул хәлдә дә ана йөрәге:**
**«Имгәнмәдеңме!» — ди улына.**

Ләкин бирегә дә тезгенсез хисләр юк, упкын төбенә тәгәрәп хур булу юк. Егетнең юлда таеп егылуын упкын төбенә тәгәрәү дип булмый бит инде. Кыскасы, бирегә сонетны очлаучы юллар күтәргән мәгънә йөге алдагы катреннар тарафыннан әзерләнмәгән, димәк, ул сәнгатьчә дәлилләнмәгән. Шуңа күрә дә сонетның төп идея-эстетик яңгырашын тәшкил итәргә тиешле соңгы фикер сурәтләү тукымасына бәйләнми. Нәтиҗәдә сонет таркала, сәнгатьчә бөтенлек югала. Ни өчен шулай килеп чыккан соң? Сәбәп шул: М. Хөсәен бу очракта таләпчән форма кысымын җиңә алмаган. Беренче катренны гына алып карыйк. Барыннан да элек, аңарга фикер агышы өчен иң кирәкле нәрсә — логика җитми. Әйтик, соңгы ике юлның алдагыларына нинди бәйләнеше бар? Һичнинди. Беренче ике юл, кем әйтмешли, мәгърипкә карасa, соңгылары мәшрикъка төбәлгән. Мондый чатаклыклар, шөбһәсез, таләпчән форма кысымын җиңә алмау бәласе. Нәкъ менә шуның аркасында бирегә үз мәгънәсен үзе сөйләп торасы шигъри чыныбарлык урынына таркау, буш сонет кысасы гына килеп чыккан.

М. Хөсәен сонетларының формасына карата да тел-теш тидерерлек урыннар юк түгел. Югарыда китерелгән беренче сонетның рифмаларына игътибар итик: дөньясы — кояшы, җырны — чорны — болар бик күп тапталган ярлы рифмалар. Катреннарда урыны-урыны белән а — а — б — б схемасына нигезләнгән парлы рифмалар кулланулы да сонет кануннары хупламый. Чөнки болай рифмалаганда бер бөтенне тәшкил иткән дүрт юллык урынсызга икегә бүленә. Сонетларның сурәтләү тукымасын алып караганда да, урыны-урыны белән чатаклыкларга очрарга туры килә.

**Ил, телләре төрле булса да,**
**Бер дошманга каршы үзләре!**
**Гомерләрен үлем буса да,**
**Тормыш бөркеп яна күзләре!**
*(15 бит.)*

Табигый рәвештә сорау туа: үлгән кешеләрнең күзләре ничек итеп «тормыш бөркеп яна» алсын икән? Яки Мәхмүт Хөсәен мәхәббәт турында чын күңелдән җитди итеп сөйләп килә дә, аннары бу хис китергән тынгысызлыкны кәтмәгәндә «төклетура» әшчәнлегенә охшатып куя. Яки ул болай ди:

**Мәхәббәт ул — әҗәл даруы,**
**Тугыз баллы хисләр давылы.**
*(«Казан утлары». 1971 ел. 9 сан. 114 бит.)*

«Төкләтура», «тугыз баллы хисләр» — болар сонет тукымасына шунда ук ясалмалылык шәүләсе төшерәләр. Гүя шаярып кына, юри-мырый гына сөйләнә шикелле.

Сонет кануннарыннан читкә китү күренеше белән без шагыйрьнең сонетлар гөләбендә дә очрашабыз. Мәгълүм ки, сонет гөләбе 14 сонеттан тора һәм 15 нче сонет — магистраль белән очлана. Соңгысы исә алдагы сонетларның кабатланып килгән юлларыннан төзелә. Магистральнең вазифасы шул: алда тәгъбир ителгән уйтойгыларның сәземтәсе буларак, ул барлык сонетлар күтәргән эчтәлекне кабат яктыртып җибәрергә һәм шушы нигездә бер мәртәбә кабул ителгән хисләрне яңабаштан кичерү өчен укучыда этәреш тудырырга тиеш.

«Ильич — мәңгелек!» исемле сонетлар гөләбендә исә магистраль бу вазифаны үти алмый. Чөнки ул үз урынында түгел. Биредә магистраль гөләбне тәмамламый, бәлки аны башлап җибәрә. Бу очракта инде магистраль ундүрт сонетның сәземтәсе буласы урынга үзе гади бер сонетка әйләнеп кала.

Хәлбуки, Мәхмүт Хәсәен — һәр яктан килгән чын сонетлар иҗат итү бурычын хәл итәрлек шагыйрь. Форма ягыннан — пөхтә, эчтәлеге белән укучыга гыйбрәтле сабак бирерлек сонетлар аның иҗатында бүгенге көндә дә юк түгел. Мәхмүт Хәсәен сонетның соңгы ике юлын эшкәртүгә аерата зур көч сала. Шуңа күрә дә алар — бер үк вакытта шома да, отышлы да, гыйбрәтле дә.

> **Ихтыярсыз — гөлне көл итә.**
> **Ихтыярлы — көлне гөл итә.**
> *(36 бит.)*

Алар арасында, патриотизм хисе тәрбияләү чарасы буларак, мәктәп залында урын алырлыклары бар:

> **Җиңә белсәң, Ватан әйткәндә,**
> **Әйләнерсең җырга, һәйкәлгә.**
> *(12 бит.)*

Колхоз клубына лаек булганнары бар:

> **Хәләл хезмәт — җирдә алла ул;**
> **Уттан кояш сыгып ала ул!**
> *(42 бит.)*

Иртә-кичен ата-аналар кабатларлыклары бар:

> **Туган телне кисү-телгәләү,**
> **Я белергә аны теләмәү —**
> **Наданлык ул, балам, түбәнлек,—**
> **Гарьлегеңнән шартлап үләрлек!**
>
> **Яхшылап бел, балам, рус телен,**
> **Сандугачтай сайрат үз телең!**
> *(101 бит.)*

Әйе, болар киң җәмәгатьчелек трибунасыннан үзләренә урын сорыйлар.

Бүгенге көндә татар совет поэзиясе, үзенең сурәтләү чараларын камилләштерә баруы белән берррәттән, яңа формалар үзләштерүне дә эзлекле рәвештә дәвам итә. Шигърияtебез мәйданында сонетларның барлыкка килүе — моңа ачык дәлил. Дөрес, сонет формасын үзләштерү юлында ирешелгән беренче уңышлар әлегә җитди кимчелекләр белән чиратлашалар. Ләкин өмет зур — алдагы елларда сонет формасы бик күп талантларны үзенә каратыр һәм кайнар илһам, зирәк акыл сәнгатьчә камил булган яңа сонетларга гомер бирер.

# УКУЧЫ БЕР ГЕНӘ ТӨРЛЕМЕ?

«Казан утлары» журналының быелгы 5 нче санында тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин китап укучыларның зәвыгын гыйльми нигездә өйрәнү кебек гаять әһәмиятле мәсьәлә күтәрә. Әйе, нәшрият һәм язучы өчен дә, әдәби тәнкыйтьне гыйльми нигезгә кую өчен дә социологик мәгълүматларның әһәмияте гаять зур.

Ләкин, ди тәнкыйтьче, ул мәгълүматларны дөрес бәяләү, дөрес яктырту да кирәк. Чөнки «укучы фикере һәм әсәрнең чын әдәби кыйммәте, аларның үзара мөнәсәбәте һәрьяклап җентекләп өйрәнүне сорый торган шактый катлаулы мәсьәлә». Ягъни, әсәрнең күп яисә аз укылуы белән аның идея-сәнгатьчә дәрәҗәсе бер-берсенә туры килмәскә дә мөмкин.

Ары китеп, Р. Мостафин әнә шул катлаулы мәсьәләне хәл итүдә ике чиккә ташлану күрә. Берәүләр (бер төркем язучылар, билгеле), укучыны үзләре өчен бердәнбер авторитет санап, әдәби тәнкыйть белән санашмыйлар. Икенчеләр исә, киресенчә, укучы фикерен бөтенләй исәпкә алмау, читләтеп узуны яклыйлар икән.

Бу кадәресендә тәнкыйтьче, һичшиксез, хаклы. Ләкин ул, укучы зәвыгын өйрәнү мәсьәләсен куйганда, бер моментны күз уңыннан читтә калдырган: китап укучылар массасы бер үк төсле молекулалардан укмашкан монолит түгел бит! Белемнәре ягыннан да, зәвыклары ягыннан да, сәләтләре ягыннан да (бусы да әһәмиятле!) укучылар гаҗәеп төрле. Р. Мостафин исә бер урында «укучы да төрле бит» дигән сүзләр язган булса да, укучылар массасын бербөтен итеп карый, ниндидер монолит укучының фикерен исәкә алу яисә алмау тирәсендә бәхәс алып бара. Ә бит теге яки бу язучының күпме укылуыннан да бигрәк, аның нинди категория укучы тарафыннан укылганын белү әһәмиятлерәк.

Мәкаләдә «Комсомолец Татарии» газетасының бер татар прозаигының һәм бер шагыйрьнең исемен атарга үтенеп моннан ун ел элек укучыларга мөрәҗәгать иткән анкетасы телгә алына. Рус укучыларының күпчелеге Г. Әпсәләмов белән С. Хәкимне атаган икән. Бусы ярый. Әмма зәвык өйрәнүдә шушы кадәресе белән генә чикләнү, белмим, зур файда китерер микән?

Нәширләр әйтер: әһә, менә кемнәргә тиражны күбрәк бирергә кирәк икән, бүтән шагыйрь һәм прозаикларны бераз кысканда да ярый. Язучыларның исә, «безне рус укучысы да белә» дип, үзләренә таләпчәнлекне киметүләре ихтимал. Тәнкыйтьчегә килгәндә дә шул ук хәл: бөтен союз аренасына чыккан авторны ничек инде тәнкыйть итәсең, мактарга гына кала.

Әгәр инде анкетага җавап биргән укучыларның яше, белеме, профессиясе һәм башка сыйфатлары билгеле булса, әйтик, Хәсән Туфан һәм Фатих Хөсни, Шәүкәт Галиев һәм Әмирхан Еники дә үзләрен аз укылучылар дип санап, күңелләрен бик үк төшермәсләр иде.

Р. Мостафин мәкаләсендәге кайбер очы-очка ялганмаган фикерләр, бик үк төгәл булмаган бәяләүләр, фактларны алдан уйланган схемага куып кертергә омтылу нәкъ менә укучылар массасының сыйфат составын исәкә алмыйча, бербөтен итеп карау белән бәйләнгән.

«Чиккә ташлануның беренче төре»нә караган фикерләрне шик астына алып булмый. Ләкин Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» романын популярлык белән сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсенең туры килмәвенә мисал итеп китерү, минемчә, бөтенләй урынсыз. Роман «соңгы еллар татар про-

засының иң популяр әсәре»дерме, әйтүе кыен. «Китапханә эшчеләренең фикеренә карагандә» дигән сүзләр генә дәлил була алмый. Ләкин хикмәт анда түгел. Сүз бит бу очракта сәнгать ягыннан түбән булып та, популярлык казанган әсәрләр турында бара.

Ә инде үзен хөрмәт иткән кайсы тәнкыйтьче һәм нинди зәвыклы укучы бу романны шундый әсәрләр җөмләсенә кертер икән? Роман файдасына түбәндәге фактны да китерми булмый. «Укучыларны,— дип яза Н. Фәттах,— гадәттә, әдәби әсәрдәге теге-бу геройның соңгы язмышы кызыксындыра. Укучылар: фәлән кыз белән фәлән егет кавыштылар микән, фәлән кеше бүгенге көндә кайда яши икән кебегрәк сораулар биреп, авторны еш кына аптырашта калдыралар. Бу юлы миңа андый хатлар килмәде. Бу юлы килгән хат авторларының күпчелеген романдагы аерым геройларның язмышы түгел, бәлки башка нәрсә — халкыбызның бай тарихы һәм шул тарихның романда ничек чагылуы мәсьәләсе кызыксындыра» («Казан утлары» журналы. 1972 ел. 6 сан. 195 бит). Күренә ки, «Этил суы ака торур» романы җитди, зәвыклы һәм хәзерлеклерәк укучылар арасында популяр булып киткән икән.

Р. Мостафин кебек сәләтле һәм тәҗрибәле тәнкыйтьченең Н. Фәттах романын тиешле дәрәҗәсеннән күп түбәнәйтеп бәяләвен ничек аңлатырга соң? Минемчә, ул әсәрнең үзенчәлегенә игътибар итмәгән: бик борынгы чор һәм әкият-легендаларга тартым чыганаклар авторны романтик ачкычта язарга этәргән. Ә Р. Мостафин аны реализм таләпләреннән чыгып тәнкыйтьли. В. Г. Белинскийның һәркайсыбыз бөти итеп тагарлык сүзләрен онытмыйк: әсәрне аның үз законнарыннан чыгып хөкем итәргә кирәк, дигән бит ул.

«Чиккә ташлануның икенче төре»нә килсәк, биредә мәсьәлә җитдирәк төс ала. Р. Мостафин, укучының фикерен искә алырга кирәк, ди. Әйе, кирәк. Ләкин күп кенә сораулар туа: кайсы төркем укучының фикерен? Нинди мәгънәдә һәм нинди максат белән? Кем, ни рәвешле искә алырга тиеш? Нәширме? Язучымы? Тәнкыйтьчеме? Түбән зәвыклы укучыларның ихтыяҗын искә алып, массовый тираж белән урта кул детектив чыгарып ятучы нәшриятны, мәсәлән, хуплап булмаган кебек, бу категория укучыларны күздә тотып яза торган авторны художник дип атау кыен. Димәк, нәшрият та, үзен хөрмәт иткән талантлы язучы да югары зәвыклы укучыны күздә тотып эш иткәндә генә уңышка ирешә алалар. Тәнкыйтьчегә килгәндә исә, әсәрне бәяләгәндә ул берсенең дә — түбән, урта һәм югары зәвыклы укучының да — фикерен искә ала алмый. Сәбәбе бик гади: бит ул әсәр турында башлап сүз әйтергә тиеш! Аның төп киңәшчеләре — тормыш үзе һәм сәнгатьнең гасырлар дәвамында кристаллашкан кануннары.

Рәсми тәнкыйть һәм тамашачы фикере арасында туры килмәүчелеккә мисал итеп Р. Мостафин «Моабит дәфтәре» фильмын китерә. Дистәләрчә уңай рецензия басылган иде, ди (шулар арасында үзенеке дә). Әмма тамашачы фильмны кабул итмәде, әсәр төшеп калды. Һәм сәер нәтиҗә: хәзер инде «без үзебез үзгәрергә, фильм турындагы элекке карашларыбыз турында тагын бер кат ныклап уйланырга тиешбез». Соң шулай булгач, Рафаэль дускай, ул фильм турында ни өчен уңай рецензия яздың? Алай эшләмәгән булсаң, «үзгәрергә» кирәк булмас иде. Аннан килеп, кем кемне үзгәртергә тиеш? Тамашачы тәнкыйтьченеме, тәнкыйтьче тамашачынымы?

Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы уңае белән әйтелгән фикерләрдә дә очы-очка ялганмау күзгә ташлана. Әсәрнең журнал варианты буенча үткәрелгән фикер алышуда күренекле язучы һәм тәнкыйтьчеләр, шул исәптән Р. Мостафин үзе, «романдагы җитди кимчелекләр турында» сөйләгәннәр. Аннары автор, «ул фикерләремнән мин әле дә кайтырга җыенмыйм», ди. Шуның артыннан ук болай дип белдерә: «Аннан бирле узган еллар хәзер безне бу әсәргә бераз башкачарак күзлектән карарга мәҗбүр итә». Сәбәбе — 6—7 ел эчендә роман гаять популяр булып киткән икән. Гаҗәп логика! Башкачарак күзлектән карау элекке фикерләрнең кайберләреннән генә булса да баш тарту түгелмени?

Мәкаләдәге әнә шундый, йомшак итеп әйткәндә, сәер фикерләр — автор үзе телиме, теләмиме — укучыны ике ялгыш нәтиҗәгә китерергә мөмкин.

Беренчесе. Әгәр укыла икән, теләсә нинди әсәр дөньяга чыгарга хаклы. Дөрес, Р. Мостафин бу кадәресен үк әйтергә теләми. Ләкин укучылар массасын дифференциацияләмичә, бербөтен итеп каравы, әнә шул монолит укучының фикере белән хисаплашырга чакыруы шуңа китерә. Менә аның, мәсәлән, Х. Вахит пьесаларын нигедер бер театр белгеченнән яклап әйт-

кән фикерләре. «Әгәр,— ди тәнкыйтьче,— Х. Вахит сәхнә законнарын шәп белә, комедиячел ситуацияләр таба, тамашачыны киеренке хәлдә тота, үз артыннан ияртә ала икән, бу начар сыйфатмыни? Инде еш кына аның әсәрләренә **тормышчан тирәнлек, зур иҗтимагый мәсьәләләр күтәрү, безнең чынбарлыкның яңа, кызыклы якларын чагылдыру җитми** (ассызык минеке — И. Н.) икән, бусы бөтенләй башка мәсьәлә». Әйтегез инде, соңгылары булмагач, Х. Вахитның сәхнә законнарын белүеннән ни файда? Кызык яклау! Тәнкыйтьче Х. Вахит пьесаларын, үзе дә сизмәстән, бетереп ташласа да, аларны сәхнәдән күрсәтүне хуплый. Чөнки, ди, тамашачы йөри. Тик бу урында да Р. Мостафин үз-үзенә бер сорау бирергә оныткан: нинди тамашачы, тамашачыларның кайсы категориясе?

Икенчесе. Р. Мостафин — үзе телиме, теләмиме — әдәби тәнкыйть арбасын әлеге «киң катлау укучылар массасы» дип аталган монолитның койрыгына тагып куя. Әсәрне бәяләүдә төп рольне укучы башкарырга тиеш, ә тәнкыйтьче, укучы фикере формалашканны көтеп алып, шуңа бер мөһер сугып куярга тиеш була. Башлап сүз әйтсә, ялгышуы мөмкин һәм беренче фикерен үзгәртергә туры киләчәк.

Юк, чын әдәби тәнкыйть мондый роль белән килешә алмый. Һәр вакыт ул алдан барды, һәр вакыт ул укучыны тәрбияләде, укучыны үз дәрәҗәсенә күтәрергә тырышты. Бер генә фактны искә төшерик. Рус укучысы Бенедиктов дигән шагыйрьне ябырылып укыганда һәм аны Пушкиннан югарырак куйган бер вакытта, В. Г. Белинский чыга да бу авторның шигырьләрен итен-иткә, сөяген-сөяккә аерып анализлый һәм әйтә: «Юк, Бенедиктов шагыйрь түгел»,— ди.

Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында тәнкыйтьнең «хезмәт ияләрен идея-эстетик яктан тәрбияләргә» тиешлеге мәсьәләсенә басым ясалу шулай ук очраклы хәл түгел.

Мәкаләдәге төгәлсезлекләрне күрсәтү белән бергә, Р. Мостафин күтәргән төп мәсьәләгә кайтып, тәнкыйтьчене кат-кат яклыйсы килә. Әйе, укучыларның фикерен һәм зәвыгын социологик планда өйрәнергә керешергә күптән вакыт! Бу юнәлештә, минемчә, иң элек Татарстан Культура министрлыгы һәм Язучылар союзы мөһим чаралар билгеләргә тиешләр. Газета-журнал редакцияләре исә, социологик лабораторияләр оешканны көтмичә, үзләрендәге мөмкинлекләрдән файдаланып, кичекмәстән шушы эшкә керешсеннәр иде. Ләкин укучыларны өйрәнү гомуми төстә барса, кемне күпме укуларын ачыклауга гына кайтып калса, моннан файда аз булачак. Укучылар массасының **сыйфат** составы өйрәнелергә тиеш. Кемне **нинди** укучы укый, кемгә **нинди** тамашачы йөри — без менә нәрсәне белергә тиешбез. Гомумиләштерелгән мәгълүмат исә һәм нәшриятка, һәм язучыларга үзләре өчен тиешле нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирәчәк. Ә инде әдәби тәнкыйтькә ул мәгълүмат идея-эстетик тәрбия эшен ничек, нинди юнәлештә алып барырга кирәклекне күрсәтә торган компас булыр иде.

**И. НУРУЛЛИН.**

*ЯҢА КИТАПЛАР*

# НУР ӨСТЕНӘ НУР

Соңгы елларда татар хатын-кызларының Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәрге һәм Совет властеның беренче елларындагы иҗтимагый эшчәнлегенә багышланган фәнни хезмәтләр еш күренә башлады. Әле 1971 елда гына В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты ассистенты А. Мәхмутова үзенең кандидатлык диссертациясендә татар хатын-кызларының нинди авырлыклар белән укырга тырышуларын күрсәтеп биргән иде. Бераздан тарихыбызның бу өлкәсе шул ук югары уку йорты доценты В. Смирнованың докторлык диссертациясендә тагын да тулырак ачылды. Күптән түгел генә әлеге хезмәтләргә «Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан»[1] исемле яңа китап өстәлде.

Бу хезмәтнең авторы Заһидә Бурнашева — олы тормыш юлы үткән карт большевик. Ул 1895 елда хәзерге Рязань өлкәсенә кергән Әҗе авылында сәүдәгәр семьясында туа, семьяда хөкем сөргән патриархаль тәртипләрне, иске гореф-гадәтләрне җиңеп, рус мәктәбендә укырга ирешә. Капиталистик тормышка көчле протестын яшь Заһидә үзенең шигырьләре аша белдерә. 1915—16 елларда аның «Гыйффәт туташ шигырьләре» исемле китабы дөнья күрә. Революция елларында исә Заһидә Бурнашева азатлык өчен ялкынлы көрәшчеләр сафына баса. Ул елларда аның Совет Урта Азиясендәге революцион эшчәнлегенә Үзбәкстан Компартиясе югары бәя бирә. Совет властен ныгыту чорында Заһидә Бурнашева укытучы, совет органы хезмәткәре була, партиянең төрле органнарында, шул исәптән РКП(б) Үзәк Комитеты аппаратында, эшли һәм бөек Ленинны тыңлау бәхетенә ирешә. Егерменче елларда ул Коммунистик Интернационалның II нче конгрессында катнаша...

Элекке тормышның бөтен ачысын татыган, Октябрь революциясенең алгы сафында булып яңа тормыш өчен көрәшкән һәм илдә халык власте урнашкач җиң сызганып эшкә тотынган, тарихның зур вакыйгаларын үз башыннан кичергән ялкынлы йөрәкле бу большевикның яңадан кулына каләм алуы — шатлыклы күренеш. Аның «Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан» дигән китабы кечерәк-кечерәк дүрт бүлектән тора. Менә «Патша Россиясендә хатын-кызлар» дигән беренче бүлек. Монда автор, ул вакытта чыгып килгән газета-журналларга, соңрак басылып чыккан кайбер фәнни хезмәтләргә таянып, патша заманындагы татар хатын-кызларының аяныч хәлен, демократик язучыларның аларны яклап, еш кына деспотизмга каршы чыгуларын яза. Шул ук бүлектә әдәбиятка омтылган һәм анда берникадәр эз калдырган хатын-кызларга багышланган язмалар да бар. Китапның икенче бүлеге укучыларны татар хатын-кызларының 1905 елгы революция чорындагы эшчәнлекләре белән таныштыра. Анда Зөһрә Таһирова, Фәрхәнә Алушева, артистка Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаялар кебек ялкынлы көрәшчеләр турында да күп нәрсә белергә була. Заһидә Бурнашева хезмәтенең өченче бүлеге «Революцион күтәрелеш һәм Февраль буржуаз-демократик революциясе елларында хатын-кызлар хәрәкәте» дип исемләнгән. Бу бүлектә китерелгән биографияләр, матбугат хәбәрләре татар хатын-кызлары хәрәкәтенең шушы чорын шактый тулы ачалар. Соңгы дүртенче бүлек Бөек Октябрь социалистик революциясе вакытында һәм Совет властен ныгыту өчен барган көрәштә татар хатын-кызларының ролен күрсәтүгә багышланган. Бу бүлектә авторның Абруй Сәйфи, Әминә Мөхетдинова, Гыйззениса Таҗетдиновалар турындагы язмалары кызыксынып укыла.

Заһидә Бурнашева үзенең бу китабын тулысынча дип әйтерлек документлар нигезендә язган. Бу, билгеле, китапның әһәмиятен арттыра. Ләкин аны укып чыккач, бер теләк тә туа. Заһидә апа китабында истә калган кызыклы эпизодларны, үзенең кичерешләрен, замандашлары тормышының әлеге документларда чагылмаган көрәш моментларын күбрәк язса, китап тагын да отышлырак булыр иде. Хезмәтнең киң катлау укучыларга адресланган булуын да искә алсак, бу бигрәк тә кирәк.

**Риф ХӘЙРЕТДИНОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

[1] Заһидә Бурнашева. Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан. Казан. 1971 ел.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЖУРНАЛ ТИКШЕРҮ

17 октябрьда язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Татарстан язучылар союзы идарәсенең киңәйтелгән утырышы булды. Ул «Казан утлары» журналының 1972 елгы 1—8 саннарын тикшерүгә багышланган иде. Утырышта катнашучылар әдәбиятның аерым жанрлары турында докладлар тыңладылар. Яшь язучы М. Маликовка журналның сигез санында басылган проза әсәрләре турында, Роберт Әхмәтжанов поэзия турында, нефть районнарында яшәүче прозаик Ш. Бикчурин очерклар, Алабуга педагогия институты проректоры, филология фәннәре кандидаты Ф. Урманчеев журналда чыккан тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләр турында сөйләде.

Докладлар буенча фикер алышуларны Б. Камалов башлап җибәрде. Ул докладларның нигездә әйбәт тәэсир калдыруларын әйтте. «Шул ук вакытта мин М. Маликова докладындагы кайбер фикерләр белән килешеп бетмим,— диде ул.— Докладчы М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романын кирәгеннән артык мактады кебек. Сүз дә юк, «Фронтовиклар» — әйбәт роман. Бусы — бәхәссез. Әмма әсәрдә йомшак урыннар да бар бит. Докладчы әсәрнең шул якларына да игътибар итәргә тиеш иде.

А. Гыйләҗевне дә бу кадәр пьедесталга менгерү кирәкмәс иде. «Урталыкта» — нигездә җыйнак эшләнгән повесть. Шулай да аңа динамика җитми, әсәрдә хәрәкәт аз. А. Гыйләҗев бу әсәрендә күпмедер дәрәҗәдә үз-үзен кабатлый. «Урамнар артында яшел болын» исемле романында ук әйткән кайбер фикерен монда кабат күтәреп чыга. Докладчының «Каты токым» романына биргән бәясе һәм «Сүзсез җыр» повесте хакындагы фикерләре белән исә гомумән килешеп булмый. М. Маликова аларны уңышсыз әсәрләр рәтенә кертте. Мин алай димәс идем.»

Б. Камалов башлаган сүзне алга таба Г. Иделле дәвам иттерде: «М. Маликова «Каты токым» романындагы образларны бер-берсеннән аерып булмый, диде. Миңа калса, киресенчә, аларның күбесе тормышчан, җанлы характер булып хәтердә кала. Алыгыз Кадермәтне, Мотгәрәйне, я булмаса Фәрхетдинне. Кем аларны бер-берсеннән аерып булмый, дип әйтә алыр? Җыйнак кына бер романда язучы башта әле шактый чуар кешеләрдән торган бригаданың ныклы коллектив булып туплануын күрсәтә алган. Әсәрнең төп кыйммәте әнә шунда».

Г. Бакиров белән Р. Мостафин да проза әсәрләренә багышланган докладтагы аерым фикерләр белән бәхәскә керделәр, журналда чыккан проза әсәрләренә булган бәяне ачыклардай тәкъдимнәр әйттеләр.

Шагыйрь Х. Туфан журналда басылган шигырьләр турында сөйләде, докладчы Роберт Әхмәтжановның кайбер фикерләре шактый бәхәсле булуын әйтте.

Х. Хәйри журналның тәнкыйть бүлеге турында сөйләде. «Тәнкыйть турындагы доклад нигездә әйбәт тәэсир калдырды,— диде ул.— Шулай да аны тагын да кызыклырак, үткенрәк итәргә мөмкин булыр иде. Журналда социалистик реализм мәсьәләләре аз яктыртыла. Соңгы вакытларда чыккан кайбер мәкаләләрдә бик үк төгәл булмаган фикерләр күренеп калды. Докладчы, ни өчендер, аларга игътибар биреп җиткермәгән».

Фикер алышуларда, болардан тыш, Ф. Хөсни, Татарстан язучылар союзы идарәсенең председатель урынбасары Г. Кашшаф катнашты. Алар журналны тагын да яхшырту буенча кызыклы фикерләр, файдалы тәкъдимнәр әйттеләр.

Ахырдан журналның баш редакторы Г. Ахунов чыгыш ясады. Ул журнал папкасындагы яңа әсәрләр турында сөйләде, язучыларны редакциянең эш планнары белән таныштырды.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Октябрь башларында Г. Тукай исемендәге клубта язучыларның ачык партия җыелышы булып үтте. Ул «Язучы һәм газета» дигән темага багышланган иде. Җыелышта катнашучы язучылар алдында «Социалистик Татарстан» газетасының редактор урынбасары Р. Тимергалин, «Советская Татария» газетасының культура бүлеге мөдире А. Авдеев, «Татарстан яшьләре» газетасы редакторы С. Гарипов, «Комсомолец Татарии» газетасының бүлек мөдире Н. Сальтина, «Яшь ленинчы» газетасы редакторы В. Ихсанова иптәшләр чыгыш ясады.

Фикер алышуларда Г. Минский, Х. Туфан, А. Шамов, Ф. Хөсни, Т. Миңнуллин, К. Латыйповлар катнашты.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Көз җитүгә Татарстан язучылар союзы каршындагы иҗат секцияләренең эше тагын да активлаша төште. Сентябрь-октябрь айларында барлык секцияләрнең утырышлары булып үтте.

Балалар әдәбияты һәм проза секцияләренең 27 сентябрьдә уздырылган берләштерелгән утырышы Мәгъсум Хуҗинның «Йомры тау итәгендә» исемле хикәяләр җыентыгын тикшерүгә багышланган иде. Кульязма җыентык буенча фикер алышуда Б. Камалов, А. Гыйләҗев, Ф. Мансуров, Л. Ихсанова, Р. Мингалимов, Р. Вәлиева, Т. Миңнуллин, Т. Нурмөхәммәтов катнаштылар. Алар җыентыктагы байтак хикәяләрнең шактый уңышлы булуын билгеләп үттеләр. Авторга хикәяләрен тагын да яхшырту юнәлешендә күп киңәш бирелде.

* * *

Драматурглар секциясенең 19 октябрьда уздырылган утырышында Шамил Бикчуринның «Тальян гармун» исемле либреттосының яңа варианты укып тикшерелде. Фикер алышуда катнашкан иптәшләрдән М. Хәсәнов, Ә. Камал, Т. Миңнуллин, Ә. Бакиров либреттоның уңышлы булуын әйттеләр.

* * *

Балалар әдәбияты секциясенең 24 октябрьда уздырылган чираттагы утырышы Хәкимҗан Халиков иҗатын тикшерүгә багышланды. Утырышта Г. Рәхим, К. Миңнебаев, Б. Камалов, Ш. Рәкыйпов, Г. Гобәй, А. Әхмәт, Ш. Галиев, Р. Әхмәтҗанов, Г. Бакиров, З. Туфайлова һәм Л. Ихсановалар чыгыш ясады. Фикер алышуда катнашучыларның күпчелеге авторның уңышлы иҗат итүен билгеләп үттеләр. Утырыш Хәкимҗан Халиковны язучылар союзына алуны тәкъдим итәргә дигән фикергә килде.

* * *

26 октябрьда шагыйрьләр секциясенең дә чираттагы утырышы булып узды. Анда яшь шагыйрьләрдән Салисә Гәрәева һәм Фәннүр Сафиннарның яңа җыентыклары тикшерелде. Кульязма җыентыкларны тикшерүдә Н. Арсланов, Ә. Исхак, Х. Туфан, Роберт Әхмәтҗанов, Г. Зәйнашева, З. Маликов катнашты.

## СССРның 50 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАП

1972 елның декабрь аенда СССР төзелүгә 50 ел тулды. Бу олы бәйрәмне илебез халыклары хезмәттә зур уңышлар яулап, әдәбият-сәнгать әһелләре исә яңа әсәрләр иҗат итеп каршы алдылар.

Бәйрәмгә хәзерлек барган көннәрдә иҗат оешмаларында күп төрле чаралар: җыелышлар, конференцияләр, киңәшмәләр үткәрелде. Шуларның кайберләре белән укучыларны да таныштырып узарга булдык.

## ГАЛИМНӘРНЕҢ БӨТЕНСОЮЗ КИҢӘШМӘСЕ

«Кешеләрнең яңа тарихи гомумилеге — совет халкы һәм социалистик реализм әдәбияты» — 30—31 октябрьларда башкалабыз Мәскәүдә булып үткән фәнни конференциянең темасы әнә шулай атала иде. СССР Язучылар союзы, А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты һәм КПСС Үзәк Комитеты янындагы Иҗтимагый фәннәр академиясе тарафыннан оештырылган бу киңәшмәдә дистәдән артык доклад һәм бик күп чыгышлар тыңланды.

Татарстан язучылары исеменнән конференциядә тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин катнашты.

## ӘДӘБИЯТ ГАЛИМНӘРЕ КИҢӘШӘ

Узган елның октябрь урталарында Әзербәйҗан ССРның башкаласы Бакуда «Совет Көнчыгыш әдәбиятларында реализм мәсьәләләре» дигән темага багышланган фәнни киңәшмә үткәрелде. Конференция эшендә Татарстан галимнәре дә актив катнашты. Филология фәннәре докторы, профессор Х. Госман «Критик реализм әдәбиятларында тарихилык принцибы», филология фәннәре докторы, профессор И. Нуруллин «Төрки телле әдәбиятларда критик реализмның асылы һәм формалашу шартларына карата», филология фәннәре докторы Я. Нигъмәтуллина «XIX йөз ахыры, XX йөз башындагы татар әдәбиятында реализм һәм аның башка иҗат методлары белән мөнәсәбәте», филология фәннәре кандидаты А. Әхмәдуллин «Реалистик татар комедиясенең формалашуы» дигән темаларга докладлар ясадылар.

## ТЕЛ ГАЛИМНӘРЕ КИҢӘШӘ

Татарстан тел галимнәренең СССРның 50 еллыгына багышланган фәнни конференциясе 9 октябрьда ачылган иде. Ул өч көн буена барды һәм анда утыздан артык кеше чыгыш ясады. Галимнәр татар тел белеме узган юлга йомгак ясадылар, туган телебезнең байлыгы, үсеш тенденцияләре турында фикер алыштылар.

Профессор Д. Тумашеваның «Совет чорында татар тел белеменең үсеше һәм аның бурычлары», профессор М. Зәкиевның «Төрле социаль-экономик шартларда әдәби тел үсешенең үзенчәлекләре», филология фәннәре докторы В. Хаковның «Татар әдәби теленең үсешендәге кайбер тенденцияләр турында» дип исемләнгән докладлары тыңлаучыларда аеруча зур кызыксыну уятты.

## СӘНГАТЬ БЕЛГЕЧЛӘРЕ КИҢӘШӘ

Сынлы сәнгать музеенда «1917—1971 елларда Татарстанның сынлы сәнгате» дигән темага конференция булып үтте. Анда барлыгы 8 доклад тикшерелде. Алар арасында «Татарстан сынлы сәнгатендә Ленин образы», «Татарстанда В. И. Ленин һәйкәлләре», «Республика рәссамнарының 30 еллардагы иҗаты», «Бөек Ватан сугышы е-

рында Татарстанның сынлы сәнгате», «Татарстанның бүгенге сынлы сәнгате» дигән темаларга язылган докладлар бар иде.

Конференция эшендә әдәбият белгечләре, рәссамнар, гомуми белем бирү мәктәпләренең укытучылары, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

## НӘШРИЯТ РЕДАКТОРЛАРЫ КИҢӘШӘ

17 октябрьда Казан шәһәрендә Идел буе китап нәшриятлары редакторларының зона киңәшмәсе уздырылды. Анда Татарстан китап нәшриятының политик әдәбият редакторлары, Башкортстан, Чувашстан, Удмуртстан, Мари АССР, Мордва АССР, шулай ук Югары Идел, Түбән Идел, Идел-Вятка һәм Куйбышев нәшриятларыннан килгән кунаклар катнашты. Редакторлар тәҗрибә уртаклаштылар, халыклар дуслыгы һәм пролетар интернационализм мәсьәләләренә багышланган әдәбият чыгаруны тагын да яхшырту турында киңәштеләр.

Киңәшмәдә катнашучыларга КПСС Үзәк Комитеты лекторы, филология фәннәре кандидаты М. Х. Хаммухамметов «СССР төзелүнең 50 еллыгына әзерлек һәм илебез үсешенең кайбер актуаль мәсьәләләре» дигән темага лекция сөйләде.

## ЯЗУЧЫЛАР—УКЫТУЧЫЛАР АЛДЫНДА

Казан педагогия институтында «50 ел эчендә татар совет әдәбияты» дигән темага семинар уздырылды. Аңа рус мәктәпләрендә татар телен укытучы педагоглар чакырылган иде. Семинар эшендә татар язучыларыннан Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, С. Хәким, Ш. Маннур, Г. Гобәй, Л. Ихсанова, Г. Ахуновлар катнашты. Алар 50 ел эчендә татар әдәбияты иреште казанышлар турында сөйләделәр, сорауларга җаваплар бирделәр.

## ТУГАНЛЫК ҖЫРЛАРЫ

Әзербайҗанда РСФСР әдәбияты һәм сәнгате көннәре булып узды. СССРның 50 еллыгына багышланган бу бәйрәмдә безнең республикадан эстрада җырчыларының Бөтенсоюз конкурсы лауреаты Зиннур Нурмөхәммәтов катнашты. Ул тугандаш республика тамашачыларын татар совет композиторларының дуслык турындагы көйләре һәм татар халык җырлары белән таныштырды.

## ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАШУ ӨЧЕН

СССР Язучылар союзы секретариаты, тугандаш социалистик илләрдәге язучылар оешмаларының эшен өйрәнү һәм тәҗрибә уртаклашу өчен, әледән-әле аларга үз вәкилләрен җибәреп тора. Күптән түгел шундый бер делегация Польшада булып кайтты. Аның составында СССР язучылар союзы идарәсе секретаре шагыйрь Зәки Нури да бар иде.

«Наш современник» журналының баш редакторы Сергей Викулов белән бергәләп алар поляк язучыларының Варшавадагы бүлегендә, Лодзь һәм Краков воеводстволары оешмаларында булдылар, алардагы иҗади-оештыру эшләре белән таныштылар.

Алар, шулай ук, «Поэзия көзе» бәйрәмендә катнаштылар, Варшава театрларында һәм музейларында, Краков киностудиясендә тамашачылар һәм укучылар белән очраштылар. Поляк китап нәшриятларына һәм «Әдәбият» исемле атналык газетага илебезнең тугандаш әдәбиятларыннан иң яхшы әсәрләрне, шул җөмләдән, татар әдәбиятының күренекле әсәрләрен тәкъдим итү турында фикер алыштылар.

## «ДАВЫЛГА ТАБАН» — ЗАВОД СӘХНӘСЕНДӘ

Лихачев исемендәге автозаводның культура сарае каршындагы халык драма театры үзенең яңа сезонын татар драматургы Риза Ишморатның «Давылга табан» исемле әсәре белән ачты. Спектакльдәге төп рольләрне завод үзешчәннәре һәм кайчандыр шушы коллективта тәрбияләнгән, хәзер инде танылган сәнгать осталары булып җиткән профессиональ артистлар башкарды. Әсәрне сәхнәгә РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, режиссер С. Штейн куйды.

## ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР, ОЧРАШУЛАР

Мәскәүнең Дөнья әдәбияты институтында М. Горький исемендәге РСФСР дәүләт премиясе лауреатлары иҗатына багышланган әдәби кичә уздырылды. Кичәдә татар шагыйре С. Хәким шигырьләре яңгырады. Мәскәү шагыйре М. Львов тамашачыларны шагыйрьнең иҗаты белән таныштырды.

Татарстан язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау бюросы СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән заводларда, цехларда, торак йортларда кызыклы очрашулар уздыра, меңләгән әдәбият сөючеләрне язучыларның иҗатлары белән таныштыра.

* * *

Оргсинтез заводының торак йортларында яшәүчеләр өчен танкыйтьче Р. Мостафин һәм шагыйрь М. Хөсәен иҗатына багышлап авторлар катнашында музыкаль кичә үткәрелде. Р. Мостафин Муса Җәлил эзләреннән йөреп язылган китабының иҗат ителү тарихын сөйләде һәм герой-шагыйрь язмышына кагылышлы күп кенә сорауларга җаваплар бирде. М. Хөсәен үзенең сонетларын укыды.

Кичәдә Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артистлары К. Басыйров, Л. Хангильдина, Ю. Михайлов та катнашты.

* * *

Гидроспецстрой мехкомбинат яшьләре өчен уздырылган кичәдә шагыйрьләребездән М. Горький исемендәге РСФСР дәүләт, республикабызның Тукай премияләре лауреаты С. Хәким, Н. Дәүли, Г. Латыйп, Г. Рәхим, Р. Мингалимов, Р. Вәлиевларның илгә, партиягә, яшьләргә, замандашыбызга

багышланган шигырьләре, прозаиклар М. Маликова, Х. Сарьяннарның яңа әсәрләре яңгыравы әдәбият сөючеләр күңелендә җылы хисләр калдырды.

Соңыннан җырчылар Г. Рәхимкулов, Ф. Сөләйманова, Р. Ильясов, нәфис сүз осталары Ф. Юсупов, М. Шиһаповлар авторларыбыз сүзләренә язылган яңа җырларны, рольләрне башкардылар.

* * *

Сентябрь-октябрь айларында язучы Ш. Рәкыйпов, Ялта, Симферополь, Минск һәм Гродно шәһәрләрендә булып, 1942—45 елларда атаклы 46 нчы авиация полкы үткән юллардан сәяхәт итеп кайтты.

Гродно шәһәрендә аны 2 нче мәктәп укучылары каршыладылар. (Бу мәктәпнең өченче пионер отряды данлыклы якташыбыз, Советлар Союзы Герое О. Санфирова исемен йөртә. Польша җирләрен фашистлардан азат иткәндә һәлак булгач, аның гәүдәсе Гроднога кайтарыла, шәһәр уртасындагы паркка — туганнар каберлегенә күмелә.) Ш. Рәкыйпов укучыларга М. Сыртланова һәм О. Санфироваларның батырлыклары, яшьлек еллары турында сөйләде, батыр очучыларга багышланган «Кызлар-йолдызлар» исемле повесть язачагын әйтте, мәктәп музеена «Чәчәкләр сөйли беләә», «Кайдан син, Җан?» исемле китапларын бүләк итте.

* * *

Пермь язучылар союзы һәм профсоюзларның үзешчән сәнгать йорты чакыруы буенча, татар язучыларыннан В. Нуруллин, Р. Гатауллин, Р. Мингалимов һәм Татарстан язучылар союзының пропаганда бюросы хезмәткәре М. Шиһапов Пермь шәһәрендә булып кайттылар.

24 октябрьда шәһәрнең Калинин исемендәге культура сараенда дуслык кичәсе уздырылды. Аны, кыскача кереш сүз белән, Пермь язучылар союзының секретаре урынбасары Н. Домовитов ачты. Пермь шагыйре Радкевич татар шагыйрьләренең шигырьләрен үз тәрҗемәсендә укыды. Татар язучылары тамашачыларны үзләренең яңа әсәрләре белән таныштырдылар. Кичәне Пермь журналисты Я. Камалов алып барды.

Татарстан кунаклары шулай ук шәһәрнең тегү фабрикаларында чыгыш ясадылар, Киров районындагы 70 нче мәктәп укытучылары белән очраштылар, андагы М. Җәлил музее белән таныштылар.

* * *

«Казан утлары» редакциясендә тәнкыйтьче Р. Мостафин белән очрашу булды. Ул Олимпия уеннарында алган тәэсирләре белән уртаклашты, очрашуда катнашучыларның сорауларына җавап бирде.

* * *

«Казан утлары» журналының очерклар бүлеге мөдире Малик Хәмитов Чаллы якларында йөреп кайтты. Ул шул якларда яшәүче яшь язучылар белән очрашты, Чаллыдагы әдәби иҗат берләшмәсенең чираттагы утырышында яшь авторларның яңа әсәрләрен тикшерүдә катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәт язучыларының чираттагы утырышы яшь язучы Газетдин Фәрхетдиновның «Кеше кабызган йолдызлар» һәм «Иртәгә дә дуслар кирәк» исемле пьесаларын тикшерүгә багышланды. Фикер алышуда катнашкан Ю. Әминов, С. Сөләйманова, С. Кальметов, Р. Төхфәтуллин, Р. Фәйзуллин, С. Өметбаев, Ф. Гыйльметдинов иптәшләр авторның укучылар тормышына багышланган «Кеше кабызган йолдызлар» исемле пьесасын чагыштырмача уңышлы эшләнгән дип таптылар һәм әсәрне яхшырту юнәлешендә файдалы киңәшләр бирделәр.

* * *

Бүлекнең сентябрь урталарында уздырылган утырышында Әдип Маликовның «Яшьлек утравым» исемле әсәре тикшерелде. Мемуар характерында язылган бу әсәрдә Бөек Ватан сугышы чорындагы солдат тормышы сурәтләнә. Фикер алышуда нефть районнарында яшәүче язучылардан М. Хәсәнов, Р. Төхфәтуллин, Ю. Әминов, Г. Афзал, С. Сөләймановалар катнашты. Алар авторның яңа әсәрен нигездә яхшы һәм тәрбияви яктан әһәмиятле дип таптылар, аны тагын да камилләштерү максаты белән байтак киңәшләр, тәкъдимнәр әйттеләр.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

РСФСР Верховный Советы Президиумының 1972 елның 22 сентябрендә игълан ителгән Указы белән, совет сынлы сәнгатен үстерү өлкәсендәге казанышлары өчен республикабызның өлкән рәссаме **Бакый Идрис улы Урманчега РСФСРның атказанган художникгы** дигән мактаулы исем бирелде.



## МӘГЪМҮРӘ ШӘРӘФЕТДИНОВА

**(1924—1972)**

Бу кайгылы хәбәр аның бәйрәм тәбрикләре белән бергә килде. Фаҗигале үлем хезмәттәшебезнең, якын дустыбызның янныбызга кайтыр юлын өзгән иде. Безнең күз алдыбызда ул үзе түгел, аның ягымлы йөзе, елмаеп сөйләшүе генә торып калды. Без әле һаман аны редакциябезнең язу машинасы янында эшләп утыргандай хис итәбез. Озак еллар бергә эшләгән кешенең якты образын күңелләрдән тиз генә чыгарып булмый шул.

Татарстанның Балтач районында туып үскән Мәгъмүрә 15 яшеннән эшли башлый. Башта Балтач МТСында машинистка, шул ук районның комсомол комитетында учет бүлеге мөдире, Нормабашта санитарка... Кайда гына булса да, хезмәттәшләре аны тырыш, гадел, кешелекле булырга өйрәтәләр. Бу матур сыйфатлар Мәгъмүрәгә Татарстан китап нәшриятында машинистка булып эшләгәндә дә, 1965 елда «Казан утлары» журналына машинистка булып күчерелгәч тә коллективка тиз ияләшергә, чын дуслар табарга ярдәм итә.

Мәгъмүрә әдәбиятны ярата, аңлый, үзе күчереп баскан әсәрләрдәге геройлар белән рухланып яши, үз эшен чын күңелдән яратып, бирелеп эшли иде. Ул бик күпләргә үрнәк итеп күрсәтерлек тормыш иптәше дә, берсеннән-берсе әйбәт өч бала үстергән бәхетле ана да булды.

Бик яхшы эшләгәне өчен Мәгъмүрә Шәрәфетдинова «Казан утлары»ның 50 еллык юбилее уңае белән Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнгән иде.

Бу югалту «Казан утлары» коллективы өчен бик авыр фаҗига булды.

Арабыздан вакытсыз киткән хезмәттәшебезнең якты истәлеге безнең күңелләрдә бик озак сакланыр.

«Казан утлары» журналы редколлегиясе һәм редакция хезмәткәрләре.

*Хөрмәтле укучылар!*

1973 елның өченче санында Эдуард Касыймовның **«һаваларда тургай»** романының дәвамын укырсыз. Мансур Хәсәновның **«Кама таңнары»** әсәрендә гигант КамАЗ төзелешендәге эшчеләр, аларның фидакарь хезмәтләре белән танышырсыз. Габдрахман Минскийның **«Синең җырың»** исемле пьесасында вакыйга безнең көннәрдә яңа төзелешләрнең берсендә бара.

Шигърият дусларына Шәүкәт Галиев, Зөлфәт, Равил Фәйзуллин шигырьләрен тәкъдим итәбез.

Малик Хәмитовның **«Егет булып йөрер чаклар иде»** очеркы Алабуга дәүләт педагогия институтының өлкән укытучысы Рифгат Гайнуллинга багышланган. Бу очеркта Рифгат Гайнуллинның сугышчан батырлыклары турында язылган.

Әдәби тәнкыйть бүлегендә Ибраһим Нуруллинның **«Аяк белән йөрүгә ни җитә!»** дигән мәкаләсе укучыларда кызыксыну уятыр. Өлкән язучыбыз Газиз Иделленең **«Беренче зур сәяхәт»** исемле истәлегендә 1929 елда әдәбиятыбызның күренекле әдипләре белән Астраханьга, Кавказга булган сәяхәте тасвирлана. Болардан тыш сәнгать мәсьәләләренә караган мәкаләләр, яңа китаплар, сатира-юмор, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары бирелә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210